ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

10.2009



# Татарстан Язучылар берлегенең 75 еллык юбилее уңае белән Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев КОТЛАВЫ

Республикабызның мәдәни тормышында әһәмияткә ия булган вакыйгалар рәтендә Татарстан Язучылар берлегенең юбилее аерым бер урын алып тора.

Әдәбият—халыкның милли мәдәниятен, милли асылын күрсәтүче, аның тел байлыгын саклаучы көч. Чын әдипләр үз заманының гына түгел, ә бәлки киләчәктә булачак вакыйгаларны да күп еллар алдан күреп, күрәзәлек итү сәләтенә ия. Безнең тарихыбызда нәкъ менә әдип сүзе, шагыйрь сүзе еш кына юл күрсәтүче якты йолдыз булып балкыды, халкыбызның язмышында хәлиткеч карар булып әверелде.

Татар әдәбиятының меңьеллык тарихына Кол Гали, Сәйф Сараи, Котб, Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Г.Утыз-Имәни, Г.Кандалый кебек әдипләрнең исемнәре алтын хәрефләр белән язылган. XIX-XX гасырлар чигендә халкыбызның рухи алгарышын билгеләүдә Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Камал, Ш.Камал, Һ.Такташ, К.Тинчурин кебек шәхесләр зур роль уйный.

XX йөз башында беренче татар әдәби оешмалары пәйда була башлый. Алар арасында иң танылганы—«Шәрык клубы». Г.Тукай, Ф.Әмирхан аның иң актив әгъзалары була.

Октябрь инкыйлабыннан соң барлык татар язучыларын бер әдәби оешмага туплау мәсьәләсе 1934 елның июль аенда Казанда уздырылган Совет язучыларының I Бөтентатарстан съездында хәл ителә. Съездда оештырылган Язучылар берлегенә 21 әгъза кабул ителә.

Бөек Ватан сугышы алдыннан Татарстан Язучылар берлегендә 50 язучы әгъза булып тора. Шуларның 40ка якыны фронтка китә, 31е әйләнеп кайтмый.

75 ел эчендә язучыларның профессиональлек мәктәбен 700дән артык каләм әһеле үтә. Төрле елларда бу оешманы Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Тажи Гыйззәт, Гомәр Бәширов кебек әдипләр җитәкләде. Татарстан Язучылар берлегенең «Казан утлары», «Идел», «Салават күпере», «Мәйдан» кебек журналлары укучылар арасында популярлык казанды.

Бүгенге глобальләштерү һәм сәяси эпохалар алышынуга корылган туктаусыз үзгәрешләр гасырында без саклап кала алган Татарстан Язучылар берлеге гражданлык җәмгыятендә иҗат интеллигенциясе һәм дәүләт арасында багланышларны гамәлгә ашыручы мөһим институтка әверелде. Берлек традицияләрне, мәдәниятне, телне саклап калу, тугандаш каләм ияләре, башка халыклар һәм әдәбиятлар вәкилләре белән иҗади багланышларны җайга салу, үзенең профессиональ һәм социаль мәнфәгатьләрен яклау, ветераннарга булышлык күрсәтү һәм әдәбиятка килүче яңа буыннарны тәрбияләүдә ярдәм итү юнәлешендә эшләүче үзидарәнең бер формасы булып тора.

Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлеге төрле милләтләрнең бердәм әдәби гаиләсен тәшкил итүче 326 язучыны берләштерә. Берлекнең Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләрендә бүлекләре бар, аның әгъзалары Мәскәүдә, Башкортстанда, Удмуртия, Мордовия, Чуашиядә, шулай ук Чиләбе, Пермь, Ульяновск, Киров, Төмән һәм Россиянең башка күп кенә төбәкләрендә яшәп иҗат итәләр. Соңгы елларда иҗат оешмасының сафлары талантлы яшь иҗат көчләре белән тулылануы татар әдәбиятының киләчәгенә өмет белән карарга ышаныч тудыра.

Кадерле язучылар! Сезне Татарстан Язучылар берлегенең 75 еллык юбилее белән тәбрик итәм! Бүгенге үзгәрешләр дөньясында универсаль мәңгелек кыйммәтләргә тугрылык, тарихи хәтерне саклау, хакыйкатьне һәм тормыш мәгънәсен эзләү татар әдәбиятының төп кыйбласы булып кала бирә. Сезгә—илһам һәм яңадан-яңа иҗади табышлар, ә сезнең профессиональ оешмагызга исә Татарстан Республикасындагы әдәби процессны үстерүдә уңышлы эш алып баруны телим!

*10.09.2009*

# Казан утлары
# Qazan utları

2009

**10**
**(1044)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

НАШИРЕ:
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

БАШ МӨХӘРРИР
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

ИДАРӘ:

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНӘ 75 ЕЛ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Үзебезнең союз, үзебезнең берлек. 5
Рафаэль МОСТАФИН. Беренче идарә. 89
Гази КАШШАФ. Нигез ташларын салганда. 94
Туфан МИҢНУЛЛИН. Минем эшем түгел иде ул. 96
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Иң бәхетле елларым. 99
Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Тыныч һәм эшлекле еллар. 103
Бергә булыйк, бергәйле булыйк! *(Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. ИБРАҺИМОВ белән Р. ЮНЫС әңгәмәсе).* 110
Данил САЛИХОВ. Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасы. 123
Вахит ИМАМОВ. Татарстан язучыларының Чаллы оешмасы. 124
ТР халык язучылары һәм халык шагыйрьләре, әдәбият өлкәсендә ТР Г. Тукай исемендәге дәүләт, М. Җәлил исемендәге республика премияләре лауреатлары. 125
Гәрәй РӘХИМ. Күңелгә уелган хатирәләр. 131
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Берләшеп, аралашып яшәү еллары. 137
Фәридә ХӘСӘНОВА. Татар шигърияте: үткәне һәм бүгенгесе. 149
Халисә ШИРМӘН. Татар прозасы: югалтулар һәм табышлар. 157
Афзал ШАМОВ. Шук хатирәләр. 167
Фәнис ЯРУЛЛИН. Берлек бердәм булса гына. 170
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Тикән-тигәнәкләр аша—рушан йолдызларга табан. 172
Кеше китә, җыры кала... *Шигырьләр.* 30, 107, 129
Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге премияләре лауреатлары. 146

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея.* 32
Рәшит БӘШӘР. Ил гаме, татар гаме бу... *Шигырьләр.* 56
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Үзем җирдә, күңелем күктә минем... *Шигырьләр.* 58
Зөлфәт ХӘКИМ. Легионер. *Роман.* 60
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Иңгә-иң. *Шигырь.* 181

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Марсель ГАЛИЕВ. Өмә. Күршеләр. *Хикәяләр.* 182
К. ШӘЛЕ. Мин дә булдым... *(«Тынгысыз каләм» сәхифәләреннән).* 186
«Казан утлары» архивыннан. 10, 16, 92, 135
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Номер посвящается 75-летию Союза писателей Татарстана. По этому случаю публикуется поздравление Президента РТ М. Ш. ШАЙМИЕВА.
Номер открывается статьей главного редактора журнала Р. ФАЙЗУЛЛИНА «Прекрасен наш Союз!» Публикуются статьи, воспоминания известных писателей:
Р. МУСТАФИНА, Г. КАШШАФА, Т. МИННУЛЛИНА, Р. МУХАМАДИЕВА, Ф. ГАЛИМУЛЛИНА, Д. САЛИХОВА, В. ИМАМОВА, Г. РАХИМА, Л. ХАМИДУЛЛИНА, А. ШАМОВА, Ф. ЯРУЛЛИНА, А. ТИМЕРГАЛИНА.
Беседа Р. ЮНУСА с председателем Союза писателей И. ИБРАГИМОВЫМ.
Статьи Ф. ХАСАНОВОЙ «Татарская поэзия: прошлое и настоящее»,
Х. ШИРМАН «Татарская проза: потери и находки».
«Остается песня после нас...»: стихи известных поэтов.
«Проза и поэзия»: роман-эпопея А.ХАЛИМА «Хунвейбин» (продолжение); роман З. ХАКИМА «Легионер» (продолжение); стихи Р. БАШАРА, Г. МУХАМЕТШИНА.
«Юмор-сатира»: рассказы М. ГАЛИЕВА, К. ШАЛЕ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Народные писатели и поэты Республики Татарстан.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

The issue is dedicated to the 75th anniversary of the Writers' Union of Tatarstan. On this occasion, there is published the congratulation of the President of Tatarstan M.SH. SHAYMIEV.
The issue opens with the article by the chief editor of the journal R. FAYZULLIN «Our Union is our commonwealth.» The publication contains articles, memoirs of famous writers:
R. MUSTAFIN, G. KASHSHAF, T. MINNULLIN, R. MUHAMADIEV, F. GALIMULLIN, D. SALIHOV, V. IMAMOV, G. RAHIM, L. HAMIDULLIN, A. SHAMOV, F. YARULLIN, A.TIMERGALIN.
Conversation of R.YUNUSOV with chairman of Writers' Union I. IBRAGIMOV.
Articles by F. HASANOVA «Tatar poetry: past and present»,
H. SHIRMAN «Tatar prose: loss and discovery.»
«It remains song after us ...»: poems.
«Prose and poetry»: epic novel by A. HALIM «Hunveybin» (continuation); novel by Z. HAKIM «Legionnaire» (continuation); poems by R. BASHAR G. MUHAMETSHIN.
«Humor-satire»: stories by M. GALIEV, K. SHALE.
From photo archives of journal.
Diary of social-cultural life.
On our covers: People's writers and poets of Tatarstan Republic.


★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.09.2009, график буенча 25.09.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1408. Тираж 3457.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2009 ел.

# ҮЗЕБЕЗНЕҢ СОЮЗ, ҮЗЕБЕЗНЕҢ БЕРЛЕК

Язучы—горур янгырый! «Человек звучит гордо!» тәгъбиренең үзгәртелгәнрәк калька варианты бу (бөек Горькийның сүзләрен искә төшерү урынсыз булмас: ул—СССР Язучылар союзын оештырган төп кешеләрнең берсе). Чыннан да, Язучы исеме соңгы берничә гасырда горур һәм көчле яңгырады. Язучы күпмедер дәрәҗәдә халыкларның рухи байрагы да булып саналды. Һәм бу хәл табигый да иде. Чөнки һәр зур язучы үз чорының елъязмачысы булды. Язучы теге яки бу дәвернең рухи кардиограммасын калдыра алды. Язучының тарихи миссиясе иде бу. Киләчәктәге җәмгыятьтә каләм иясенең дәрәҗәсе, язучылык хезмәтенең урыны нинди булыр?

СССР дигән илдәге язучылар оешмасының төзелүенә быел 75 ел тулды. Гыйбрәтле юбилей. Чөнки дәүләти дәрәҗәдәге абруйлы мондый иҗади оешма дөньяның бер генә илендә дә юк иде. 1934 елда оешкан Язучылар союзының (соңгы елларда «берлек» дип йөртә башладык) тарихына беркадәр күз салу, төп вакыйгаларны өстән-өстән генә булса да барлап чыгу әлеге куелган сорауларга беркадәр җавап эзләү дә булыр. Үткәнне белмичә, бүгенгене анализламыйча, киләчәкне ачыклау кыен.

Язучылар оешмасы тарихы мине күптәннән кызыксындыра. Моны аңлап та була. 75 еллык юбилеен үткәрүче оешманың өчтән ике өлешенә, ягъни 50ләп елына үземнең дә беркадәр катнашым бар. Инде 42 ел дәвамында берөзлексез Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы булып торам икән! 9 рәис белән йә аппаратта, йә идарә әгъзасы булып хезмәттәшлек ителгән... Үзе бер гомер! (Идарә әгъзасы булыр өчен дә бит әле житлеккән язучы саналуың шарт...) Моннан биш еллар элек Татарстан Язучылар берлеге тарихы хакында «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дип исемләнгән бер китап та чыгарган идем. Бу язмада информацион характердагы кайбер кабатланулар булса, ул китап белән таныш яки аны «яттан белгән» укучылар гафу итәр.

***

СССР Язучылар союзы төзелү 1934 елдан саналса да, аның башлангычы 1932 елга—ВКП(б) Үзәк Комитетының 23 апрельдә чыгарган карарына барып тоташа. Язучылар союзын оештыру мәсьәләсе, нигездә, шул елны хәл ителә. 1934 елга кадәрле ике ел әзерлек эшләренә китә. Үзәктә һәм республикаларда бу юнәлештә кызу эшләр башлана. Шул ук елның маенда Татарстан совет язучыларының Бердәм союзын төзү буенча Г. Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты төзелә. Комитетның максаты—төрле төркемнәргә бүлгәләнгән (ТАПП, СУЛФ, «юлаучылар» һ. б.) язучыларны бер максатка юнәлтеп берләштерү. Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: башлангычы «Безнең юл» булган журналыбыз да ул елларда бүлгәләнеп, «Яңалиф», «Атака» исемнәре белән чыккан. Алар урынына «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») исемле журналның чыга башлавы әнә шул берләштерүнең бер чагылышы.

СССР Язучылар союзының чишмә башы итеп совет язучыларының Інче Бөтенсоюз оештыру съезды санала. Ул 1934 елның 17 августында ачылып, 1 сентябрьдә (Гиннес китабына кертерлек съезд—ул ике атна дәвам итә!) тәмамлана. Әдәбият тарихында тиңе булмаган җыен. Масштаб-колачы да нинди диген!—52 милләт вәкилләрен тәшкил иткән 600гә якын делегат, 40лап чит ил язучылары... Монда чыгыш ясаучыларның, котлау-тәбрикләүләрдә катнашучыларның саны гына да 300дән артык! (Съездда делегат булып катнашкан язучыларның һәммәсе диярлек мәрхүмнәр инде. Шулай да бер кеше—Екатеринбургта яшәп ятучы Елена Хоринская әле дә исән икән! Съездда ул иң яшь делегат—Бурят-Монголия вәкиле булып катнашкан. Хәзер аңа 101 яшь! Ярты

ел элек «Литературная газета»да интервью биргән иде. Шушы съездда Татарстаннан катнашкан 12 кешелек делегация әгъзалары арасыннан иң соңгы булып Хәсән Туфан 81 яшендә 1981 елда вафат булды). Бөтенсоюз язучыларының кабатланмас бу җыены турында үз вакытында төрле буын язучылары тарафыннан байтак язылды, хатирәләр күп сөйләнде. Җөмләдән, алда әйтелгән китабымда да беркадәр мәгълүмат бар. Кабатланып тормыйча шуны гына әйтәм: татар әдәбиятын таныган, зурлаган съезд булган ул. Анда татар әдәбияты турында махсус доклад тыңлана. Докладчы К. Нәҗмигә сүз беренче булып бирелә (грузин, әрмән, әзәрбайҗан, таҗик һ. б. әдәбиятлар вәкилләреннән алда!). Шуңа өстәп, К. Тинчурин аерым чыгыш ясый. Бүтән халык язучылары чыгышларында да татар әдәбияты еш телгә алына... «Ул елларга инде кайтып булмый... Сагынып кына була!»

Хәзер үзебезнең Татарстан җирлегендәге хәлләрне күзаллыйк. Алда әйтелгәнчә, СССР съездына кадәр берәр ай элек, Зур җыенга әзерлек булып, урыннарда—республикаларда, өлкәләрдә корылтайлар уза, Бөтенсоюз съездына вәкил-делегатлар сайлана. Татарстанда да башкарыла бу эш.

Язучыларның беренче җыены рәсми рәвештә «Совет язучыларының Беренче бөтен Татарстан съезды» дип аталган. Съезд Татар дәүләт академия театрында 1934 елның 25 июлендә ачыла һәм Мәгариф эшчеләре йортында дүрт көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла. Съездны кыскача кереш сүз белән язучы Кави Нәҗми ача. Язучылар союзын оештыру комитеты председателе Г. Ризвановның өч сәгатьтән артыкка сузылган докладны тыңлана. Съездда иҗат мәсьәләләре буенча Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат, Фатих Кәрим докладлары тыңлана. Чыгыш ясауларда Гази Кашшаф, Хәбра Рахман, Гомәр Толымбайский, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов, Ибраһим Салахов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һ. б. катнаша. Съездның оештыру эшләре мондый нәтиҗә белән тәмамлана: Татарстан Язучылар союзының беренче идарә составына 9 кеше сайлана. Алар: Кави Нәҗми (председатель), Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский, Хәсән Туфан, Ләбиб Гыйльми, Г. Ризванов, В. Красный, Кәшшаф Төхфәтуллин (секретарь). Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына. Бу 12 делегатның 9ы әле саналган идарә әгъзалары, калган 3есе идарә әгъзалыгына кандидатлар: Ибраһим Гази, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Сәйфи-Казанлы. Аерым исемнәрне искә алмаганда, нигездә, мәгълүм шәхесләр, татар әдәбиятыннан хәбәрдар булган кешеләр өчен билгеле язучылар. Ул вакытта алар әле яшь: 30-40 лар тирәсендәге гайрәтле ир-егетләр. Әлбәттә, бу съезд әдәби-мәдәни тормышның чын чагылышы ук түгел. Була да алмый. Шул чор вәзгыятен күз алдына китерергә тырышып карыйк.

Октябрь инкыйлабына 15 ләп, СССР төзелгәнгә 10 еллап вакыт үткән. Советлар Союзында моңарчы дөньяда күрелмәгән хәл—сыйныфсыз җәмгыять төзелеп килә. Шәхси милек юк дәрәҗәсендә: завод-фабрикалар национальләштерелеп дәүләткә күчкән, җирләр башта алпавытлардан, соңрак крестьянның үзеннән дә тартып алынып, күмәк хуҗалыклар—колхозлар төзелгән. Авылның хәлле кешеләре еракларга сөрелгән. Пролетариат, юксыллар, социализм сүзләре гегемоник яңгыраш алган мохиттә милек, мөлкәт төшенчәләре бөтенләй контр сүзләр булып кабул ителә. Олы-кечененме, надан-укымышлылынмы, колак төбендә яңгыравыклы шигарьләр: Иске Дөньяны штурмлау бара! Капитализм җәмгыяте бетәчәк! (Шул заманда, капиталистик мөнәсәбәтләрнең 60-70 елдан соң СССР кинлекләренә яңадан кайтачагын, уртак байлыкның талап-урланып, халыкның аз сандагы бик байларга, күп сандагы бик хәерчеләргә аерылып бетәчәген күз алдына китерүчеләр булдымы икән?!). Кешелек капитал изүеннән азат ителәчәк! Яшәсен Бөтендөнья революциясе! Яшәсен коммунизм!.. Интеллигенция аптырашта! Дворян тәрбиясе, университет белеме алганнарның байтагы эмиграциядә, бер өлеше тавыш чыгармый, дәшми, сагаеп нидер көтә, бериш аумакайлар партия җырын җырлап көн үткәрә...

Татарстанда «солтангалиевчелек»не «фаш итү» тәмамланган чор, татарның байтак акыллыбашлары юк ителгән, зыялы катлам өркетелгән, куркытылган чор... Әдәбият дөньясы таркау, чуар; өстәвенә зур-зур шәхесләр аренадан китеп бара... Г. Исхакый—эмиграциядә, Такташ инде юк, Г. Камал яңа гына вафат, Г. Ибраһимов—авыру, Казаннан еракта, Кырымда яши, Г. Газиз—Бакуда, Г. Кутуй,

Н. Исәнбәтләр «җидегәнчелек»тә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, Г. Бәширов, С. Баттал, Ә. Еникиләр—әле яшь, башлап язучылар санала... Шулай да, зур дәрәҗәгә ия язучылар шактый булган әле Казанда. Татарстанда туып-үскәннәр дә җитәрлек, төрле төбәкләрдән килеп кушылганнар да байтак. Чөнки татарлар яшәгән төбәкләрдә—Себер-Уралда, Идел-Кама буйларында, Казакъстан-Урта Азия якларында чын мәгънәсендә милли мохит исән, татар мәктәпләре бар, тамыр бар... Ким дигәндә ярты гасыр эчендә бик күп җете талантлар килеп торачак әле татар әдәбиятына!

Шулай итеп, 1934 елны, ягъни моннан 75 ел элек СССР Язучылар союзы төзелә, бөтен ил буенча аның җирле бүлекчәләре булдырыла. Дәүләт күз уңындагы бу оешманың функциясе дә, шул нисбәттән иҗтимагый әһәмияте дә зур, язучының дәрәҗәсе югары була. Язучы—горур яңгырый, дип әйтерсең дә шул.

75 еллык Язучылар берлеге тарихын шартлы рәвештә берничә чорга бүлеп карарга мөмкин. Шәхсән мин ул бүленешне болайрак күз алдына китерәм: 1934 еллардан Ватан сугышы ахырына кадәрге еллар; сугыш соңыннан башлап 60нчы елларга кадәрге дәвер; 1960 елдан башлап 80 еллар ахыры; 90нчы еллар башыннан бүгенге көнгә кадәрге еллар. Сәяси төсмер биреп әйтсәң, болай килеп чыга: репрессия һәм сугыш чоры, илне торгызу, бишьеллыклар чоры; «җепшеклек» һәм «торгынлык» чоры; үзгәртеп кору—ягъни, социализмнан яңадан капиталистик мөнәсәбәтләргә күчү чоры... Шул шартлы бүленеш кысаларында татар әдәби хәрәкәтен, шул нисбәттән Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлеген мөмкин кадәр хронологик эзлеклелектә күз алдыннан кичереп карыйк.

## I

1934 елдан сугыш ахырына кадәрге чор—ун елдан артык вакытны эченә ала. Әйткәнемчә, бу чор дигәндә, ин әүвәл, репрессия һәм сугыш еллары күзаллана. Авыр югалтулар чоры—безнең әдәбият өчен бигрәк тә.

1934 ел тоташы белән Язучылар союзын оештыру елы. Әйтик, май аенда «Кызыл Татарстан»да СССР совет Язучылар союзының уставы басыла. Июнь аенда Совет Язучылары союзына кабул итү Үзәк комиссиясенең утырышы була. Союзның беренче әгъзалары кемнәр соң? Менә алар—Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, К. Тинчурин, Ш. Камал, Г. Гали, Г. Толымбайский, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гали, И. Гази, М. Крыймов, Ә. Фәйзи, И. Туктаров, М. Максуд, Ф. Кәрим, С. Баттал, Т. Госманов (Хатип Госманның абыйсы). Совет Язучылары союзына кандидат итеп Ш. Усманов, Р. Ишморат, Б. Зернит, А. Шамов, Галимҗан Мөхәммәтшин, Т. Гыйззәт, Ә. Ерикәй, Н. Баян тәкъдим ителә. Алда әйтеп үтелгәнчә, июль ахырында Татарстан совет язучыларының Беренче съезды үткәрелә... Соңрак—язучылар союзы инициативасы белән төрле секцияләр оештырыла, яшь язучылар белән эшләү буенча консультация бюросы төзелә. Язучылар төрле юбилей чараларында актив катнаша (Пушкинның үлгәненә 100 ел, Тукайның тууына 50 ел, Горький, Г. Камал, Ш. Камал, Такташка багышланган кичәләр һ. б.)... Әлбәттә, җыелышлар (гомумиләре дә, партиялеләрнеке дә) үтә, мотивлары «татар совет әдәбиятының яңа үсеш баскычлары» яки шуңа охшаш булган докладлар сөйләнелә...

Сүз дә юк, бердәм оешма барлыкка килгәч, язучыларда билгеле бер күтәренкелек, яңа әдәбият тудырырга омтылыш булган. Шул ук вакытта партия диктатурасы басымы аркасында иҗат кешеләренең күңелләрендә шик, шом, курку хисләре дә куера төшә... Борын төбендә коточкыч рәхимсез еллар—репрессия еллары... Аңларга һәм аңлатырга авыр еллар. Язучылар лидеры булып, союзны оештырып йөргән яки бу башлангычны күңеле һәм гамәле белән хуплаган байтак әдипләр төрмәләргә утыртылган. Әле бер ел элек кенә тантаналы рәвештә 25 еллык иҗат бәйрәме үткәрелгән К. Тинчурин ябылуда, Г. Ибраһимов төрмәдә... Вакыт аралыкларында бераз аерымлыклар булса да, шул ук язмышка дучар ителгән И. Салахов, Ш. Усманов, Г. Толымбайский, Г. Гали, М. Галәү, Г. Нигъмәти, Ф. Бурнаш, Г. Рәхим, Ж. Валиди, Ф. Кәрими, С. Сүнчәләй, Ф. Сәйфи-Казанлы, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, М. Әмир, С. Рафиков, Л. Гыйльми, Х. Туфан... Исемлекне дәвам иттерергә була. Тарихчылар әйтүенчә, ул елларда илләгә

якын татар язучысы репрессияләнгән. Кайсылары юкка чыгарылган, кайсылары алтын гомерләре мәхбүслектә үткәч кенә кайта алган, кайсылары фәлән ай гына утырып, куркытылып, кушканны үтәүчеләр булып калган... Әдәби фигураларның байтагы кулга алынгач, көчләр таркатылгач, табигый, Союзның тулы канлы эшчәнлеге турында сөйләү кыен... «Чор таләбе» буенча оешма житәкчелегендә дә яна «лидерлар» пәйда була. Т. Имаметдинов, И. Вахитов, Х. Жәмил... Бу исемнәрне өлкән буын язучыларның да бик сирәге ишетеп кенә белә булыр... Архив тарихында бар саналсалар да, әдәбиятта юк алар. Шулай да, еллар хроникасына күз салсаң, оештыру эшләре бер дә бармаган дип әйтеп булмый. Әйтик, 1937 елның 28 апрель—5 май көннәрендә Татарстан язучыларының гомуми жыелышы була (докладчы Т. Имаметдинов), июнь аенда Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» пьесасын укып тикшерү уздырыла, сентябрьдә иң яхшы опера либреттосына игълан ителгән конкурсның комиссия составына берничә язучы кертелә, «Совет әдәбияты»ның 6-7 нче саннары тулысы диярлек М. Горький ижатына багышлана. 1938 елның апрелендә Тукайның вафатына 25 ел тулуга багышланган зур кичә үтә, июньдә язучыларның гомумжыелышы уздырыла (докладчы—Н. Баян). 1939 елның башында яшь язучыларның зур бер төркеме оешмага әгъза итеп алына (Ф. Хөсни, А. Шамов, Г. Бәширов, Г. Галиев, Г. Гобәй, А. Әхмәт, А. Алиш, Ә. Исхак, Р. Ишморат, Г. Хужи, И. Гази, Г. Кутуй, Н. Дәүли, Х. Госман, М. Бубеннов, С. Хәким, Г. Хәбиб, Г. Халит, Л. Жәләй, М. Вәдүт, М. Әблиев; ел ахырында бу төркемгә Н. Исәнбәт, Х. Садри, С. Урайский, Ә. Камал һәм тагын берничә айдан—З. Солтанов, Ә. Ерикәй дә өстәлә), Язучылар союзының фольклор секциясе әзерләгән «Халык ижаты» дигән жыентык басылып чыга, СССР Югары (ул вакытта Верховный) Советы Указы белән Ш. Маннур—Хезмәт Кызыл Байрагы, Т. Гыйззәт Почет Билгесе орденнары белән бүләкләнә, бер елдан соң Ш. Камалга СССРның иң зур ордены—Ленин ордены бирелә (сонрак «орденлы шагыйрь», «орденлы язучы» дигән сүзтезмә әлеге язучыларның исемнәренә озак дистә еллар синоним-тагылма булып йөриячәк). Язучылар оешмасы өчен бу елның бер мөһим вакыйгасы, мөгаен, Муса Жәлилнең Язучылар союзы идарәсенең жаваплы секретаре, ягъни житәкчесе итеп сайлануыдыр. Әдәби житәкчелекнең очраклы кешеләрдән арынуы—бу инде репрессиянең бетүгә, илдә сәяси-рухи тормышның беркадәр савыгуга таба баруын күрсәткән фал. Гомумән, сугыш алдындагы ике елда татар жәмәгатьчелеге өчен күңел булырлык гамәлләр кылына башлый. Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла. (Беренче куелган тамаша Н. Жиһановның «Качкын» операсы. Ә. Фәйзи либреттосы). Татарстан хөкүмәте Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. СССР Халык комиссарлары Советы карамагында Сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә татар сәнгате декадасын үткәрүне планлаштыра... Югалтулар табулардан күбрәк булса да, нииндидер стимул бар!

Шул чорда (яки беркадәр алданрак) язылган кайбер әсәрләрне хәтеребезгә төшермәсәк, сүз сөрешенең мәгънәсе тулы булмас. Алар—«Тапшырылмаган хатлар» (Г. Кутуй), «Агыйдел» (М. Әмир), «Мәржәннәр» (К. Тинчурин), «Хужа Насретдин» (Н. Исәнбәт), «Флейталар» (Ә. Фәйзи)... Бу әсәрләрне язуга язучылар оешмасының тәэсире никадәр булгандыр, аны ул язучылар үзләре генә белгәннәрдер, без фәкать фараз итә генә алабыз. Хронология буенча шул елларга туры килә үзләре... 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Идегәй» дастанының дөнья күрүе үзе бер вакыйга. Бу бөек дастан әдипләр, бигрәк тә шагыйрьләр өчен бик озак еллар осталык мәктәбе булып хезмәт итәчәк әле.

***

Сугыш еллары... Ил өчен, халык өчен сынаулы фажигаи еллар... Татар язучыларын 37нче еллар бер «чабып» ташлаган булса, икенче бер афәт—сугыш янә байтагын кырып сала. Бүтән халыклар белән чагыштырганда, сан нисбәтендә язучылардан иң күп югалту татарда, диләр. Булгандыр, саный башласаң да, байтакка чыга бит: М. Жәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй, Н. Баян, Х. Мөжәй, М. Вәдүт, Р. Ильяс, К. Басыйров, М. Әблиев, Р. Саттар, Д. Фәтхи, Х. Кави... Эзтабар-журналист, язучы Шаһинур Мостафин язып чыкканча, Ватан сугышында 104 татар язучысы һәм журналисты (яшь һәм башлап

язучыларны да кертеп) катнаша, шуларның 31е корбан була. Өчтән бере дигән сүз!

Исән кайтканнарның да күбесе фронт яраларыннан җәфаланып яшәде. Фронтовикларның кайберләре—Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, З. Мансур, С. Урайский һ.б. 50 яшьләренә дә житмичә дөнья куйды.

Фронтта байтак язучыларыбыз, каләмне штыкка тиңләп, алгы сызыктагы сугыш операцияләрендә катнашу белән бергә, фронт газеталарын чыгаралар. 1942 елның июленнән башлап, төрле фронтларда татарча 16 газета нәшер ителә. «Ватан өчен», «Алга, дошман өстенә!», «Сталин байрагы», «Совет сугышчысы» һ. б.). Үз вакытында аларда Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Х. Госман, Ә Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, Б. Рәхмәт, Г. Галиев һәм башка язучылар эшләгән. Шулай ук, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Иделле, Х. Хәйри һәм башкалар, озак вакытлы командировкаларга барып, бу газеталарда эшләп-эшләп ала.

Тылда да фронттагы кебек киеренкелек: «Барысы да фронт өчен!». Язучылар оешмасы да шушы рух белән яши. Сугыш башлануның беренче көннәреннән үк Союз идарәсе утырышларында оешманың эшен хәрби шартларга яраклаштыру мәсьәләсе карала. Тукай исемендәге кабинет (соңрак ул Клуб дип йөртелде) үзенә күрә бер штабка әверелә. ПВХО төркеме оештырыла, Мәскәүнен качак язучыларын үзенә сыендыра, интернациональ составтагы язучылар җыелышлары уздырыла (мәсәлән, бу залда А. Фадеев «Совет язучылары Ватан сугышында» дигән доклад ясый), оборона фондына акча җыйнала (Т. Гыйззәт, Ш. Камал 1000әр сум, Г. Кутуй 650 сум акча кертә), сугыш шартларында язучының барлык иҗат эшләрен янача кору, бөтенләе белән фронт өчен хезмәткә буйсындыру һәм активлаштыру, шуларга җитәкчелек итү өчен Язучылар идарәсе каршында агитация-пропаганда бүлеге оештырыла (җаваплылар—Ш. Маннур, Т. Гыйззәт, Р. Ишморат, Г. Кутуй)... һәм 1942 елның 8 январенда Казандагы совет һәм чит ил язучылары катнашында Тукай клубында М. Җәлилне фронтка озату була (Мәңгелек Бөеклеккә озату!). Язучылар тарафыннан (К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Х. Ярми) күмәкләшеп «Татар халкының фронтовик татарларга сәлам хаты» языла. Соңрак миллионнан артык кеше кул куйган бу хат «Правда», «Известия» газеталарында игълан ителә (март, 1943), аннан соң республика һәм фронт газеталарында басылып чыга. Классикларның, бигрәк тә рус язучыларының төрле унай белән (М. Лермонтовның үлүенә 100 ел, М. Горькийның тууына 75 ел; И. Крыловның үлүенә 100 ел, А. Грибоедовның тууына 150 ел һ. б.) юбилейлары уздырыла, апрель айларында Г. Тукайны искә алу кичәләре үтә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында «Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше» турында карар кабул ителә. 1944 елның август аенда (М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең башын кискән көннәр) Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештырыла башлый. Бу эштә тылда калган каләм ияләре актив катнаша. Шул ук елны Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла (хәзерге заман язучыларының күпчелеге шушы бүлектә укып чыккан). Шул чор хроникасыннан искә алырлык тагын бер мөһим вакыйга: 1943 елның октябрь аенда СССР Язучылар союзы президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы махсус тикшерелә. А. Фадеев рәислегендә үткән бу җыелышта Казаннан—Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Кашшаф; шуларга өстәп, фронттан чакырып кайтарылган Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, М. Садри, Г. Галиев тә катнаша. Шул еллардагы татар әдәбияты турында Г. Кашшаф доклад ясый (сугыш елларында Г. Кашшаф Казан әдәби хәрәкәтендә иң үзәк фигураларның берсе була. М. Җәлилнең васыять рәвешендә язган язмасында аның исеме беренчеләрдән булып аталуы тикмәгә түгел!). Татар әдипләренә М. Горький кебек туганнарча караучы А. Фадеев язучылар делегациясен ВКП(б) Үзәк Комитеты пропаганда һәм агитация бүлегенең җаваплы хезмәткәрләре белән дә очраштыра. «Авыр сугыш елларында татар телендәге әдәби журналның («Совет әдәбияты») саклануын партия Үзәк Комитетында хупладылар гына түгел, бәлки, югары бәяләделәр: «Бу—сезнең каһарманлык! Партия Үзәк комитеты безгә тиражны өч тапкырдан күбрәк арттырырга (ул елларда журналның тиражы уртача 4 мең) һәм 10 мең данәгә кадәр җиткерергә рөхсәт итте һәм кәгазь ягыннан ярдәм күрсәтте»,—дип яза соңрак журналның шул еллардагы редакторы Гази Кашшаф.



*Татар язучылары беренче съезд көннәрендә. 1934 ел.*




*Язучыларның I Бөтенсоюз съездында катнашучылар.*
*Беренче рәттә сулдан уңга—К. Нәҗми, А. Толстой, М. Горький;*
*икенче рәттә—Л. Гыйльми, Х. Туфан, Г. Толымбайский,*
*Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти. 1934 ел.*



*Әдип Фәтхи Бурнашның кулга алынган көннәрендә (1940) һәм төрмәдә утырганда (1942) төшерелгән рәсемнәре.*



*Европада татар шагыйрьләре. М. Садри (сулда) һәм Г. Хуҗи. Вена, 1945 ел.*




*Муса Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәре».*

Зур күтәренкелек, зур планнар белән төзелгән Язучылар союзы яшәвенең беренче елларында ук бик нык сирәкләндерелсә, хәлсезләндерелсә дә, сугыш елларында авыр югалтулар кичерсә дә, барыбер, оешма булып сакланып кала, иҗат көчләрен нииндидер бер мобилизацияләүче штаб ролен үти (бу очракта Язучылар союзының башында торган берничә шәхеснең исемнәрен атап үтү дөрес булыр: К. Нәҗми (1934-37), М. Җәлил (1939-41), Т. Гыйззәт (1942-44)...) Автономия кысаларында, житмәсә сугыш чорында, һич югы рухи терәк һәм бергәлекне тояр өчен генә дә, татар язучыларының үз оешмалары, үз үзәкләре булуы унай бәяләнергә хаклы.

Сугыш елларында «Әдәбиятның Әнкәсе» саналган поэзиянең көче, халыкчанлыгы, яшәүчәнлеге тагын бер мәртәбә раслана. Мона дәлил итеп М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Ф. Кәримнең сугыш чоры әсәрләрен (әйтик, «Кыңгыраулы яшел гармун», «Идел егете») искә алу да житә. Бүтән жанрларда бәлки ул кадәр үк казанышлар булмагандыр (табигый, сугыш чорында—фронттамы, тылдамы—киң полотнолы зур романнарның тууы икеле), шулай да, кайбер әсәрләр язылып калынган. Әйтик, «Миңлекамал» драмасы (М. Әмир), «Йөзек кашы» (Ф. Хөсни)... Сугыш елларында ул чакта әле яшь, ә соңрак әдәбиятта зур урын тотачак байтак язучылар гыйбрәтле тормыш мәктәбе генә түгел, иҗади үсеш мәктәбен дә үтте. Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ә. Фәйзи, А. Расих, И. Гази, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов һәм башкалар.

Бу чор турында язу кыен. Сугыш елларында (алданраклары турында әйткән дә юк) әдәби мохитне үзе күреп кичергән кешеләр юк инде... 50нче елларны азмы-күпме хәтерләгән, күзаллаган язучыларыбыз әлегә бер дистәләп бар-барын (Л. Ихсанова, М. Юныс, Х. Камал, Ә. Баян, Ш. Галиев, М. Насыйбуллин, Р. Мостафин...), әмма алар да ул вакытта әдәбиятның үзәгендә түгел әле. Алар әле кайсы студент, кайсы—армиядә, кайсы—авылда мәктәп укучысы яки колхозчы үсмер егет... Шуңа күрә бу бүлекне архив материалларына, матбугат битләрендәге хроникаль язмаларга таянып бәян итәргә туры килде.

## II

Сугыштан соңгы—60 нчы елларга кадәрге чор. Монысы чагыштырмача бүгенгегә якынрак дәвер. Шулай да арада 15 елдан артык вакыт ята. Бу чорның да шаһитләре, бигрәк тә әдәби-мәдәни дөньяның шаһитләре, алда әйтелгәнчә, күп түгел. Дөрес, әйтик, 60нчы елларда әдәбиятка килгән безнең буын 50нче елларны беркадәр хәтерли, күргән-ишеткәннәр, укыган китаплар буенча бераз чамалый. Бу буын вәкилләре дә инде яшьләре белән 70 ягына авышкан...

1945-1960 еллар алдагы дистә еллар белән чагыштырганда, аңлаешлырак, тотрыклырак чор! Сугыш беткән, ачлык-ялангачлык хәттин ашса да (дистәләгән төрдәге салымнар, мәҗбүри заемнар...), кешеләр күңеленең өметле чагы: җимереклекне торгызабыз, илдә социализм—гадел җәмгыять төзибез, киләчәктә, һичшиксез, яхшы яшәячәкбез! Һәрхәлдә, күпчелек шулай уйлаган. Әмма шунысы бар: бу чор Сталин хакимиятенең иң «кикрикле» чагы, «генералиссимус доктринасы»ның халыкара дәрәҗәдә санлаштыра торган чагы... Шул чорны күзаллау өчен сугыштан соңгы ун-унбиш ел эчендәге кайбер факт-вакыйгалар белән танышып үтик. Тукайның 60 еллыгы зурлап билгеләнә (Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында тантаналы кичә үтә; Казан университеты һәм педагогия институты студентлары өчен Г. Тукай исемендәге стипендияләр булдырыла; СССР Фәннәр академиясендә шагыйрьгә багышланган фәнни сессия уздырыла һ. б.). Татарстан Мәгариф комиссариаты һәм Язучылар союзы балалар өчен татар телендә язылган иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итә. Шагыйрь Ә. Ерикәй СССР Верховный Советына (1946), К. Нәҗми Татарстан АССР Верховный Советына депутат итеп сайлана. Чистай шәһәре музеенда «Язучылар Чистайда» дигән яна бүлек оештырыла. Рус телендә «Литературный Татарстан» дигән альманах чыга (1947-1958). 1951 елда К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус» романнары Сталин (соңрак аны Дәүләт премиясе дип тә йөртteләр) премиясе белән бүләкләнә. 1953 елда М. Җәлил өстеннән «кара болытлар» алып ташлана, берничә елдан аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә, «Моабит дәфтәре» Ленин премиясенә лаек була. Сугыш елларында тукталып калган «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре»)

газетасы, «Чаян», «Пионер» («Ялкын») журналлары кабат чыга башлый. Хәзерге «Идел» журналының яралгысы саналырга тиешле «Үсү юлы» дигән альманах чыга. 1957-58 еллар әдәби-мәдәни вакыйгаларга бигрәк тә бай. 1957 елның 24 май—4 июнь көннәрендә Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы гөрләп үтә (алда әйтелгәнчә, ул декада 1941 елның ахырына планлаштырыла, әмма сугыш башлану сәбәпле булмый кала). 1958 елда «әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр өчен һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкарган өчен» Г. Тукай исемендәге Республика (соңрак Дәүләт дип аталачак) премиясе булдырыла. Шул ук елның 9 августында Казан үзәгендә Тукайга һәйкәл торгызыла (соңрак бу урын Тукай мәйданы дип йөртеләчәк). Бу еллар елъязмасының тагын бер кадерле сәхифәсе—шәхес культы корбаннары аклана. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Галәү, Г. Газиз, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти һәм башкаларның әсәрләре кабат басыла башлый, зиндан-сөргеннәрдән исән калган Х. Туфан, И. Салахов, С. Рафиков кебекләр әдәби сафка кайта... 50нче еллар ахырында, соңрак халык язучылары, халык шагыйрьләре булачак, әле ул вакытта өметле яшь язучылар саналган Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камаллар әдәбиятта яңа буразналар сыза. 1957 ел беренче мәртәбә Татарстан язучылары турында белешмәлек—биобиблиографик китап чыга (анда 126 язучы турында мәгълүмат бирелгән. Соңрак мондый китаплар 1970 һәм 1984 елларда дөнья күрде һәм, ниһаять, татар язучылары турында икетомлык белешмә китаплар якын айларда укучылар кулына килеп ирешәчәк).

Әйе, тыныч тормышка хас вакыйгалар хроникасы. Әйтергә кирәк, чагыштырмача матур хроника! Язучыларның төп җыены булган съездлар үткәрү дә билгеле бер тәртипкә салына башлый .

Язучылар союзы эшчәнлегенең төп этапларын, гамәл-нәтиҗәләрен, максат-юлларын билгеләүче төп маяк-ориентир—ул съездлар, соңгы дәвердәгечәрәк әйтсәк, корылтайлар. Чөнки съезд язучылар оешмасының идарә органнарын сайларга вәкаләтле иң зур җыен. Съездлар аша әдәби хәрәкәт дисбесенең төп төеннәрен (бу очракта, тенденцияләрен) тоеп, чамалап була. Әйе, алда тәфсилләп әйтелгәнчә, беренче оештыру съезды Казанда да, Мәскәүдә дә 1934 елда уза. Шул ук елны СССР Язучылар съездында кабул ителгән Устав нигезендә язучылар съездлары өч елга бер уздырылырга тиеш диелгән. Ә ничек килеп чыкты? СССР язучыларының икенче съезды нәкъ егерме елдан соң—1954 елда гына җыела! Егерме ел бит! Сугыштан соң да ун елга якын вакыт үтә... Димәк, бу оешма, табигый ихтыяҗдан бигрәк, хакимиятнең ихтыяр көче белән идарә ителә торган оешма булып чыга.

Шулай да Татарстан язучылары 1950 елда үзләренең II съездын үткәрә. (СССР Язучылар союзының II съездыннан дүрт ел элек!) Үзәк кушуы беләнме, аллә җирле инициатива өстенлек иткәнме? Мөгаен, соңгысыдыр. 1950 елның язында КПССның Татарстан өлкә комитеты «Татарстан совет язучылары союзының эше турында» дигән махсус карар кабул итә. Бу инде үзенә күрә съезд алды прелюдиясе дигән сүз.

Татарстан язучыларының II съезды 1950 елның 13-15 июнь көннәрендә үтә. Съездда язучылардан тыш, республика житәкчеләре, СССР Язучылар союзы һәм үзәк нәшрият вәкилләре, фән эшлеклеләре, журналистлар, укытучылар, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче студент яшьләр катнаша. Татарстан совет язучылары союзы идарәсенең эше турында хисап докладын Гази Кашшаф ясый. Ревизия комиссиясе отчеты белән Гариф Гобәй чыга. Фикер алышуларда 29 кеше катнаша. Алар арасында—Г. Әпсәләмов, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Гулиа (Мәскәү), С. Баттал, Ш. Мөдәррис, С. Кирьянов (Мәскәү), З. Мансур, М. Хөсәен, М. Максуд, И. Нуруллин, Ә. Давыдов, М. Елизарова, Х. Рәхмәтуллин (ВКП(б) өлкә комитеты секретаре), Г. Насрый, А. Гомәр һ. б.

Съезд Татарстан совет язучыларының эшен канәгатьләнерлек дип бәяләми һәм киләчәктә эшне яхшыртуга юнәлтелгән карарлар кабул итә. 1945-50нче елларда идарә рәисе булып торган Ә. Ерикәй нык тәнкыйтьләнә. «Идарә (Ә. Ерикәй А. Шамов, М. Әмир, Б. Зернит, Х. Хәйри, Г. Кашшаф, Т. Гыйззәт), гомумән, язучыларның иҗат эшенә тиешенчә житәкчелек итмәде», дип таба. Съездда яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылары союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана:

Гариф Гобәй (председатель), Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Гали Халит, Риза Ишморат, Константин Лебедев, Әхмәт Исхак, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Салих Вәлиди (җаваплы секретарь). «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп Гази Кашшаф раслана.

Шулай итеп, съездда Язучылар союзы идарәсе эше канәгатьләнерлек дип табылмый. Совет дәверендәге идарә механизмында болай бәяләнү сирәк очрак.

Съездлар әдәби хәрәкәт дисбесенең үзенә күрә «бисмилла» төеннәре булса да, бу очракта аларның һәрберсенә (съезд-корылтайлар бездә инде 16 тапкыр булып үткән икән! Сугыштан соң үткән, асылда беренче мөстәкыйль съезд буларак, II съездга киңрәк тукталдым) тукталып, эш программалары турында тәфсилләп сөйләү кирәк түгелдер. Теләгән, кызыксынган кешеләр, әйткәнемчә, 2004 елда чыккан «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дигән китаптан шактый тулы мәгълүмат ала алалар. Алга таба ул съездлар турында кыска информация биреп кенә үтәрбез. Әйе, 60нчы елларга кадәр тагын ике съезд (III съезд—1954, IV съезд—1958 елда) үткәрелә. Әмма шул елларда (1958) үткән РСФСР язучыларының I оештыру съезды турында беркадәр әйтеп узу кирәк булыр.

Моңарчы әле үзәкнең бер югары җыены—СССР Язучылар съезды гына бар иде. 1958 елдан соң ул ике үзәклегә әйләнде: рус уенчыгы «матрешка» принцибы барлыкка килде. СССР оешмасы, РСФСР оешмасы, ТАССР оешмасы. Кыскасы, күкәй эчләрендә күкәй... Бер караганда Россиянең үз оешмасын гамәлгә кую кирәк тә булгандыр. Бу гамәл белән үзәктәге рус-яһүд язучылары мәнфәгатен кайгыртуда яңа мөмкинлекләр ачылды, шулай ук аз санлы дистәләгән халыкларның әле яңа формалашып килгән профессиональ әдәбиятларын аякка бастыруда реаль адымнар ясалды. Әйтик, Төньяк Себер (эвенк, чукча һ. б.) яки Кавказ (карачай, авар, нугай һ. б.) халыкларының профессиональ язучылары барлыкка килде, җирле милли колорит белән сугарылган кызыклы әсәрләр язылды.

Россия язучылар оешмасы төзелү меңьеллык тарихы, ике гасырдан артык басма китап традицияләре булган татар әдәбиятына ни бирде соң? Унай җавап әйтү кыен. Чынлыкта, без Зур союздан (ССР Союзыннан) Кече союзга (РСФСР) күчтек. Күчерделәр. Безнең рәсми әдәби статус—автономия, ягъни союздаш республикалар рәтендә тормый булып чыкты. Гәрчә зур Союз белән бәйләнешләр өзелмәсә дә (кайбер абруйлы язучыларыбыз СССР Язучылар берлеге дәрәҗәсендәге чараларда катнашып килде, хәтта югары органнарга да сайланды), һәммәбез СССР Язучылар союзы әгъзасы дигән таныклык йөртсәк тә, без инде турыдан-туры РСФСР язучылар оешмасына беркетелдек, СССР язучылар съездларына РСФСРдан делегатлар булып бардык. Зур съездларда безнең язучыларыбызның тавышы тоныграк, әсәрләребез турында сүзләр сирәгрәк ишетелә башлады. 1934 елдагыча язучыларның илкүләм җыенында татар әдәбияты турында махсус докладлар тыңлау, тәфсилле чыгышлар ясау татлы истәлек булып калды. Зур съездлардагы төп докладларда татар әдәбияты чуаш, башкорт, якут, бурят һ.б. әдәбиятлары белән бер яссылыкта телгә алына башланды.

РСФСРның бу беренче съездына Татарстаннан 11 кеше делегат булып бара (Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Г. Гобәй, Ә. Еники, Т. Журавлев, Н. Исәнбәт, Л. Ихсанова, Г. Кашшаф, И. Гази, З. Нури, А. Шамов. Бу төркемнән бүгенгә бердәнбер исән кеше—Ләбибә апа Ихсанова. Хәзер аңа 86 яшь, ул чакта 35 булган). Бу съездда Татарстан вәкилләре сыйфатында ике язучы чыгыш ясаган—Ф. Хөсни, А. Шамов. Ф. Хөсни чыгышы (стенографик язма буенча әйтүем) укыр өчен әле дә кызык, фикере искермәгән. А. Шамов Язучылар союзы рәисе сыйфатында чыгыш ясый, түрәләргә хас пафос, реверанс, рәсмилек... Шулай да, чыгышында заманы өчен бик тә мөһим мәсьәлә—яшь язучылар өчен журнал кирәклеге турында күтәреп чыга (ә мәсьәлә утыз еллап гомер үткәч, партия диктаты йомшап, демократик үзгәрешләр булгач кына—1989 елда хәл ителде. Мәскәү катнашыннан тыш, республика җитәкчелеге «Идел» журналын чыгаруны үзе хәл итте).

Әйе, үзенчә авыр чор бу. Бигрәк тә сугыштан соңгы еллар... Әмма халыкның рухы сынмаган, киләчәккә ышанычы ныгыган чор. Җиңү, шиксез, ышанычны ныгыткан. Ә уйласаң, ач-ялангач чор бит, авыл халкы «таяк»ка эшләгән чор, чабаталы чор, черек (тунган) бәрәңге чоры (соңрак бу еллар турында Н. Фәттахның «Артта калган

юллар», А. Гыйләжевнең «Язгы кәрваннар», М. Мәһдиевнең «Без—кырык беренче ел балалары» кебек әсәрләрендә ачык язылачак)... Әмма—китаплы чор! Шул чорда ачлы-туклы яшәп, тырышып белем алган, китаптан аерылмаган буын XX гасыр ахырына кадәр дөньяның тоткасы булып тора алды да.

Алларак бу чордагы (1945-60 еллар) мәдәни-әдәби хроникадан вакыйга булырлык кайбер фактлар саналган иде. Шуларга өстәп әйтергә була: «Татар поэзиясе антологиясе» чыга (1956), дөнья һәм рус әдәбияты классикасыннан йөзләрчә әсәр татар теленә тәрҗемә ителә (татар авылларында берничә буын, шул исәптән безнең буын да шул китапларны укып үсте инде! Сүз уңаеннан әйтеп үтик: 60нчы еллар башында башка телләрдәге матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча Татарстан—СССРда дүртенче урында, ә татар теленнән башка телләргә тәрҗемә ителү ягыннан бишенче урында торган).

Әдәбиятның, гомумән, язу эшенең дәрәҗәсе югары заман бу. Әдәбиятыбызның халыкара танылуына ике зур форсат чыккан еллар. Беренчесе, алда әйтелгәнчә, К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировнең «Намус» романнарының Сталин премиясе алуы. Заманы өчен ифрат зур вакыйга. Шушы премия бирелү уңаеннан бу әсәрләр дөньяның байтак телләренә тәрҗемә ителде, татар әдәбиятының данын еракларга таратты. Икенчесе—М. Җәлилгә Герой исеме һәм Ленин премиясе бирелү. Җәлил поэзиясе татар шигыре данын тагын да югарырак күтәрде. Соңрак—40-50 ел эчендә талантлы әсәрләр байтак язылса да, аларның авторлары халыкара масштабта алай ук янгырый алмады. Субъектив һәм объектив сәбәпләр булды бугай. (Хәер, соңрак, 60-70нче елларда Г. Әпсәләмов әсәрләре шактый ук популяр булып алды). Без тикшерә торган сугыштан соңгы бу унбиш ел эчендә, табигый, әдәбият мәйданының ир уртасы егетләр, сугышта катнашкан фронтовиклар тотты. Төп әсәрләрне дә алар язды. «Тукай» (Ә. Фәйзи), «Онытылмас еллар» (И. Гази), «Газинур» (Г. Әпсәләмов), «Суд залында» (С. Хәким), «Яшәү белән үлем арасында» (Н. Дәүли)... Шул чорда Тукай исемендәге Дәүләт (ул вакытта Республика премиясе дип йөртелә иде) премиясе «Тукай» романы өчен Әхмәт Фәйзигә (1958), «Сүнмәс утлар» романы өчен Габдрахман Әпсәләмовка (1959), «По зову Ленина», «Жил исми—яфрак селкенми» исемле шигырь китаплары өчен Сибгат Хәкимгә (1960) бирелде (1961-1965 елларда бу премия бирелми торылды. Сәбәбе ни?—казаныш дип санарлык әсәрләр табылмаудамы? Ә хәзер алар әллә бик күп микән соң?).

Һәр чор әдәбиятының лидерлары була. 50нче еллар әдәби хәрәкәтенең иң эре фигурасы, һичшиксез, Гомәр Бәширов. Сталин премиясе лауреаты, СССР Верховный Советы депутаты, Язучылар союзы рәисе... Хуҗа булырлык дәрәҗәдәге тел остасы, фольклорчы, гомумән, аксакалларга хас зирәк кеше. Язучылыгыннан тыш, оешма хуҗалыгын ныклап корган, ныгыткан шәхес. Ярты гасырдан артык тарихы булган язучылар дачаларын—Аккош күлендәге иҗат йортын оештырган, нигезләгән кеше дә шул ук Гомәр ага Бәширов («Аккош күле»нен әдәбиятыбыз өчен никадәр кадерле һәм истәлекле җир икәнен иркенәеп язып тормыйм. Моннан ике ел элек—2007 елда галим-язучы Мөдәррис Вәлиев тырышлыгы белән «Мәгариф» нәшриятында «Аккош күле—илһам аланы» дигән истәлек-хатирәләр китабы басылып чыкты. Ходай Гомәр аганың үзенә дә мәрхәмәтле булды: ул озак яшәп, 98 яшендә (1999 елда) иҗатының кадерен, халыкның ихтирамын тоеп дөньядан китте). Бу чордагы язучылар оешмасының җитәкчеләрен дә янә искә төшереп үтик: председательләр—Ә. Ерикәй (1945-50), Г. Гобәй (1950-53), Г. Бәширов (1953-58), А. Шамов (1958-61), рәис урынбасарлары—җаваплы секретарь вазифаларын фронтовик шагыйрьләр Ә. Давыдов, З. Нурилар башкара.

## III

1960-90 еллар—оешма елъязмасында саллы гына утыз ел тотрыклы торгынлык дәвере. Әмма торгынлык сүзен мин калын хәрефләр белән язмас идем. Татар әдәбиятының үскән, көчле чагы бит әле ул чорлар. Дистәләгән зур язучылар бар. Миллионлаган укучылар бар! Иң мөһиме—язучы белән гавам арасында табигый бәйләныш бар. Кемнәрдер Г. Әпсәләмов әсәрләрен егылып укый, кемнәрдер Ә. Еники повестьларына мөкиббән, кемнәрдер Х. Туфан, С. Хәкимнәрнең шигырь-җырларын көтә, кемнәрдер янартаудай күтәрелгән яңа буын шагыйрьләрен байракчылары итеп



*Ватан сугышында катнашкан бер төркем татар язучылары. Беренче рәттә (сулдан уңга)—Әдип Маликов, Сибгат Хәким, Мәхмүт Хөсәен; икенче рәттә—Шәйхи Маннур, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Вадим Земной; өченче рәттә—Мөнир Мазунов, Әхмәт Исхак, Шәрәф Мөдәррис. 1948 ел.*



*«Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы» шигаренең рәсми девиз булып яңгыраган чорлары. Рәсемдә сулдан уңга: латыш Вилис Лацис, татар Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. Үткән гасырның 50нче еллары.*



*Шәхес культы елларында төрмә-сөргеннәрне кичкән татар әдипләре. Сулдан уңга: Сөббух Рәфыйков, Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов. Озак еллар үткәч янә Казанда очрашу 1957 ел.*



*Язучыларның иҗат һәм ял йортлары урнашкан «Аккош күле»ендә 60нчы елларда яшәгән язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Ф. Хөсни, Р. Ишморат, Х. Туфан, Г. Бәширов, Н. Дәүли, З. Нури (улы белән).*



*«Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә. Сулдан уңга: М. Хәмитов, Н. Юзиев, Ф. Хөсни, Я. Халитов, В. Ганиев, А. Гомәр (баш редактор), Г. Әпсәләмов. 1962 ел.*

саный... Татар әдәбиятын, татар халкын байрактай күтәреп М. Җәлил иҗаты дөнья гизә. 1966 елда Казан Кремле янында герой-шагыйрьнең һәйкәле калка...

Әлеге чорны характерлый торган кайбер вакыйгаларны, тарихи фактларны, лозунг-шигарьләрне искә төшерик. Шул еллар әдәби хәрәкәтенең асылын аңларга җинелрәк булыр. 60нчы еллар башларында Хрущев вәгъдә иткән «коммунизм»ның төзелеп бетәргә тиешле чоры бу. 30 елга якын шул чорнын 20ләбендә Брежнев идарә итте. СССРның, АКШ лидерлары тарафыннан «явызлык империясе» дип тамгаланса да, дөньякүләм мәйдан тоткан, табигый байлыкларын, бигрәк тә нефтьне ифрат күп чыгарып, нигездә, шуның хисабына милитаристик державага әверелгән чагы. Идеологик яктан да шактый катлаулы чор: тышкы сәясәттә—көч-тынычлык ике системаның көрәшенә (беренче чиратта хәрби потенциалны арттыру юлы белән) сарыф ителсә, эчке сәясәттә—төп игътибар халыкларның милли үзенчәлекләрен бетереп, бердәм совет (рус дип аңларга да була) халкы ясауга бирелде (мәсәлән, Казанда татар мәктәпләре бөтенләй диярлек бетерелде, авыл мәктәпләренең күбесендә уку-укытылу русчага күчерелде). Әдәбият хәлләренә килсәк, аның әле абруйлы чагы. Иң күп китап укучы халык СССРда дип әйтәләр иде. Дөрес тә булгандыр—өйдә-китапханәдәме, юлда-пляждамы дигәндәй, олысының да, кечесенең дә кулында китап булыр иде. «Китап—белем чишмәсе» дигән канатлы сүзләр күпчелекнең аңында, күнелендә иде. Әдәбиятның дәрәҗәсе халыкның шигърияткә мөнәсәбәтендә бигрәк тә ачык чагылды. Халык ташкын булып мәйдан-стадионнарны, мәдәният сарайларын тутырып шигырь тыңларга җыелсын әле! Кабатланмас еллар! Без дә—60нчы еллар башында әдәбиятка килеп, хәзер 60 яшькә житкән буын—шигырь язып, иҗат итеп, дөньяны яхшыга үзгәртәбез, дип нык ышандык ул елларда! Һәм шул ышаныч илһамландырды да, эшләтте дә, яшәтте дә. Кызыклы чор, парадоксларга бай чор. Бер яктан, «нык үскән социализм» илендә иҗат иреге турында тәкрарланса, икенче яктан, мәгълүм канун-кысаларга яраклы партияле иҗат таләп ителде ул чорда. «Без йөрәгебез кушканча язабыз, ә йөрәкләребез партиягә бирелгән» дигән сүзләр еш яңгырый иде. Ялгышмасам, бу сүзләрне партия съездында М. Шолохов әйтте. Әдәбият белән җитәкчелек итүне партия, беренче чиратта, Язучылар берлеге аша башкарды. Тулысынча партия идеологиясенә хезмәт иткән оешманың эш стиле дә, табигый, партия дисциплинасына буйсынган булды. Ул стиль шул система өчен уңайлы һәм шактый ук мөкәммәл дә иде. Язучыларның съездлары, пленумнары Устав буенча төгәл вакытында үткәрелә (1960-90нчы елларда V-XI съездлар, җәмгысе җиде съезд), партоешма җыелышлары вакытында уздырыла, әдәби ел йомгаклары утырышлары зур вакыйгага тиң була (аларны үткәрә башлауга быел 45 ел тулды, ел йомгакларына багышланган беренче җыелыш 1964 елда үтте)... Булдыклы, талантлы язучыларның (дөрес, сирәк-мирәк кайбер әсәрләрдән идеологик «ялгыш» табып, басылмау очраклары булгалады) әсәрләре даими чыгып килде. Каләм хакы бәрабәренә заманы өчен яхшы гына яшәп, гаилә тотып була иде. Язучыларның китапларын бастырып чыгаруда Язучылар союзы реаль булыша алды. Язучылар, аларның гаилә әгъзалары иҗат йортларына, курорт-санаторийларга барып, иҗат белән шөгыльләнә, ял итә һәм дәвалана ала иде... 50-60 ел эчендә язучы халкы өчен Әдәби фонд аша меңләп путевка-юллама алынгандыр дип уйлыйм.

***

Матбугат йортында урнашкан, заманында уңышлы гына эшләп килгән тагын бер оешма—Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы. 60нчы еллар ахырында, М. Әмир рәислек иткән чорда оешты ул. (Дөрес, әдәбиятны пропагандалау гел актуаль булып килгән, язучыларның беренче съездларында ук күтәрелә бу мәсьәлә. 1953 елда җәмәгатьчелек тәртибендә берничә язучыдан торган (М. Садри, М. Хөсәен, Г. Шамуков) махсус бер бюро да оештырыла. Әмма аның юридик статусы булмаган, әлбәттә. (Соңгы вакытта бу фактны, оешма төзелүнең башы санап, ясалма юбилей да билгеләп йөрделәр әле). Чынлыкта, штатта кешеләре, реквизиты, тиешле бүтән атрибутлары булган оешма 1967 елда төзелде. Бер ел элек Мәскәүдә, СССР Язучылар союзында Бөтенсоюз пропаганда бюросы оешкан иде. 70-80нче елларда Советлар Союзының күп республикаларында һәм өлкәләрендә

бик тантаналы һәм рәсми рәвештә үтә торган Совет әдәбияты көннәрен (заманында Татарстанда да узды), нигездә, шушы Бөтенсоюз бюросы оештырды да.

Безнең пропаганда бюросының штаты өч кешедән гыйбарәт иде: директор, әдәби хезмәткәр, бухгалтер. Конкрет эшкә килгәндә, бюро төрле оешмалар, предприятиеләр, колхозлар белән хезмәттәшлек турында договорлар төзеп, шул килешү нигезендә берничә язучыдан (арада берәр популяр җырчы белән баянчы да була иде) торган бригада төрле аудиторияләр алдында чыгышлар ясый иде. Бюроның җитәкчеләре булып Мөнип Шәймөхәммәтов (сәнгать буенча аспирантура үткән Сарман ягы кешесе. Мөнип Газар псевдонимы белән шигырьләр дә яза иде), Мансур Шиһапов, Эльс Гаделов, Рәфкать Кәрамиләр, әдәби хезмәткәр булып төрле елларда Марсель Галиев, Фәннур Сафин, Хәкимҗан Халиков, Камил Кәримов, Нурислам Хәсәнов, Рәдиф Сәгъдиләр эшләде.

Сүз дә юк, пропаганда кирәк нәрсә. Хәзерге заманда бигрәк тә. Реклама индустриясенең көннән-көн колачлана баруы тикмәгә түгел. Татар китабы (басма китабыбызның 300 елга якын тарихы бар!) яклауга, пропагандалауга аеруча мохтаҗ. Пропаганданың ысуллары күп: радио, телевидение, газета-журнал, буклет-проспектлар, афишалар, төрле видео-аудиокассеталар... Әмма язучының үз укучылары, бигрәк тә мәктәп балалары белән очрашулары бөтенләй үзгә эффектка ия. Тере язучыларны күрү, алар белән аралашу бала күңелендә гомерлеккә калучан. Әлбәттә, сүз—чын, зыялы язучының югары дәрәҗәдә үткән очрашулары турында бара. Чын мәгънәсендә әдәби-әхлакый дәрес булырдай кичәләр, шөкер, бихисап оештырылды. Шулай да, әдәбият файдасына булмаган аралашу фактларын да таныйк. Бер заман әлеге бригадаларда уртакул яки үзешчән дәрәҗәдәге каләм ияләре күбәеп китте (чөнки зур язучылар очрашуларга бик еш чыга алмый, талант иясенең һәр сәгате исәпле). Уртакул каләм ияләре артыннан гөл үсеп калмый, әлбәттә. Минемчә, язучының төп вазифасы артык күренеп йөрү түгел, иҗат итү. Гарәпләрдәге бер әйтемне дә онытмыйк: «Мөгәйдинең үзен күргәнгә караганда, шигырьләрен ишетү хәерлерәк».

Матбугат йортында 80нче елларда республикакүләм дәрәҗәдә китап сөючеләр җәмгыяте дә эшләп килде. Хәзерге яшьләр өчен сәеррәк яңгырыйдыр бу сүзтезмә... Әлеге язмамны әзерләгәндә яшьләр газетасында бер хәбәр укыдым да, сискәнеп киттем. Россия халкының 70 проценты бер дә китап укымый. 80нче елларда илдә андыйлар 10 процент кына тәшкил иткән. 1990 елда Россиядә 18 мең китап кибете эшләгән булса, бүген алар берничә меңгә калган. Көндәлек газеталарны ил халкының 20ләп проценты гына укый икән. Хәтердә: бу оешмада ул вакыттагы яшь язучылар Н. Акмал, А. Хәсәновлар эшләп йөрде... Менә хәзер—халык китаптан бизеп барган чорда кирәктер ул Китап сөючеләр җәмгыяте!

***

Шул ук 1963 елны Татарстан Язучылар союзының филиалы рәвешендә Әлмәттә язучылар оешмасы гамәлгә куелды. Шул вакыттагы әдәбият үсеше өчен зур вакыйга. Бу төбәктә моның өчен җирлек һәм инициатива булган, димәк, югарыдан да тиешле булышлык-ярдәм күрсәтелгән. Әлмәт бүлегенең җитәкчесе, ягъни җаваплы секретаре итеп язучы Гариф Ахунов билгеләнде. Бу бүлек Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче шактый күпсанлы талантлы каләм ияләрен туплап, иҗади рухландырып, шул регионның үзгә бер мәдәни-әдәби үзәгенә әйләнде. Әлмәт ул вакытта нефть башкаласы саналды. Илкүләм масштабтагы төрле чаралар—кинәшмәләр, слетлар, фестивальләр еш үтә иде анда. Татарстанга килгән атаклы язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре Әлмәткә сугылмый калмады. Алар чыгышлар ясап, җирле язучылар белән аралашып, Әлмәт оешмасының ныгуына унай йогынты ясады. Язучыларның Әлмәт бүлеге саны һәм әдәби куәте ягыннан кайбер өлкәләрдәге язучылар оешмаларына караганда көчлерәк саналды. 70нче елларны бүлектә СССР Язучылар союзы әгъзасы булган каләмдәшләрнең саны 25-30га җитте, ә яшь һәм башлап язучылар йөзәрләп исәпләнде. Нефть төбәге җирлегендә укучы яратып укырлык байтак күренекле әсәрләр—романнар, поэмалар, повестьлар, пьесалар язылды, күпсанлы җырлар туды. Ул әсәрләрне иҗат иткән берничә язучы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, соңрак Татарстанның халык шагыйре,

халык язучысы дигән мактаулы исемнәргә лаек булды. Ярты гасырга якын вакыт эчендә бу оешма белән Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Ә. Маликов, Ә. Гаффар, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллин, З. Дәүләтов, Д. Салихов җитәкчелек итте. Хәзер Әлмәт язучылар оешмасында вәзгыять бүтәнрәк: иҗади ялкынның сүрелә төшүе сизелә. Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ә. Маликов, Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, М. Хәсәнов, Ю. Әминов, Ж. Рәхимов, Ф. Гыйльми һ. б. эстафетасын дәвам итеп, татар әдәбиятын яна үрләргә күтәрерлек яшь көчләр, кызганыч, бик аз... Өлкән буыннан бүген дә актив иҗат итүчеләрдән К. Булатова, Ә. Сәлахов һәм А. Хәсәнов кенә калып бара бугай...

1980 елны Чаллыда язучылар бүлеге ачылды. 60нчы еллар башында Әлмәттә язучылар оешмасы ачылуга Татарстанда зур нефть чыгу сәбәп булса, Чаллыдагы бүлек оешу КамАЗ төзелешенә бәйле. Бу ике оешманың төзелү-оешу тарихы Гариф Ахунов исеме белән аерылгысыз. Әлмәт язучылар оешмасының беренче җитәкчесе ул булды, ә Чаллы оешмасы аның Язучылар союзына рәислек иткән чагында ачылды. Әлбәттә, җирлек, тиешле зәмин юк җирдә оешма кадәр оешма төзеп булмас иде. Чаллы бүлеге шул төбәктә актив эшләгән ике төп әдәби берләшмә нигезендә барлыкка килде: берсе—Чаллыдагы «Ләйсән» (җитәкчесе—Р. Лотфуллин), икенчесе—Түбән Камадагы «Кама таннары» (җитәкчесе—Р. Хисмәтуллин). Сонрак Зәйдәге «Зәй энҗеләре» (җитәкчесе—Р. Сәлимҗанов) берләшмәсе дә килеп кушылды. Чаллының җыелма халкы шикелле, язучылар оешмасы да, нигездә, төрле тарафлардан килгән язучылардан хасил булды. Берара җитәкчеләрне дә, Әлмәт мисалынчарак, Казаннан китереп кую хәлләре дә булды (Разил Вәлиев). Бу оешманың төзелүенә инде 30 елга якын. Үзенә күрә бер юбилей. Шул чакта күбрәк, тәфсилләбрәк сөйләрләр әле. Зур югалтулар да кичерергә өлгерде бу оешма: төрле елларда бүлек эшен җитәкче булып җигелеп тарткан Э. Касыймов, Г. Кашапов, Я. Игәнәйләр инде гүр ияләре... Шулар рәтендә—С. Рафиков, Х. Хөснуллин, К. Сибгатуллин, А. Сафин, Н. Мадъяров, Р. Хисмәтуллин, З. Гомәрова... Шулай да, әлегә шактый көчле каләмдәшләребез яши Чаллыда (А. Хәлим, Ф. Әмәк, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, Р. Бәшәров һ. б.). Әдәби хәрәкәтне берләштерүдә Чаллы язучыларының үз әдәби басмасы булу да бик мөһим. 1991 елдан гасыр ахырына кадәр «Аргамак» журналы чыкты, сонрак аны «Мәйдан» алыштырды.

***

Партия заманында интернационализм дигән сүз кин кулланыла иде. Кызганыч, бу сүз сирәк ишетелә башлады. Күпләр өчен интернациональлекнен ин яхшы билгесе—доллар яки евро хәзер. Интернационализм, минемчә, бөек төшенчә. Дөньяда халыклар дуслыгы дигән нәрсә булса, анын нигезе шушы төшенчә белән бәйле. Татарстан Язучылар союзы гомер-гомергә яхшы мәгънәсендә интернациональ оешма булды. Татар телле язучылар да, рус телле яки башка бер телдә язучылар да бердәм, тату иҗади хезмәттәшлектә яшәде. Татарстанда һәрвакыт рус язучыларының зур төркеме яшәп иҗат итте. (Сугыш вакытында Мәскәүдән һәм башка шәһәрләрдән килгән йөзләгән рус һәм яһүд язучылары турында әйтеп тә тормыйм). Сонгы дәвердәге кайбер исемнәрне генә искә төшерик: М. Бубеннов, Т. Журавлев, А. Салмин, С. Радзиевская, Г. Паушкин, М. Скороходов, Я. Винецкий, Ю. Белостоцкий, Н. Орешина, В. Корчагин... Шулай ук милләте белән татар, әмма рус телендә иҗат итүчеләр—И. Кәлимуллин, Р. Кутуй, И. Ахунжанов, Д. Вәлиев, Р. Бохараев, М. Зарипов, Ә. Мушинский, Р. Кожевникова, Л. Газизова, А. Кәримова... Безнең оешма җирлегендә чуаш язучылары секциясе дә уңышлы эшләп килде (шунысы игътибарга лаек: бүтән республикаларда һәм өлкәләрдә яшәгән татар язучыларының беркайчан да диярлек ни оешмалары, ни иҗат секцияләре була алмады. Сонгы елларда Башкортстанда татар язучылары оешмасы борынлады борынлавын...). Дөрес, республикада чуаш телендә язучылар сирәкләнде хәзер. Шулай да, без үз сафларыбызга кардәш халык вәкилләрен кабул итә торабыз. Мәсәлән, моннан берничә ел элек чуаш егете Евгений Турхан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды.

Сүз төрле телләрдә иҗат итүчеләр турында баргач, бу урында рус телендә

язучы милләттәшләр хакында янә әйтеп узыйк. Күрәсең, чынлыклап үз дәүләтең булмагач, гамәлдәге дәүләт телендә язарга омтылуны анларга мөмкин. Дәлилле фактлар да житәрлек. Еракка барасы юк, үзебезнең татар язучыларының ижади сәләткә ия балаларының бик күбесе рус телендә яза. Г. Кутуйның улы—Рөстәм Кутуй, Г. Әпсәләмовнең оныгы—Альбина Әпсәләмова, А. Расихның кызы—Фәридә Расулова, И. Юзеевнең улы—Салават Юзеев... Шуларга республикадан читтә яшәүче бүтәннәрне өстик: мәрхүм Роман Солнцев (Ренат Суфиев), Рөстәм Вәлиев, Рауль Мирхәйдәров, Камил Тангалычев... Яшьрәк исемнәр тагын да күбрәк... Аларны татар язучысы итеп санаргамы? Бәхәсле нәрсә. Күбесе Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары булып тора. Ижади потенциаллары зур булган актив шәхесләр. Минемчә, аларны татар әдәбияты хәрәкәтенә мөмкин кадәр ныграк тартырга кирәк. Кан тартмаса, бәлки, жан тартыр, диләрме әле! Әйтик, тәржемә эшендә, мөхәррирлек вазифаларында... Бу каләмдәшләребезгә читсенеп, үгисетеп карау әдәбиятыбызны тарайту булыр иде. Тараю ул үзе дә килә, ә менә кинәю, тирәнәю...

***

70нче елларда Татарстан Язучылар берлеге башында М. Әмир, И. Гази, З. Нури, Г. Ахуновлар торды. Шул елларны характерлый торган кайбер фактларны, вакыйгаларны искә төшереп узыйк. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулган еллар бу (VII белән VIII съездлар арасын әйтүем). Шуна күрә бу даталар унае белән Казанда да, Мәскәүдә дә бик күп чаралар үткәрелгән. Конкрет язучылар тормышына караган вакыйгалардан—Муса Жәлил турында «Ленфильм»да «Моабитская тетрадь» исемле кинофильм чыга; өлкән язучыларыбыздан Н. Исәнбәт, Х. Туфаннарның 70 яшьлек юбилейлары үтә; С. Хәкимгә РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе бирелә; татар язучылары Донбасска барып әдәбият көннәре үткәрә, шул ук җәйне (1972) Ворошиловград өлкәсеннән жавап визиты белән украин язучылары Татарстанга килә... Бу елларда Татарстан комсомолының М. Жәлил исемендәге премиясе булдырыла. Язучылардан беренче лауреатлар: И. Юзеев (1970), Р. Фәйзуллин (1972). Гомумән, ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк, 70нче еллар башында яшь ижат көчләренә хакимият тарафыннан игътибар зур булды. 1969 ел ахырында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында «Ижади яшьләр оешмасы» төзелде, житәкчесе итеп Р. Батулла билгеләнде. Шул елларда Актерлар йортында үтә торган «Ядкарь» кичәләрен өлкәнрәк буын ижатчылар яхшы хәтерли булыр. Халыкара яшьләр лагере «Волга»да («Идел»дә) һәр ел саен яшь язучылар, рәссамнар, композиторлар, актерлар катнашында бер атнага сузыла торган республика семинарлары уза иде...

70-80нче еллардагы әдәби хәрәкәтнең бер унай күренеше (күрсәткече дияргә дә ярыйдыр)—язучыларыбызның бүтән әдәбият вәкилләре белән даими аралашуы, үзара йөрешүе. Әдәбият көннәре, әдәбият-сәнгать декадалары, бөтенсоюз яки региональ семинарлар, ижади-фәнни конференцияләр, тегеяки бу әдипнең юбилейлары... Аларның һәрберсенә диярлек Татарстаннан вәкил булып кемдер барды. Әлбәттә, андый жирләргә республика исеменнән сөйләрлек, әсәрләре киң жәмәгатьчелеккә билгеле, язучы буларак дәрәжәләләр бара иде. Заманында төрле республикаларга З. Нури, Г. Ахунов, С. Хәким, Р. Мостафин, Р. Харис һәм тагын кайберәүләр күп йөрде. Минем үземә дә СССРның бөтен республикаларын диярлек гизеп чыгарга туры килде, сирәгрәк булса да, рәсми делегацияләр составында чит илләргә дә чыгылды, 1985 елда СССР Язучылар союзы делегациясенең житәкчесе сыйфатында Италия кебек илләргә дә барып жителде. Чит ил димәктән, бу елларда татар язучылары төрле илләргә шактый еш чыга башлады. СССР һәм РСФСР Язучылар союзларында чит ил эшләре комиссияләре язучылар өчен махсус туристик сәяхәтләр оештыра иде. Бүгенге белән чагыштырганда, символик бәягә атна-ун көн дәвамында Европа, Азия илләрен гизеп кайта иде язучыларыбыз. Ул елларда безнең байтак каләмдәшләр бу мөмкинлекләрдән даими файдалана белде. Язучы халкының килере һәм мөмкинлекләре шактый иркен булган, димәк! Бу чорда драматургларның эшләре бигрәк тә яхшы барды (хәер, матди яктан алар һәр чорда да чагыштырмача яхшырак

яшәде), төрле республикаларда, өлкәләрдә аларның пьесалары буенча спектакльләр еш куелды. Безнең театр коллективлары да бөтен СССР кинлекләрен гизде, аеруча Казакъстан, Урта Азия якларында җәй саен гастрольләрдә булып, халыкны туплау, рухи берләштерү юлында тарихи миссия башкарды.

80нче елларда оешма зур активлык күрсәтеп, байтак иҗади-оештыру эшләре башкарылды. Агымдагы эшләрдән тыш, хәтердә җуелмаслыклары—Башкортстанда һәм Чуашстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Шул заманга хас колачлылык, патетик рух, бәйрәмчә тантаналар. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы, табигый, моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә яхшы үтте. Тугандаш республикалардан да байтак кунаклар килгән иде (1986 елның 26 апреле—Тукайның тууына 100 ел тулган көн—Чернобыльдәге коточкыч фаҗига көне белән дә тарихка кереп калды).

Туфан Миннуллин җитәкчелек иткән чорда «Халык шагыйре», «Халык язучысы» дигән мәртәбәле исем булдырылды. 1985 елда бу исем турында Татарстан Югары Советы Указы игълан ителгәннән соң (хәзер ул Президент Указы белән бирелә) бүгенге көнгә кадәр халык шагыйре, халык язучысы исемен йөрткән әдипләрнең саны 22гә җитте. Күбрәк тә бугай бу сан. Шуларның 12се мәрхүмнәр инде... (Алдагы битләрдә аларның тулы исемлеге бирелә.—**ред.**)

***

Бу язмамда Язучылар берлегенең төрле еллардагы составы, сан-исәбе турында да беркадәр әйтеп узу урынлы булыр. Сүз Язучылар берлеге әгъзасы саналган каләмдәшләр турында.

Әлбәттә, әдәбиятны бернинди оешмалар тудырмый, әдәбиятның сыйфатын оешмадагы әгъзаларның саны да билгеләми. Әдәбиятны талантлы аерым шәхесләр тудыра, XIX гасырда русларда махсус дәүләти әдәби оешмалар булмаса да, бөек әдәбият бар. XX гасыр башында Тукай, Исхакый, Ибраһимовлар йөзендә бөек татар әдәбияты бар. Шагыйрь әйтмешли, әдәбиятның зурлыгын билгеләр өчен «бер Толстой җитә, бер Тукай!» Үткән гасыр башында, ягъни йөз ел элек, татар мохитендә язучы-мөхәррирләр бердәм иҗади оешмада тормаса да, бүгенгедән ким булмаган дип уйлыйм.

1934 елда, Татарстан Язучылар союзы оешканда 30лап язучы оешма әгъзасы саналган. Сугыштан соңгы елларда СССР Язучылар союзы таныклыгын йөрткән кешеләр 50ләп исәпләнгән. Алда әйтелгәнчә, 1968 елда бу сан 111 гә җитә. 1990 нчы елларда Союзга алу артыгы белән активлаша. Ун ел эчендә (1989-1999—Р. Мөхәммәдиев рәислек иткән чор) 126(!) кеше әгъзалыкка кабул ителә (XI-XII съезд арасында 72 кеше, XII-XIII съезд арасында 54 кеше). «Кояш» сүзен язганда биш хата җибәрүче кешеләр Союзга керә» дигән төртмәле сүзләр шул елларда чыкты шикелле. Шулай итеп, XXI гасыр башына гомумсан 280гә җитә. Хәзерге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 326 әгъза. Уртача яшьләре—60 чамасы. Искә төшереп чагыштырыйк: СССР Язучыларының беренче съездында катнашкан делегатларның уртача яше 38,5 булган. Без—пенсионерлар оешмасы булып чыгабыз түгелме соң?

«Кадрлар һәммәсен дә хәл итә» дигән искерми торган бер гыйбарә бар. Бу гыйбарә безнең эшкә дә кагыла. Язучылар берлегенә алганда төп роль Кабул итү коллегиясенә (комиссиясенә) йөкләнгән. Коллегия карарын идарә, гадәттә, хуплап раслый. Кире кагылу очраклары, гайре табигый хәл саналып, бик сирәк була. 90нчы елларга кадәр соңгы мөһерне Мәскәү—СССР Язучылар союзы секретариаты суга иде. Соңгы 10-15 ел эчендә бу мәсьәлә үзебездә—Татарстан Язучылар берлегендә хәл ителә. Кабул ителгән каләм иясенә «Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы» дигән таныклык тапшырыла. Бар иде заманнар: теге яки бу халыкның, республиканың әдәби потенциалын, дөресрәге, оешма потенциалын саннар да билгели иде. Әле хәтердә: 60-70нче елларда өлкән язучы агайлар: кара, үзбәкләр язучылар санын 300гә җиткергән, украиннар—400гә... Безгә дә арту кирәк, диләр иде. Чыннан да, сан арттыруда мәгънә дә бар иде: язучылар исәбенә карап җирле союзларга Үзәктән акча җибәрелә, торак төзелешләренә өстәмә чыганаклар бүлеп бирелә, санаторийлар, иҗат йортларына юлламалар күбрәк килә... Хәзер вәзгыять бөтенләй бүтән: җирле

бюджет хозурына һәм үз тырышлыгына карап үз көненне үзен күрәсен.

Язучылар берлегенә әгъза итеп алынган каләм ияләре турында төрле фикерләр дә бар. Алар матбугат битләрендә дә чагылып ала. Табигый хәл. Әмма бу очракта шуны кистереп әйтергә кирәк: Кабул итү коллегиясе әзме-күпме әдәби сәләте булганнар арасыннан иң яхшыларын сайлап алырга тырыша һәм шулай эшли дә. «Балкып торган 20-25 яшьлек фәлән иптәшне нигә һаман Берлеккә алмыйсыз?» дип беркем дә әйтә алмас. Бүгенге Коллегиядә түбәндәге иптәшләр эшли: Равил Фәйзуллин (рәис), Марсель Галиев, Хатыйп Миннегулов, Нәбирә Гыйматдинова, Газинур Морат, Юныс Сафиуллин, Фәйрүзә Мөслимова, Лилия Газизова, Вакыйф Нуриев. Орлыктан кибәкне генә аера торган иптәшләр дип беләм мин бу язучыларны. Элек тә кабул итү комиссиясендә абруйлы зур язучылар эшләде—Г. Бәширов, С. Хәким, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев... Шуны анларга кирәк: вәзгыять элекке белән чагыштырганда нык үзгәрде, язучының җәмгыятьтәге роле тоныкланды... Чит төбәкләрдән түгел, үз республикабызда да яшьләр әдәбиятка ургылып килми. Сер түгел, бүтән өлкәләрдә яшәүче авторларга игътибарны күбрәк бирергә тырышабыз, аларга кайчак ташламалар да ясарга туры килә... Шунысы да бар: артык чикләүләр куеп, иҗади оешманы алып булмаслык крепость-кирмән дә ясарга кирәкмидер. Әйе, бездә берлектә саналган 300ләп чын язучы юк, 300 дә фәлән әгъза гына бар. Таныклык йөртү—син әле коеп куйган язучы дигән сүз түгел. Язучылар оешмасында әзме-күпме талантлы кешедән язучы ясап була дигән идея, башлангыч чорда—30нчы елларда, бәлки, булгандыр да. Булса—тамырдан ялгыш фикер. Әмма оешмага әгъза булып кергәч, үзен чын язучы санарга әзер иптәшләр хәттин ашкан. Әйтик, Зөлфәт Хәкимгә, язучылар таныклыгы йөртмәү танылган драматург булырга комачауламады бит әле! Язучылар оешмасы—демократик характердагы ирекле иҗтимагый оешма. Бу оешмага керергә теләүчеләр бихисап булса да, аннан гариза бирен чыгарга теләк белдергән кешеләр дә юк түгел. Хәтта идарә составыннан да... Соңгы айларда гына Устав таләпләренә туры килмәгән гамәлләре өчен кайбер иптәшләрне Берлектән чыгару турында карарлар да кабул ителде.

Коллектив турында сүземне йомгаклаганда шуны да искәртеп узасы килә: Язучылар берлегенә яна әгъзалар кабул итү—идарә эшчәнлегенең төп күрсәткече булып кала бирә әлегә.

## IV

Язмамның бу бүлеге соңгы 20ме елга карый, 1989 еллар ахырыннан бүгенгегә кадәр чор. Үзебез яхшы ук белсәк тә, вакыйгалар үзәгендә катнашсак та, объектив бәя бирер өчен кыен чор. Чын бәяне фәкать Вакыт Галиҗәнапләре генә бирәчәк. Шулай да, соңгы 15-20 еллардагы әдәби хәрәкәтне беркадәр анализларга тырышып, фикер йөртә башлау дәвере җитте кебек.

Иң әүвәл 90нчы еллар башындагы иҗтимагый вәзгыятьне искә төшереп карыйк. Мәгълүм хакыйкать: өскормa—базисның ныклыгына, тотрыклыгына бәйле. Бу елларда иң зур глобаль үзгәреш—СССРның (империянең дисәң дә буладыр) таркалуы булды. Бу таркалу зур илнең бөтен эчке һәм тышкы халәтен, икътисадын, идеологиясен үзгәртте. СССР таркалудан берәүләр отты, берәүләр ярык тагарак алдында калды... Кайбер халыклар мөстәкыйльлек алып, үз дәүләтләрен төзеде. Берәүләр... Хәер, нинди генә авырлыклар булса да, ул еллар Татарстан, гомумән, татар халкы тарихында да үзенчә онытылмас еллар!

Авыр, киеренке, әмма халык рухының күтәренке еллары. Суверенлык, мөстәкыйльлек турында хыялланып һәм ышанып авыз тутырып сөйләнгән еллар. Урамнарда халык ташкыны. Митинглар, Югары Советта кайнар бәхәсләр. Ниһаять, Татарстанның Дәүләт Суверенлыгы турында Декларация! Президент сайлаулары, Референдум үткәрүләр... Бөтендөнья татарларының I Конгрессы. Болгар җирендә Ислам дине рәсми кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган тантаналар. Татар энциклопедиясе әзерләнә башлау... Татарстан белән Россия арасында төзелгән тарихи Шартнамә... Чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә Татарстан илчелекләре—Вәкаләтле вәкиллекләре булдырылу...

Шул ук елларда мәдәни-әдәби тормышыбызда да тарихи вакыйгалар,

елъязмаларга керерлек гамәлләр байтак булды. Иң әүвәл—партия диктаты бетте, классик мәгънәдәге цензура юкка чыкты. 1989 елның июленнән яшьләр журналы «Идел» (ярты гасырлык хыялда йөргән басма!) чыга башлады. Озак та үтми, «Салават күпере», «Мирас» журналлары пәйда булды. 1995 елда атналык «Мәдәни җомга» газетасы оештырылды. 70 елдан соң, 1991 елда иң зур нәшриятларыбызның берсе «Мәгариф» торгызылды. Тыелган мирас (әйтик, Г. Исхакый) кире кайта башлады. Мөхәммәдъяр, Кандалый кебек борынгы шагыйрьләребезгә багышланган тантаналар узды. Төп әдәби журналыбыз «Казан утлары»ның юбилейларына багышланган кичәләр үткәрелде... Классик әдипләребезнең күптомлыклары чыга башлады...

Җиңүгә тиң бу казанышларда безнең каләмдәшләребезнең дә өлеше зур булды. Матбугатта чыгыш ясапмы, җыелыш-митингларда катнашыпмы, төрле акцияләр оештырыпмы, алар Татарстанның киләчәге, аның бәйсезлеге өчен җан атып йөрде; көрәш мәйданының уртасында булды. Кирәк чакта меңләгән халык алдында яндырып сөйләде, мәйданнарга чыгып, ач утырды, шигарь булырлык шигырьләр язды, күпләргә фидакарлек үрнәге күрсәтте.

Депутатларыбыз да күп эшләде ул елларда. Мандатлы вәкаләте булгач, табигый, эшләргә тиеш иделәр дә. Элегрәк, язучылардан бер кеше, гадәттә, идарә рәисе югары органнарга (СССР, РСФСР, ТАССР Югары Советларына) сайлана иде. 90нчы елларда депутат булып җиде кеше үтә алды (Т. Миннуллин—СССР Югары Советына, Р. Мөхәммәдиев—РСФСР Югары Советына, Ф. Бәйрәмова, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис—Татарстан Югары Советына). Шул еллардан башлап, бүгенгә кадәр дүрт-биш язучы Татарстан парламентына сайланып килә. (Соңгы чакырылышта Татарстан Язучылар берлеге рәисенең депутат итеп сайланмавы күпләрдә гаҗәпсенү тойгысы уятты уятуын. Оешма тарихында рәисләр һәрчак депутат булды. Бу статус рәискә үзенең төп вазифаларын яхшырак башкару өчен кирәк ләбаса!) Әгәр парламентта язучыларның көчле төркеме булмаса, милли мәнфәгатьләрне кайгырткан кайбер законнар, карарлар, мөрәҗәгатьләр, мөгаен, дөньяга чыга да алмас иде.

Искәртеп узыйк: бу соңгы 20 елда оешма җитәкчеләре булып Р. Мөхәммәдиев (1989-99), Ф. Галимуллин (1999—2005), И. Ибраһимов (2005 елдан бүгенгәчә) эшләде.

***

«Атай үлде, хөррият килде!» дип әйткән ди, имеш, бер малай. СССР таркалып, демократия дигән хөррият килеп алды-алуын (Казансу ярында хәтта «Хөррият» исемле биек сын-стелла да калкып чыкты!), әмма аның «ләкин»нәре дә безнең өчен күп икән шул! Чәчелгән, сибелгәнлекнең тагын бер «татлы» җимешен татыдык: байтак милләттәшләребез тарихи Ватаныннан тәмам өзелеп, чит дәүләт-мәмләкәтләрдә калды... Үз туфрагында берегеп, күмәкләшеп яшәгән халыклар үз дәүләтләрен корды, ә без—татарлар, тагын да азаеп, Россия карынында калдык... Казакъстан һәм Урта Азиядә күпләп яшәүче милләттәшләребез белән рухи аралашу бөтенләй диярлек бетте. Кая ди ул театрларыбызның ел саен «Ефәк юллары» буйлап Урта Азиягә чыга торган гастрольләре? Газета-журналларыбыз, китапларыбызның юлы кырт киселде. Әйтик, совет чорында «Казан утлары», «Азат хатын» («Сөембикә») журналларының өчтән-дүрттән бере (ул 15-20 мең дигән сүз!) шул якларда таралса, хәзер алар өч-дүрт дистә данәгә калды... СССР таркалгач, татар матбугатының (бу хәл башка халыкларга, шул исәптән русның үзенә дә кагыла) тиражлары катастрофик дәрәҗәдә кимеде. Дөрес, Россиянең татарлар яши торган кайбер төбәкләрендә татарча газеталар ачылды-ачылуын. Әмма алар безнең район газеталары сымак, әдәбият-сәнгать үсешенә әллә ни тәэсир итәрлек дәрәҗәдә була алмады. Казанда чыга торган төп басмаларның таралуына да әллә ни булышлы тәэсир итмәделәр шикелле. Бәлки әле киресенчәдәдер: чөнки татарча укучылар катламы бик «юка», гомумтатар укучысының матди яклары кысынкы икәнлеген дә исәпкә алсак, әбүнәчеләр, гадәттә, берәр басмадан артыкка языла да алмый. Кайберләре, бәлкем, әнә шул җирле газетаны алдырадыр... Кыскасы, татар телендәге басмаларның тиражы кимүе безгә—язучыларга бик «кырын сукты», укучыларыбызның кискен кимүенә

китерде. Ә язучының укучысы булмаса... Өстәвенә, Язучылар берлегенең махсус үз басмалары юк диярлек хәзер. Дәүләт нәшриятларында да китаплар чыгару кимеде. Барлы-юклы каләм әжерен алу кыенлашты. Нәшриятларның Бауман урамындагы Матбугат йортында бергәләшеп эшләгән елларны да сагынырга гына кала.

***

Әйе, СССРның таркалуы күпләр өчен көтелмәгән тетрәнү булды. Асылда, СССР таркалгач, Горькийлар оештырган, азмы-күпме без белгән СССР Язучылар союзы да таркалды. Шунысы факт һәм кызганыч: кем белән берләшергә, кемгә таянырга, кем белән алга омтылырга? Әлегә ачыклык юк. Совет чорын үткән иҗат кешеләре өчен бу—үзгә бер фаҗига. Элеккеге СССР һәм Россия язучылары арасында бердәмлек һәм уртак максат булмау иҗат кешеләрен аптырашта калдырды... Әмма Үзәк тә тик ятмады. Төп йорт таркалгач була торган хәлләр башланды илдә. Аерымланулар, бүлгәләнүләр, мал бүлешүләр... Бу процесс иҗат оешмаларын да читләтеп үтмәде. Иҗат оешмаларының иң көчлесе саналган Язучылар союзларында бу процесс бигрәк тә ачык күренде. Үзәк Әдәби фонд карамагында булган мөлкәт тирәсендә никадәр шау-шулар, суд-низаглар булды. Чөнки байлык та бар иде шул! Атаклы иҗат йортлары гына күпме иде! Пицунда, Ялта, Дубылты, Переделкино... Мал-мөлкәт тирәсендәге ыгы-зыгы (Мәскәүдә аның әле хәзер дә тынганы юк) бер хәл, язучылар үзләре дә бүлгәләнеп бетеп, төрле төркемнәр булып оешты. Башкаладан үрнәк алыпмы, үзләренең ихтыяҗы булыпмы, мондый хәлләр регионнарга да күчте. Мисалга ерак барасы түгел, күрше чуашларда язучыларның берничә оешмасы хасил булды... Ә бездә? Бездә андый бүлгәләнүләр булмады дияргә мөмкин. Дөрес, 80нче еллар ахырында язучылар оешмасының кирәклеген шөбһә астына куйган фикерләр булгалады, «Язучылар колхозы»н тәнкыйтьләгән мәкаләләр күренгәләде. Әмма, сүз, нигездә, оешманы бетерү турында түгел, оешманы янача үзгәртеп кору, камилләштерү кирәклеге хакында барды. Бердәм Язучылар оешмасының безнең өчен зарурлыгы хакында күпчелек зур язучылар бердәм булып, кистереп, дәлилләп әйтте. Оешмабызның таркалмый-бүлгәләнми тотрыклы булып калуы, минемчә, бердәмлегебез, эчке көчебез билгесе. Дөрес, 1995 елда Татарстанда, Халыкара язучылар оешмасының бер тармагы буларак, татар ПЕН-үзәге төзелде. Әмма ул—үзебезнең төп оешмадан аерымлануны түгел, киресенчә, язучылар коллективының иҗади-сәяси мөмкинлекләренең зурлыгын гына күрсәтте. Чөнки ПЕН-үзәктә шул ук абруйлы язучылар, байтагы—Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзалары...

Татарстан Язучылар берлегенең бу чордагы сәяси зирәклек күрсәткән бер акциясен аерым бәяләп үтәргә кирәктер. Ул—Татарстан Язучылар оешмасының мөстәкыйльлеген тәэмин итеп, аны Халыкара Язучылар бердәмлегенә кертү. Шул максатны күздә тотып, 1991 елның 15 мартында язучыларның съезд дип аталган бер җыены булды. Ул, асылда, ел йомгакларына багышланган җыелыш иде. СССР Язучылар союзының соңгы съездына вәкилләр сайлау өчен, Устав кушканча, бу җыелышның съезд дип аталуы кирәк иде. Шуна да, бу җыелыш-съезд, чираттан тыш саналып, фәләненче санлы съезд булып исәпләнмәде дә. Шулай да, ул җыелышта әле хәзер дә гамәлдә булган Татарстан Язучылар берлеге Уставы кабул ителде. Шул ук елның октябрендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлеге арасында хезмәттәшлек итү турында килешү» төзелде. Килешүнең беренче җөмләсендә «РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, тигез хокуклылык шартларында, һәрьяклап хезмәттәшлек итәргә килеште» диелә. Тарих өчен кызык, гыйбрәтле документ. (Соңгы вакытта бәгъзе иптәшләрнең Татарстан оешмасын янә Россия Язучылар оешмасына буйсынулы итәргә, дөресрәге, үзләренең Россиякүләм җитәкчелек даирәсенә керергә омтылышлары булды. Безнеңчә, ашыгырга ярамый. Ашыккан ашка пешкән, ди халык. Россия язучылары әлегә үзләре берничә үзәккә бүленеп беткән. Икенчедән, иске үзәккә кайтуның безнең өчен әлегә бернинди файдасы күренми. Чөнки Мәскәүдәге нәшриятлар һәм басма органнар Язучылар союзына карамый, элеккечә үзәктә китаплар чыгару мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Киресенчә, кайбер Мәскәү журналлары үзләре, ярдәм сорап, Татарстанга мөрәҗәгать итә... Иҗат эше—сәнәгать тармагы түгел (анда, чыннан да, интеграциясез булмый!).

безнең эш иреклеккә, демократик тигезлеккә корылган. Гомумән, чын дуслык, хезмәттәшлек тигезләр арасында гына була ала. Бу—аксиома).

Мәсьәлә хәзергә, чыннан да, шулай. Берләшү түгел, киресенчә, кирегә сутүгә охшаган фикерләр дә юк түгел. СССР язучыларының төп газетасы, ул замандагы демократик көчләрнең төп басмасы «Литературная газета» бүген менә нәрсә яза (1 сентябрь 2009 ел): «В дни, когда отмечается 75-летие Первого съезда Союза советских писателей, вполне уместно задаться вопросом: насколько необходимо было подобное объединение и нужно ли оно сейчас?

Вопреки расхожему мнению, будто писателей насильно загоняли в союз, они вступали туда по доброй воле. В условиях, когда сами труженики пера устали от дрязг и бесконечной борьбы противоборствующих группировок, новая объединяющая структура пришлась как нельзя кстати. Это дало возможность писателям эффективно решать не только профессиональные и организационные, но и бытовые проблемы, вести прямой диалог с властью, отстаивать свои интересы.

Несмотря даже на то, что компартия стремилась превратить союз в проводник своих идей, в его рядах состояло немало мастеров, далёких от политики и карьеризма, оставшихся в литературе именно в качестве незаурядных авторов, а не функционеров.

Ныне ситуация в отечественной словесности поразительно напоминает ту, что была 75 лет назад. Несколько враждующих между собой объединений литераторов никак не могут договориться и заняться наконец своим прямым делом, вместо того чтобы обливать друг друга помоями и делить давно уже расхищенное имущество бывшего Союза писателеи СССР.

Неудивительно, что власть не уделяет этим структурам серьёзного внимания, которое уделяла бы, разговаривая с серьёзной организацией, представляющей интересы всех писателей страны—«от Москвы до самых до окраин».

Есть над чем задуматься...»

Шул ук газетада Россия Язучылар союзы рәисе В. Ганичев мәкаләсе дә басылган. Анда мондый юллар бар:

«Мы работаем по многим направлениям, но главное, к чему мы стремимся,—чтобы наш союз всегда участвовал в созидательных акциях во благо Отчизны. Мы являемся соучредителями Всемирного Русского народного собора, который возглавляет Святейший Патриарх Московский и всея Руси Кирилл. Я являюсь заместителем главы Всемирного Русского народного собора. Союз писателей России самым активным образом участвует в организации и работе соборов. Мы рассматриваем самые животрепещущие вопросы жизни русского народа—духовное возрождение, проблемы русского языка, русской национальной школы, здоровья нации, православие, положение русских в мире.»

Милли әдәбиятлар, аларның традицияләре, үсеш перспективалары турында ник бер кәлимә сүз булсын! Уйландыра...

***

Без съездлар, юбилейлар турында сөйлибезме, оешманың көндәлек эше турында сүз алып барабызмы, барыбер, уйлануларыбызның төп мәгънәсе язучы хезмәтенең асылына—аның әсәрләренә барып тоташа, һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Житәкчеме син, урын биләмәгән каләм иясеме, язучы саналасың икән, байрак булып иң алдан әсәрең барырга тиеш. Укучы өчен, язучының шәхесеннән бигрәк, аның әсәре кадерле (балачакта китапханәдән китапны, авторыннан бигрәк, исемен әйтеп сорап ала идек; күрәсең, яшь чакның логикасы хакыйкатькә күбрәк якын булган). Мина калса, хәзер, бигрәк тә соңгы 10-15 елда хәл бүтәнрәк: игътибарыбыз беренчелгә караганда күбрәк икенчел факторлар тирәсенәрәк юнәлгән. Гадәттә, фәлән әсәрнең язылуына (чыннан да, «Туган тел» «Инкыйраз», «Моабит дәфтәре» яки «Әйтелмәгән васыять»нең вакыт-вакыт кайчан язылуларын җәмәгатьчелеккә белдереп торсак, тарихи хәтер өчен зыян булмас, һәрхәлдә, нindidер графоманның фәлән елда туганлыгын белгертүгә караганда файдалырак булыр иде),

фәлән китапның чыгуына фәлән ел димибез, фәлән язучы яки шагыйрьгә фәлән яшь, дибез. Без теге яки бу язучының яна әсәрен укып-тикшерү утырышында яки китап укучылар конференциясендә булдык дию урынына, күбрәк, фәлән язучының юбилеенда яки банкетында булдык, дибез. Юбилей димәктән, аларның иге-чиге юк. Хәер, уртача яше 60 тирәсе булган оешмада юбилейлар күп була инде ул—ел саен йөзәрләп җыеладыр. Шуна өстәп, әдәби мирастан классик әдипләрнен истәлекле даталары (боларын чыннан да әдәбият файдасына дип әйтик)... Ә юбилейлардагы пафосның ниндилеген барыбыз да яхшы белә. Бу ыгы-зыгылы чаралар язучылар коллективының, бигрәк тә оешма аппаратының күпме җегәр-энергиясен ала! Әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт килеп чыга. Ә әсәрләребез турында кайда сөйлибез соң? Газета-журнал битләрендә. Табигый, беренче чиратта, «Казан утлары»нда (китап күзәтүләр, рецензияләр, дискуссияләр һ. б.). Әмма бу гына аз. Әгәр көндәлек матбугатта чыккан материалларны анализласаң, аларның күбесе әлеге дә баягы юбилейлар, премияләргә тәкъдим ителү уңаеннан булыр. Әлбәттә, алар инде мактау, зурлау рухында... Иҗат секцияләрендә дә (хәзер аларны остаханә дип йөртәләр) яңа әсәрләрне укып-тикшереп, анализ ясауга корылган җыелышлар сирәк үтә. Бу остаханәләрнең соңгы еллардагы төп эше теге яки бу авторны Язучылар берлегенә тәкъдим итү булды дип әйтергә ярыйдыр. Дөрес, хәзер хәл беркадәр үзгәрде: каләмдәшләрнең иҗатларына караш җитдиләнә төште. Язучылар үзләре өзлексез йөреп тора. Җыелышлар, конференцияләр, Сабан туйлары, юбилейлар, сайлаулар яки бүтән сәяси вакыйгалар уңаеннан агитбригада рәвешендәге «десант»лар... Чыннан да, хәрәкәт шактый көчле... Теләк бер: бу хәрәкәт, әйткәнебезчә, әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт кенә түгел, конкрет әдәби әсәрләр нисбәтендә, укучыларга, шулай ук язучыларның үзләренә дә кирәк һәм файдалы хәрәкәт булсын иде.

Әйе, татар әдәбияты зур (аны белү өчен Мәскәүгә, Орел яки Воронежга бару хаҗәт түгел), әмма аны дөнья без теләгәнчә танымый әле, дидек. Сүз, мантыйк буенча, үзеннән-үзе әдәби бәйләнешләргә, мирасыбызны пропагандалау мәсьәләләренә кайтып төшә. Алда әйтелгәнчә, үткән гасырның икенче яртысында ул бәйләнешләр шактый нык иде. Соңгы дистә еллар эчендә, һәммәбезгә мәгълүм сәбәпләр аркасында (СССР таркалу, глобализм факторы һ. б.), әдәбиятлар, бигрәк тә, гадәт буенча әйтелә торган милли әдәбиятлар (дөреслектә һәр әдәбият милли) беркадәр изоляциядә, йомылуда калды. Билгеле бер вакыт аралыгы өчен бу хәл дә ярыйдыр. Бай тарихлы, бай мираслы әдәбият берара үзенең асылын ныграк өйрәнә, үзләштерә, үзенең эчке потенциалы хисабына яши ала. (Бу вазгыятьтә тарихи тамыры булмаган «яшь» әдәбиятлар, гадәттә, «киселеп» кала.) Укучылары беркадәр кими төшсә дә, татар әдәбияты, әдәбият буларак, бу елларда әллә ни оттырмады, дип уйлыйм. Кызыксынган укучылар онытылган яки әле монарчы күпләргә бөтенләй мәгълүм булмаган мирас белән таныша алды. Дөрес, бу заманда үзеннең «эч мае»н хисабына гына озак яшәп булмый. Гомумкешелек цивилизациясенә кушылып, бердәм хәрәкәттә катнашып кына, заманча әсәрләр язып, эстетик кыйммәтләр тудырырга мөмкин.

Әйе, әдәбиятыбыз, шөкер, бай әдәбият. Гомумкешелек мәдәнияте мирасына керерлек әсәрләр бар. Теләк җимеше итеп әйтелгән сүз түгел, бу—хакыйкать. Әмма... бу хакыйкатьне беләләрме?—бүтәнчәрәк әйтсәк, дөньяда моны белүчеләр күпме? Кызганыч, күп түгел, һәрхәлдә, без теләгән дәрәҗәдә түгел. Өстәвенә, белүчеләрдән танучылар һәрчак кем чыга бит әле!.. Минемчә, татар әдәбияты тарихын объектив өйрәнү һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Борынгысын әйткән дә юк (аны бармак белән генә санарлык кешеләр яхшы белә булыр), соңгырак чор әдәби мирасны да юньләп белмибез һәм, шуңа күрә дә, әдәбият белемендә моңа кадәрге критерийлар күп сораулар тудыра да. Академик, Татарстан Фәннәр академиясенең элекке президенты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Мансур Хәсәнов байтак еллар элек үк тикмәгә генә мондый сүзләр язып чыкмагандыр: «Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменең, гомумән, татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Аның төп принцибы—фәлсәфи категорияләрне турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятның, сәнгатьнең, кеше рухи эшчәнлегенең мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә

түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып-белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш». Чыннан да, әдәбият тарихы буенча үткән гасыр ахырларына кадәр чыккан хезмәтләрнең абсолют күпчелеге сыйнфый караштан чыгып, социалистик реализм шигаре астында сәяси күрсәтмәләр тәэсирендә теге яки бу идеологик схемаларга туры китереп язылган. Хәзер аларны уку кыен, чөнки алар тарихи анны рәнҗетә, эстетик тоемны боза, чын әдәбияттан биздерә... Ә бит төптән уйласаң, социалистик реализм да, тәнкыйди реализм да уйлап чыгарылган, асылда юк нәрсәләр, дөньяда фәкать бер генә реализм бар: ул—тормыш чынбарлыгы.

Әйе, совет заманындагы ысуллар бик үк ярап бетмәс шул хәзер. Күпмилләтле совет әдәбиятына лаеклы өлеш кертәбез, дигән заманнар үтте. Күпмилләтле Россия әдәбияты дигән сүзләр ишетелми диярлек. Безнең өчен багланышларның иң ышанычлы һәм дәлилле күрсәткече булган тәрҗемә эшенә дә бүген беркадәр бүтән яссылыкта карарга мәҗбүрбез. Элек тәрҗемәләр ике яклы иде: русчадан татарчага, татарчадан русчага. Хәзер күренекле әдәби әсәрләрне татарчага тәржемә итү юк дәрәҗәсендә. (Рус һәм чит ил әдәбияты үрнәкләрен бернічә буын татарча тәржемәдә укып үсте. Бу—факт). Ә татарчадан русчага? Бу процесс әзме-күпме бара әле. Барса да, элеккегечә эффектлы дәрәҗәдә түгел. Чөнки бүген атаклы рус язучыларының яки шагыйрьләренең дә китап тиражлары—2-3 мең данә (тиражлары зур булган детектив жанрындагы бестселлерларны чын әдәбиятка санамыйм). Ә аз санлы халыклар әдәбиятыннан тәржемә үрнәкләренә ни сан? Россиядә яңа Гамзатовларның мәйданга килүе шикле... Димәк, зур дөньяга чыгуның бүтән юлларын эзләргә кала. Рус кириллицасыннан тыш, бу кояш астында бүтән имлялы телләр дә бар. Әйтик, инглиз, гарәп, испан теле... Бар компьютер, интернет теле... Хикмәт—теге яки бу Союзга рәсми елышуда, сәяси лояльлекне белдереп, формаль әгъза булып торуда түгел. Мәгънәви алгарышны конкрет эш-гамәлләр хәл итә. Соңгы елларда республиканың иҗат оешмалары катнашы белән башкарылган байтак күркәм сәхифәләр хәтергә килә. Казанда һәм Ульянда—Кол Гали, Петербургта—Тукай, Оренбургта һәм Мәскәүдә Җәлилнең бюст-һәйкәлләре булдырылды. «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивалендә безнең иҗат төркемнәре, шул исәптән язучылар активрак катнаша башлады. Тәржемә эшләре буенча Россиякүләм киңәшмә уздырылды. Мәскәүдә чыга торган «Дружба народов» журналы белән эшлекле мөнәсәбәт урнаштырылды. «Казан утлары» белән Уфаның «Агыйдел» журналлары алмаш саннар чыгарды... Быел язын Ч. Айтматовның 80 еллык юбилее унае белән Камал театры бинасында онытылмаслык кичә узды... Болар бит киңәюнең, аралашуның күркәм мисаллары, ахыр чиктә, күп көч салынган хезмәт нәтиҗәләре...

Шулай ук бу соңгы дистә еллар эчендә югалтулар да күп булды. Чын мәгънәсендәге классик әдипләребезне югалттык: Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Еники, С. Баттал, Г. Афзал, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, И. Юзеев, Н. Фәттах, Роб. Әхмәтҗанов, М. Әгъләм, Зөлфәт... Кояш астында кайберләренең урыны буш тора сыман... Өстәвенә, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрендә «Фәхрине үтереп ташладылар» дигән шикелле, моннан бер ел элек «Болгар» номерларын җимереп ташладылар... Менә шулай, табышлар югалтулар белән үрелеп бара. Дөрес, республика соңгы 10-15 еллар эчендә икътисади яктан әкияти адымнар белән алга китте. Әмма рухи үсешне икътисади үсеш белән адекват дип әйтеп булмый.

Иң зур проблемаларның берсе, әлбәттә, яшь язучыларны үстерү. Оешманың төп бурычы дип тә әйтеп була моны. 75 ел элек, ягъни Язучылар оешмасы төзелгәч кабул ителгән Уставта да төп маддә итеп язып куелган ул. Яңартылган хәзерге Уставта да шулай. Табигый хәл. Дөнья шулай яратылган, киләчәген—дәвамчыда. Без әдәбиятка килгәндә артта үкчәңә басып килерлек яшьләр бар иде. Хәзер инде аларны яшьләр дип куштырнаклар эчендә генә әйтеп була, үзләре остаз булырлык, 40 яшьне узган ир уртасы кешеләр. Алар артыннан кемнәр килә, кемнәргә өмет баглый алар, кемнәрне нинди традицияләрдә тәрбияли? Татарстан Язучылар оешмасы яшь иҗатчыларны үстерү юнәлешендә байтак эш башкара: яшь язучылар конференцияләре үткәрү, күмәк җыентыклар чыгару («Иделем акчарлагы» һ. б.) районнарда семинарлар оештыру һ. б. Шулай да, реаль вәзгыятькә карап, оештыру эшләрен тагын да колачлырак итү, эш алымнарының яңа ысулларын табу ихтыяҗ икәнлегенә инанасың. Танырга кирәк: соңгы елларда уңай нәтиҗәләр сизелә дә.

Татар әдәбияты дигән зур дәрья турында фикер йөрткәндә, гыйбрәтләр алып, уйланыр нәрсәләр житәрлек. Кайчак шундый сорау да туа: бүгенге әдәбиятыбыз гомумтатар әдәбиятымы, әллә Идел-Урал регионының мәдәни үзәге булган Татарстан әдәбияты гынамы (онытмыйк: заманында яна татар әдәбиятында беренче проза әсәрләрен Ростов, Пенза якларыннан чыккан шәхесләр язган бит. Әйтик, безнекеләр хәзер еш кына баргалап торган Олы Әләзән тормышы татар әдәбиятының берәр сәхифәсе була алмас идеме? Бу җәһәттән, бүтән төбәкләрнең исемнәрен әйтеп узарга була. Түбән Идел—Сарытау, Астрахань.., тоташ Урал—Пермь, Чиләбе, Жаек.., Урта кинлекләр—Рязань, Касыйм...). Без еш кына әдәбиятыбыз берничә гасыр буе, югалган дәүләт институтларының кайбер функцияләрен (мәгърифәт, мәдәният) башкарып килде, дибез. Бу хал хәзер ничек? Милли анны, милли идеяне халыкка житкерүдә язучыларыбызның бердәмлеге бармы (әгәр язучылар, галимнәр арасында, сүз көрәштерүдән бигрәк, бердәмлек булса, имля мәсьәләсендәге дискриминацион хокуксызлыклар килеп чыкмас та иде).

Язмамның баштагы өлешендә сораулы җөмләләрем инде булган иде: әдәбиятыбызның язмышы алга таба ничек булыр? Элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хажәте ни дәрәҗәдә булыр? Алдан ук куелган сорауларым күңелемдә, сөттә йөзгән елан кебек, язмам буе шомлы уй булып барды. Чыннан да, безне ниләр көтә? Әдәбият язмышы белән оешма язмышын да күз алдында тотып әйтүем (оешмасыз да әдәбият бетмәс-бетүен).

Уйланырлык сәбәпләр бар. Язучылар берлеге—ижтимагый оешма. Ә әлегә андый оешмаларның яшәешен билгеләүче уртак бер канун юк. Димәк, юридик хәят—бар белән юк арасында. Бүгенге көндә язучы хезмәтен социаль яктан гарантияләгән законнар юк (шуна күрә дә Россиядә бик күп язучылар фәкыйрьлек дәрәҗәсендә. Бу яктан бездә дә матди яктан иркен яшәгән язучыларны бармак белән генә санарлык). Димәк, хәзерге прагматик яшьләр өчен әдәби ижат өлкәсендә гарантияле тормышчан перспективалар күренеп тормый (шуна күрә дә, бүген шигърияткә Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Жәлилләр урынына, үсмер егетләрдән бигрәк, күбрәк кыз-кыркын килә дә инде). Ә оешма әгъзаларының уртача яше 60. Фәкыйрь карт-корыны кайсы җәмгыятьтә үлеп яраталар икән? Дөрес, бездә Россиянең бүтән регионнары белән чагыштырганда хәлләр әлегә шөкер итәрлек. Әгәр республика булмаса, борынгыдан дәүләт тоткан хисне йөрткән затлы катлам булмаса, татарның ил-көн хәлен тойган Илбашы булмаса, эшләр бик мөшкелгә әйләнер иде.

Хәер, гомумән, нигә мөшкел булырга тиеш ди әле! Талантлы булу фажига булырга тиешме? Талант—Күкләрдән индерелгән илаһи байлык, ил-халык байлыгы, жиһан байлыгы. Без әлегә ил-дәүләтле булудан ваз кичкән халык түгел. Мина калса, бүгенге көндә мең еллык татар әдәбиятының бөек традицияләрен дәвам итәрлек, ким дигәндә биш дистәләп талантлы язучыбыз бар. Бу—зур байлык. Язучы кеше—тел сакчысы. Ә тел—милләтнең төп билгесе. Халык, милләт булып сакланып калырга телибез икән—ижат кешеләренең, шул исәптән заман елъязмачылары—язучыларның кадерен белик! Алар булганда, шөт, нинди генә рәвештә булмасын, ижат оешмасы да яшәр.

...Инде байтак еллар, көн саен диярлек Мөштәри урамында урнашкан Язучылар берлеге бинасы яныннан үтеп-китеп йөрим. Сәер гадәт: үзем дә белештермичә, гәүдәмне төзрәк, башымны югарырак тотып узарга тырышам бу урыннан. Әллә, чыннан да «Язучы горур янгырый» дигән уй жаннан тәнгә күчкәнме?.. Жае чыкканда кергәләп тә чыгам бу бинага. Кермичә үтеп киткәндә, яшермим, каерыла-каерыла карыйм ул йорт ягына. Хәрәкәт бармы? Тәрәзәләрдә кешеләр шәүләсе шәйләнәме? Ишек алдында машиналар торса, уйлап куям—кемнәр килгән? Тимер ажур челтәр эчендәге затлы ишек төбендә таныш йөзләр бармы? Мөгаен, бу гади кызыксыну гына түгел, иң әүвәл—Төп Йортыбызның исән-имин булуына ышанасы килү теләгедер ул. Начар теләк түгел бит. Яшәсен Уртак Йортыбыз!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*шәрәфле академигы.*

## МУСА ҖӘЛИЛ
*(1906–1944)*

### Бер үгет

**Мин күп күрдем филдәй кешеләрне,**
**Киң күкрәкле, тимер бәдәнле,**
**Тик күрәсе иде эше белән**
**Кеше булган иң чын адәмне.**

**Кем сокланмас көчкә, тимер сынса**
**Һәм су чыкса баскан эзеңнән.**
**Тик ни файда, көчең филдәй булып,**
**Эшең булса чыпчык тезеннән.**

**Эзе калсын керсез намусыңның,**
**Ни үтсә дә синең кулыңнан,**
**Көчлелегең белән горурланма!**
**Кешелегең белән горурлан!**

**Һәр адымыңда синең туры акыл,**
**Көчле йөрәк эзен күрсеннәр,**
**Кылыч белән түгел, турылык һәм**
**Чынлык белән көчле кешеләр.**

**Син яшәмә җирдә файдасыз бер**
**Түмгәк булып тигез урында.**
**Янып калсын гомрең маяк булып,**
**Үзеңнән соң килгән буынга.**

**Утта булган балчык кире купмас,**
**Эштә булган тимер тутыкмас.**
**Эш күрсәткән ирне ил онытмас,**
**Каберенә эзне суытмас.**

*1943*

## ФАТИХ КӘРИМ
*(1909–1945)*

* * *

**Сөйләр сүзләр бик күп алар,**
**Иренмичә сөйләсәң;**
**Озын сүзнең кыскасы шул:**
**Күп яшәргә теләсәң,**

**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла,**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

*1944*

# ХӘСӘН ТУФАН
*(1900–1981)*

## Сәлам әйтегез

Көннәр һаман җилле дә давыллый,
Урман шаулый, Идел моңлана...
Бәхилләшкән сыман баш иям мин
Дулкынланган яшьлек дөньяма.

Үзем монда—сездә, ял йортында,
Күңел ләкин читтән, еракта—
Кайларгадыр илткән юл чатыннан
Күз сала күк безнең бу чакка.

Хәлне сорап, җанны сыйпап китә
Уйга калган иске танышлар,—
Сүзләрендә—серле саубуллашу,
Күзләрендә—яшерен сагышлар.

Нидер тоя күңел, нидер юрый,
Юраганы, бәлки, юш булыр:
Хушлашырбыз... Бәлки, бик озакка
Мин утырган урын буш булыр.

Кайчан булса исегезгә төшеп
Безнең шушы көзге җәебез,
Сездә берәр сагыну хисе туса,
Миннән аңа сәлам әйтегез.

Көннәр җилле, төннәр өермәле,
Урман шаулый, Идел шомлана...
Ерактагы юллар ташына басып,
Кул изим күк иркен дөньяма.

*1940*

# СИБГАТ ХӘКИМ
*(1911–1986)*

* * *

Бер татарда ничә йөзләп шагыйрь,
Һәр шагыйрьне истә тот аерым,
Кайта идем уйлап мин шуларга
Йогынтысын бөек Тукайның,

Яшен кырны яктыртты шул вакыт,
Күренеп китте юлда ат кабат,
Күренеп китте басу уртасында
Карт карама белән карт нарат.

Яшен кырны яктыртты берьюлы,
Менә, дидем, читен мәсьәлә,
Кайсына соң күбрәк төште якты?
Карамага? Атка? Нәрсәгә?

Яшен кырны яктыртты бертигез,
Бер кыр—бер чор кинәт гөлт итте,
Күз алдында җир яшәреп китте,
Берсен-берсе узышып гөл китте.

*1978*

Айдар
Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

## III

Таң алдыннан ярышып-ярышып кычкырган әтәч тавышларына уянган иде ул. Шулкадәр дә арыткан, шулкадәр дә басылып йоклаган ки, Иркен-ага беравык үзенең кайда икәнен исли алмый ятты. Үзенең тарихи туган авылы Кизләүдә икәнлеген, бу көмеш быргы кычкырткан әтәчләр дә туган Кизләү әтәчләре, аның яткан-йоклаган түшәге дә туган җир түшәге икәнлеге исенә төшкәч, кичәге вакыйгаларны башыннан кичереп, җылы юрганы астында бераз иркәләнеп, назланып ятты. Әйе, аларның автосын тартып килгән урыс, рәхмәт төшкере, аларны авыл башына кадәр китерде, тик урамнан Сихәт-сылулар йортына ук үтәлмәгәч, кайтып китте.

Кизләү урамнары һич кенә дә Тау Иленекеннән ким ергаланмаган икән. Алар күзгә төртсәң күренмәс төн карасында Сихәт-сылу артыннан кулларындагы саквояж-арбалары белән коймаларга асылына-асылына, сикерә-атлый, кайда бата-чума, тәмам шүрәле рәвешенә кереп, көч-хәл белән килеп егылдылар. Сихәт-сылуның ата-анасы җан рәхәте кешеләр булып чыкты.

Сәбах намазына аны әтәчләр уяткан икән бит. Кана, никадәр кыска монда төн!.. Йокларга дип яткан иде—инде торырга да кирәк. Хәтеренә һаман да шул тарихи Ватанына ислам дине алып килгән гарәп сәяхәтчесе Ибн Фадлан килде. Ул да һиҗрәтче, ул да мөһаҗир бит!.. Әгәр Иркен һәм аның нәселе бередән куылып киткән мөһаҗир булса, Ибн Фадлан ислам хакына Болгарга һиҗрәт кыйлган мөһаҗир буладыр. Сәяхәтнамәнең инглизидәге нөсхәсен ул Вашингтонның Конгресс китапханәсендә укыган иде. Текст әле яна гына укыган кебек хәтердә саклана: «Болгарда төннең кыскалыгы шулкадәр ки, ашар аш ахшам вакытында салынса—сәбах намазы шул аш пешеп чыкканчы укылырга тиеш болады...» Әйе, Ибн Фадлан Болгарда төннең иң кыска, көннең иң озын көннәрендә—июньдә булган да шул!..

---

*Дәвамы. Башы 9нчы санда.*

Сихәт үзе дә, анын ата-аналары да намазлы түгел икән.

Сиздермәскә тырышып, аяк очларына гына басып, кичтән хәстәрләп куелган комганын эләктереп тышка чыкты. Туган якнын барлык исән калган кошлары, хәтта ки бөҗәкләре сайрый иде. Шәйхенур кардәш ишекләренен эчтәгесе дә, тыштагысы да шыгыр-шыгыр килеп җырлый икән. Майлыйсы булыр.

Намазыннан сон, җаны да, тәне дә пакъләнгән Иркен ага сабый йокысы белән янадан йоклап киткән.

Ул аягынын сызып сызлавына уянды. «Көч килгән, күрәсен. Мунчада кайнар себерке буында тотканда яхшы булыр иде дә бит». Баш очындагы караватта—үзе күренми—ана шулай ук башын куеп, кем әйтмешли, башкабаш, балаларча мышный-мышный Рәгыйбь йоклый. Алик идәндәге түшәктә сүнеп калган. Торырга вакыттыр. Нәрсәдән башларга? Алмаш киемнәрен саквояждан чыгарасы булыр. Тәрәзәләрдә кояш балкый икән. Көн матур булачак. Кояш гүя анын күнеленнән чыккан иде. Тизрәк аягына басасы һәм беренче тапкыр туган яктагы Туган Кояшына турыдан-туры, тутырып карыйсы килеп китте...

Урам ягындагы тәрәзәләрдә кеше-фәлән күренми. Өйнен алгы ягында гына нәрсәдер гөжгелдәп яна, богыр-богыр кайный, ир белән хатыннын лабыр-лобыр килеп сөйләшкәне ишетелә. Торырга вакыт. Торырга кирәк. Тор, әфәндем. Шулай үз-үзе белән сөйләшә-сөйләшә яткан җиреннән артыш таягын сузылып алды һәм тавыш-тынсыз гына урыныннан күтәрелде. Беренче итеп күргән нәрсәсе—кичә юлда кешегә күренә алмаслык шакшы хәлгә килгән, ә хәзер инде юыласы юылып, үтүкләнәсе үтүкләнеп, күренеп торсын өчен шифоньернын ярымачык ишегенә эленеп куелган костюмчалбары, күлмәге булды. Икенче ишеккә Рәгыйбьнен шулай ук юылган һәм үтүкләнгән өс-башы эленгән иде. Аннан эчтәрәк Шәйхенурнын күкрәге орден-медальләр белән тулган пинжәге күзгә чалынды. Бу Сихәт-сылунын эше иде. «Кардәшем сугышта катнашкан микәнни?—Иркен-аганын башына нидер суккандай булды.—Болай булгач, катнашкан гына түгел, күкрәген орден белән тутырырлык каһарманлыклар кылган, димәк? Бәлки, сөйләр әле.»

Менә Рәгыйбь кардәше дә уянды. Кәефе яхшы иде. Эшен тиз тота торган зат икән.Сикереп тә торды, спорт трикосын киеп, юл капчыгыннан берсе зәңгәр, берсе яшел төстәге чәнечкеле «кытай энәләре»н чыгарды һәм йөзен дә чытмыйча энәләр өстенә ятты:

—Бу кытайлар уйлап таба бит, әй!.. Тормышымда мин шушы энәләрдә генә ләззәт алам, Иркен-ага...Китап ташудан түгел, нервылардан бил өзелә!..

Иркен-ага Рәгыйбь өчен куанып елмайды һәм диварларга игътибар итте. Алар рам эчләренә куелган фотосурәтләр белән чуарлаган иде. Урам як диварында, уртада, Шәйхенурнын буденновкадагы хәрби сурәте һәм хуҗабикәнен кыз чагындагы сурәте бергә зурайтып куелган иде...

Киенгән арада Рәгыйбь ихатанын сул почмагында, алмалары белән авыраеп утырган алмагачлар артыннан күккә ап-ак сүс аркан булып суырылып күтәрелгән төтенгә күрсәтте:

—Менә чын татар хатыны!.. Мунчасы да ягылган!..

—Синен бәхеткә, кардәшем!—диде Иркен-ага кеткелдәп.—Син хатынсыз, ул ирсез бугай... Өйләнеп җибәр, мин кияү егете булаемчы!..

—Сез тагын бигрәк!.. Эрләмәгән-сукмаган...—Рәгыйбь Иркен-аганы тартып китереп, колагына пышын-пышын сөйләп алды.—Белеп торыгыз дип кенә... Кичә колак очым белән генә ишетеп калдым. Сихәтнен улы биредә, дәү әтиләрендә яшәгән булган икән... Менә биш көн инде егетнен

эзе югалган, ди...

—Кит аннан?! Милисигә мөрәҗәгать иттеләр микән?

—Юк , ди. Сәбәбе бар, диде карт. Сихәт белән бу темага бөтенләй сүз кузгатырга кушмады...

Иркен ага «Ярар!» дигәнне анлатып баш какты да өстәде:

—Син дә...авызынны ачып йөремә, шундый кәмпер[1] барда тот та башлыкүзле булсаңчы!—дип тагын күзен кысты.—Сонлама!.. Өйлән дә куй!

—Фатыйр юк!.. Зимагурлар ятагының идәнендә йоклыйм!..

—Кәмпер дә бала кеби, үз ризыгы, малы белән киләдер күǃ..

Иркен-агага Рәгыйбь кардәше белән сөйләшүе бик күнелле иде. Ул әдәбиятны, бигрәк тә урыс әдәбиятын яхшы белә. Зур язучылары турында сүз киткәч:

—Аларнын дүрт бөек шагыйрь-язучылары бар,—диде ул кистереп.—Некрасов, Толстой, Чехов, безнең көннәрдә—Виктор Астафьев.

—Ә Пушкин?

—Ул урыс шагыйре түгел. Артык француз. Мин аны анламыйм.

—Ә Достоевский? Әмрикәдә иң күп укылган урыс язучысы...

—Достоевскийга аерым исәп. Шактый кара йөрәкле булса да, ул аларның бөекләреннән бөеге. Шулай да урыс әдәбиятының төп герое Раскольников та, кенәз Мышкин да, Базаров та, Печорин да түгел...

—Кем?

—Чичиков. Гогольнең Чичиковы. Ул дөньяга урыснын ришвәткә корылган чынбарлыгын Чичиков аша ачып бирде...

Алар бер-бер артлы ишекләрне җырлатып, алгы якка чыктылар.

—Майлар иден, ичмасам!—диде хатын-кыз эчке яктан.—Бигрәк шыгырдыйлар...

—Җырласыннар, карчык, алар арасында да үзләренен Илһам Шакировлары бар бит!—дип кеткелдәде алгы якта Шәйхенур.—Мина ишек майлау вак нәрсә ул, карчык. Син менә нәрсә эшлә: нәзекәй генә бармагыңның башы белән генә ялмап, син аларга атланмай сөрт.. Һәрнәрсә майлаганны ярата... Менә, безнең кебек...—Арты белән баскан Шәйхенур чүпрәгеннән кадерләп кенә сүтеп, бер ярты ак аракыны өстәлгә куеп маташа иде.

—Хәерле иртә, кунаклар! Яхшы йокладыгызмы?—диде ул тегеләрне абайлап.—Сыер мөгрәүләре, тычкан кыштырдаулары, авылдагы сәтсиәлистик ярышның башка мыштырдаулары йокыгызны бүлмәдеме?

Алгы якта бөтенләй дә кояш туплавы иде. Ике тәрәзә аша бәрәнге бакчасы, чыгырлы кое, анын баганасына эленгән зу-у-ур кояш һәм печән эскерте күренде. Аларны тәмле аш, ит—Иркен-агага әле Шәркый Төркестандагы Кизләүдә әнкәсе пешергән мал эчәгесеннән пешерелгән вак бәлеш исләре каршылады. Кичә төнлә көрешкән булсалар да, алар хужа белән янадан мөселманча ике кул биреп күрештеләр. Шәйхенур, күрер күзгә алтмыш өстенә чыккан һәм, авыл жирендә үз көче белән яшәп, иске әләм кебек шактый иләнгән, калай кашык кебек ябык, гәүдәсе белән изелгән-тапталган күренсә дә, әле шактый җегәрле вә көчле иде. Каш өсләренә көлтә-көлтә булып ишелеп төшкән, әле чалара да башламаган, әмма алдагы бер учмасы тумыштан ак булган коңгырт чәчле, зәп-зәнгәр күзле, туры таза борынлы, маңгаендагы җыерчыклары дугалар ясап, инде авыз-борын тирәләрен дә уратып алган бу инсан бик теремек, бер урында озак басып тора алмый иде. Ул , кулына ак сөлгесен тотып, кунакларны мич арасындагы юынгычта шалдыр-шолдыр китереп юындырганда галдыр-голдыр сөйләнде:

[1] Кәмпер (үзбәк) — хатын.

—Сыер малы тотабыз... Минекеләр менә, Аллага шөкер, икәү... Безнен пенсия—сыер имчәгендә. Керәстиәнгә малсыз—дөнья сансыз... Труд крипәстнуй булса да, тап син выход запаснуй, әйбит. Дамкратлар[2] влачка килгәч, колхозның бар малы талангач, авылда бернәрсә дә калмас кебек иде... Калды, әтнәке, ике күрсәтер нәрсә калды авылда—зират һәм чучка күмпликсе... Шулар аркасында авылны крыса басты... Ана чучкалар артыннан зиратка кереп, каберләрне чокый башлаган иде, имансызлар... Хәзер инде керәлмиләр, ничөн дисәгез, ничөн дисәгез... прусты керәлми. Борынгы бабаларыбыз ураткан ташкойма урыны-урыны белән ишелгән иде, янадан өйдек, былтыр хакимият тагын бер тапкыр чәнечкеле тимер чыбык белән уратты... Чучкаларга хут бетте...Кем әйтмешли, хәзер каберлеккә якын барып та, аннан чыгып таеп та булмый...

Җәмәгате Тәрбия ханым, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, такта белән яртылаш кына бүленгән аш-су бүлмәсеннән килеп чыкты һәм менә хәзер елап җибәрердәй йомшак, хиссияти йөз сурәтендә коңгырт күзләре карашын кешенең күкрәк тирәсеннән югарырак йөретмичә, санаулы гына сүзләр әйтеп исәнләште һәм гөжгелдәп газ янган бүлмәчегенә кереп китте.

«Тәрбия... Нинди матур исем. Тегесе Тәбрия иде. Монысы Тәрбия. Бер генә аваз. Әмма икесе дә нинди зур мәгънәгә ия. Тәрбиягә ярдәмгә табигый газ кергән икән»,—дип куанып куйды Иркен-ага.

Шәйхенур-кардәш кунакларын иңендәге тастымалы белән сөртендерә-сөртендерә мич арасыннан алып чыгып, тагын да иркенләп сөйләнә генә башлаган иде, хатынының табак тулы леркелдәп пешкән ит, тәлинкәләрдә кайнар аш та чыгара башлавын күргәч шымып калды.

—Җә, кунакларны утырт, әтисе. Иртән ир-атка аш та зыян итмәс. Итенне тураштыргала...

Шәйхенур кунакларны аш өстәленә чакырды.

—Әйдәгез, бары белән житешегез әле..—Ул эшенең рәтен белеп, вәкарь белән генә итне турый башлады.

—Сарык чалган идем...Сезгә насыйп булган. «Ит тураган—табыштыр, аннан-моннан кабыштыр», дигәндәй, башта үзем кабыйм әле, дип кечкенә үткер чалгы пычагы белән калҗаны кыеп кына алды да кабып җибәрде.—Шулай тиеш. Кунакларның әппититен китерү өчен, димәк...

Ул зур-зур калҗаларны, майлы кабыргаларны аеры-аеры бүлгәләп кунакларның тәлинкәләренә өләште.

—Житешегез әле!..

Күпмедер вакыт бүлмәдә тәлинкә-кашык, ашаган тавышлар гына ишетелеп торды.

—Бәй, карт шайтан, онытып ук торам, ләбаса!—Ул башкаларны үпкәләтмәдем микән, дигән кыяфәт белән тирә-якны күзеннән үткәреп чыкты да, һаман да шул сөйләнә-сөйләнә, бәллүрләргә аракы коя башлады.—Элеккеге авыл юк ул... Үлде ул. Прощай шулпасын эчәбез, әйбит?.. Ут-күрше дигән төшенчә бетте...Йомышка керү юк... Утка керү дә, чуртка керү дә юк... Хәл белеп керү юк. Кунакка, ашка чакыру юк... Утырып еларга калды. Кем әйтмешли, борынына борып тыккысыз кара туфрак—иген үстерергә кеше юк, әйбит. Менә шушы калды...—Ул тагын гаепсез кеткелдәп шешәгә күрсәтте.—Бердәнбер бәйрәм—туган көн калды—бүген минеке, иртәгә—синеке, әйбит. Кайберләребез елына дүртәр-бишәр туган көн үткәрә. Гәзит-журналга язылып булмый—акча юк. Китап алыр идек—акча юк. Менә шушы сикс-микс-сникерс тилевизыр гына калды. Кайбер ихаталарда икешәр-өчәр, хәтта бәдрәф почмакларына да телевизор

[2] «Демократ» дигән латин сүзенең бозылып әйтелеше.

куйганнар. Шуна карап чукыналар. Мин үзем сирәк карыйм аны...

—Ну-ка!.. Һоп!...—Ул уйнаклап торган идән сайгагына калушалы аягы белән типте.

Сайгакның теге очындагы телевизор, урынында калтыранып куйды да кабынды. Эфирдан томан эчендә кайнашып, ниндидер реклама бара иде.

—Безнең монда, чокырда, биек мачталар, антенналар булмагач, әлҗе-мелҗе генә күрсәтә шул.. Сукыраеп бетәбез инде. Ә нишләргә, өйрәт!.. Мәктәптә күзлек кимәгән бала да юк, диләр...—Ул тагын идән сайгагына типте, телевизор тагын калтыранып куйды да сүнде.—Менә шулай тыңлаучан бала ул минем еле-визорым... Хи-хи-хи... Әйдәгез әле, берне тотып куйыйк!..—Ул бәллүрен күтәреп, кунакларга таба омтылды.—Әйдәгез, очрашу, танышу-күрешү хакына!..

—Мин эчмим,—диде Иркен-ага шундый хуҗалыкчан Шәйхенур белән йөреп торган идән сайгакларын рәттән куя алмыйча.—Авызыма да алганым юк.

—Мин дә эчмим,—диде Рәгыйбь.

—Сез... нәрсә? Сөйләшеп куйдыгыз мәллә?!—Сезне мин... тагын ничекләр кунак итим, җәм-мә-гать?! Минем башка кунак итәр азыгым юк.—Шәйхенурның күзләре түшәмгә менде дә, аннан янадан кунакларга күчте.—Әнкәсе, болар—дистиллированный халык, эчмиләр!... Сез эчмәгәч, мин берүзем эчеп утыра алмыйм бит инде...Юк, алай итмик әле, бергә утырган хәтердә калсын әле, әйбит? Әйдәгез әле, әйдәгез... Әнкәсе, кил, сыйлаш!..Телисез икән, җырлап, телисез икән...—Ул каяндыр өстәл астыннан ике рәтле гармунын тартып чыгарды һәм «Сарман»ның бер генә буынын чәлдердәтеп алды да, янадан урынына куйды.—... телисез икән, Әмерикәләрдән үк килгән сөекле кунакларым хакына биеп тә күрсәтәм!..

—Мин Америкадан түгел лә..—диде Рәгыйбь.

—Әмерикәнисне озатып йөрегәч, син дә әмерикәнис инде! Хи-хи-хи!.. Эчмисезме? Димәк, эчмисең?—Ул Иркен-агага бармагы белән төбәде.—Син дә эчмисеңме?—Ул бармагын инде Рәгыйбькә төбәде.—Сез эчмәгәч, үзем эчәм!.. Был-ла ни был-ла!—Шәйхенур кулын гусарларча терсәкләреннән сындырды һәм бәллүрен авызына китерде.—Ярый, исәнлеккә!... Мин, едрит-күдрит, алган хатынны аера, салган аракыны кире шешәгә коя торганнардан түгел!..

—Авылдагы тормыш аманмы, дисез. Аманы аман ла ул, тик кесә ягы яман... Менә икенче ел инде колхоз акча бирми... Алты ай пинсә алган юк. Акчабыз юк, әмма үзебез тук, күзебез ач... Күп кенә шәһәрләрдә дә булмаган мәдәният йортыбыз бар иде.. Өч катлы, утыз өч бүлмәле... Биллиард, баян, әркистр... Ельцин домкратиясе килгәч электр куыгына кадәр талап бетерделәр, едрит-күдрит! Дүрт авылдан торган колхозыбыз икегә бүленгән иде... Сигез мең баш сарыктан бер сарык, алты мең баш тавыктан бер тавык, биш йөз баш ана куяннан бер ана куян... яшелчә бакчасы—бернәрсә калмады! Ике колхозның берсе фермаларны үзләренә аласы килмәде, малай! Бәй, фермада эш күп!.. Сарык йонын акча иткәнче күпме ызаланырга кирәк, әйбит? Ташландык биналары гына череп утыра... Һәр хуҗалык җитәкчесе ат, сыер малын үзләренә җитәрлек кенә калдырып, калганнарын иткә озатты. Акчасын кесәсенә салды да мал асраудан туктады...

—Әтисе, телеңә салынма, кунакларыңа ризыкларны кайнар килеш авыз иттер!

—Беләм мин анысын гына!—Шәйхенур кардәш шыпырт кына тагын бер бәллүрне йомдырды да бармакларын уйнатып алды.—Бүтән ни-ни!.. Әмерикәнен үзеннән үк дәрья кичеп килгән ир-егетләрнең бер генә минут вакытын да бушка сарыф итәсем килми, әнисе... Якташ шагыйребез Шәйхи

Маннурның Гайжан бабасы кебек чәемне суытканчы сөйлисем килә... Хәзер колхозның өчтән бер чәчүлек жире чәчелми ята. Аның каравы, чәчүлек кимегән саен уңышлары арта, имеш. Гектарыннан сиксәнгә житеп баралар инде. Кәгазьдә... Чәчүлек гектар кимегән саен кәгазьдәге уңышны арттыра баралар, үләт. Хужаларыбыз өч мең баш сыер малыннан үзләренә иткә, сөткә, майга житәрлек 150 баш сыер, ике мең баш танадан 180 баш кына тана калдырды да, куштаннардан әрмия ясап, чучка кумплексе өчен сәнәк сугышы оештырды... Бер ел буе сәнәк тотып чучка кумпликсе өчен абарунда яттык!.. Авылда атлар калмады!...—Шәйхенурның тавышы өзелде, ул күзләрен челт-челт йомып, нәрсәдер әйтергә итте.—Шулар аркасында... минем оныкларым Биарыслан белән Хәбибнажар... Әй-й, сөйләсәң сүз, төртсән—күз инде ул, едрит-кудрит!..

—Чучка итендә житмеш жиде зарарлы дегенерат матдә бар...Ул таптаган, нәжесләгән туфракта иген дә, үлән дә үсми... Коръән аны мөселман өммәтенә юкка гына тыймаган...—дип кыстырып куйды сүз арасына Рәгыйбь.

—Анысы шулайдыр аның, энекәш... Әмма китергән акчасында син әйткән дегенерат юк аның . Акчасы чиста!.. Бүген авыл шуның белән яши... Ә чучкага нәрсә? Ул беркемне татарга-урыска аермый... Чучка мырык-мырык килеп тирес ашый, безгә саф алтын ташый... Алты ай саен егермешәр бала имезә, менә сиңа дегенерат!.. Бездә, Татарстанда, иң кадерле мал ул. Ул, безнең Татарстан, Гитлер кәнсәләренә беренче байракны элгән абзыебыз Газый Заһитов хакына урам исеме бирмәсә дә, мырыкбашлар хакына исем бирә, әйбит. Мырыкбаш-Моркваш дигән пачулкабыз да бар бит әле.. Миндә дә бар алар. Ике баш ана-чучка... Без бит мырыкбашлар кумпликсе өчен сәнәк сугышында жинеп чыктык. Кумпликс—бездә!.. Әле генә туктады бу кайнар сугыш... Чучка безгә эләккән өчен үпкәләгән Ишкиләр безне үзләренә кертми—урап үтәбез! Сөйләп китсәң, бүгенге авыл кызык инде ул... Син үзең... авылданмы соң?

—Әйе,—Рәгыйбь башын кагып, елмайды.—Юньле кешеләр авылдан булмый, каян булсын.

—Димәк,син авыл дигән үлемсез жанны аңлыйсың булыр.

—Үлемсез иде дә бит. Хәзер үлеп ята. Авылыгыз зурмы?

—Заманында ике йөз йортка житкән. Хәзер йөз илле чамасы. Йөзесендә, караңгы төшкәч, мезелдәп булса да ут яна... Калганнарына жәй житкәч, шәһәрләрдән «абика-бабайкаларын» ияртеп, дачниклар кайта... Ике бай татарның бетереп житкермәгән кәттиҗләре бар. Йөзгә якын пенсионер. Утыз жиде хатын алмый картайган ир заты, илле-алтмыш кияү күрми картайган түткиләр... Авылда күкрәк ташларын иркәләрлек кызлар да калмады, әйбит, карчык?

—Кит, юләр, әллә нәрсә сөйләп утырасың!... Килешмәгәнне... Кайчакта артыгын ычкындырасың, әтисе!..

—Бәй, шулай булгач, нишләтим? Һәм шул пенсионерлар арасында без алтмыш биш яшьлек яшь жегет белән яшь кыз—Шәйхенур Галимжанович галиҗәнапләре һәм Тәрбия Галижәнәбия торып калдык. Әйбит, карчык!..

Шулчак болдырда нәрсәдер дөбердәде, тагын да шул жырлый биреп, өй ишеге ачылды, аннан жиңелчә киенгән, бит алмалары алсуланып, чокырланып торган Сихәт-сылу килеп керде. Күлмәге өстенән чәчкәле алъяпкыч та киеп жибәргән Сихәт-сылу белән бергә өйнең алгы ягына кояш үзе дә кергәндәй булды. Әмма, игътибар итсәң, аның тирән уй-сагышта булуын һәм бу уйны актив хәрәкәт, нindидер ясалма тереклек белән капларга, жанындагы борчылуын ничек булса да сиздермәскә тырышуын аңлау кыен түгел иде. «Улы турында безгә сиздерер микән?»—дип уйлап куйды Иркен-ага.

—Менә, ичмасам, өлгерләр!.. Әткәй, маладиссың да инде!.. Чынлап та шартына китереп кунак ит, тик арттырып та ташлама!.. Берәр сәгатьтән мунча да өлгерә!...

—Кызым, шулаен шулайдыр, әмма алар.. теге... мине кат-тегрич-чески тынламыйлар бит әле... Әллә үзең сыйлап карыйсыңмы?—Ул кызына бәллүр сузды.

—Син, әткәй, бигрәк инде... Мине кунакларга бер эчкән кеше кебек тасвирлыйсың... Син сындыра алмагач, мин аларны ничек сындырыйм?

«Сирәк сүзләр куллана...Укытучы булмак кирәк...»

—Сихәт-сылу, кул-аякларыңыз сырхаусыз булсын!.. Кылган догаларыбыз сезнең теләкләрегезгә юлдаш булсачы. Төн йокыларыгызны кызганмыйча, кием-салымнарыбызны юып...

—Иркен-ага, бу бит хатын-кызның бурычы!.. Әгәр мөмкин булса, мин сезнең авылдагы программагыз буенча кинәшергә иде...—Әнисе белән икәүләп алгы якка вак бәлеш, гөбәдия, тәмле-тәмле чәкчәк, карлыган, куражиләк кайнатмалары ташыган арада Сихәт-сылу сүзен дәвам итте.—Ашап утырыгыз әле!.. Көн бик матур булмакчы, сез мунча кереп чыкканчы яңгырда җипшегән урамыбыз да кипшенер, Алла боерса. Әй, әйтергә онытып торам икән. Мәктәпне урап килгән идем. Сездән рөхсәт тә алмый торып, көндезге сәгать икегә балалар белән очрашу тәгаенләдем. Мин менә шундый диктатор инде ул!...—Сихәт-сылу үзе дә мәктәп кыңгыравы кебек зеңгелдәп көлеп җибәрде.—И-и-и, куандылар, и-и, куандылар!... Америкадан кайткан дигәнгә ышанмыйлар!..

—Хуп, мәйле[3],—диде Иркен-ага.—Килештек.

—Мин ни өчен шулай кызу тоттым?—диде Сихәт-сылу гафу үтенгәндәй.—Бәлки бу очрашу кардәшләрегезне эзләп табуны тизләтер, дип уйладым.

Иркен-ага көтелмәгән шатлык шаукымыннан тетрәнү кичерде. Күзләреннән пылт итеп яшь чыкты. Туган авылы мәктәбендә очрашу. Хакмы бу? Төш түгелме бу?

Агасының бу халәтен яхшы аңлаган Рәгыйбь башкаларның игътибарын Иркен-агадан читкә юнәлтү ниятеннән табакка үрелде, вак бәлешләр алып Иркен-ага алдындагы җамаякларга салды да, Шәйхенурдан сорап куйды:

—Мәчетегез бармы соң?

—Кирпечтән бинасы бар барлыкка... Минем улым төзетә иде аны, рәхмәт төшкере... Тик менә мәсьәлә килеп чыкты бит әле...—Шәйхенур нәрсә килеп чыгуын әйтергә теләмәде, ахрысы, фикерендә бераз тотлыгып торды да, дәвам итте.—Иске мәчетне утызынчы елларда клуб иткәннәрие... Сиксәненче елларда яңа клуб житкердек тә, искесеннән чучка күмпликсендә малчылар йорты ясадык...

—Алай икән. Исем кушарга, китүчеләрне озатып, женаза укырга мулла-имам кебек кешегез бармы?

—Чаллының «Йолдыз» мәдрәсәсендә әллә нишләп һаман да кырынырлык мыегы чыкмаган бер егетебез йөрештергән була, әйбит. Үзе дә наркоматка (бу аның наркоман дигәне икән) әйләнеп, Төркиягә чыгып качмаса. Кайта да, эчәсез дип бәйләнә. Эчмәсәң, тормышы бармый, эчсәң—зиһенең кими, әйбит?

Шәйхенур белән сөйләшүе ифрат та җинел һәм уңайлы иде. Бу шартлылык хәтта Иркен-аганың тизрәк урам-җир күрергә чыгу теләген дә баскандай итте.

—Бездә әлегә кадәр юньле-рәтле мәхәллә дә төзелмәгән. Хәзер бит район саен бер мөфтият, дигәндәй. Кемгә буйсынырга, кая барып бәрелергә белмибез. Ә-әй, алып куй әле монау нәрсәңне! Иркенәеп сөйләп тә булмый,

[3] Мәйле (үзбәк-уйгыр.) — ярар,килештек.

ялгыштыра, шайтан!—дигән булды Шәйхенур суган суфыена әверелеп һәм шешәсен, шалтыр-шолтыр китереп, бәллүрләрен дә Тәрбиясенә сузды.— Без, авыл картлары, егерме ике кешедән торган мәхәллә кораштырып маташканыек, әйбит. Яртыбыз яна оешкан Казан мөфтие Госман хәзрәткә, яртыбыз Уфа мөфтие Тәлгать Тажетдингә буйсыну ягында...

—Ә нигә яртысы.... бөтенегез дә түгел?

—Һи-и, әкәмәт бәндә син. Татар бөтен булалмый.

—Ул чакта кемдер... буйсынмаска тиеш була бит. Ә нигә... буйсынырга?

Бераз төшереп алган Шәйхенур ирекне сөя һәм иректән курка да иде.

—Буйсынмыйча... кәк же инәче? Безнең халык аерымланып буйсынырга өйрәнгән. Буйсынмасак—күнелсез, әйбит. «Мәскәүдән шулай куелган мәхәлләдәге хәлләр», дип жырлыйм мин аны. Мәхәллә бирүләрен сорап, Уфа юлына тузан да төшермиләр, әмма Мәскәү мөфтие белән бер дә борчагы пешмәгән руханилар ни сәбәпледер сузалар. Әле кичә дә Уфадан буш кул белән кайтканнар.

Мосафирлар Тәрбия ханым пешергән вак бәлеш, әче кабартмалар белән кинәнеп туклык иттеләр. Иркен-аганың әле генә аерткан сыек каймакка манып-манып, мондый чын кабартмаларны күпме гомер ашаганы юк иде икән? Дөрес, Мәдинә-иркәсе пешергәләгән була әче кабартма, ләкин ул Висконсин тупрагында бу кадәр тәмле булалмый. Мәсьәлә, күрәсен, судадыр. Шул судагы көмештәдер, алтындадыр. Хуш исле кайнатмалар, татлы гөбәдияләр, чәкчәк, бавырсаклардан авыз иттеләр. Куян каны кебек куе кызгылт чәй, ана әле генә савылган куе сөт тә салынгач, бөтенләй үк йөзе килгәндәй, кызарып агарынды. Чәй ифрат та тәмле, эчкән саен эчәсен китереп, үсендерә иде. Кунакларның йөзләренә генә түгел, лепкәләренә кадәре тирләде.

—Суларыгыз бигрәк тәмле. Каян аласыз?—дип сорап куйды Иркен ага.

—Кизләү чишмәсеннән торба белән төшә,—диде эчке яктан Тәбрия ханым.—Суларыбыз бик тә шифалы. Кизләү-чишмәбез Чөкәймә таудан бәреп чыга. Колхозны бүлешеп беткәч, яна рәисебез аны үз хуты белән чучка комплексенә төшертте...

—Ничек үз хуты белән? Чишмәгез шулай күчеп йөримени?—диде Рәгыйбь.

—Син нәрсә? Торбага куып кертте дә, чишмәгә дәвлинжә өстәде. Хәзер чишмәбез шул дәвлинжәсе белән йөгереп чучкаларга үзе төшә! Шул түбәнгә йөгергән сулардан авылга да өлеш чыга...—диде Шәйхенур.—Их, бер генә тапкыр гармун уйнап алсам?

—Әти, иртә белән гармун уйнау килешми.

—Шулайдыр шул. Сонрак, әйеме? Башка вакытта. Биарысланнар табылгач, әйеме?

Өйгә шакып-нитеп тормыйча антрацит күмере кебек кара кеше килеп керде. Кырыс кына исәнләште дә, шундук мәсьәләсенә керешге:

—Нәрсә, Шәйхенур абзый, минем белән пайга керәсенме, юкмы? Йөз гектар жирем бар, тагын да йөз гектар алабыз...

—Юк, Корбангали,—диде Шәйхенур.—Мин ирекле. Синен белән мин жә мироед, жә кулак булам. Минем кулак буласым килми...

—Әнә, калхуздан качкан атларның берсе... калхуз утарында калган сыерның берсе синеке бит. Аны утызынчы еллар башында синен бабаңнан тартып алганнарие, шулаймы?..

—Шулай. Шуннан ни булган?

—Ни башына ни кунган, Алла бәндәсе.—Корбангали шомырт

кебек кара күзләрен әйләндерде.—Кире тартып ал да, миңа пайга кер, ялгышмассың!..

—Юк, Корбангали энем! Такташның Мохтар карты малын колхозга бирмәс өчен жыласа, мин үз малымны колхоздан кире алмас өчен кыр талашам. Шундый бозык кеше мин... Бер кешедә—ике мин!..

—Шулай, колхозда бер-берегезнекен урлап яшәрсез микәнни?

Шәйхенур кып-кызыл булып бүртенде.

—Кем белән булу—анысы минем эш. Әмма сиңа кол да булмам. Тәк вәт!.. Әйдә, берәр йөз грамм?

—Юк. Синең белән ботка пешми. Кая ди миңа, кулакка, синең белән йөз грамм эчеп торырга. Яңа Ысталиннар килә. Эзләтеп жанга тиярләр.

Корбангали чәй эчәргә дә утырмыйча кызулап чыгып китте.

—Каты мужик. Кырмыска Корбангали. Моңа эләксәңме? Мизгелендә мозгаңны кол итә!.. Колхозда калсам калырмын, әмма мироедка кол булмам...

Ул арада уянып, алгы якка Алик та чыкты. Үзенә хас житезлек белән юынып алганнан соң , ул өстәл артына килеп утырды һәм авызына азык та алмас борын, беренче эш итеп, ул Иркен-агадан Кукмара юлы өстендә яткан авылына кайтып килергә рөхсәт сорады. Шулай килештеләр: өч көннән соң кайтышлый Иркен-аганы кереп алырга тиеш.

Ләкин өч көннән соң Иркен-аганы килеп алачак автомобильне әлегә авыл очында батып яткан жиреннән өстерәп чыгарасы бар иде. Вәләкин Шәйхенурның күңеле канатлы иде. Бу хакта тынычсызланган Аликны:

— Борчылма. Минем Ләвән шикелле ат-аргамагым бар чагында борчыласы юк,—дип Аликны тиз генә тынычландырды.—Башта тамак туклык ит...Без аны—хәзер!..

Тынычланып алган Алик тамагын яхшы гына туйдырды. Хужаларга тәмле аш-су өчен рәхмәтләр әйтеп, дога кылдылар.

Кай арада чыгып та китқән, инде янадан килеп тә кергән Сихәт-сылу ир-атларга мунчага әзерләнергә кушып, яңадан чыгып йөгерде. Ул гүя үзенә урын табалмый иде. Иркен-ага аның якты чыраен, йөз төзелешен әнисенеке белән чагыштырды. Йөз суларының төсе, чагылышы, килеш-килбәте, тыныч табигате белән дә ул чынлап әнисенә охшаган иде. «Берәр форсатын табып, улы турында сорашырга мәллә?—дип уйланды Иркен-ага.—Яшь ананың болай да кансырап торган ярасын тырнау файдага булырмы? Ул, мөһажир мосафир, нинәрсә кыла ала?! Бәлки үзе дә чишелер әле, сабыр ит.»

Алик, хушлашып, машинасы янына китте.

Абзар эченнән тавыклар кыткылашкан, чучкалар мыркылдашкан тавышлар ишетелеп куйгандай итте.

Озак та үтми, саквояждан алынган алмаш эчке киемнәрен ак пакетка салып, тышка чыктылар. Аларны тупсадан әлегә салкынлык бәргән кояшлы иртә, коймалары өстеннән олпат өянкеләре ишелеп торган авыл, коеп яуган янгырлардан үзләнеп, парланып яткан тупрак, тегендә-монда атлап йөрер өчен түшәлгән ак ташлары ялтырып торган кара балчык каршылады.

—Калуша гына өстерәгез! Мунчабыз, әнә, карлыганнар аша гына!..—Алар артыннан чыккан Шәйхенур, өтәләнеп-өтәләнеп, аяк асларына пары-пары белән чиста калушалар ыргыта башлады.—Авылның иң кирәкле транспорт чарасы, әйбит? Калуша—безнең афтавыз, әйбит. Хи-хи-хи...

Иркен-ага үз гомерендә беренче тапкыр, тышта, яктыда кайчандыр ата-бабалары нигезләгән авыл уртасындагы ихатага күз салды. Әйе, татар тормышы дәвам итә: алда, коймадан югары күтәрелгән казыкта ике күз чокыры белән дөньяга сереп ат башы сөяге эленеп тора, койма аша озын буй булып сузылган, әлегә уңышы казылып алынмаган бәрәңге бакчасы.

Аннан—яланнар һәм урманнар күзгә элenә икән. Азбар алдындагы кабыклы арбага бәйләп куелган бурлы ат жөгәненең аелларын бәрә-бәрә үлән кертләтә, азбар эченнән төрки дөньяга мең ярым ел—Күлтәгин бабаларыбыз заманнарыннан булмаган-күрелмәгән ят, авырсу ис таратып, чучкаларның чинаша-чинаша, тешләшкәне, мыркылдаганы ишетелде...

—Маткалардан. Опорос вакытлары житсә, шундый сырсыган ис чыгарып тирлиләр... Бу тирнең исен комыклар ифрат та ярата... Мондый чакта чучкалар белән хәтта сыер малы да янәш булалмый... Мөгезле терлекне бакча ягына күчереп торам...—диде Шәйхенур үзен дуңгызчылык буенча зур белгеч күрсәтеп.

Алар калушаларын җайлап кына өстерәп, картая төшеп тимгелләнгән карлыган, куражиләк куаклары арасыннан алмалы алмагачлар астында татлы исләре белән буланып-парланып утырган мунчага якынлашты...

Ярабби Ходай, ул Туган җир тупрагыннан килә иде! Чынмы бу? Абзар артында тавык буылып-буылып кытаклады да тынып калды. Ул арада булмый, тавыкның сәленеп төшкән башын тирбәлтә-тирбәлтә келәткә кереп киткән Сихәтнең сылу гәүдәсе күзгә чалынып калды.

—Шәйхенур абзый тагын бер тавыкның гомерен кыскартты,—диде Рәгыйбь.—Моны Берләшкән Милләтләр Оешмасы исәпкә дә алмый бит инде.. Татар тавыгы!.. Әгәренки ул Израильнеке булса? Холокост дип шау куптарырлар иде, әйеме?

Алар мунчаның алгы ягына керделәр. Рәгыйбь гүя күптән таныш урында кирәк җирен икеләнмичә тапкан хәрәкәтләр ясап, электр утын черт итеп кабызды. Ишек ярыгы аша ихатага карап алды.

—Кара әле син аны, Шәйхенурны!.. Егетләрски!.. Атына атланып, Аликны саздан тартып чыгарырга дип торып та олакты!..

Мунчаның эче бик тә чиста һәм тәрбияле, идәннәре сап-сары итеп кырып юылган иде. Аяк астында чүпрәк палас, артлы эскәмиягә җылы келәм, келәм өстеннән ак җәймә җәелгән. Нарат бүрәнәләре әле табигый сарылыгын да югалтмаган мунчаның кечкенә тәрзәчеге төбендә шәм салынган калай савыт, шунда ук шырпы, кадак, ниндидер ачкычлар бәйләме дә ята иде. Мунчаның алгы ягында балачактан, Шәркый Төркестандагы Кизләүләрдән сеңеп калган икенче бер йөрәккә якын, самими, кадерле хуш ис кытыклады аның борынын. Йолдызлар күрергә теләгәндәй, югарыга, күккә, аның үзеннән ике аршын аша түбә белән чикләнеп куелган арадан чиксезлеккә карады. Анда йөрәккә охшаган яшел яфраклы, араларына карлыган, куражиләк, сары һәм зәңгәр мәтрүшкә сабаклары кушып бәйләнгән каен себеркеләренең тигез рәтә асылынып төшкән иде.

Иркен-аганың мондагы хуш исләрдән башы әйләнгән, мондагы сихәтләрдән җаны сихәтләнгән иде.

—Сихәт хәзер тырыша-тырыша тавыкның мамыгын йолкый инде...—дип сөйләнә бирде Рәгыйбь.—Их-х, авыл тормышы!... Ятабыз инде без дә шәһәр дигән булып, сасып!..

—Нигә соң кайтмыйсың? Нигә тормышыңны яңартып җибәрмисен? Әнә, кандай чибәр кәмпер йөреп ята, авылда канча буш йортлар үксеп утыра, кайт та кил!..—диде инде чишенеп тә өлгергән Иркен ага.

—И-их, Иркен абзый! Әйтүе генә җиңел!...Кайтып урнаша башласаң, башыңны кая алып таярга белмәссең!.. Бозылды дөнья!.. Бозылдык без үзебез!.. Бу утызынчы елдагы Магниткалар, бу раскулачиваниеләр, бу колхозлашуларның төбендә милләтләрне бетереп, алардан моңсыз биомасса ясау яткан икән бит! Шагыйрь Нәҗар Нәҗми әйтмешли, «Татар акылы төштән соң—кайчан төш житәр икән?»

Иркен-ага мунчаның эчке ишеген ачты, күкрәгенә парда пешектерелгән

каен себеркесе, шул ук сихәтле үлән исләре белән томаланган ялкынлы кайнар һава ыргылды. Кереп, ишекне япты һәм бер мизгелгә тынсыз торды. Бу мизгел миллион күзәнәкләрдән торган Вакыт кәрәзе иде. Ниһаять, тәне вә җаны бу шифалы һавада эреп, тән шәрифләрендә аны анламый, кабул итми торган бер генә күзәнәге дә калмагандай тоелды.

Мунчалары ак мунча—байлар мунчасы икән.

Ул шулай ук чиста итеп юылган, әле такталарында су салкынын да югалтмаган сап-сары ләүкәгә узды, тастагы, күрәсен, Сихәт-сылу үзе үк таманлап куйган су белән башыннан алып коенды, аннан таяксыз-нисез алпан-толпан атлаштырып, мунча мичен ачты, андагы кайнар ташларга бер-бер артлы ике ижау су томырды. Берсен үзе, берсен Мәдинә-иркәсе өчен. Эчтән порхылдап кайнар пар күтәрелде.Аның башта бер, аннан биш тире чыкты. Мәтрүшкәләр кыстырып бәйләгән сөтле каен себеркесеннән әчкелтем кузгалак исләре чыкты. Куанычыннан түземе төкәнеп, ул балачактагы гадәте буенча каен себеркесе яфрагын чәйнәде. Анарда чынлап та кузгалак тәме иде. Иркен-ага каен себеркене иснәп туя алмады. Сөт калыр, Ватан китәр! Сөт калыр, Ватан китәр!..

—Ин,[4] Рәгыйбь! Җәннәтнең нәрсә икәнен белерсән!..

Янадан ләүкә өстенә менеп утырып, бер уйсыз-гамьсез калып, күзләрен йомды.

Ул Рәгыйбьнең кергәнен дә, сөйләнә-сөйләнә юынганын да, шулай ук алдан пешереп куелган икенче себерке белән чабынганын да, хәтта пошкыра-пошкыра коенганын да сизмәде. Бәлки сизгәндер дә—тик хәтерләми иде. Ул туган тупрагында яна гына ана карынынннан чыккан сабыйга әйләнгән иде...

—Мин чыгам, Иркен абзый!..

Кем чыга? Кая чыга? Инде киенеп тә өлгергән Рәгыйбь ана аваз салды:

—Әнә, эскәмйә очындагы савытта әйрән дә бар икән!..

Ашыкмыйча, рәте-чираты белән кадерен белеп керде ул туган тупрагындагы беренче мунчасын. Тәнендәге кере дә көрәлеп чыкты, билләһи. Болай булгач, мондый яхшы инсаннар бар чакта, иншалла, юлы да унар, берәр генә булса да чыбык очын да табар кебек... Бүген мәктәптә булачак очрашуда бу мәсьәләгә кагылырга кирәк булыр. Сихәт-сылу хак әйтә...

Ул ике мәртәбә чабынды. Юлга чыкканына бер атна тулуга карамастан, кунакханә шартларында юньләп юыну бәхете тимәгән карт, Кизләү суынын исәпсез муллыгы, йомшаклыгы, сихәтлелеген тоеп, алай гынамы, аның үзенеке, хәләле булуыннан иркәләнеп, кат-кат сабынланып юынды һәм коенды.

Ниһаять, ул алгы якка чыкты һәм Сихәт-сылу җәеп куйган чүпрәк паласка басып, эскәмйәгә утырды. Күзе почмактагы пыяла савытка төште. Анда каймак салып, әче катыктан болгатылган әйрән иде. Эчте. Тагын эчте.Ул сөт агыннан гүя бары әйрәндә генә була алган көчне эчте. Мондый әйрәннәрне Шәркый Төркестанның Элә буйларында печән чапканда бары әнисе Нәркәс кенә тугылый ала торган иде!..

Ул иренеп кенә киенә башлады. Кинәт карашы көмеш җептән юл үреп, аңа таба төшеп килүче үрмәкүчкә төште.

—И-и-и, Ходай бөҗәге! Хәерле генә юл булсын!...

Ул үрмәкүчнең үз өстенә, хәтта баш өстенә—лепкә уртасына төшеп утыруын тели иде.Киенүеннән туктап, нәрсә эшләр икән дип, үрмәкүчкә карап катты. Ул исә юл сабып төште-төште дә, мунча ярыгыннан ургылып

[4] Инү,инү (гомумтөрки) — керү,сенү.

кергән кояш нуры кылычы бу юл жебен аркылы кискәндәй итте... Кинәт ниндидер жил ниндидер тын өргәндәй булып, үрмәкүч юлы югалып торды. Иркен-ага борчыла биреп куйды. Аннан теге жил теге тынын янадан өрде, аркылы киселгән төшендә генә бу жеп ялганып, алтынга әйләнде. Аннан, чайкала-чайкала тагын көмеш төсенә кайтты, үрмәкүч юл буйлап янадан төшә башлады. Иркен аганың мангаена төшеп утырды дигәндә генә бу Ходай бөжәге, аның биотоклары өермәсенә эләгеп булса кирәк, кымыржып, бөтергәләнеп алды, аннан бу шаукымнан котылып, көмеш жебен карынына жыя-жыя янадан түшәмгә таба күтәрелә башлады һәм, ниһаять, күздән дә югалды.

Иркен-ага бу манзараны унайга юрады. Димәк, ул бу сәфәрдән ниндидер хәбәр алып кайтачак, Аллаһы боерса. Шулай гына булса иде дә бит! Аның кичектергесез рәвештә мәктәпкә барасы, хәтта атлап түгел, очып барасылары килеп китте.

Эләктерәсе сәдәпләрен эләктереп, авыз-борынын бөрчекле тастымалы белән каплап, мунчадан чыкты. Ат һаман да авызлык тимерен арба кабыгына бәрә-бәрә, үлән кымтый иде.

Аларны тагын да тәмле чәй, тагын да шул ук кунак өстәле каршылады.

Берничә чынаяк эчте чәйне Иркен-ага. Башта лимонлап, аннан сөтләп, аннан каклап—коры гына эчте.

Чәй артында ниндидер мәшәкать белән йөргән Шәйхенур да, Сихәт-сылу да булмагач, гәп куера алмады. Сүз арасында Иркен ага Тәрбия ханымнан Сихәт-сылуның кайчандыр житмешенче еллар уртасындарак, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, Чаллы комсомол-яшьләр төзелешенә үз теләге белән килеп урнашканлыгын гына белә алды. Чынлап та мөгаллимә икән шул.

Очып диярлек Сихәт-сылу кайтып керде.

—Мәктәптә безне көтәләр, Иркен-ага. Атлый башласак та таман булыр...

—Әткәй кайтмадымы әле?—дип сорады ул әнисеннән, нәрсәдер сизенгәндәй итеп.

—Теге баткан машинаны Тау Иленә кадәр өстерәтеп илтеп кайтты да, тагын китте әле, Биарысланнарны эзләштереп кайтам дип,—диде тегесе чак-чак ишетелерлек итеп.—Шул югалган атлар артыннан китмәделәр микән, дип уйлыйм. Ат жене кагылган бит ул балаларга...

—Шулай гына була күрсен иде инде...—диде Сихәт-сылу чак ишетелер дәрәҗәдә.—Ярый шулай булса... Кунаклар белән булырга иде әткәйгә. Алар көн дә килми...

—Нишләсен, йөрәге түзми бит. Яраткан оныклары...

Хатынкайның йөзеннән шәүлә сызылып үтте.

Алар һидаягә кибеттән сатып алган Ак Ат бирмәкче булдылар. Һәр нәрсәне төптән уйлап эш итә торган Рәгыйбь мунчадан чыгу белән китап арбасын, Иркен-ага әйтмешли, таярлап та куйган булып чыкты.

Алар, теге Гәрәй хан авылындагы шикелле бер якка бераз чалшая төшкән урыс капкасының кече капкасын ачып урамга чыктылар да, Сихәт-сылу артыннан сулга борылып, койма буйлары буйлап, урамның саз, ләм вә былчырак яткан тирән буразналарга чак-кына шуып төшмичә эленеп калган, урыны-урыны белән ярыйсы ук сарыга, кипшенә төшкән сукмактан киттеләр.

Рәгыйбь өчен барасы юл әллә ни газаплы булмады, югыйсә: эрзин итекләренең кунычын юып ялтыраткан мосафирның, борынын кояшка элеп, арбасының бер тәгәрмәчен корыдан, икенчесен сыек былчыракта

чупылдатып баруында үзе бер самими шигърият бар иде.

—Авылда хәзер йорт төзегән кеше юк...—диде Иркен-ага кичергән хисләрне гүя һавадан тотып алган Сихәт-сылу.—Бездә хәзер өч көнгә булса да таларга килгән сәүдәгәрләрнең кибет-маркетлары гына яна...

—Әйе, Горбачев перестройкасыннан соң өмет белән яшәрә башлаган татар авылы Ельцин демократиясендә бөтенләй таланып, сүнүгә бара...—дип куәтләде аны Рәгыйбь.

—Бу кадәр тирән буразналар авыл урамында ничекләр итеп хасыйл булуы мөмкин?—дип сорады шаккаткан Иркен-ага.—Авыл урамын болай тирән итеп җир йөзендә нинди махсус техника чокый ала?

—И-и Иркен-ага, бирердә әле мин белгәндә дә, әткәй әйтмешли, кызлар теше кебек ап-ак таш юл ялтырап ята иде. Көнбагыш мае белән бузганнармыни!.. Әле коммунистлар хакимияттә чакта, таш юлдан бер таш чыгып ычкынса, икенче көнне үк урынына чөй белән яна таш кагып куя торганнар иде...

Алар Чак-су елгасы аша күпергә керделәр. Буылып-буылып аккан агымсу тавышы ишетелде.

—Революциягә кадәр бу таш юлны һәм менә бу бетон күперне Нигъмәтҗан бай салдырган булган... Соңгы ун елда авыр техника белән баткакта йөзә-йөзә чөгендер чыгарып, авылыбыз менә шундый базга төште инде...—диде Сихәт-сылу.—Шунысы кызык, акчасын түләмиләр—чөгендере кирәк!.. Чөгендердән бөтен илнең танавы кызарды ләбаса!... Җәй көне, янгыр яуса—авылга кереп булмый!.. Көзен, спирт заводына чөгендер кирәккәч, авылга бронетранспортерларда керәләр. Балалар паркына да, үзәк урамнарга да танкларны юкка куйдырмый безнең хакимнәр!..

—Авыл зыялылары... интеллигенция монда ничек карый?

—Хәзер интеллигенция юк бит ул. Хәерче акчасы алган укытучылар исемлеге генә бар. Аларны да сайлаулар житкәч кенә искә төшерәләр...—диде Рәгыйбь.—Йорттан йортка йөгертеп, үз кандидатларын сайлатырга мачтырлар...Безнең танкистларга чөгендер кирәк тә, халыкны сайлауга куарга укытучы кирәк... Әгәр курчак кандидатлар үтми икән, монда инде... ук-кы-туч-чы гаепле!..Хезмәт хакын бирмиләр!...

Сихәт-сылу сабыйларча самимилек белән көлде.

Күперне чыккач, ташландык тимерлек яныннан үттеләр. Кәүсәләре белән бил тиңентен умырылып төшкән карт өянкеләр уртасында яшел мүккә әйләнгән таш алачык тирәсен иске-москы техника, тимер-томыр каберлеге уратып алган иде.

Иркен-ага авылны бер күрүдә кочакларга теләсә дә, бу мөмкин түгел иде. Чак-су буйлап сузылган Кизләүне ике яктан да калкулыклар озата бара, әле булса көмеш бөдрәләрен коймаган өянкеләр авылның уң канатын каплап тора икән. Бара торгач, сирәк-сарак булса да төзек кенә йортлар, каралтылар, мәйдан сыман җирдә яктырып утырган кибет бинасын, болардан тыш кызыл кирпечтән төзелеп яткан бер-ике кәттиж корылмаларын да күреп, Иркен-аганың күнеле күтәрелде, авылның киләчәгенә өмете арткандай булды.

—Боларын кемнәр төзи?

—Әрмәннәр.

—Әрмәннәр? Алар бармыни? Каян?

—Алар кайда гына юк.Авылларыбызны хәзер әрмән, әзәри басты. Татарның икмәген, бәрәңгесен очсызга җыеп, биш хакка саталар. Ирсез татар хатыннарына йортка кереп, балалары булгач, ташлап китәләр. Кайберләре үз гаиләләрен дә алып килә. Кармак танаулы балалар күрсәгез, аптырамагыз, дип әйтүем... Күбесе туган илләренән качкалак-рецидивистлар. Илләренә кайтсалар, аларны утырталар. Наркотик татар

авылына шулар аша керә. Аннан, татар авылындагы төзелешне безнен хужалар татарга бирми дә... Татарны алар әрмәнне, әзәрине жиккән кебек жигә алмыйлар. Хәер...бүгенге татар ул төзүче дә түгел инде... күбрәк эчүче татар...—Сихәт-сылу ниндидер жаваплы сүзен әйтмичә йотып калдырып, авыр сулыш алды.—Житәкчеләребез әрмәннәр белән эш йөртеп, акчаны жинел генә бүлешәләр...

—Бу ташпулатларны әрмәннәр үзләренә саламы?

—Юу-у-ук. Монысын—читтән килгән бер татар эшкуары.Вологдадан кайткан, Әлмәттә яшәгән нефть маклеры диләр. Монысы мәчет бинасы... Минем энем төзи иде...

—Энегез? Бертуган энегез?

—Әйе.

—Әле ул кайда? Авылдамы?

—Төрмәдә.

—Төрмәдә?—Иркен-ага ялгыш анламадыммы дигәндәй, кабаттан сорады.—Зинданда?

—Әйе, зинданда. Казаннын Черек Күл төрмәсендә...—Дәһшәтле нәфрәттән Сихәт-сылунын бит алмалары кызарды.—Беләсезме, минем энем... сигез сыйныф белем белән Ньютон биномын янадан ачкан даһи. Балта остасы...

—Нигә ары таба укымады?

—Әти укыта алмады. Иртән укырга дип мәктәпкә китә, кичен колхоз эшеннән кайта торган булды. Шулай сабый чактан кара эшне яратты... Плотник башын белән Кара дингез флотыннан бер башын белән ике вертолет алып кайтып кара әле!.. Татар көнчелеге гафу итмәде...

—Ниндәен вертолет?!

—Сөйләрмен әле...—Сихәт-сылу анын беләгеннән кысты.—Әнә, безне каршыларга да чыкканнар!

Яшелгә буялган мәктәп ихатасыннан кин ябалдашлары белән урамга чыккан сомгыл тирәкләр астыннан очып чыккан балалар аларга чәчкә гөләндәмнәре тапшырды. Аларнын артыннан ук терекөмеш кебек тәгәрәп килгән ир, елмаеп һәм кулларын сузып, күреште:

—Дамир Хажиевич. Директор... Хуш киләсез!... Бик шатбыз!..

Алар мәктәпнен чиста, күрәсен, директорнын каты кулы белән шактый тәрбияле тотылган ихатасына үттеләр дә, беркатлы агач биналар яныннан түгәрәк чәчкә түтәле буйлап килә башладылар. Иркен-ага кызыл кирпечләре изрәп, ярымжимерелеп беткән таш очлам янына килеп туктады. Башкалар да туктадылар. Язулары да жуелып, инде укылмас дәрәжәгә житкән бу ташбүкән Бөек Ватан сугышында һәлак булган корбаннарга истәлекле һәйкәл икән.

Корбаннар хакына Иркен-ага кылган догага башкалар да кулларын кушырды.

Директор гына дога кылмады.

—Минуточку!.. Менә шушы инде безнен байлык...—диде директор куллары белән мәктәп биналарына күрсәтеп.—Монысы 1932 елда раскулаченный мулла-мунтагай, бай-кулаклардан реквизированный йорт-келәтләрдән кораштырылган. Тегесе мастерской. Колхоз төзеткәние. Әнә, иске булса да тракторыбыз бар. Минуточку!.. Әнә, теге...—Ул лапас сымак алачык астында авызын һавага элеп чак басып торган алашага күрсәтте.—... ат та үзебезнеке. Әле биш көн элек кенә колхоз дворыннан килеп керде!.. Бөтенләй хәлсез. Дилбегә белән карыны астыннан күтәртеп куйдык, гел генә, киләчәктән хат укыгандай, түшәмгә генә карап тора... Ашамый, черт побери!..

—Күтәрәмгә калгандыр ул...—диде Рәгыйбь.

—Шулайдыр. Минуточку!..—директор кире үз роленә кайтты.—Колхозга рәхмәт, ярдәм итә!... Бер гектар җиребез бар, бәрәнге, чөгендер, кәбестә, бер еллык, күп еллык үләннәр үстерәбез!.. Җитеп тора!... Әйдәгез, үтик әле!..

Мәктәп бакчасында караеп яткан бәрәнге җирендә җыелган чүп өемнәреннән пошлыгып кына соры төтен саркый иде.

Укытучылар бүлмәсенә үткән арада директорның мәктәптәге балаларның авылдагы йөз илле йортка нибары йөз чамасы, ә менә, кинәя белән, ягъни сүз уйнатып әйткән хәлдә, авылда өйләнмичә картаеп, пенсиягә чыккан, әле булса ялгыз дөнья көткән «сукбай яшьләрнең» утыз җиде кеше булуын телгә алганнан соң, Иркен ага гомерендә беренче тапкыр—кайда дисез, туган авылы мәктәбендә!—барлык Җир Шары халыклары өчен дә сирәк булган ошбу демографик кыйралыш күренеше белән очрашты. Һәм бу хәл, әйтүләренчә, һәр авыл өчен дә хас күренеш икән.

Мәктәп ихатасында укучыларның һәм мөгаллимнәр бүлмәсендәге мөгаллимнәрнең үзара гел генә урысча сөйләшүен ишетеп, Иркен ага шунысын да ачыклады: моннан ике генә чакрымда, бүген-иртәгә бетәбез дип яткан Васильево авылыннан бирегә укырга ике урыс баласы да йөри икән. Милли низаг килеп чыкмасын дип, Татарстан Мәгариф министрлыгы толерантлык[5] хакына укытуны урысча алып барырга кушкан. Дамир Хаҗиевич әйтүенчә, Кизләү мәктәбе Казандагы реестр исемлегендә милли мәктәп исәпләнсә дә, гамәлдә «смешанный» икән. «Смешанный мәктәп»нең нindирәк булуын тәфсилләп сораштырырга Иркен-аганың форсаты калмады. Аңлавынча, туган тел, туган әдәбиятка сәгатьләр саны дүртенче сыйныфка кадәр күбрәк бирелсә, хәтта берничә табигый фән туган телдә алып барылса, дүртенчедән соң дәресләр саны киметелә килә, туган телдә алып барылган фәннәр исә кайберләре дүртенче, кайберләре җиденче сыйныфтан тулаем урысчага күчерелә икән. Авылдан милли язучы, композитор, җырчы кебек күренекле сәнгать әһелләре чыкканы юк, ди.

—Очрашу кайда була?—дип директорның исенә төшерде Сихәт-сылу.

—О, да!.. «Мулла йорты»нда,—диде директор.—«Актовый зал»ыбыз шунда бит. Совет заманында типовой мәктәп төзи алмый калгач... Әйдәгез, балалар көтәләр!.. Минуточку, почмак калган!..

Мәктәпнең иң читтәге «Мулла йорты»на барышлай икенче бер кечкенә бинага алып кереп, директор, пеләшенә туктаусыз сытылып чыгып торган тир бөрчекләрен сөртә-сөртә, Американың үзеннән үк кайткан авылдашларына «минуточку»ларны сыдыра салып, мәктәп музее дигән «почмагын» күрсәтте. Анда авыл турында игътибарга лаек тарихи чыганаклар да, сирәк очрый торган комарткы-мирас нәрсәләр дә күзгә чалынмады. Дөрес, анда татар-болгарга катнашы булмаган мукшы чабатасы, тычканнар кимергән чабагач, кисәү агач, җәмкә, бакыр самавыр, чуен чүлмәк, чөшле, беләзек, чулпы, патшадан калган бердан-мылтык түтәсе ише бергә өелеп яткан әйберләр бар иде барлыкка, ә менә авылның кечкенә булса да тарихи нигезләмәсен язып элергә, кызганычка каршы, беркемнең дә башына килмәгән иде. Бу хакта әйткәч, Дамир Хаҗиевич кабынып куйды. Ул тарих укытучысы икән. Әгәр Иркен-ага белгәнен язып бирсә, ул киткәч, бу эшкә чынлап та тотынырга мөмкин, дип ышандырды ул мөһаҗирне.

Иркен-ага Дамир Хаҗиевичтән дә авыл зыялылары белән кызыксынды. Дамир Хаҗиевич «зыялы» дигән сүзне аңламый булып чыкты.

—Интеллигенция вәкилләрен әйтәмен...—дип аныклады Иркен ага.—Аларның очрашу урыны—клуб кебек нәрсәләре бармы?

—Интеллигенция... Интеллигенция...—дип кабатлады Дамир Хаҗиевич

[5] Толерантлык (латин.) — башка милли гадәт, инану, фикерләргә карата түземлек күрсәтү.

бер сүзне, кабынып китә алмаган трактор кебек. Аннан, теге алачыгындагы атны хәтерләтеп, озак кына мулла йорты түшәменә карап торды.—Бер караганда, бар да кебек инде ул... Чынлыкта юк та түгел инде ул... Без, интеллигенция, сайлаулар житкәч кенә көрешәбез... Йорттан йортка йөреп, халыкны үгетләү өчен властьләр жыеп ала безне, соныннан, әйе...чәй-мәй, туда-сюда... Минуточку!..

Мәктәп эче чым-чыкыр килеп тора иде. Очрашуны сабантуйдан да ныграк көткән укучылар кунаклар күренү белән дәррәү бастылар һәм котырып кул чаптылар. Иркен ага, Рәгыйбь һәм директор кызыл тукыма ябылган өстәл артына, уйлары әллә кайда булган Сихәт-сылу мөгаллимәләр катына утырып, урынына сенде. «Аяк табаннарында ут уйнаткан бу мөслимәгә нинәрсә булды?—дип уйланды Иркен-ага.—Башына ниндәен кайгы төште? Моны нигә яшерәләр?»

Могжиза көткән укучылар чебен очкан тавышны тынлагандай тын калдылар.

Очрашу башында бисмилла-фәлән әйтелмәде. Мәктәп белән төзелеп яткан мәчет янәшәдә генә булса да, аларның арасы бик ерак, бер-берсенә юл хәтта Мәскәү аша килгәнлеген сонрак анлады Иркен-ага.

Әллә һәрчак шулай бизәнгән, әллә ошбу очрашу хөрмәтенә йөзен-битен махсус мич сыман акшарлаган, башына тубал кадәр ак чәчле парик кигән Фикция Саматовна—ул мәктәп мөдирәсе булып чыкты—директорга сүз бирде. Укучылар барысы бер тында уфырып куйды. Бу уфыру барлык «Мулла йорты»нда янгырады. Илтифатлы һәр жан иясе балаларның гына түгел, гомумән, мәктәп жәмәгатенең директордан никадәр дә арыган-туйган булуын жинел анлый ала иде.

Һаман да шул тиреннән жәфа күргән, пеләш башын, кан качкан аксыл йөзен, кролик борыны кебек йомры борынын кульяулыгы белән еш кына сөртеп алган Дамир Хажиевич укучыларны һәм укытучыларны кунаклар белән таныштырган арада Иркен-ага тирә-якка караш сирпеп алды. Сул диварда урысның Александр Пушкиныннан алып, Маршак, Агния Барто, Борис Заходер, Борис Житков кебек милләте ягыннан барысы да гыйбрәни[6] язучыларның сурәтләре бар иде. Диварның икенче ягында татар әдипләреннән бары тик бер Габдулла Тукайның ялгызы серәеп торган сурәтеннән чыгып, бу бүлмә икесе берьюлы урыс һәм татар әдәбиятлары бүлмәседер дигән нәтижә ясады. Шунда ук Президентыбызның бер кыз баланы күтәреп төшкән «Бәхетле балачак» дигән фотосурәте эленеп тора.

Ул кул чабулардан айнып киткәндәй булды. Сүз ана бирелгән иде. Аягына торып басты. Залны иркенләп күздән кичерде. Шәйхенур хак икән: сабыйларның яртысы диярлек күзлектә иде!..Анын ин курыкканы юш килде: күнеле тулды. Тамагына килеп тыгылган төерне йотып жибәрә алмый берничә секунд торганнан сон, бисмилласын әйтеп, Татарстандагы татар балаларына барлык дөнья татарларыннан, әле генә булып үткән Икенче бөтендөнья татарлары Конгрессы делегатлары, үзенен гаиләсе, балалары, туганнарыннан кайнар күнел һәдияләрен тапшырды. Ул нәселе, анын ошбу Кизләү авылын нигезләүдәге роле, авылның үзенә билгеле булган тарихы, бер унайдан тәржемәи хәле, ир вә кыз туганнары, гаиләсе, күргән-торган жирләре турында кыскача гына сөйләп бирде.

Сүз авылга кайтуынын беренчел бурычы—нәсел шәжәрәсен эзләп табуга килеп житкәч, мәсьәлә, аһ, жинел генә ачыкланды да куйды: биредә шәжәрә турында нәрсәдер ишетү-белү түгел, ул сүзнен мәгънәсен дә анламыйлар икән. «Шәжәрә» дигән әйбернен ниндидер бер хилаф нәрсә икәнлеген ачык чамалаган кебек, бу хакта белмәү тойгысыннан туган рыясыз куанычларын

---

[6] Гыйбрәни (гарәп.)—яһүди.

укытучылар да, тарих укытучы директор үзе дә яшермичә белдерделәр.

—Мондый нәстәне авылның «кадрлар бүлеге» начальнигы Мөкәрәмә ападан сорарга кирәк булыр...—диде балаларча беркатлылык белән директор.—Хәзер партком юк! Мөкәрәмә апа белми булмас!..

Шунда ук Сәлахиләр нәселеннән авылда беркем калмавын халыкның үз авызыннан ишетү аны ифрат та сискәндерде, бүгеннән башланачак эзләнүләренә өметләрен сүрелтә төште. Ләкин тәмам сүндерә алмады: аның кальбендә әле аңа үзе дә исем таба алмаган, аның нинәрсә икәнлеген ачыклап та өлгермәгән икенче бер мөкатдәс, җанҗылыткыч мирасның барлыгы кайнар куз булып яна иде. Бу мирас хәтта аның үз туганы—борәдәрен эзләүдән дә кадерлерәк иде...

Шәркый Төркестандагы Татар Кизләве, андагы мәктәп, мәктәптәге иртәнге тормышның көн дә бөек Тукайның «Туган тел»ен рәтләргә басып җырлау белән башлануын сөйләп таң калдыргач, аннан ошбу комар, ошбу хиссият белән илһамланып китеп:

—Әйдәгез, солтаннарым вә сылуларым, без дә «Туган тел» җыруын бергәләп көйләп, шөһрәт казаныйк,—дип көтелмәгән тәкъдим ясаганын һәм табигатьтән бирелгән матур мәкаме белән бу җырны балалар да күтәреп алыр дип җырлый да башлаганын Иркен-ага сизми дә калды.

Әмма озакламый укучыларның гына түгел, укытучыларның, шул исәптән директор, аның урынбасары Фикция Саматовнаның да бу җырның сүзләрен дә, көен дә белмәүләре ачыкланды. Аның белән «Туган тел»не Сихәт-сылу, Рәгыйбь-кардәш һәм шуларга өстәп бер сабый да җырлый иде.

Җырчылар җырның дүртенче строфасына барып җиттеләр. Малай туктады. Рәгыйбь белән Сихәт-сылу тотлыгыбрак калды. Иркен-ага аны берүзе диярлек җырлап бетерде:

И туган тел, синдә булган
Беренче кыйлган догам,
Ярлыкагыл, дип үзем,
Әткәм-әнкәмне, ходам..

Зал теләр-теләмәс кенә кул чапкандай итте. Иркен-ага соңгы бу дүрт юлның совет заманнарында тыелган булуын, әле, дөресен әйтсәк, бу залда беренче тапкыр янгыравын белми иде.

—Сезнең белән җырлаган малай—әрмән малае!—дип пышылдады аңа судан Дамир Хаҗиевич.—Ованес Шекоян. Шундый смышленный малай. Татарча сочинениеләрне мәктәптә ул гына бишлегә яза!..Үзебезнекеләр татарны начар тарталар. Ә болар, алар бездә өчәү—барысы да по-татарски сыптырталар гына!..

Коңгырт кара күзле, бөдрә чәчле, Сихәт-сылу әйткән кармак танаулы ике малай, бер кыз бала башкалар арасыннан әллә каян аерылып торалар иде.

«Безнең булачак нәчәльникләребез...»Смешанный мәктәп» менә шундый була инде ул, абзый кеше,—дип уң колагына пышылдады Рәгыйбь кардәш.—Смешной мәктәп ул, гаҗәеп сәер мәктәп!»

Ул сабыйлар белән мөмкин кадәр шигъри телдә сөйләшергә тырышты, чөнки шигърилек вә сабыйлык аның өчен тигез төшенчә иде. Әмма сабыйлар, сизелүенчә, мөгаллим вә мөгаллимәләр тулаем үзләре дә, Дәрдмәнд дигән тагын бер бөек татар шагыйрен, хәтта Грохань—Гәрәй хан кальгасе турында да ишеткәннәре юк иде. Ул шагыйрьнең аны менә җитмеш елга якын инде Элә сәхрәләре, Тәклә-Макан чүллекләре, Әмрикә

саванналары аша исән-имин үткәзеп, туган Кизләвенә алып кайткан даһи авазларын монда мотлак ишеттерергә тиеш иде!.. Дәрдмәндне яттан белмәгән булса, ул Тәкле-Маканның чаянлы зинданнарында да намаз укый, Нью-Йоркның Гудзон култыгындагы «Азатлык» сыны каршында барча милләтләрнең «Азат шигърият» бәйрәмендә татарча шигырь дә укый алмаган—кыскасы, исән дә кала алмаган булыр иде!..

Ә шигырьне ул оста итеп түгел, гадел, дөрес, сагынычлы итеп, эчке бер сусау белән, театраль селтәнүләрдән азат чалымнар белән укый иде...

Гөрләгән сулар башында,
Тынлагыз, шунда үтәр—
Йөрсә сыктап тан-сәхәрләр
Мон-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнжемә, зинһар, күтәр!
Рәнжемә, зинһар, күтәр!..

Ни газизрәк—бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни житәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!..

Әле генә ничектер боегып, сынган канатларын, читлектәге кош кебек, очлайтып утырган балаларның сары коелган йөзләренә шушы унөч юллык шигырьдән нур һәм алсулык кунды. Алар беренче тапкыр чын шигъри сүзнең нинди илаһи көчкә ия булганлыгын сизенделәр. Бу бик зур һәдия иде. Әмма бала кайда да бала шул. Алар мосафир бабайлары белән һич кичекмәстән сөйләшергә, Америкадагы тормыш турында кичекмәстән белергә, бүген иртәдән үк әзерләп куелган сорауларын (укытучылары ярдәмендә, дип фараз итсәк тә була) кичекмәстән бирергә теләп кайнаша иде.

Ләкин Иркен-аганың тагын бер тәбриге бар иде шул.

—Солтаннарым вә сылуларым!..

Нә авылда, нә гаиләдә мондый сәер сүзләрне ишетмәгән сабыйлар бер-берсенә сәер караштылар. Гүя аларның сүнгән күзләре жанлана иде.

—Безнең бабайларымызны ошбу туган Кизләвебездән кугандан кин, алар Тын Океан ярларына, Тын океан ярларыннан Манчжуриягә, Манчжуриядән Эчке Кытайга—барлыгы унсигез-егерме мең чакрым юлны ат белән үткәннәрдер. Ат—бөек жан иясе. Кешелекнең бишеге ат ялында тирбәлгән. Ат—кешелек цивилизациясен алга алып барган илаһи жан ияседер кү. Ат безнең телефон, ат безнең телевизор, ат безнең китап, ат безнең язасы каләм-дәфтәремез болады...

Ул нәрсә әйтергә белми тукталып калды.

—Татарның икенче даһи шагыйре Мәжит-ага Гафури үзенең «Ат» дигән шигырендә бу Бөек Мәхлукъка багышлап, менә нинди шигъри юллар калдырган:

Ат ул үз өстенә төшкән эшне
Эшли, һич бер көчен аямый,
Кеше кебек, махсус эш киеме,
Айлык жалованье дә сорамый.

Ат—ул кайбер ялкау, ансыз кеше
Кебек ясамый ул прогул,
Хәл җыйдымы, тамак туйдырдымы,—
Эшкә әзерләнеп тора ул...

Балалар елмаештылар.

—Менә кандай матур итеп сурәтләгән Гафури бабабыз ат дигән җан иясен... Ишеткәнегез бар идеме бу шигырьне?

—Ю-у-у-ук!—диеште балалар җанланып китеп.—Ю-у-у-ук!..

—Атларны яратамсыз?

—Яратабыз, яратабыз!..

—Бездә атлар юк бит хәзер!.. Канюшнай бикле!!..

—Ат безне Галәмгә алып менде. Ат безләрне алыс Әмрикәләрдән сезләр илә күрештерде... Шул сәбәпле мин сезләргә һәдия итеп мәгърур Ат сыны һәм, аның ялына төйнәп, мәктәбегезгә кечкенә хәерхаһ—йөз доллар китердем. Кабул итеп алынызлар!.

Рәгыйбь алдан әзерләнгән ак сынны төрелгән җәймәсеннән чыгарып, Иркен агага, ага исә үз чиратында аны аксыл костюмда агарып утырган Дамир Хаҗиевичкә тапшырды.

—Матур ат!—дип сөенеште балалар.—Он нам нужен!..

—Канюшнайдагы атларның исәннәре качып киткән, ди!..

—Берсе мәктәпкә килгән!.. Укырга...

Балалар шаркылдап көлештеләр.

—Их, долларын тотып карарга иде!..

—Тотмый тор әле!.. Тоткач атарлар, яманатың сатарлар...

Укытучылар тыймадылар: гомерләрендә юньләп ат һәм доллар күрмәгән балалар берсе артыннан берсе урыннарыннан күтәрелеп, ат сынын һәм конверттан чыгарылган ассигнацияне сыйпап карадылар. Очрашу тәмам җанланып китте.

Акбүзат сыны кысла кебек кызарып утырган Фикция Саматовна янына барып кунаклады. Дамир Хаҗиевич исәпсез-сансыз рәхмәтләрен әйткәннән соң очрашуның төп өлешен башлап җибәрде:

—Йә, беренче сорауны кем бирә?

Тәрәзә катында утырган сары чәчле малай кулын да күтәрде, урынынnan да торды, сул кулындагы кәгазьгә карап, соравын да ярып салды:

—Ник американецларга «ковбой» диләр? Син дә ковбоймы?

—Сез дә дип әйт, агач тел!..—дип төзәтте Дамир Хаҗиевич.

—Сез дә...

—Әмрикәннәргә түгел, Әмрикәнең малчы кавеменә... Кызык сөәль... атларга бәйле сөәль!..—Иркен-ага артына борылды.—Тактагыз бармы?.. Әһә, бар икән.—Ул класс тактасына якын килде, кулына акбур алды да сорады:

—Чит лисанның ниндәен өйрәнәмсез?

Аны аңламадылар.

—Аһ!..Чит телнең кайсысын өйрәнәсез?—дип ачыклады.

—Анлийский... немецкий...—дип шаулашты балалар.—Кемдер ярымшаярып, өстәде:—Татарчадан башка барысын да...

Иркен-ага тактага инглизидән «cowboy» дип язды да, аны ике өлешкә бүлеп, янадан язды һәм укыды:

—Cow—сыер... boy—егет дигән сүз. Димәк ки, әмрикәннәрнең ковбой дигәне безнеңчә «Сыер малы көтүче егет», тагын да кыскарак итеп әйткәндә, «Көтүче» дигән сүзгә тап киләде... Шуңа күрә, ковбойлык сәхифәсе Әмрикәнең малчылык бик тә алга киткән көньяк Нью-Джерси, Техас, Калифорния,Миссисипи,

Миссури штатларында таралган. Аларның кигән киеме—кин эшләпә, кин каеш, житеннән тукылган джинсы чалбар-күлмәк, янда пистолет, кулда—озын камчы... Авызда—жыру. Жыру аларга төнлә, таборга төшкән сыерларны тәмле уйкуда йоклату өчен кирәк булады. Сыер малы төнге ялга туктап, күши башлагач, аларны тынычландыру, ашказаннарын ял иттерү, иртәгә иртән тагын да зуррак аппетит тудыру өчен ковбойлар авыз эчләреннән сыерга охшатып мүгрәп жырлаганнар вә көтүне әйләнеп йөргәннәр. Угрылар да көтүгә якын килә алмаганнар. Шулай итеп, жыру малны иткә вә сөткә утыртырга ярдәм иткән, угърылардан саклаган вә карыннарындагы туар бозауларын сау-сәламәт саклап, малны иртәнге азыгын тагын да яратып вә сыгынычлы итеп ашарга әзерләгән... Менә шулай Көньяк Әмрикәдә, татар халкының зимагур жырулары кебек, ковбой жырулары, О Генри кебек атаклы язучылары, Чарльз Рассел кебек рәссамнары барлыкка килгән...

Мондый тәфсилле жавантан балалар зерә дә канәгать калды.

—Абый, мин, мин!.. Нигә Һиндстанның төп халкын һиндләр, ә Американың төп халкын индеецлар дип атыйлар?—дип сорады кәгазеннән карап тешсез бер малай.

—Алар икесе дә бер тамырдан, икесе дә берүк төшенчәдер, солтаным. Жирле милләт, жирле кавем дигән сүздер. Адмирал Христофор Колумб Һиндостанны ачам дип кенә ачкан бит Американы... Шуна күрә, кулына әсир итеп төшергән төсле тәнлеләрне дә «һиндиләр» дип атаган. Бу вакыйгаларга биш йөз елга якын гомер үтсә дә, Әмрикәнең жирле халкын һаман шулай ялгыш атап йөртәләр. Гамәлдә һиндиләрне Һиндостан һиндиләре, Әмрикә һиндиләре дип атау дөресрәк булыр иде. Мин үзем хәлбуки шулай атап йөртәм дә...—Иркен-ага нәрсәнедер исенә төшергәндәй туктап калды.—Туктагыз, солтаннарым, сезләргә бер тарих сөйләемче. Әмрикәне Христофор Колумб ачкан, әйеме?

—Әйе! Әйе!—дип шаулашты укучылар.

—Хак. Тик хак та, түгел дә... Әмрикәне, гамәлдә без, төрки-татарлар, ачканбыз...

—Без?! Татарлар?!—Зал шаулашып алды.—Булмас!..

—Әмрикәнең күп кенә галимнәре һиндиләрне йөз рәвешләре, килешкилбәтләре белән мангулидлар, ягъни Азиядән чыккан мангул расалы кавемнәр дип исәплиләр. Һиндиләр дә мангуллар кебек каты кара чәчле, конгырт йөзле, кысык күзле, әмма аларның танаулары озын бөркет танау. Бу мангул кавемнәренең яңа континентта кичергән физиологик үзгәрешләредер... Әлбәттә, бу Әмрикәнең рәсми даирәләре фикере түгел. Күп кенә галимнәр һиндиләрне Үзәк Азия кинлекләреннән тарихи сәяхәткә чыккан төрки кабиләләр—һуннар, диләр. Мин дә шул фикердә торам. Безнең Висконсин штатында һиндиләр яшәгән ике резервация бар. Мин аларга барып йөрим һәм аларны үгрәнеп инанам: алар—төркиләр. Һун бабаларымыз Эчке Кытайдан Алты Ай тауларына житкәчтен икегә бүленәде: бер өлеше йөз мең япмалы арбаларда Европага, икенче өлеше—Беринг бугазы, Әләс бозлыклары аша Көньяк Әмрикәгә таба кузгалады... Озак гасырлар буе үз телләреннән консерва ясап, төрки сүзләрне саклап калып, алар берүк вакытта яңа тел—ацтек, майя, ирокез кебек дисталәгән телләр, мәдәниятләр ижат итәләр. Вәләкин шунысы гажәптер: алар үзләрен төркиләр дип исәпләй. Миңа моннан ике ел элек Төркиянең Измир каласында төрки халыклар ассамблеясының корылтаенда булу насыйп итте. Корылтай Әмрикә һиндиләрен төркиләр ассамблеясына әгъза итеп кабул итте, беләмсез!.. Анда майя теле буенча белгеч чыгыш ясап, мисалга йөзләгән төрки сүз китерде: алардагы гөл—бездә дә гөл, алардагы таш—бездә дә таш, алардагы чәчәк—бездә дә чәчәк...Менә сез яратып кигән джинсы

күлмәк-чалбарларга да катнашы бар безнең төрки-татар теленен...

Балалар шым калды.

—Джинс махсус житен, махсус киндер сүсеннән тукыла. Сез «житен» дигән татар сүзе белән «джитнс» дигән Әмрикә һиндиләре сүзе арасында охшашлык күрмисезме?

—Күрәбез! Күрәбез!..

—Аларның икесе бер тамырдан болады. Бу хакта мөхтәрәм галимебез Әбрар Кәримуллин махсус китап та язды, күрдеңезме? Укыдыңызмы?

—Күрмәдек, укымадык!—диеште балалар тел шартлатып.

—Американецларның яраткан азыклары нинди?

—Әй, тапты сорау! Тагын да шул ашау!..

Йөзләренә чынлап та кызыксыну, танып-белү нуры балыккан зал бер тавыштан көлде.

—Күркә ите,—диде Иркен ага.—Күркә ите—әмрикәннәрнең иң яраткан ризыгы.

—Нинди була соң ул?

—Күргәнегез юкмыни?

—Юк, юк! Күркә бездә үрчеми.

—Күркә—җир йөзендәге иң тәмле, иң файдалы кош-корт ите. Татарның казы кебек...

—Бездә каз үрчеми бит!..Ана бәпкә үләне кирәк!..

—Ә күркә нәрсә ашый?

—Чикерткә ашый.

—Чикерткә бездә юк бит ул!.. Америкадан китертик!..

—Күркә ите әмрикән өчен татарның бәлеше кебек милли азыктыр. Алар аны төрле-төрле кетчуп, соуслар белән тәмли, куыра, ыслыйлар...—диде Иркен ага.—Әмрикәннәрнең безнең сабантуй сыман уныш бәйрәме бар. Нарат җиләге белән бергә кабак эчендә пешкән күркә ите ашау өчен алар ул көнне маңгаен җимерергә дә әзер...

—У-у, күркә өчен мин дә маңгай җимерер идем...

—У-у, нарат җиләге...

Арткы рәткә утырган өлкән яшьтәге укытучы ханым сөйләшүне янадан житди ызанга керту өчен:

—Америка, андагы тормыш турында сөйләмәссезме?—дип сорады.

Бу аның иң курыккан соравы иде. Әмрикә кебек катлаулы, чиксез үзенчәлекле мәмләкәт хакында ничекләр генә сөйләп бетмәк кирәк?

—Атлантик дәрьядан Нью-Йоркка кергәндә Гудзон елгасы тамагында кечкенә Либерти дигән утрау бардыр кү. Анда бөтен дөньяга таныклы «Азатлык» сыны тора. Аны 1886 елда АКШның игълан ителүенә йөз ел унаеннан француз хөкүмәте бүләк иткән. Башыннан төрле тарафларга нурлар чәчелеп торган, кулына якты шәм тоткан Ана сынының биеклеге 38 метр. Тутыкмый торган корычтан ясалган бу сынны французлар егерме ел буе коралар. Аны күрү, солтан-сылуларым, бер тетрәткеч манзарадыр. Аның нигезенә менә нинди сүзләр язылган.Мин аларны хәтеремдә калганынча әйтәм: «Арып талчыкканнар, кимсетелгәннәр, ярлылар, ачлар, азатлыкка сусаучылар—миңа килегез. Туган илләрендә изелгәннәр, йөрәкләре урталай ярылганнар—миңа килегез. Йорт-җирсезләр, тормыш-хәяткә ышанычын югалтканнар—барыгыз да миңа килегез... Мин ошбу шәмдәлем берлә сезләр бәхетенең Алтын Капуларын яктыртам!...»

Залда тантаналы тынлык хөкем сөрә иде. Шушы минутта аның кесәсендә телефоны кунгырады. Фикция Саматовна сәгатенә карап алды.

Директор Фикция Саматовнага карап алды.

Иркен-ага телефонны алды һәм колагына куйды. Чынгызи икән.

—Угъланым, рәхмәт кунгыратуыңа! Мин туган мәмләкәтемездә, туган

авылымыз Кизләүдә үз бавырдашларым берлә йөреп ятам!.. Әле мәптектә, сабыйлар илә очрашу катындамын. Сәлам тапшырайым? Әлбәттә!.. Әнкәнә, Гөлмәрфугага кунгырат, сәламнәр күндер! Аман булын!..

—Угъланым Чыңгыз Төркиядән мине эзләп ятадыр кү...

—Төркиядән? Булмас! Вәт, әй!—дип шаулашты балалар.

—Менә ошбу кыска, әмма тирән мәгънәле чакыруда, солтан-сылуларым, Әмрикә халкы, анын хәяте, тәрәккыятенең сере яшерелгән... Без Әмрикә халкы, димез.. Ул татар да, инглизи дә, кахул да, француз да түгел...—Иркен ага нотыгының бу өлешен күбрәк мөгаллимнәргә юнәлтә иде.—Дөрес, ул—әмрикән. Ул—милләтсез. Андыйларны фәндә «космополит» диләр. Әмма бу тыштан караганда гына шулай. Шунысы хак, гамәлдә бик чуар булган әмрикән җәмәгатьчелек...—Иркен-ага уйланып торды:—Ничек итеп нибары ике йөз ел эчендә дөньяның иң алга киткән, иң демократик, иң азат мәмләкәтенә әверелгән сон? Бер карасаң, алар илләренән качкан качкын-зимагурлар...Хәтерлимсездер, татарда шундый җыру?

Зимагурлар талчукта,
Кайгырмайлар мал юкка,
Кайгырсалар, кайгыралар
Тәмәкеләре юкка..

—Талчукны беләсезме, нәрсә?

—Юк белмибез!

—Как, белмисез?—дип кычкырып җибәрде иң арттан бер хатын. Ул урыс теле укытучысы иде бугай.—Проходили же! От слова»толкаться»...

—Иске-москы, кырыктартмачылар, ваклап сату урыны болады...Зимагур... Зимагур...—Иркен-ага тагын уйланып калды.—Бу тәгъбир безнең Шәркый Төркестан татарлары лөгат[7]ендә але булса кулланышта. Мин урысча яхшы белмим, шунысын гына беләмендер кү. Ул урысча ике сүздән торады: «зима»—«кыш»мы? «горе»—«кайгы»мы? Димәк, җәен рәхәтләнеп ил гизгән зимагурга салкын кыш «горе—кайгы»га әйләнәде... Әмрикән ковбой-зимагурлар алар кавем дә, милләт тә түгел. Алар—сәяси, икътисади изелмештән, төрле кыерсытылулардан качкан, яхшы тормыш төзергә ихтыярлы, азатлыкка, иреккә сусаган халык. Теге һәйкәл нәкъ шул хакта бәян кыладыр. Әйе, нинәрсә халыкларны дистә баллы давыллар аша океан кичәргә мәҗбүр иткән? Бары тик ирекка, азатлыкка булган бөек омтылыш!.. Әйе, ошбу сәяси, икътисади, сыйнфый, дини, рухи ирекка сусаган сукбайлар—искиткеч батыр, тырыш, җырлы, моңлы, ачык йөрәкле, йөз телле, ихлас табигатьле мөһаҗирләр Әмрикәнең ирекле һавасыннан Әмрикәнең ирекле туфрагына ирекле орлык булып төшәләр дә, мул уныш булып житешәләр!.. Башка илдән качкан качкалак биредә баеп котыла да гражданин булып житешә, кача алмаганы, теләмәгәне, тегендә череп тотыла!..—Иркен ага кеткелдәп куйды.—Шулай итеп, качкыннардан тамган алтын тир кара тупракта алтын пальма булып күтәреләде...

—Нәкъ сезнең кебек, бабай!—диде алда утырган түм-түгәрәк малай.—Сез дә алтын кебек ап-ак бит!..

Зал рәхәтләнеп көлде.

—Рәхмәт, солтаным, зур үс!.. Рәсәйдә менә ошбу ирек тойгысының канаты сынгандыр, шуңа инсанның тире тупракка алтын булып таммай һәм аннан алтын пальма күтәрелмәй... Шуңа күрә Әмрикәнең тавыклары елына ике йөз сиксән йомырка сала...

—Ике йөз сиксән йомырка!..—дип аһ итте зал.

—Помидорны да комбайн белән җыйдырта!..

---

[7] Лөгать (гарәп.)—сүзлек.

—Комбайн белән—помидор!—дип аһ итте зал.

—Мин яшәгән Висконсин штаты гына житештергән мал агы барча Әмрикә халкын туендырырга житә. Автоматлашу шулкадәр дәрәҗәдә ки, ике-өч фермер менәр баш сыерны карый, асрый, сава, сөтен эшкәртә...

Балалар күңеленнән гүя ул хәзердән үк Әмрикәгә күчеп китү өчен арбасын таярлый, табаннарын майлый иде...

Әрмән малае кулын күтәрде.

—Минуточку! Әйт, Ованес,—диде Дамир Хаҗиевич.

—Бабай, син үзең баймы соң?—дип сорады орлык кебек тулы Ованес.

Зал күтелмәгән сораудан аһ итте.

—Һм... Мин?... Әмрикә өчен бай да, ярлы да түгел—урта сыйныф. Мин—мөгаллим...биолог (Иркен-ага мизгелгә каушап калды, укытучылар җанланып алды)...(балалар гына түгел, «мөгаллимнәр» сүзен өлкәннәр дә анламады шикелле)... картлык буенча ялда, пенсиядәмен...

—Пенсиягез күпме? Пенсиягә ничәдә чыгалар?—дип сорады икенче бер мөгаллимә.

—Әмрикәдә пенсия Рәсәйдәге сыман халык өзелеп көткән нәрсә түгел. Анда пенсиягә чыккач та эшләү мактаулы санала. Рәсәйдә пенсиягә чыгу үлемгә әзерләнү кебек булса, Әмрикәдә ул чын-чынлап яши башлау кебек. Хатын-кызлар алтмыш биш, ирләр житмеш, хәтта сиксән яшьтән дә пенсиягә чыга, чөнки тормыш һәм хезмәт шартлары яхшыдыр. Гомумән алганда, пенсиягә чыгу өчен Әмрикә гражданины булу, бер урында сигез елдан да ким эшләмәү вә пенсия Фондына эш хакыннан акча түләп торганлыгың шарттыр. Пенсияне ике-өч урыннан алалар. Мин, мәсәлән, жиде йөз доллар дәүләт пенсиясе, мең дә ике йөз доллар Федераль Мәгариф Фондыннан алам. Җәмгысы мең тугыз йөз доллар...

—Мең тугыз йөз доллар? Ул күпме була?

Зал шаулашып, кунак барлыгын да онытып, исәпли башлады. Икене икегә тапкырларга хәтердән өйрәтелмәгән укучылар укытучылары белән бергә калькуляторларын чыгарып, Америка долларын безнең курска әйләндереп, ниһаять, исәпләп чыгардылар: тиеннәре-ниләре белән вакланмыйча ул якынча илле жиде миллион сум икән. Күзләр чокырыннан маңгайга, маңгайдан түшәмгә сикерде. Зал касыктан кату алгандай тынсыз торды. Мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр бөтенләй катып калды.

—Бу Әмрикә өчен зур акча түгел. Мин, моннан тыш, Кизләү дип аталган ранчо... ягъни утарымда... умарталык тотам...

—Кизләү? Америкада?! Барабыз!—дип шаулашты балалар.

—Әйе, бар андый авыл, балалар. Мин туган авылыбыз Кизләү һәм Шәркый Төркестандагы Кизләү авылларының тарихи исемен дәвам итеп, Әмрикәдә дә кечкенә генә Кизләү дигән авыл нигезләдем. Шул авылдагы умарталарымны сәхрәдән сәхрәгә күчереп йөртү өчен автотрейлерым, күчмә йортым, негр кавеменнән ике хезмәтчем бардыр кү. Сезонына карап, тагын да ялчылар яллыймындыр..

—Сезнең негрларыгыз да карамы? Алар нәрсә ашый? Жир ашап караямы?

—Бал кортлары Америкада да бармыни? Очалар дамы? Баллары да баллымы?—дип яңадан кыбырдашып алды балалар.

—Баллы...—дип көлемсерәде Иркен-ага.—Бал ашарга килегез... Очалар да! Минем кортларым, мәсәлән, утарыбыздан егерме-утыз чакрым юл үтеп, күрше Иллинойс штатыннан ташыйлар хәтта балны... Югыйсә, без яшәгән Висконсин штаты ул Әмрикәнең мал-туар үзәге—анда житештерелгән сөт, ит, бал дөньяның егерме иленә китә... Анда чәчкәләр житәрлек, ләкин кортларга, күрәсең, Иллинойсның зелпе чәчкәләреннән алынган сары кәрәз кирәк!..

Очып кайтканда аларнын аякларына уралган баллары жилләрдә жилләп, сары кәрәзгә әверелә... Ә менә сезнен авылда умарта тоткан инсаннар (балалар бу сүзне анламады, Иркен-ага «кеше» дип ачыклап китте) бармы сон?

Балалар белми иде.

—Яланнарыгызда чәчкәләрегез беттемени?

Балалар бу хакта да белми иде.

Директор ярдәмгә килде.

—Заһретдин абзыйда өч баш бар иде, былтыр кышын үлделәр бугай... Хәер, Интендант абзыйда ике баш, Бензол Әмировичтә ике баш бар бугай... Барлык авылга ун-унбиш баш умарта жыелыр...

—Күбрәк!—диде Фикция Саматовна пырылдап.—Чит ил умарталарыннан күбрәк!..

—Юк, Сайрус Әмировичныкы быел язда кырылып бетте,—дип аваз салды почмактан бер иркәй.—Шикәрләре житмәгән. Бал кортына шикәр, көмешкегә шикәр—нихәл житкермәк кирәк?..

—Кырларга сибелгән ашламадан кырыла ул кортлар,—диде почмактан икенчесе.—Елгадагы балыклар кебек...

—Ярар. Хуп.Тагын сораулар бармы?

—Нәрсә ул «хуп»?

—Хуплыйм, килешәм болады. Төрки сүз. Үзбәктә вә уйгырда еш кулланыла...

—Сезнен бал кортлары океан аша Кизләүгә кайтып, безнен ялан балларын жыеп китә алырлар идеме?

Иркен-ага бу сораудан тынсыз-телсез калды. Күзләренә мондый чакларда пылт итеп яшь бәрә дә чыга. Ул дулкынлану, күнеле тулудан эндәшә алмады. Аптырагач, тамагындагы төер үтеп киткәнче дип булса кирәк, бу сорауны биргән сабый янына барды, аны кочаклап яратты, манганнан үпте, аннан капшангандай жай гына килеп, чак ишетелерлек итеп эндәште:

—Рәхмәт.. Рәхмәт... Авылда ничә йорт бар сон?

Балалар белми иде.

—Аны Мөкәрәмә әбидән сорарга кирәк!..

—Йөз илле чамасы бардыр, диеп уйлыйбыз...—диде Дамир Хажиевич.

—Йөз илле йортка егерме баш умарта... Безнен Шәркый Төркестанда Кәшфеләсрар абзыйнын, мәсәлән, балаларыныкы белән бергә өч йөз баш умартасы бар иде..Татар умарта тотарга тиеш. Умартасыз татар—умырткасыз татардыр кү. Мина умартачылык шаукымы шул Төркестандагы Кизләвебездән күчте. Анда умартасыз татар юк иде... Мин аны Әмрикәдәге Кизләүгә дә күчердем...

Зал котырып кул чапты.

—Әмрикә бай булса да, билхаккый, акчага саран. Гомумән, галел саран булу—байлыкнын нигезедер. Кеше бай булган саен саран болады. Әмрикәдә тормыш акчалы кыйммәтчелеккә корылган. Ул бары тик файда-зыян координатасында яшәйдер. Әмрикәнен үзләрен утрауда хис иткән беренче мөһажирләре барча нимәләрен кораб карынында материктан китертергә мәжбүр булгач, мал-мөлкәткә бик сакчыл карарга өйрәнгәннәр. Анда әйбер әрәм-шәрәм ителми. Тимернен, калак бәясе—доллар бәяседер. Әле без монда килгәндә тимерлек янынан үттек. Янадан кулланырга, энергиясен алырга, бәрәкәтен саварга мөмкин булган күпме байлык ята анда, балалар... Әмрикәдә булса, мондагы аунап яткан металл өемнәреннән бер металл эретү фабригы ачкан булырлар иде...

*Дәвамы киләсе санда*



Рәшит
Бәшәр

# ИЛ ГАМЕ, ТАТАР ГАМЕ БУ...

## Ана телем

**Ана телем—татлы тел,
Олуг тел ул, затлы тел.**

**Олпат тел ул, данлы тел,
Күп гасырлык шанлы тел.**

**Ул—әрем тел... Тәмле тел!
Гөлле тел ул, ямьле тел.**

**Куркак түгел, батыр тел,
Күп михнәтләр татыр тел.**

**Сихәтле тел, шифа тел,
Бик назлы тел, зифа тел.**

**Дошманнарга дошман тел,
Бик кирәктә куштан тел.**

**Ипле тел ул, әйбәт тел,
(Йә сертотмас, гайбәт тел!)**

**Моңлы тел ул, гамьле тел,
Чая тел ул, зәмле тел.**

**Хәйләкәр тел, сабыр тел,
Тирән уйга салыр тел.**

**Шаян тел ул, купшы тел,
Ана телем—шушы тел!**

## Болгарым

**Ата-бабам җирләренә,
Моңлы чишмә илләренә
Килдем әле, килдем мин, Болгарым.
Болгарым, Болгарым,
Йомшак җилләр сыйпый йөземне,
Яшь томалый моңсу күземне,
Нур яктырта җылы күгеңне.**

**Харап булган күпме башлар,
Әрнеп елый изге ташлар
Чиркәүләрнең астында, Болгарым.
Болгарым, Болгарым,
Иртә белән Идел кызара,
Риваятьләр сөйли алкын су
Чишмәләргә килгән кызларга.**

**Егетләрең ак атларда
Чаба синең кай якларга?—
Ук-сөңгеләр сынган шул, Болгарым.**

Болгарым, Болгарым,
Былбылларың сайрый талларда,
Сагыш-моңнар өстәп җаннарга,
Җанны куйыйм икән кайларга?

## Милләт хәле

1

Мәйданда чыр-чу килдек:
—Без—азат халык!—дидек,
Ирек кулдан ычкынды...
Искергән коллар булып
Яңа гасырга кердек.

Ут идек, ялкын булдык,
Давыл идек, җил булдык,
Йөгердек тә туктадык...
«Азатлык үзе килер!»—
Чишендек тә йокладык.

Өй селкетеп гырлыйбыз.
Көз җитте. Шиңә үлән.
Язмасак ярый телдән.
Йоклап китмәсәк ярый
Үлем йокысы белән...

Кем селкетер якадан
Һәм уятыр йокыдан?

2

Ватылган бит арбабыз...
Ватык арбаны сөйрәп,
Көч-хәл алга барабыз.

Арба рәтләр кеше юк...
Сакал төкләрен санап,
Юл чатында торабыз.

## Илдар абый

*Язулардан ял иткәндә*
*Кычкырып та куйгалыйсың,*
*Кайчакларда балаларча*
*Ычкынып та куйгалыйсың.*

Илдар Юзеев

Кычкырып та куела шул,
Ычкынып та куела.
Йокысыз кара төндә
Бимазалый уй гына.
Җемелди соңгы йолдыз...
Таң атарга җыена.
Синсез, и Шагыйрь абый,
Җирдә яшәү кыен ла.
«Күтәрик,—дигән идең,—
Җансызлар өчен түгел,
Җан сызлар өчен, энем!»
Җан сызлый. Сызлый, сызлый,
Җаным, абый, ут минем.
Ил гаме, татар гаме—
Башка гамем юк минем.
Сискәнеп китәм кинәт:
Ай да урланган дисәм,
(Үрелеп алалмыйлар,
Кесәгә салалмыйлар),
Тәрәзгә кереп тора—
Исән ярымай, исән!
Әлифсез калдырмакчы,
Корытмакчылар телне—
Булмас эш болар бары,
Җәелә татарымның
Шәҗәрә ботаклары.
Мәтрүшкәле аланнар,
Аланнарда оланнар,
Тай буласы колыннар
Көтәләр сине, абый.
Ишетәм күк: «Кайтырмын,
Көтегез! Ярый, ярый...»
Мәңгелектә ниләр бар,
Ни өннәр, Илдар абый?
Бездә һаман шул ук хәл:
Әҗәл белән көрәшеп,
Тырмашып ята татар,
Нәселем ишәйтәм дип
Тырышып ята татар.
Киләчәккә барышлый
Туктый-туктый хәл алам.
Юлларым—чокыр-чакыр,
Көч-куәт бирче, Аллам!

**Редакциядән:**
*Бу айда балалар шагыйре, Чаллыда яшәүче танылган әдип Рәшит Бәшәргә 60 яшь тула. Каләмдәшебезне гомер һәм иҗат бәйрәме белән күпсанлы укучыларыбыз исеменнән дә котлыйбыз, ана сәламәтлек һәм яңа уңышлар теләп калабыз.*



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# ҮЗЕМ ҖИРДӘ, КҮҢЕЛЕМ КҮКТӘ МИНЕМ...

## Бәхилләшү

**Бу дөньяда миңа кадәрле дә**
**Хәят булган,**
**Галәм әйләнгән,**
**Гөлләр үскән,**
**Кемдер кемне сөйгән—**
**Язмыш язмышларга бәйләнгән.**
**Шушы җирдә гамен тапкан кеше**
**Җирдә яшәү**
**Тормаса да тоташ бәйрәмнән.**

**Мин дә йөрдем сезнең арагызда—**
**Нидер таптым,**
**Нидер югалттым,**
**Мәңгелеккә килдем дөньяга дип**
**Үз-үземне гел дә юаттым.**

**Нидер төзегән булдым бик тырышып,**
**Сөйгән булдым шунда үземчә—**
**Уйламадым,**
**Гәрчә дөньяда мин**
**Бер узгынчы гына югыйсә.**

**Бу дөньяда мин бит булмаганмын,**
**Килер бер көн—**
**Кабат булмам да,**
**Былбыл кебек кереп югалырмын**
**Таң алдыннан ап-ак томанга.**

**Кояш чыгар аннан,**
**Ә томанны**
**Таң җилләре куып таратыр.**
**Мин ул чакта инде бик еракта—**
**Мәңгелектә очып йөрермен,**
**Сез күрмәссез мине,**
**Ишетмәссез,**
**Тик мин генә сезне күрермен.**

**Кемдер елар мине тапмаганга**
**Һәм эзләнер**
**Кая китте дип.**
**Кемдер гайбәт сөйләр**
**Күп буталды,**
**Китсен әйдә, вакыт җитте, дип.**

**Мин вакытлы гына килгән идем,**
**Калам диеп түгел мәңгегә—**
**Вакытында килеп,**
**Вакытында китәм,**
**Рәхмәт әйтеп бөек Тәңремә.**

**Шулай килеп,**
**Шулай киткән күпләр,**
**Нидер көткән,**
**Нидер калдырган,**
**Мәңгелеккә килдем җиргә диеп**
**Затлы ташпулатлар салдырган.**
**Үзе киткән,**
**Затлы сарайларын**
**Еллар тузан иткән,**
**Җимергән,**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941)—*шагыйрь, публицист, «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Робагыйлар бакчасы» һ. б. китаплар авторы. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлеге әдәби бүләге—С. Сөләйманова исемендәге премия лауреаты. Балтачта яши.*

Җимерек хәрабәләр арасында
Нидер эзләп сукбай җил йөргән...

Патшалар да киткән,
Җәлладлар да,
Сакыйларсыз калган табыннар.
Шагыйрьләр дә киткән җырлый-җырлый,
Тик җырлары калган—
Йолдыз булып күктә кабынган.

Бу дөньяда бер чак булмаганмын,
Килер бер көн,
Кабат булмам да,
Мине эзләп таң җилләре генә
Шыңшып елап йөрер урамда.
Ак каеннар бераз моңсуланыр,
Озаграк кибәр таң чыгы,
Аннан бар да тынычланып калыр
Ыгы-зыгылардан талчыгып.

Җирдә бераз моңсу булып калыр,
Берәү генә яшерен яшь кояр,
Юксынуын яшереп йөрәгенә,
Салкын мендәренә баш куяр.

Мин килгәнмен җиргә болай гына –
Адаштырган кемдер китереп,
Ваклыкларга кертеп батырган да,
Ташлап киткән гаҗиз иттереп.

Әлләни зур эзем калмый җирдә –
Бакчам кала гөлләр утырткан,
Балаларым, оныкларым кала,
Шәкертләрем кала— укыткан.
Максатларым кала— ирешмәгән,
Хыялларым— эшкә ашмаган.
Мин ышанам,
Аларны да беркөн
Дәвам итәр бүтән-башкалар.

Нидер кылдым кешеләргә тагын,
Нәрсәгәдер дәрман җитмәде—
Кайсынадыр үзем гаеплемен,
Кайсыларын заман чикләде.

Заманасы сикәлтәле булды –
Уттан алып салды суларга,
Буш хыяллар мавыктырды безне –
Ярты гомер китте шуңарга.

Шулай килеп,
Шулай киткән күпләр,
Чынга ашыралмый хыялын
(Һәрбер инеш
Идел булам диеп
Язлар саен ашый үз ярын).

Ә шулай да максат, хыял барда
Бу дөньяда яшәү – мәгънәле,
Яшәүләрдә мәгънә булган чакта
Йөрәк дәртле,
Күңел кәгъбәле.

Безнең заман булды каршылыклы –
Ак чорлары булды, карасы,
Шуңа күрә безнең чордашларның
Һәрберсендә йөрәк ярасы.

Безнең гомер үтте гел көрәштә,
Аерыйк дип акны карадан,
Күпләребез китте бик вакытсыз
Шул көрәштә алган ярадан.

Ул чорларны күздән кичергәндә
Сез аларны искә алыгыз,
Каберләре исән булганнарның
Каберенә чәчәк салыгыз,
Аларның ак хыяллары калган –
Изге мирас итеп алыгыз.

Минем дә ак хыялларым кала –
Бу дөньяны төрү аклыкка...
Китсен иде җирдән кайгы-хәсрәт,
Урын биреп бары шатлыкка.
Хыялларым мирас итеп китәм,
Яшәвегез булсын мәгънәле:
Яшәвеңдә мәгънә булган чакта
Йөрәк дәртле,
Күңел кәгъбәле.

Зөлфәт
Хәким

# ЛЕГИОНЕР

РОМАН

## 16

Туып-үскән якның җылысын, балачагы узган төбәкнең ямен-тәмен, чит җирләрдә чакта үләр дәрәҗәгә җитеп сагынган табигатьнең аһәңен җаны-тәне белән ничек кенә эстәсә дә, авылдашлары дошман итеп карагач, Яббар туган җирендә басып торудан рәхәтлек тою түгел, хәтта күңел тынгылыгына да ирешә алмый җәфаланды.

Авылдашлары белән аралашырга омтылып карады ул. Әмма аны чит-ят иттеләр, очрашкач әйткән сүзенә коры гына җавап биреп, яисә бөтенләй дәшмичә, аның яныннан тизрәк китү ягын карадылар. Шулай да аның белән гәпләшергә, дөресрәге, төрле авыр сораулар биреп төпченергә тырышучылар бар иде, андыйлардан исә Яббар үзе кача торган булды. Аны аңларга, хәленә керергә теләүчеләр дә юк түгел иде дә... Ләкин Кызылъярдан йөз алтмыш кеше сугыш кырында ятып калды, ике кеше хәбәрсез югалды, күпмесе гарипләнеп кайтты, шулай булгач, ничек акласыннар да ничек якласыннар аның бу хәлдә калуын?!

Тора-бара ул үзе авылдашларының күзенә чалынмаска тырыша башлады. Ә өйдәгеләрдән, туган-тумачадан кайларга качып котылмак кирәк! Телисеңме-юкмы, бер түбә астында йокларга кирәк, күз карашлары белән очрашырга да, сүз катарга да туры килә.

Берданбер кеше аңардан баш тартмады, берданбер олы җан иясе аны элеккечә яратты—әнкәсе. Әминә өчен улы Яббар сатлыкҗан да, легионер да, дезертир да, төрмәче дә түгел, барыбер ул аның баласы, яраткан улы иде. Кече улының газаплануын күреп, ана үзе дә нык иза чикте, баласын бимазалаган хәсрәтнең аз гына булса да өлешен үзенә аласы килеп, аның белән утырып ягымлы иттереп сөйләште, аркасыннан сөйде, җылы, назлы сүзләр әйтте.

Беркөнне Нәгыйм белән Сәет урманга араталыклар әзерләргә барырга җыендылар. Яббар ишегалдында аларга эндәште:

—Мин дә барыйм әле сезнең белән.

—Йөрмә!—диде атасы, кул селтәп.

—Эти, миңа берәр эш куш инде ичмаса,—диде аңа Яббар.

Нәгыйм тавык кетәклегендә тавыкларга көрпә болгатып маташкан Әминәгә ымлады:

—Әнә, анаң кушсын.

*Дәвамы. Башы 9нчы санда.*

Балта, бау алып, Нәгыйм белән Сәет чыгып киттеләр.

Яббар лапаска кереп утын яра торган бүкәнгә утырды. Ул көннәр буе шулай ялгызы, кеше күзенә чалынудан качып үз уйларына чумып утыра да утыра.

Әминә кулына ябышып калган көрпәне сыпыра-сыпыра улы янына килде:

—Кайгырма, улым. Аларның ачуы бервакыт басылыр.

—Мине бөтен авыл күралмый,—диде Яббар хәлсез тавыш белән.—Миннән хәтта җирәнәләр. Китәргә туры килер, ахрысы. Туган авылымда яшәргә мөмкин түгел микәнни?! Мин бәлки туган ягымны артык нык сагынганга шушындый бәлагә дучар булганмындыр да.

—Китмә, улым. Болай да инде бик озак көттем. Мин сине бик сагыначакмын. Китмә. Түз. Халык ул усал да, миһербанлы да.

Анасы өйгә кереп киткәч, Яббар шактый вакыт үзенең караңгы уйларына чумып утырды. Бер мәлне ул бөтен вөҗүде буйлап ниндидер дулкын йөгереп үткәнен тойды. Күңел ниндидер яңа төрле җиксенү белән аны урамга чыгарга әйдәде.

Ул капканы, гадәттәгечә, кысып кына ачты һәм тыкрыкка таба, көянтә-чиләкләрен асып, Фатыйманың барганын абайлады.

Дөнья чайкалып куйды, күз аллары томанланып китте. Фатыйма бит бу! Фатыйма! Үзгәргән ул. Ә шулай да гәүдәсендә дә, йөрешендә дә якын, кадерле чалымнар калган, якынрак килсәң, мөгаен, төс-битендә дә сөеп туймаслык мөлаемлык саклангандыр.

Аны ниндидер көч капкадан этеп үк чыгарды. Аяклары үзләре атладылар. Биш-алты адымнан соң ул якынаерга базмыйча туктап калды.

Бу вакытта Фатыйма инде тыкрык башына җитте, аның адымнары, никтер авырайды, чиләкләр буш булуга карамастан иңнәрендә зур йөк авырлыгын тойды. Арттан кемнеңдер карап торуын сизде ул. Фатыйма туктады, ләкин борылып карарга җөрьәт итмәде. Шулай беравык торгач, Яббарның якынрак килүен теләгәндәй, әкрен генә адымнар белән тыкрык буйлап атлады.

Яббар аны тыкрык уртасында куып җитте.

—Ничек хәлләр, Фатыйма?—диде ул, көчкә сулыш алып.

Фатыйма авылдашларының күзәтүеннән куркып як-ягына карады.

—Ярыйсы,—диде ул чак кына ишетелерлек итеп.

Сугышка озатканнан соң Фатыйманың әле аны якыннан күргәне юк иде. Яббарның кыяфәтен, йөзен, күзләрен күргәч, аның тизрәк китеп барасы килде шикелле, ләкин шул ук вакытта аны ниндидер бер хис урынында калырга мәҗбүр итте. Шул Яббармы соң бу? Йөрәкләрне җилкендереп үзенә гашыйк иттергән шул егетме соң бу? Фатыйма аны кызганып чак кына елап җибәрмәде. Ләкин хәзерге минутта елау Яббарның җәрәхәтле җанын тагы да ныграк әрнетер дип Фатыйма үзен тыярлык көч тапты. Шулай да аксылланып киткән бите буйлап ике күзеннән ике яшь тәгәрәп төште.

Алар шактый вакыт бер-берсен күзәттеләр. Юк, алар инде башка кешеләр, бер-берсенә тартылу да юк шикелле, нәрсәдер сүнгән, үлгән, беткән. Икесенең дә күңелендә әйтеп булмаслык тирән сагыш кына күз яшьләре булып атылырга тора.

—Әйбәттер хәлегез,—диде Яббар карлыккан тавыш белән.—Улыгыз үсеп килә. Гаиләгез тулы. Бик нык үзгәргәнсең. Чибәрлегеңне исә һич кенә дә җуймагансың.

Фатыйма ни әйтергә белми торды, үзенең бәхетле булып күренүеннән хәтта оялып, читенсенеп куйды, Яббар алдында үзен гаепле сизде.

—Син дә бик нык үзгәреп кайткансың,—диде ул боек тавыш белән.

—Үзгәрдем. Миндә бөтен нәрсә үзгәрде. Минем өчен дөнья үзе үзгәрде.

—Нишләргә җыенасың?

Яббар елмайгандай итте:

—Миннән бөтен кеше шулай дип сорый: нишләргә җыенасың? Китәргә туры килер.

—Кая?

—Белмим,—диде Яббар Фатыймага текәлеп.—Син шундый чибәр! Син хәзер гел башкача гүзәл. Бәхетле икәнең әллә каян күренә.

—Хәлләремне үзем генә беләм,—диде Фатыйма сагышлы тавыш белән.—Бәхетлеме, юкмы икәнлеген дә кеше үзе генә белә.

Яббарның күнелен якты хатирәләр дер селкетте. Фатыйма белән кулга кул тотышып болыннарда йөгереп йөргәннәр иде бит алар. Фатыйма хәзер аныкы түгел. Ул инде моннан ун ел элеккеге Фатыйма да түгел. Ул җитлегеп олыгайган, ул инде үзе ана кеше. Күрше йортка килен булып төште ул хәзер. Янәшә генә югыйсә, ә инде бөтенләй ерагайды. Чит кешенеке ул хәзер.

—Шуны әйтәсем килә. Бик сагындым сине,—диде ул халәтен ничек аңлатырга белмичә.—Һич кенә дә мәхәббәтем сүрелми. Хәтта бәгыремә асылынган бәла дә сине яратуымны баса алмый. Син уфтанасындыр инде: шушы сатлыкҗан белән йөргәнием бит яшь чакта дип.

—Син сатлыкҗан түгел,—диде Фатыйма, аның тонык күзләренә карап.

—Бөтен авыл шулай ди бит.

Фатыйманың тагын бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

—Ә мин сиңа ышанам. Син инде халык алдында җитәрлек күп акландың, түбәнсендең. Кирәкми, җитәр. Син мескенләнгән саен, алар сине ныграк басачаклар.

Яббар Фатыймадан мондый сүзләрне ишетермен дип һич кенә дә уйламаган иде.

—Дөрес әйтәсең,—диде ул, кинәт җанланып.—Димәк, син миңа ышанасың?

Фатыйма тагын як-ягына каранып куйды да башын аска иеп:

—Минем күңелемдә син элеккеге якты йөзле, олы йөрәкле, әйбәт егет булып калдың,—диде.—Тик... миңа бик очрамаска тырыш инде. Әнсарның ачуы килә. Кайвакыт, бераз салып алса, көнләшүе чыгып куя. Әле беркөнне: «Теге изменник родины кайткач сәерләнеп, сүрелеп калдың»,—дип бәйләнде.

Яббар башын аска иеп уйга калды.

—Их, Фатыйма!—диде ул, башын күтәреп.—Югыйсә арабызда нибары бер тыкрык кына хәзер. Ләкин ерагайдык бит бер-беребездән!

Фатыйма кешеләр күргәнче китәргә ашыкты.

—Якынайсаң да, ерагайсаң да, халык әйтмешли, язмыштан узмыш юк,—диде ул кузгалганда.

—Әйе, халык әйтә ул,—диде Яббар торган урынында калып. Һәм кинәт өстәп куйды.—Яшь чагыбызны өзелеп сагынам!

Фатыйма туктап борылды:

—Мин дә. Ләкин үтте китте инде ул чаклар, язмыш үзенекен итте. Әгәр дә якты йөз күрсәтмәсәм яисә читләтеп узарга тырышсам, ачуланма. Ирем көнләшкәнгә генә түгел... Мин авыл халкының ихтыярына буйсынырга мәҗбүр инде. Авыл сиңа ничек караса, мин дә шулай карарга тиеш булам. Татарның гап-гади бер хатын-кызы мин.

Ул, тыкрыктан менеп, кая барырга белми аптырап торды, аннары үзләренең читәне буендагы чирәмгә йөзтүбән капланды. Җан сызлавы белән бергә юкка чыгарга иде, иңәргә иде, сеңәргә иде шушы җиргә. Ишетерләр, күрерләр дип уйламыйча, ул сулкылдап елады.

Үзләренең бакчасында түтәл утап маташкан Зәкия аны читән өстеннән үрелеп-үрелеп күзәтте. Аннары эшен ташлап, кызу-кызу адымнар белән

ишегалдың үтте, шыгырдатмас өчен саклык белән генә капкаларын ачып урамга чыкты. Яббарның, гәүдәсен калкытып, коймага терәлеп утырганын күргәч, Зәкия барган жиреннән шып туктап бер мәл генә басып торды да Яббарны танымаган булып кыланып якынрак килде:

—Яббар, синме бу?

—Мин булмый кем булсын тагы,—диде Яббар, ана карамыйча гына.

—Нинди исерек аунап ята дип торам.

—Мәет ята дип уйламадыңмы?

—Әстәгъфирулла!—дип кулын селтәде Зәкия.—Шулай диләрмени!—Шуны сорамакчы идем, авылда калмакчы буласыңмы?

Яббар аның соравыннан көлемсерәп куйды:

—Зәкия апа, ник соң син: «Бу дөньяда калмакчы буласыңмы?»—дип кенә сорамыйсың?

Зәкия кыяфәтенә ясалма курку чыгарып:

—Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Нишләп сүзне гел андыйга борасың?—дигән булды.

—Гел бертөрле сорауларны ишетәм: нишләмәкче буласың, ничек яшәргә җыенасың, авылда каласыңмы, китәргә җыенмыйсыңмы?

—Тагын ни дип сорасыннар инде.

—Син, Зәкия апа, алай карама миңа.

—Ничек?

—Җирәнүле кызгану белән.

—Ялгышасың.

—Син гомумән безнең гаиләгә карата ничектер салкынайдың. Әнкәйне дә хәзер элеккечә якын итмисең. Әнкәйнең ни гаебе бар, ник аның белән аралашмый башладың?

—Сез үзегез кыргыйландыгыз,—диде, Зәкия, акланып.

Килененең тыкрыктан менеп килүен күргәч, ул ана:

—Фатыйма, нишләп бик озак йөрисең?—дип кычкырды.—Чыгып киткәненә бер сәгать бардыр.

—Кая бер сәгать булсын инде!—диде Фатыйма үпкәле тавыш белән.

Фатыйма тизрәк, Яббар ягына карамаска тырышып, сулга каерылды, Зәкия, җил-җил атлап аны кертергә дип барып капкаларын ачты.

Яббар, коймага сөялгән килеш, үзенең караңгы хатирәләренә чумып әле бик озак утырды.

## 17

825 нче батальонны фронтка озату тантанасы 1943 елның 14 февралендә узды.

Оркестр тавышы, җилфердәгән байраклар, күңел тулы курку катыш өмет, күз карашларын билгесезлеккә төбәгән легионерлар... Фронтка китүчеләр алдында чыгыш ясаучылар шактый иде. Яббар бигрәк тә Берлиннан Едлинога доклад белән килгән профессорның чыгышын яхшы хәтерли. Ул урысча да, вата-жимерә татарча да авыз кырыйларын күбекләндереп, вакыт-вакыт ярсуга күчеп, сөйләде дә сөйләде. Мондый чыгышлар ясап шомарып беткән бу пропагандистның һәрбер җөмләсе тавышының сирәк очрый торган бай тембры белән бергә нык тәэссоратка ия иде. Ул бик оста, урыны-урыны белән тетрәндергеч итеп, большевикларны юк итәргә өндәде, Гитлер татар дәүләте төзиячәк, дип кат-кат кабатлады.

18 февраль төнендә батальон Витебскига килеп житте, шуннан Суражски шоссесы буенча Белыновичи авылына таба юл алды. Батальонның төп өлеше Көнбатыш Двинаның сул ягындагы Гралево авылында урнашты.

Батальон оешкан вакыттан бирле үк легионерлар арасында үзебезнекеләр

ягына—Сәвит армиясе ыстанына чыгу турында берөзлексез пыш-пыш килүләр туктамады. Ләкин арада чын сатлыкҗаннар да бар иде. Сталин режимына каршы көрәшергә ихластан ризалык биреп корал алганнар янында мондый сүз сөйләү үлемгә тиң. Инде берничә кеше шулар аркасында харап та булды. 900 кешенең 70 кә якыны немецлар (болар батальонның командирлар составы) һәм ихластан дошман ягына чыгып сәвит армиясенә каршы сугышырга теләк белдергән сатлыкҗаннар булганлыктан, легионерлар арасында шомлы, аңлашылмаслык атмосфера хөкем сөрүе табигый иде.

Партизаннар актив хәрәкәт иткән тарафларга якынайган саен, үзебезнекеләр ягына чыгу теләген батальон легионерларының күбесе белдерә иде инде. Тажиев, Рәхимов һәм Мөхәммәтов фамилияле кешеләр партизаннар ыстанына чыгуны оештырачакларын Яббар ишетеп кенә белә иде, роталар арасында элемтәне исә махсус кешеләр тәэмин итеп торды. Яббар бер икеләнүсез тизрәк үзебезнекеләр янына качу турында хыялланды.

21 февральдә легионерлар тарафыннан партизаннар белән элемтәгә керү өчен дүрт парламентер җибәрелә. Партизаннар үзләренең шартларын куялар: беренчедән, партизаннар ягына күчәр алдыннан батальон немец офицерларыннан торган командный составны юк итәргә, шуннан соң Сеньково, Гралево, Сувары авылларындагы немец гарнизоннарын тар-мар китерергә тиеш. Икенчедән, легионерларга партизаннар ягына өч төркемгә бүленеп күчәргә кушыла. Өченчедән, партизаннар ыстанына чыкканнан соң, легионерлар коралларын ташлап, боеприпасларын партизаннарга тапшырырга тиеш булалар. Бу шартларны, әлбәттә, партизаннар үзләренең куркынычсызлыгы өчен куялар.

Сөйләшүләр барышында карар кабул ителә—22 февральдә 23 сәгатьтә легионда гомум восстание күтәрергә һәм легион, кораллары, сугыш кирәк-яраклары, җиһазлары белән, партизаннар ягына чыгарга тиеш.

Кызганычка каршы, батальондагы немец офицерлары фетнәчеләрнең планнарын сизәләр һәм баш күтәрер вакытка бер сәгать калгач, восстаниенең җитәкчеләре Тажиев белән Рәхимов кулга алына. Штаб ротасының командиры Хөсәен Мөхәммәтов, үзен аямыйча, шул хәлиткеч вакытта җитәкчелекне үз өстенә ала. Немец офицерларын үтереп, төрле авылларда урнашкан подразделениеләргә сигнал бирелә һәм восстание башлана. Бары тик икенче ротаның ике взводына гына хәбәр итә алмый калалар.

Партизаннар бригадасының командиры Бирюлин шул ук төнне Партизан хәрәкәтенең төп штабына хәбәр итә: «... Безнең якка 506 кеше чыкты, үзләре белән өч 45 миллиметрлы пушка, алты станоклы пулемет, дүрт батальон минометы, 22 кул пулеметы, 430 автомат, 76 пистолет, 26 ат һәм башка күп нәрсәләр. Легионерлар Захаров һәм Бирюлин җитәкчелегендәге партизан отрядларына беркетелделәр...»

Партизаннарга кушылган легионерлар шундук вермахт армиясенә каршы сугышта катнашалар. Бигрәк тә 1943 елның 28 февралендә блокададан чыкканда каты сугыш була.

Смерш контрразведкасы батальонның партизаннар ягына чыгу тарихын, сәбәпләрен, нечкәлекләрен җентекләп тикшерә. 1943 елның июнь азагында Подольск шәһәрендә урнашкан 174 спецлагерьның контрразведка бүлеге начальнигы майор Кирсанов һәм шул ук лагерьның контрразведка начальнигы Сизов Мәскәүдә урнашкан Партизаннар хәрәкәтенең Белоруссия штабына 825 нче батальонның безнең якка чыгуы турында отчет җибәрәләр: «... Подольскидагы спецлагерьда милләтләре буенча татар булган элекке кызылармеецлар бар. Алар әсирлектә чакта немецлар оештырган Идел-татар легионына хезмәткә кергәннәр һәм партизаннарга каршы сугышырга җибәрелгәннәр...»

1943 елның 2 июлендә партизаннарның Белоруссия штабы хәбәр итә:

... «Батальон партизаннар ягына чыкканнан соң, аның составы партизан отрядларына таратылды һәм легионерлар немец оккупантларына каршы сугышта катнашалар...»

Әйе, легионерларның 825 нче батальоны партизаннар ягына чыккач, аның составының зур өлеше төрле отрядларга таратыла. Ләкин кайберәүләргә бик җентекле тикшерү, допрослар аша үтәргә туры килә. Аларны Подольскида урнашкан фильтрация лагерена алып киләләр. Монда шик астына алынган легионерлар төрле сәбәп белән эләгә—тәрҗемәи хәлләрендәге мәгълүматлардагы чуалыш аркасында, кемнендер шикаяте нәтиҗәсендә, үз-үзен тотышы сәер күренеп, ничек һәм нинди шартларда дошманга әсир төшүен исәпкә алып. Тагын әллә нинди сәбәпләр белән тикшерү үтәләр.

Яббар да эләкте бу лагерьга. Партизаннар отрядындагы НКВД вәкиле анарга мондый сорау биргән иде:

—Легионга иң беренчеләрдән булып кемнәр керде?

Яббар белә иде ул кешеләрне. Ләкин әйтмәскә булды һәм болай дип җавап бирде:

—Мин исән калып үзебезнекеләр ягына чыгар өчен легионга керергә карар кылдым. Каяндыр агитаторлар килеп әйдәгәннән соң. Мин легионга кергәндә анда инде кеше күп иде, мин кемнәр беренче кергәнне әйтә алмыйм.

—Синең дустың, Башкортстаннан, Хәнәфиев иң беренчеләрдән булып немец формасын кияргә өндәгән бит, моны белмәденмени?

Әйе, Башкортстан егете Хәнәфиев Габделбәр белән Яббар дуслар иде. Легионга кереп исән калу һәм фашистлардан котылып үзебезнең ыстанга чыгу турында алар бергәләп хыялланып йөрделәр. Әле Яббар икеле-микелеләнеп йөргәндә Габделбәр инде катгый карар кылып, легионга беренчеләрдән булып язылган иде.

Әмма Яббар, Габделбәрнең язмышы өчен куркып, дөресен әйтмәскә булды.

—Без якын дуслар түгел идек. Йоклый торган урыннарыбыз янәшә иде. Мин аның кая, ник, нинди оешмага язылганын беркайчан да сорамадым, үзенең дә әйткәне булмады. Аның беркемне дә өндәгәнен яки легионда яхшы булачак дип сүз катуын ишетмәдем. Ялгышмасам, без легионга бер тирәдәрәк кердек, ләкин бер-беребезне үгетләп түгел.

Аның мондый җавабын НКВД вәкиле ошатмады. Чөнки Хәнәфиев Габделбәр өстеннән бик күп шикаятьләр, күрсәтмәләр җыелып шактый материал тупланган иде инде. Аны хөкем итәчәкләрендә шик юк иде. Хәнәфиев өстеннән күрсәтмә бирмәгәне өчен Яббарны да фильтрация лагерена озаттылар.

Күпмесен хөкемгә тартканнардыр, ничәсен кире партизан отрядларына кайтарганнардыр, Яббарга мәгълүм булмады. Ә аның үзен исә, ике атна чамасы кат-кат допрослаганнан соң, егерме дүрт кешедән торган элекке легионерлар төркеме белән янә Бирюлинның партизаннар бригадасына илтеп тапшырдылар.

## 18

—Күрше! Туктале!

Яббар Хәлиулланың тавышын ишетеп туктады, аның салмак кына атлап килүен сабырлык белән көтте.

—Нәрсә, Хәлиулла абый?—диде Яббар, юньле әңгәмә булмасын алдан ук сизенеп.

—Күптән синең белән сырты ихластан сөйләшәсем килә,—диде Хәлиулла, маңгаендагы тирен кул белән сыпырып.—Монарчы һич кенә дә җай чыкмады.

—Минем ише белән сөйләшергә теләгәнең өчен рәхмәт инде. Дөрес, синнән җылы сүз ишетмәячәгемне дә алдан ук белеп торам.

—Ярар, сүз башланмаган килеш шыңшырга тотынма әле,—диде Хәлиулла.—Мин сиңа начарлык теләмим ләбаса. Мин шуны сорамакчыем... Әгәренки легионга кермәгән булсаң, үтерерләр иде микәнни?

—Немесләрме? Бәлки үтерерләр иде... Белмим... Минем тизрәк үзебезнекеләр ягына качасым килде.

Хәлиулла чыраена ясалма борчылу чыгарды:

—Менә ышанмыйлар шул! Бер дошман киемен кигән кешегә ышанасылары килми шул.

Яббар төссезләнгән күзләре белән читкә карады:

—Син минем ныграк газаплануымны телисеңме, шуңа бу турыда сүз катасыңмы?

Хәлиулла усал гасабилык белән кызу-кызу сөйләргә тотынды:

—Юк, миңа, киресенчә, синең бимазалануыңны күрү авыр. Менә сиңа алга таба нишләргә икән дигән сорауга бергәләп җавап табып булмасмы дигән идем. Син, минемчә, авылга кайтып дөрес эшләмәдең. Беркавым читтә яшәгәч кайтырга идең.

—Мин авылымны, туган ягымны сагындым,—диде Яббар ишетелер-ишетелмәс итеп, гүя ул аны кемгәдер түгел, ә үз-үзенә генә әйтте.—Әнкәйне сагындым.—Ул Хәлиуллага туры карап өстәп куйды.—Әнкәйне бүтән күрә алмам дип куркып легионер киемен кидем дә инде мин.

—Сине хәзер кайда нинди рәтле эшкә алырлар икән? Шулай да, уйлавымча, авылда калмасаң яхшырактыр.

—Мин сиңа комачаулыйммы?—диде Яббар, кинәт кызып.—Мин кайтканнан тормыш бозылдымы? Син әйткән киңәшләрне мин әллә ничә кат ишеттем инде. Мин үзем дә меңләгән вариантларны башымнан уздырдым!

Аларның сөйләшеп торуларын Әнсар койма ярыгыннан күзәтте. Яббарның җикергәнен ишеткәч, ул атылып урамга чыкты. Аның җил кызулыгы белән килеп җиткәнен сизми дә калдылар.

—Әти, сине әнкәй чакыра, бар, өйгә кер,—диде ул атасына, эчке ярсуын яшерә алмыйча...

Хәлиулла Яббарга:

—Олы кеше сүзенә колак салсаң, үзең өчен яхшы булыр дип уйлаган идем,—диде дә өйләренә таба юнәлде.

—Рәхмәт!—дип кычкырды Яббар аның артыннан усал тавыш белән.—Миңа яхшылык теләп әйтмисең син сүзеңне!

Әнсар атасының капкадан кереп киткәнен көтеп торды да Яббарны түшеннән йомарлап тотты:

—Син нишләп тавышыңны күтәрәсең, ә?

—Миңа бернинди киңәш тә, үгет-нәсихәт тә кирәкми,—диде Яббар тыныч кына.

—Моннан ары минем әтигә җикермә!—дип кычкырды Әнсар Яббарның битенә төкрекләрен чәчеп.—Аңладыңмы?!

—Син миңа бала чактагы сыман бәйләнергә маташасың. Берегез дә миңа килеп вәгазь укымагыз! Нотыкларыгызның кирәге юк—миңа да, сезнең үзегезгә дә! Миңа киңәшләр бирүегез ул фәкать мине күралмавыгыздан. Миңа карата булган нәфрәтегездән!

—Син изменник Родины!

—Мин изменник түгел!

Әнсарның ярсуы тәмам бәреп чыкты:

—Син бук! Һаман акланмакчы буласыңмы?! Тикмәгә утыртмадылар сине! Изменник Родины!

Яббар куркудан түгел, ачудан, эчендә кайнаган давылдан калтырана башлады:

—Мин бүтән беркайчан да, беркем алдында да акланмаячакмын! Кешене анларга теләмәүләре аркасында анда лагерьлар тутырук. Анда тикшерүчеләр нәкъ менә син хәзер мина ышанмаган шикелле ышанмыйлар. Бәлага дучар булган миллионлаган кешеләрнең сүзенә колак та салмыйлар, хөкемгә тарталар, таптыйлар, бетерәләр, юк итәләр.

Әнсар муенындагы кан тамырларын бүртереп кычкырырга тотынды:

—Мин Туган ил алдында, партия алдында үз бурычымны намус белән үтәдем, дошманны көнбатышка кудым, яраланып, офицер званиесендә, орден-медальләр белән кайттым. Минем кебекләр синең ишеләргә беркайчан ышанмаячаклар, һәрвакыт хөкем итәчәкләр! Анладыңмы, изменник?!

Бу вакытта Нәгыйм белән Сәет урманнан кайтып киләләр иде. Алар капка төбендә Әнсар белән Яббарның якалашуын еректан ук шәйләделәр. Сәет Әнсарның Яббарга нинди сүзләр әйткәнен дә аермачык ишетте.

—Бу кадәре нәфрәтен белән тончыга күрмә,—диде Яббар тыныч кына.

—Авылда эзең дә булмасын!—дип акырды Әнсар, йодрыкларын төйнәп.— Мин сина монда барыбер тормыш күрсәтмәячәкмен!

Шулчак ана Сәет ерактан ук эндәште:

—Силсәвит рәисе булсаң да, синең кешене авылдан куарга тулы полномочиең юк!

—О-о-о, бала чактагыча энекәшенне яклыйсыңмы?—диде Әнсар, кайтып килүчеләргә таба борылып.

—Аны яклаучы юк, сина да монда командовать итәргә ирек бирүче юк,—диде Сәет коры гына.

—Влач кешесе белән ызгышма инде,—дип пышылдады Нәгыйм, улына терсәге белән төртеп.

Сәет кинәт атасына жикерде:

—Ызгышса! Без бит бөтенебез дә сатлыкжаннар түгел!

—Син дә энең белән бергә бер бәйдә китмәгәең,—диде Әнсар, Сәетнең кулындагы балтадан бераз шүрләп.

—Китмәм,—диде Сәет аз гына да курыкмыйча.—Мин Берлинга барып житкән кеше. Яббар жәзасын алды, аның газабы гомере буена житәрлек. Синең бугаз киереп кычкыруыннан бернәрсә үзгәрмәячәк. Яббарга авылда калу зуррак кайгы китерәме, әллә китүеме—кем белгән.

Нәгыйм матавыкның зурга китүеннән куркып тизрәк Яббарга эндәште:

—Яббар, бар, ананa кереп әйт әле, самавыр куйсын.

Яббарга шул гына кирәк иде дә, ул капылт кына капкадан кереп китте.

—Әти, бар син үзең дә кереп кит әле,—диде Сәет басынкы тавыш белән, атасына жикергәненә үкенеп.

—Мин керермен,—диде Нәгыйм, авыр сулап.—Балакайлар, сез икегез дә дошманны жинеп кайткан егетләр. Үзегездәге дошманлыкны да жинегез инде! Сез бит ир кешеләр.

Аның күзләре дымланды. Жиңе белән күз яшьләрен сыпырды. Тагын нидер әйтергә теләде, ләкин сүз табалмады, кулындагы бауны иңенә асып, Сәетнең кулындагы балтаны алды да, капкадан кереп китте.

Сәет белән Әнсар беравык сүзсез калып бер-берсенә карап тордылар.

—Яббар безнекеләргә бер тапкыр да атмаган,—диде Сәет тыныч кына.

Әнсар көлемсерәп куйды:

—Аның сүзенә ышанасыңмы?

Сәет Яббар кайтканнан бирле беренче тапкыр энекәшен яклап сүз әйтте:

—Ышанам. Син ул, авылдашың була торып, шуны исбатларга булышмагансың. Синең бит ничек тә булса ярдәм итәргә мөмкинлекләрең булгандыр.

—Фильтрация лагерындамы?!—диде Әнсар гаҗәпләнеп.—Син нәрсә! Анда берничек ярдәм итү мөмкин түгел. Ярдәм итә алсам, үземне дә изменник дип шуларның этабы белән җибәрерләр иде. Әле мин ана ипи белән махорка биргәннән соң да бер атна куркып йөрдем—берәрсе нәчәлствога әләкләп үземне кулга алмаслармы дип.

—Без күршеләр булсак да гел чәкәләшеп үстек. Алга таба да шулай дәвам итәр микәнни? Олыгаймадык микәнни?

—Без күршеләрмени?—диде Әнсар.—Безнең арада тыкрык бар бит. Ә хәзер инде тыкрык кына да түгел.—Ул авызын чалшайтып ямьсез иттереп көлде.—Күршеләр... Безнең арада хәзер—оһо-һо!

Ул куен кесәсеннән папирос алып капты. Аннары чалбар кесәсеннән шырпы кабын чыгарып селкетеп карады. Кап буш булганга, ул аны читкә ташлады да, папиросын авызына капкан килеш, тиз-тиз атлап үз өйләренә таба китеп барды.

Сәет ишегалдына кергәндә Яббар лапас буендагы бүрәнәдә утыра иде.

—Абый, чынлап та нишлим икән?—диде ул Сәет анын янына килеп утыргач.

—Теләсәң нишлә!—диде абыйсы.

—Асылыныйм микән әллә?

—Үзеңә кара.

—Әнкәй кызганыч.

—Менә шул-шул!—диде Сәет ачу белән.

Яббар абыйсына таба борылды:

—Абый, мин сатлыкҗан түгел, ышанасыңмы?

—Әсир төшеп, фашист формасы кигәнсең, янадан фронтка килгәнсең... Шулай булгач, синең сатлыкҗан түгеллегеңә кем ышансын?

—Абый, мин бит фронтка килү белән үк үзебезнекеләр ягына чыктым!

—Ә ник әсир төштең?

—Ничек инде...

—Ник качарга тырышмадың? Ник йөгермәдең? Йөгерсәң, аткан булырлар иде, хәзер оят, хурлык кичереп ятмас идек, бимазаланмас идек.

—Их, абый! Син дә ышанмыйсың. Бала чакта син бик гадел идең, абый. Гаебем булса әрли идең, хәтта тәпәләп тә ала идең. Берәр яхшылык эшләсәм, мактый идең. Син минем өчен һәрвакыт олы һәм абруйлы булдың. Минем өчен син хәзер дә шулай ук абруйлы, тик кая китте синең гаделлегең?! Хәтерлисеңме, син бер тапкыр су буенда күн каеш тапкан идең. Мин аны малайларга мактанып күрсәтергә алып чыктым. Аннан җыелышып урманга киттек. Каешны шунда онытып калдырганмын. Кайткач, син мине бик каты ачуландың да, бар кире урманга, каешны алып кайт, дип куып чыгарып җибәрдең. Мин елый-елый киттем. Ярты юлны узгач, син мине кызганып куып җиттең. Күзләреңдә яшь иде. Шунда синең мине нык яратуыңны тойдым, абый. Син мине кочаклап: «Энекәш, ни пычагыма ул каеш, караңгы төшеп килә, әйдә өйгә»,—дидең. Кайткач әле миңа сыбызгы бүләк иттең. Ул сыбызгыны мин бүген өй базында таптым. Мин аны югалткан идем, базга төшкән булган икән. Егерме ел яткан базда, череп беткән.

Сәет энесенең сөйләгәне тәэсирендә ни әйтергә белми торды. Аның үзенең дә тамагына төер тыгылды. Күнеле тәмам җебеп киткәнче коры гына әйтеп куйды:

—Синең аркада беребезгә дә көн булмаячак. Кайтмаска иде сиңа.

—Кайтмас идем... Әнкәй бар бит.

Сәет каядыр югалып торган усаллыгын тагын барлап:

—Син хәзер анын иң зур кайгысы инде!—дип урыныннан кузгалды.

Өйалды ишеген ачыйм дигәндә, ул энесенен лапаска йөгереп кереп киткәнен шәйләде. Сәет анын артыннан лапаска атылды. Яббар инде эленеп торган бауны алган, калтыранган куллары белән элмәк ясап маташа иде. Сәет бауны тартып алмакчы иде, Яббар читкә тайпылды. Аннары бавын тоткан килеш лапастан чыгып йөгерде. Сәет аны сарай артындагы тирес өеме янында куып тотты, чалып егып, бауны тартып алмак булды. Ләкин Яббар бауны ычкындырмады.

—Җибәр!—дип ыңгырашты Яббар, абыйсынын кулыннан азат булыр өчен бәргәләнеп.

Сәет анын кулын каера алмый җәфа чикте:

—Нишләргә җыенасың? Тинтәк!

—Асылынам!—дип үкерде Яббар аста яткан килеш.

—Менә асылынырмын мин сиңа!—диде Сәет, ниһаять бауны талап алгач.

Яббар шашынып тирес саламында аунады:

—Яшисем килми!

Сәет бауны биләгенә урый-урый:

—Әнкәй бар бит, җүләр!—диде.—Әнкәй барлыгын оныттыңмы әллә?! Асылынсаң, ул нишләр?!

—Нишлим со-о-он?!—дип үкерде Яббар, абыйсына күзләрен акайтып.

Сәетнең күңелендә аз гына кыймылдый башлаган кызгану хисе урынына тагын рәхимсезлек урын алды:

—Син инде җайлы гына үлеп китү ягын карама. Хәзер инде ахыр чиккә кадәр үзеңнең хәсрәт йөгеңне күтәреп барырга тиешсең! Котылмакчы буласыңмы? Ә без бу хурлыктан ничек котылырбыз?

—Абы-ы-ы-й!!!—дип улады Яббар, чалкан ятып.

Абыйсы исә анын елаудан туктаганын көтеп торды да:

—Авылдан кит!—диде.

## 19

Яббар партизаннар отрядына кире эләгүенә куанып туймады. Хәзер инде сатлыкҗан дигән яман аты да юылыр, легионер булганы да тора-бара онытылыр. Бәлки ата-анасы, Фатыйма, туган-тумача, авылдашлар бөтенләй белми калырлар дошман киемен киеп йөргәнен. Сугыш дәвам итә. Үлем куркыта куркытуын, ләкин әле күптән түгел кичергән халәте үлемнән дә яманрак түгел идемени?!

Хәер, легионга кермәгән булса, бәлки бүген бу дөньяда йөрмәс иде инде. Бүген исә анын җанын өмет җылыта—сугыш тәмамлангач, ул, Алла боерса, Туган илгә, Кызылъяргa кайтып ата-анасы, Фатыймасы белән очрашачак.

Ләкин хыялдагыча гына булып чыкмады шул. Хата дисәң хата түгел, аң томаланды дисәң, алай әйтү дә дөрес микән... Югыйсә отрядта ана партизаннарнын мөнәсәбәте яхшы иде, чөнки ул төрле заданиеләрдә үзен батыр, оста сугышчы итеп күрсәтте. Инде анын легионга үзебезнен якка чыгу хәйләсе белән кергәнлегенә шикләнүче юк иде, аны сатлыкҗан дип беркемнен кычкырып атаганы ишетелмәде. Дөрес, кырын караучылар бар иде, әмма андый гына өнәмәүләр дошман итүмени инде ул. Биографияләренә бөтенләй тап төшмәгән партизаннарнын да үзара мөнәсәбәтләре төрле вакытта төрлечә иде әле.

Отрядта үз урынын табып, үзен Ватан өчен кан коярга әзер сугышчы итеп таныткач, тагын кулга алырлар һәм хөкем итеп ерак Себергә җибәрерләр дигән уй Яббарнын башына да килмәгән иде. Соныннан ул үзен нык битәрләде, үкенде, уфтанды шикелле, ләкин шул ук вакытта башкача мөмкин түгел иде дигән уй-фикер белән килешеп яшәде.

Нәрсә этәрде аны, нинди көч әйдәп чыгарды урман авызыннан ул немецны күмәргә?.. Ник атты соң ул аңа?! Атмаска да мөмкин иде бит. Аткач, ник барып карарга, ник күмәргә тотынды соң?..

Болай булды ул хәл. Яббарны Пилипенко фамилияле бер украин егете белән урман авызында каравылга куйдылар. Чигенеп баручы немец полкының калдыклары, урманнан чыгып, Калинковичи авылындагы гарнизоннары белән кушылдылар. Аларны эзәрлекләп баручы партизаннар да урман эчендә таралып-таркалып калганнар иде. Отряд командиры алдан кечкенә бер төркемне урман авызыннан немецларның Калинковичидан кайсы тарафка китүләрен күзәтергә җибәрде. Урманда берән-сәрән калган фашистларны юк итү белән мәшгуль булганлыктан, партизаннар бер юнәлештә җыйнала алмый интектеләр. Күзәтергә җибәрелгән төркемнең җитәкчесе Яббар белән Пилипенконы урман авызында калдырды, калганнары кире урман эченә кереп киттеләр.

Калинковичи авылында ыгы-зыгы купты. Фрицлар ашыга. Аларны юк итәргә тиешле дивизия шактый ерактa әле, ләкин якында гына, урманнарда яшәп, утны-суны кичеп оста сугышырга өйрәнгән тәҗрибәле партизаннар һөҗүм итәргә тора. Немецларның аларга каршы торырлык көчләре юк инде бу тирәдә. Алар тизрәк качып үзләренең төп гаскәрләренә кушылырга ашыга.

Авылдан уннан артык йөк машинасы, берничә танк, жиде-сигез броневик, йөкле атлар, мотоцикллар чыкканы күренде. Берникадәр вакыт узгач, шау-шу, техника тавышы, командалар ишетелми башлады—немецлар киттеләр.

Пилипенко бу хакта кичекмәстән отряд командирына хәбәр итәргә кирәк дип, Яббарны үзен генә калдырып, урман эченә йөгерде.

Ун-унбиш минут чамасы вакыт үткәч, Яббар бер йөк машинасының кире авылга таба килгәнен абайлады. Авыл белән урман арасында ярты чакрым ара бар, кайчандыр иген кыры булган, ахрысы, монда. Авыл өстәрәк урнашкан, кырга чыга торган юл авыл кырындагы шактый текә калкулыктан аска таба төшә. Күптән түгел яңгыр явып узганлыктан, машина юлдан кырга таба төшмәде, туктады. Машина арбасыннан берәү сикереп төште дә кырга йөгерде.

Урман ягына—үзенә таба йөгереп килүче дошманны күреп Яббар аптырап китте. Күрәсең, фрицлар партизаннарның бу тирәгә үк килеп җиткәннәрен белмиләр. Чөнки алар үзләре кичә генә урман эчендә иде. Шуна күрә курыкмый-нитми килә немец урманга таба. Коралсыз. Ник килә икән ул? Яббар каушанкырап артка борылып карады—юк, Пилипенко да, башка иптәшләре дә күренми, урман гына үз көенә шаулап тора. Яббар винтовкасының затворын саклык белән генә тартты.

Ләкин немец кыр уртасында туктап нәрсәдер эзләргә тотынды.

Нәрсә эзли икән ул? Берәр серле мәгълүматлы документларнымы? Әллә үзенең берәр документынмы? Пүчтәк кенә нәрсә артыннан кире килмәс иде.

Машина янында кул болгый-болгый кычкыра башладылар.

Атаргамы, юкмы? Бер немецның урман белән авыл арасындагы кырда нидер эзләгәнне командирга барыбер әйтергә кирәк булачак. Ник ычкындырдың, ник атмадың дип тенкәгә тиячәкләр.

Ә теге машина монда килсә һәм фрицлар урманны капшый башласалар?.. Атарга да, машина монда килә башласа качарга кирәк булыр. Әллә атмаскамы? Тигезеп буламы, юкмы бит әле.

Менә немец иелеп җирдән нәрсәдер алды. Тапты, ахрысы, эзләгән әйберсен. Нәрсә икән ул?

Немец кулын болгый-болгый иптәшләренә кычкырып шатлыклы аваз бирде. Аңа җавап итеп машина ягыннан тавышлар ишетелде.

Шул вакытта Яббар мылтыкны төбәп атып җибәрде. Немец инде үзләренекенә таба бер-ике адым атлаган иде. Ул кинәт туктады, бер мәл тораташ булып катып торды. Тагын берничә адым авылга таба атлады да урман ягына борылып карады.

Шуннан соң Яббар аның чалкан ауганын күрде. Тиде.

Машина монда таба кузгалса, Яббар урман эченә йөгерергә әзер иде. Әмма машина кузгалды да, урманга таба түгел, килгән юлыннан китеп барды һәм тиз арада күздән югалды. Партизаннар инде урман авызына ук килеп житкәннәр дип уйладылар, ахрысы, хәтта кырда ятып калган иптәшне дә килеп алырга җөрьәт итмәделәр.

Яббарның окоплардан күп тапкыр дошман ягына атканы бар, ләкин тигезгәне, берәрсен үтергәне булды микән—күргәне дә, белгәне дә юк иде. Ә хәзер ул менә аермачык белә—кеше үтерде ул. Бәлки, исәндер фриц? Бәлки, яраланган гынадыр. Урыныннан кузгалып ул әкрен генә урманнан чыкты һәм винтовкасын әзер тоткан килеш, кыр уртасында яткан дошман гәүдәсенә таба атлады.

Немецлар туктап торганнар икән бу урында. Мөгаен, ял итәр өчен түгел, ә бәлки тирә-яктагы обстановканы өйрәнеп үзләре өчен карар кылырга—нишләргә, кайсы тарафка юл тотарга, авылга керергәме, урманда урнашыргамы, әллә төп гаскәрләргә кушылыр өчен марш-бросок ясаргамы. Монда чүп-чар, тәмәке төпчекләре, тушенка банкалары, иске гәҗит кисәкләре, саргаеп беткән листовкалар, кеше хаҗәтеннән калган күп төрле пычраклыклар бар иде.

Немец тере түгел иде. Яббар аның чалкан ауганын аермачык күргән иде. Күрәсең, җан биргәндә ул әле җирдә аунаган—гәүдәсе иләмсез кыяфәттә кәкрәйгән, әйтерсең лә аны башыннан һәм аякларыннан тотып сыгарга теләгәндәй боргалаганнар. Янагын җиргә куеп нәрсәдер тыңларга теләгән дә сыман, шул ук вакытта сыңар күзе белән күк тарафыннан ни дә булса абайларга тырышкан кебек акайган. Пуля калак сөяге астына тигән.

Яббар үтергән немец—утыз-утыз биш яшьләрдәге унтер-офицер иде. Аның янында яткан чүпрәк төргәкне чишеп карагач, Яббар аңлады—унтер-офицер үзе өчен бик кадерле булган фоторәсемнәрне һәм өйдән килгән хатларны төшереп калдырган да, шуларны алырга дип кире килгән.

Фоторәсемнәр арасында берсе аеруча игътибарны җәлеп итте. Анда олы яшьтәге ир кеше белән хатын-кыз—алар алда урындыкларда утыралар. Ир кешенең алдында ике-өч яшьлек малай утыра. Арттa шушы унтер-офицерның әле бөтенләй яшь чагы, кырыенда ап-ак йөзле чибәр ханым. Бу рәсемгә карагач шундук аңлашыла: рәсемдә аның ата-анасы, хатыны, атасының алдында оныгы, ягъни моның баласы. Бик кадерле карточка булган инде бу, шуңа күрә берәр солдатны җибәрәсе урынга үзе кире килгән.

Озак карап торды Яббар фоторәсемгә. Аның башы чайкалып китте. Ник атты ул бу немецка? Китсен иде үзләренекеләр белән. Бәлки исән калып Германиясенә кайтып җитәр иде. Гаиләсен, ата-анасын күрер иде. Хатынын, улын кочагына алыр иде.

Яббар мәетне җайлап чалкан яткырды. Күзләрен йомдырды. Һәм ике дә уйлап тормыйча, каешындагы сапер көрәген алып кабер казырга кереште.

Каберне бигүк тирән казый алмады ул, хәле тиз бетте. Мәетне казылган чокырга сөйрәп төшергәч, фоторәсемнәр белән хатларын чүпрәгенә төреп аның күкрәге турысына кителе эченә тыгып куйды.

Шул вакытны ул урман ягыннан үзенә эндәшкән авазларны ишетте. Күп тә үтмәде, ул казыган кабер тирәсендә партизаннар аптырап басып торалар иде инде.

—Нишлисен?—дип сорады отряд командиры.

—Мин кеше үтердем,—дип җавап бирде Яббар, немецны күмә-күмә.

—Син урман авызында каравылда торырга тиеш иден. Ник чыктың?

—Бу нимес кырга килеп әйберләрен эзләп йөрде, мин аны атып үтердем.

—Ник соң син аны күмеп ятасың?

—Ә кем күмсен аны?

Яббарның сәерлегеннән барысы да таң калдылар.

—Бәлки, син аны атып үтергәненә дә үкенәседер әле?—диде Пилипенко.

Яббар дәшмәде.

—Кадерле кешесемени—өф-өф итеп күмеп ята! Легионда чактагы танышыңмы әллә?

—Юк, таныш түгел,—диде Яббар кабер өстендәге балчык өемен көрәге белән тигезли-тигезли.

Шул ук көнне партизаннар Калинковичи авылына керделәр. Вакытлыча авыл мәктәбендә урнашкан штабка Яббарны партизаннар бригадасының НКВД вәкиле каршысына алып килделәр. Кыска гына допростан соң Яббарны нindidер келәткә бикләп куйдылар, ә икенче көнне Гомельгә баручы полуторкага утыртып ике конвоир сагы астында Гомель шәһәренә озаттылар. Вакытлыча гына оештырылган мондагы фильтрация лагеры Подольскиныкыннан нык аерылып тора иде. Тегесе аның предварительный тикшерү өчен, сортировка өчен генә файдаланылса, Гомельдәгесе исә инде контрразведка тарафыннан нык тикшерелүчеләрне җыйнаган лагерь иде. Вакытлыча дип төзелсә дә, мондагы хәлләрне күргәч, бу мәхшәрнең чиге-азагы буласына ышанырлык түгел иде.

Контрразведка капитаны коры сөякле, урта яшьләрдәге кеше, папиросын күзләрен чекрәйтеп суыра-суыра башта бик озак нидер кучереп язды. Аннары сорау алу башланды. Яббарның исем-фамилиясен, ата-анасының исемнәрен сорашканнан соң, кыскача тәрҗемәи хәлен, ничек әсир төшүен, нинди шартларда легионга керүен, аннары ни сәбәпле партизаннар ягына чыгуын тәфсилләп сөйләтте.

Шуннан соң капитан Яббарның немец офицерын атып үтерү вакыйгасына ныклап тукталды.

—Димәк, син урман авызында берүзең калдың?

—Әйе.

—Синең иптәшең Пилипенко фашистларның китүе хакында командирыгызга әйтергә дип үзе киттеме, әллә син тәкъдим иттеңме?

—Үзе тәкъдим ясады, мин килештем, шуннан соң китте.

—Немецларның соңгы машинасы киткәч үк урманнан чыктыңмы?

Яббар инде йөзенче кат кабатлагандыр:

—Машиналар китеп ун-унбиш минут чамасы үтте. Бер машина авыл янына кире борылды. Шул тарафтан берәү кыр буйлап килде.

—Сине абайламы?

—Юк инде, ничек күрсеннәр, мине күрерлек түгел иде, мин бит урман эченнән күзәтеп яттым. Чыкмадым, күренмәдем.

—Ник күмәргә булдың син дошман офицерын?

—Машиналары китеп баргач, тере түгел микән дип барып карадым мин аны.

—Бәлки, сез элек аның белән очрашкансыздыр?

—Ничек инде?

—Бәлки сез аның белән монда махсус очрашкансыздыр? Бәхәсләшеп, яки үзенә бездән шик төшмәсен өчен атып үтергәнсеңдер?

—Юк.

—Бәлки, син фашистлар белән гел элемтәдә торгансыңдыр?

—Сез нәрсә инде! Мин легионнан котылып үзебезнекеләр ягына чыкканга сөенеп туймадым. Ничек мин дошман белән элемтәдә торыйм?!

—Ник күмәргә булдың соң син аны?

—Соң, кеше бит...

—Фашист унтер-офицерын кеше дип атыйсыңмы? Бәлки, син атмагансыңдыр аңа? Берәр башка партизан урман эченнән аткандыр?

—Юк, мин атып үтердем аны.

—Син аның белән легионда танышкан идеңме?

—Кем белән?

—Атып үтергән унтер-офицер белән.

—Юк, минем аны беркайчан да күргәнем юк иде.

Допрослар көн саен озын-озак дәвам итте.

Яббарны монда тагын бер тетрәнү көткән икән—шушында ул авылдашы, күршесе һәм көндәше Әнсар белән очрашты.

## 20

Яшәү дәвам итте. Кызылъяр авылы үзенең дөньяви мәшәкатьләрендә кайнады. Ил сугыштан соңгы еллар сынавын да үтәргә тиеш иде. Беркайчан рәхәт, тулы канлы тормыш күрмәгән авыл халкы әле һаман өмет белән яшәде. Коммунистлар партиясенең авыл кешесен санга сукмый торган, хәтта ана паспорт бирмичә «крепостной» итеп тоткан вәхши идеологиясенә дә сабыр, тырыш, буйсынучан авыл халкы ышанырга теләде, бүген авыр булса, иртәгә рәтле тормыш башланыр, хәзер без интексәк, балаларыбыз юньле тормыш күрер дип гомер сөрде.

Үз дәүләтен югалтып дүрт йөз ел яшәгән, илгә бихисап корбан биргән татар авылының яшәү рәвешен яхшыртыр өчен мөмкинлекләре дә, барып мөрәҗәгать итәрдәй, иганә сорардай инстанциясе дә юк иде.

Яшәү дәвам итте.

Тормыш авырлыкларыннан да авыррак йөк бар адәм баласы өчен—җан газабы.

Яббар һаман авылдашларына күренмәскә тырышты. Ул хәтта урамга, бала чагы үткән инеш буйларына, болынга төнлә генә чыга башлады. Авыл халкы белән аралашырмын дигән өмете бар иде аның, ләкин тора-бара аңлады—сугышта һәлак булганнарның туганнары бар чагында, сугыштан гарипләнеп кайткан ир-егетләр исән вакытта, бала чактан таныш, якын булган кешеләр белән уртак тел табу мөмкин түгел.

Нәгыймгә кече улының фаҗигасе каты тәэсир итте, беркөнне аның каты өянәге булды. МТСтан машина алып Сәет аны район больнисенә алып китте. Сырхауханәгә ятып стационар рәвештә дәвалану алырга кирәк, диделәр.

Яббар атасы янына больнискә барды. Сигез кешелек палатада алар ни турында сөйләшә алсыннар инде. Атасының кырынмаган, аксыллы-зәңгәрсулы йөзенә карап Яббар үзенең дә йөрәгенең кысып-кысып чәнчеп алганын тоеп бик озак утырды. Нәгыйм улына шактый вакыт карап ятканнан соң күгәргән иреннәрен чак кына кыймылдатып:

—Улым, син бар кайт инде,—диде.

Атасыннан 1942 елдан соң беренче мәртәбә «улым» дип әйтүен ишетү Яббарның күңелен ташкын белән тутырды. Күзләрдән ургылып агарга торган яшьләрен көчкә тыеп ул:

—Әти, терел, зинһар, яме,—диде дә, палатадан атылып чыкты. Коридордан барганда инде аның күз яшьләре битен, муенын чылатып бетергән иде.

«Улым, диде. Кит, димәде. Күренмә, димәде.—Кайт, диде. Улым, диде, кайт,—диде. Рәхмәт әти! Кичер әти! Ярлыка!»

Авылга кайтып киткәнче ул бик озак район үзәгенең урамнары буйлап йөрде. Аңлатып булмаслык халәттә онытылып йөрде ул—ниндидер өмет күкрәк түрендә сулкылдады. Яшәргә кирәк. Гомер алда әле. Дөнья бөтенләй караңгыланырга һәм барлык кешеләр дошман булырга тиеш түгел. Ул бит инде җәзасын алды. Аны кешеләр легионер булганы өчен хөкем итәргә тиеш түгелләр. Аның бит зуррак гөнаһы бар, ул кырык дүртенче елның көзендә кеше үтерде. Ике баласы, хатыны төшкән фотосурәтне алырга дип килгән нимес кешесен үтерде. Менә бит

аның иң зур гөнаһы. Кешеләр аның ул гөнаһын белсәләр, вакытлыча дошман киемен кигәне өчен бәлки битәрләми башларлар...

Кызылъярга ул төнлә генә кайтып керде.

... Икенче көнне өйдә Әминә белән икесе генә калгач, Яббар:

—Әти бүлнистә озак ятыр микән?—дип куйды.

—Янына баргач, ник дуктырлардан сорамадың соң?—диде анасы.

—Курыктым.

—Нәрсәсеннән курыктың инде аның?

—Врачлар минем легионер булганымны беләләрдер шикелле тоелды.

—Каян белсеннәр инде алар, улым!

—Инде кая гына барсам да бөтенесе беләләрдер кебек.

—Юк, юк, улым, сиңа шулай тоела гына. Ә атаңа килгәндә... Берәр ай дәваланыр әле ул.—Әминә авыр сулап куйды.—Йөрәк белән интекте инде гомергә.

Яббар:

—Хәзер инде минем аркада да интегә,—дигәч, өйдә авыр тынлык урнашты.—Әнкәй, синең әле бер тапкыр да сораганың юк...—дип тагын сүз башлады ул.

—Нәрсә дип?

—Нимес ягына чыктыңмыни дип.

Әминә дымлы күзләре аша елмаю нуры сирпеп сәкедә бөкрәеп утырган улының янына килде:

—Син бит минем улым, нишләп мин синең җәрәхәтләрең өстенә җәрәхәт өстим ди. Исән-сау булуыңа куанып туя алмыйм, балакаем. Синең исән калуыңны көн саен Ходайдан сорадым бит мин. Догаларым кабул булды.

—Яу кырында ятып калуымны тели торган доган юк идемени соң синең, әнкәй?—диде Яббар, ачынып.

—Ни сөйлисең син, улым!—диде Әминә, Яббарны такыр башыннан сыпырып.—Мин ничекләр түзәр идем, әгәренки син чит җирләрдә үлеп калсаң?!

—Ә болай сатлыкҗан исемен йөртүемә түзәрсеңме?

—Нинди сатлыкҗан инде син, улым!—дип көлемсерәде Әминә.—Бөҗәкне дә кызгана торган бала идең бит син. Табигатьне, туган авылны яратучы малайга ничек андый ямьсез исем тагылсын. Кемне, нәрсәне саттың соң син?

Яббарның күңеле талпынып куйды:

—Беркемне дә, бернәрсәне дә сатмадым!

—Шулай булгач...

—Беркемгә, бернәрсәгә хыянәт итмәдем! Тик ничек исбатларга соң моны?

—Ышанырлар, улым, түз, ышанырлар.

Яббар әнкәсенең кулын ике учына алды:

—Димәк, син миңа ышанасың?

—Ничек ышанмаска. Син бит минем балам. Син бит минем иң яраткан улым.

Яббарның күңеле тулды:

—Әнкәй, син бит миннән баш тартмаучы бердәнбер кеше.

Әминә арткарак каерылып улының терсәген капшады:

—Күлмәгеңнең җиңе ертылган. Сал, тегеп куйыйм. Кайда эләктердең икән?

—Кичә мин бакча артыннан кайттым. Читән буенда кыштыр-кыштыр нәрсәдер йөри. Карасам, керпе икән.—Ул көлеп куйды.—Бала-чага сыман, шуны якыннанрак карыйм дип, җиңемне читән чыбыгына эләктереп ертканмын.

Яббар күлмәген салып әнкәсенә бирде дә тәрәзә янына барып басты.

Шунда Әминә улының җилкәсенә карап котсыз калды:

—И-и-и, балакаем, тәнең гел җөйләрдән, яралардан гына тора икән.—Ул Яббарның аркасын тәрәзә яктысында җентекләп карарга тотынды.

—Монысы нинди яра, улым?—дип бармагы белән төртеп сорады ана.—Снаряд кыйпылчыгыныкымы?

—Юк, кыйпылчыкныкы өстәрәк. Инбашына якынрак. Аның эзе, ни гаҗәп, чак кына беленә. Ә бу җөй штык эзе. Әсир төшкәч, кызык өчен, бер фашист штык белән төрткән иде.

—Снаряд кыйпылчыгын кайда алдырдың соң син?

—Концлагерьда. Кул астындагы әйберләр ярдәмендә бер хирург—белорус кешесе алды. Үзе үлде ул аннары. Ачтан үлде.

Әминә бармагын улының җилкәсе буйлап йөртте:

—Бусы?

—Ансы концлагерьда бер сакчы үткен көрәк кыры белән сукканнан калды. Фамилиясе Крупп иде. Кырырга куелган казан эченә кереп басканым өчен. Безне, алты меңгә якын әсирне, башта тимерчыбык белән уратып алынган бер зур мәйданда тоттылар. Сакчылар үзләренә аш пешергән зур-зур казаннарны, бушагач, безгә кертеп куялар иде. Казан төбенә ябышкан ризыкны, төрткәләшә-төрткәләшә, житешкәнчә, кем ничек булдыра, кырып ашый идек. Берсендә этешә-төртешә торгач ялгыш казан эченә кереп бастым. Шунда Крупп көрәк белән сукты.

—Ә менә бу җөйләр?

—Болары Магадан янындагы лагерьда, үзебезнең конвоирлар эше. Әле аягымда эт тешләгән эзләр дә бар.

Әминәнең куллары салынып төште:

—Әй, балам, ниләр өчен шушы кадәр иза чиктең соң син?

—Шуннан соң яңа газаплар чигәргә язган икән бит әле.

—Нинди газаплар?

—Хәзер миңа туган ягымда, өзелеп сагынган туган авылымда кешеләрчә яшәү мөмкин түгелдер инде.

Әминәнең бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

—Тора-бара онытырлар, улым.

—Юк, әнкәй, онытмаслар. Үзем бимазаланган гына житмәгән, кешеләрнең нәфрәте аска бөгә, сыта, изә. Мин үземә кул салыр идем... тик, әнкәй, син бар.

Әминәнең коты очты:

—Әстәгъфирулла! Ни сөйлисең син! Авызыңнан жил алсын!

—Мин үземнең башымнан кичергәннәрне, ничек җәзалаганнарын ни өчен кешеләргә ачыктан-ачык сөйлим дип уйлыйсын? Бәлки ышанырлар һәм кичерерләр дип. Легионер булган да, кыска гына вакытта булса да рәхәттә яткан икән дип уйламасыннар өчен. Ләкин миңа барыбер ышанмаячаклар.

Әминә улының җилкәсен кулы белән сак кына сыпырды:

—Ышанырлар!—Аннары ул сәке башындагы күлмәккә ымлады.—Әнә, атаңның күлмәген киеп тор.

Яббар әнкәсенең сак кына хәрәкәтләр белән күлмәгенең җиңен типчүен күреп шаккатты. Әйтерсең лә ана җаны-тәне җәрәхәтләнгән улының күлмәген дә инә белән тишеп яраларын әрнетүдән курка.

Бераздан Нәсимә кайтты.

—Әнкәй, чәй эчеп алыйк әле, ашарга аннары әзерләрбез,—диде ул, нәрсәгә тотынырга белмичә кучкар тирәсендә таптанып.

—Кызым, самавыр кайнаган ул, өстәлгә генә куясы бар,—диде Әминә, инә җебен төйнәп.

—Әйдә, Яббар, чәй эчәргә,—диде Нәсимә, чәй табыны әзерләп.

Килен кешенең мондый мөгамәләсе Яббарга гына түгел, ананың да күңеленә хуш килде.

Яббар елмаеп өстәл янына утырды:

—Ярый чәй бар әле!

Әминә Яббарның күлмәген сәке башына салды да:

—Сез эчә торыгыз, мин намаздан соң эчәрмен,—дип намаз укырга җыена башлады.

—Яббар, сиңа сөтләп ясыйммы?—диде Нәсимә.

Яббар читенсенеп кенә:

—Сөтләп,—диде.

Шул вакытны Сәет кайтып керде. Хатынының Яббарга чәй ясаганын күреп ул беравык ишек катыннан кузгалмый басып торды.

—Менә Сәет тә кайтып житте,—диде Нәсимә, шатланып. Аннары шаярып өстәп тә куйды:—Мактап йөрисең икән. Чәй ясыйммы?

Сәет борын төбенә генә мыгырдады:

—Яббарга чәй ясаганны, үз иреңә генә ясарсың инде. Аңа сөтләп ясагач, миңа да сөтләп ясарсың шәт.

Иренең өстәл янына утырып Яббарга усал каравыннан Нәсимә нык каушады.

—Бик кәефсезләнеп кайткансың әле,—диде ул иренә чынаяк куйганда.

Әминә өйдә кубасы давылны сизенеп, кулындагы комганны аралыкка куйды да, казан тирәсендә нидер эзләгән булып кыланды.

Сәет алдына куелган чынаяктагы чәйгә карап торды да, Яббарга текәлгән килеш усал тавыш белән хатынына мөрәҗәгать итте:

—Син Яббарга чәйне куерак яса, сыек ясагансың түгелме...

Нәсимә утырган урыныннан әкрен генә торып басты:

—Нәрсә булды, Сәет?

—Тагын бер тапкыр аңа чәй эчерткәнеңне, ашатканыңны күрсәм... үзенә үпкәлә!—диде Сәет йодрыгы белән өстәлгә сугып.

—Сәет, нишләвең бу!—диде Нәсимә җәһәт кенә өстәл сөртә торган чүпрәк белән түгелгән чәйне сыпырып.

Сәет чайпалып түгелгәннән соң яртылаш кына калган чәен шопырдатып эчеп куйды:

—Мине эшемнән алырлар, ахрысы.

Әминә әкрен генә өстәл янына килеп утырды:

—Эшеңнән? Ник алай?

—Эшемнән чыгаруларын көткәнием инде аңсы. Эшен табармын. Элекке дусларым минем белән аралашмый башладылар—менә шунысы начар.

—Чын дусларың аралашырлар,—диде Нәсимә.—Сиңа артлары белән борылучылары, димәк, чын дуслар булмаган.

Кайтканнан бирле моңарчы абыйсы белән кирле-морлы сөйләшмәгән Яббар башын аска игән килеш әйтеп куйды:

—Нәсимә миңа чәй ясамаса сиңа җиңелрәк булыр идеме?

—Тынының чыгарма, үләксә!—дип ярсып кычкырды Сәет һәм сикереп торып чынаяк төбендә калган чәйне Яббарның битенә сипте.

—Сәет, табын яны бит бу!—диде Әминә ачыргаланып.—Ник дулыйсың! Атаң бүлнистә яту житмәгән, бөтенебез дә авыруга сабышсын дисеңме! Ничек оялмыйсың—анаң каршында, табын янында...

Сәет кискен хәрәкәтләр белән ишеккә таба юнәлде.

—Берегезне дә күрәсем килми!—диде ул һәм ишекне бәреп, чыгып китте.

—Чыннан да, кайтасыларым калмаган икән,—диде Яббар беркавым

битендәге юешне күлмәк җиңе белән сөртеп.—Ә уйлап карасаң, хәзер инде китеп югалсам да барыбер, әти әйтмешли, нәселгә тап төште. Кайтмаган булсам да сезгә кырын карарлар иде. Авылдашларым мине аңларлар дип өметләнгән идем. Шуңа күрә кайтырга җөрьәт иттем мин.

Нәсимә Сәетнең кая таба киткәнен күрергә теләп тәрәзәдән карады.

—Авылдашларга үпкәли алмыйсың инде, Яббар,—диде Нәсимә.—Күпме күз яше, күпме кан, күпме кайгы-хәсрәт, күпме югалту кичерде халык.—Ул елап җибәрде.—Минем Фәрук абыемның каберен дә күрә алмыйбыз бит менә.

Нәсимәнең Фәрук абыйсын искә алып елаганы күп булды, ләкин бу юлы Әминәгә дә, Яббарга да аның күз яшьләре, әйткән сүзләре аеруча авыр тәэсир ясады.

—Мин беркемгә дә үпкәләмим,—диде Яббар.—Хакым юк. Ә син ничек уйлыйсың, әгәр дә мин үземне сатлыкҗан дип танысам, кешеләрнең шулай диюләренә күнсәм, авыл халкының миңа мөгамәләсе яхшырырмы?

—Белмим,—диде Нәсимә, нишләргә белмичә як-ягына каранып. Шулай да Яббарга җавап бирергә кирәк дип тапты.—Синең эчке кичерешләрең, синең шәхси халәтең берәрсен кызыксындырадыр дип уйлыйсыңмы әллә? Синең яманатлы даның синең үзеңнән тормый лабаса.

Яббар башын какты:

—Дөрес әйтәсең.

Нәсимә Сәет өчен нык борчылып беркавым тәрәзәдән тәрәзәгә йөрде дә:

—Кибеткә барып кайтыйм әле,—дигән булып өйдән чыгып китте.

—Әнкәй, берәр көнне авыл халкы җыелган җирдә тезләнеп ярлыкауларын сорыйммы?—диде Яббар.

Әминә сискәнеп китте, беравык улына карап торды, аннары әкрен генә торып басты да бөтенләй үзенә хас булмаган каты тавыш белән:

—Юк, улым, тезләнмисең дә, ярлыкау да сорамыйсың!—диде.

Яббар әнкәсенең олы якка кереп намаз укыганын көтеп урыныннан кымшанмыйча утырды. Әминә намазын тәмамлап кече якка чыккач, Яббар китәргә катгый карар кылуын белдерде.

—Кая китәсең, улым?—дип сорады ана.

—Район үзәгендә ишетеп кайттым: Куйбышев янында, Великие Луки дигән урында зур гидростанция төзеләчәк ди. Электр чыгара торган станция. Бик зур төзелеш, имеш, эшчеләр бик күп кирәк икән. Шунда барып урнашырга исәбем бар. Алсалар инде...

## 21

1952 нче елның язы башка язлардан нәрсәсе белән аерылып торгандыр, әйтүе кыен. Язлар алар гел бертөрле килә—ташулары белән, табигатьнең яңаруы белән, өмет белән. Кешеләр язмышлары гына төрлечә керә язларга. Һәр кеше үзенең кайгы-хәсрәте белән, үзенең тәкъдиренә язылганы белән атлый елларның котылгысыз үзгәргән фасылларына.

Апрель тәмамлангач, унбиш-егерме көннән алмагачлар чәчәк атачагын уйлап, табигатьнең яшәреп, яңарып китәчәген күзаллап, Нәгыймнең тән сыкраулары кимиячәгенә ышанып, улы Яббарны күрәсенә өметләнеп, Әминә лапастан баз өстенә кадәр үк аркылы сузылган бауга яңа юган керләрне элеп маташа иде. Капканың ачылуыннан Әминә сискәнеп китте, якты уйлар мизгел эчендә юкка чыктылар.

Зәкиянең капкадан килеп керүеннән үк Әминәнең кәефе кырылды. Анардан ихласлык белән әйтелгән җылы сүз беркайчан ишетмәссең, ул башлаган әңгәмә һәрвакыт Әминәнең күңел җәрәхәтләренә тоз сипми калмый. Шуңа күрә соңгы вакытта Зәкия белән аралашмаска тырыша ул.

Анын гадәттәгечә, кем әйтмешли, «фурмы» өчен генә:

—Нихәлләрең бар, Әминә?—диюенә ул да керләрен элә-элә салкын гына:

—Аллага шөкер, Зәкия,—диган булды.

—Чирләп алдың, ахрысы?—диде Зәкия Әминәнең йөзен җентекләп күзәтеп.

—Булды бераз. Рәтләндем инде. Үзең ничек?

—Ярыйсы,—диде Зәкия.—Урын өстендә үк ятып алдың бугай?—дип төпченүен дәвам итте ул.

—Әйе шул. Мин чирлим дә, тиз арада терелэм дә... Мин үзем өчен түгел, күбрәк Нәгыйм өчен борчылам. Аның сәламәтлеге ныграк какшаган. Үзен сакламый. Духтырлар биргән даруларны да эчми.

—Алай икән. Йөрәк белән шаярырга ярамый. Яббар кайгысы да өстәлгәндер инде.

Әминә керләрдән бушаган тазын куярга дип өйалды баскычына таба юнәлде:

—Бардыр инде.

Зәкия аңа иярде:

—Шуны сорамакчы идем... Яббар күренми... Кайда ул?

Бу юлысы Яббар турында сүз башлану Әминәне сөендереп җибәрде.

—Яббар зур төзелештә эшли,—диде ул горурлык белән.—Куйбышев янында гис төзелә. Бик зур буа буылачак ди.

Зәкия Яббарның кайда икәнен белгән килеш аптыраган булып кыланды:

—Алай икә-ә-ән. Кем булып эшли инде ул анда?

—Башта гади эшче иде. Хәзер шоферга укыган, машинада эшли башлаган.

—Алай икә-ә-ә-ән...

Күршеләре белән соңгы вакытта аралашмаса да, Әминәнең Әнсарга рәхмәт сүзе бар иде:

—Әнсарыгызга рәхмәт яусын инде... Сәетебезне эшендә калдырганы өчен.

Зәкия читенсенгән булып кыланып:

—И-и-и, Әминә, минем Әнсарым үз авылдашын, күршесен кыерсытуга бармас инде ул. Тәрбиясе андый түгел.

—Рәхмәт яусын.

—Маладис инде ул минем Әнсарым. Кеше сүзенә карамады, авыл халкы кырыслана дип тормады, Сәетегезгә җил-янгыр тигезмәде.

—Кеше сүзе дисең... Ансы инде Яббар өчен Сәет җавап тотарга тиеш түгел. Яббарның үзенә дә чиксез авыр. Безнең Сәетебез дә бит сугыштан орденнар белән кайтты...

—Шулаен шулай да, Әминә, халык бит ул ай-яй. Аерым бер кешегә тукып аңлатып була, ә кешеләр бөтенесе бергә җыелса һич кенә дә аклана да, аңлата да алмыйсың.

—Ансы шулай,—дип килеште Әминә.

—Хәтта авыл халкының чит җирләргә китеп урнашкан туган-тумачалары да сабантуйга кайткач гөр китереп синең Яббарың турында гына гәпләшteләр бит.

Әминәнең йөзе саргаеп китте:

—Син авырткан җәрәхәтләргә кагылмый калмыйсың инде... бигрәк тә соңгы вакытларда.

—Мин бит булганны гына сөйлим, Әминә. Үзем уйлап чыгармыйм.

—Ярар, ярар, рәхмәт барысы өчен дә.

Зәкия Әминәнең тәмам шәлберәеп киткәнен абайлап, сүзне икенчегә борып, тормыш-көнкүрешкә бәйле вак-төяк турында бераз быр-быр килде дә, чыгып китте.

Әминә барыбер рәхмәтле иде күршеләренә. Сәетне, сатлыкҗаннын абыйсы дип, чак кына эшеннән алмадылар бит. Кемнендер берәр туганына эш кирәк булгандыр инде. Энесе изменник дигән сылтау бик яхшы сәбәп бит. Имештер, Әнсар МТСта баш инженер булып эшләүче әшнәсеннән Сәеткә тимәүләрен үтенгән.

Әминә элгән керләре янында бик озак уйга чумып ,боегып басып торды. Аны авыл халкынын үзләренә карата мөгамәләсе түгел, Яббарны—сөекле улын—чит-ят итүләре нык бимазалады. Яббарны дошман итмәсеннәр өчен ул үзе әллә нинди җәзаларга да ризалашыр иде, мөгаен.

Ана йөрәге үзенең баласына әллә нинди яманатлар тагуларын, аны дошман итүләрен кабул италмады, ананың акылына, анына сыярлык түгел иде бу хәл. Юкка, нахакка рәнҗетәләр улымны, диде ул һәм бу вәхши гаделсезлек белән мәнге килешмәячәген гел искәртеп торды. Бөтен дөнья Яббарга карата арты белән борылган сурәттә дә, бөтен дөнья анын улын дошман итсә дә анасы анардан беркайчан, бу дөньяда да, тегесендә дә баш тартмаячак. Ана өчен нәрсә ул «легионер» дигән җанга ятышсыз сүз? Ана өчен изменник, предатель, сатлыкҗан дигән төшенчәләр нәрсә ул? Бала-чага бер-берсен үртәгәндә генә кулланыла торган сүзләр түгелме соң алар? Улының ничек авылны яратканын, ничек табигатьтән тан калуын, анын нечкә күнелле, олы җанлы, игелекле бала булып үскәнен үзе генә түгел, авылдашлары да күргән ләбаса! Үз карынынннан чыгып күкрәк сөтен имгән баласына ни өчен әллә нинди ямьсез кушаматлар тагуларын ана белә һәм анлый шикелле, әмма шул ук вакытта беләсе дә, анлыйсы да килми. Монын белән ана мәнге килешмәячәк һәм күнмәячәк!

Яббар кебек әдәпле, игелекле, нечкә күнелле бала үз яшьтәшләре арасында юк иде!

## 22

Куйбышев ГЭСы төзелеше турында Яббар беренче тапкыр радиодан ишетеп белде. Шунда китәргә теләге бер мизгелдә туды шикелле. Тизрәк китәргә, китәргә, китәргә. Авылдан еракрак, таныш-белешләрнен күз карашларыннан арырак олагырга кирәк. Әнкәйне сагынгач, авылны юксынгач, яшертен генә, бөтенләй үк яшертен булмаса да, тып-тын гына кайтып китәргә дә мөмкин ләбаса. Тормышны корырга кирәк, алда гомер бар, аны яшәми кая куясын. Бу дөньяда ходай җан биргән икән, димәк, үз урынын да бардыр бит инде.

Эшчеләр поселогында, ГЭС төзүчеләрдән тыш, нефтьчеләр дә, баржалар ремонтлаучы бригадалар да яши иде. Яббарга сонгы еллар эчендә беренче тапкыр бәхет елмайгандай итте—гидромонтажчылар бригадасына грузчик итеп алдылар һәм бер озын иске баракнын ин кырый бүлмәсендә урын да билгеләделәр. Шунсы куанычлы булды—ул килгәндә монда үзләренен бригадиры урыс агае Арсений Михайлович кына яши иде. Дядя Арсен (Яббар ана беренче көннән үк шулай эндәшә башлады) Яббарны эштә дә, бүлмәдә дә җылы кабул итте. Яббар ана үзе турында барысын да сөйләргә җөрьәт итмәде. Әмма бригадирга, ничектер, тиз арада анын турында барысы да мәгълүм булды. Бригадасында шундый биографияле кешенен булуы Арсенийны бераз пошамanга салды, Яббарга карата шундук кырысланды, тик шулай да аны бригадада калдырды һәм Яббарнын легионда булганын, нинди статья буенча утырганын беркемгә дә сөйләмәде.

Ике ай чамасы узгач, Арсений Михайлович, әллә легионерны бригадасыннан еракрак җибәрәсе килгәннән, әллә чынлап та яхшылык

теләп, Яббарга шоферлар курсына укырга керергә тәкъдим итте.

... Курсларын тәмамлап, имтиханнар биргәннән соң, төрле оешмалардан шоферларны эшкә чакыручы вербовщиклар килде. Аз сүзле, йомыкыйрак, укытучы инструкторлар әйтүе буенча бик тырыш курсант Әүһәдиев Яббарны тәбәнәк буйлы, төптән юан бер агай үзенә шофер итеп урнашырга чакырды.

Бу базык кеше зур начальник булып чыкты. «Гидромонтаж» оешмасының бетон капланмалар белән тәэмин итү бүлеге житәкчесе Стыков Захар Федорович Пермь ягыннан иде. Соңгы вакытта шоферлардан уңмаганга күрә, ул үзе автошколага кеше эзләп килгән икән.

Яббар затлы машинага утырып, зур кешене йөртергә насыйп булуына хәтта сөенергә дә курыкты, чөнки әле һаман бу бәхеткә ышанып житалмады, күз тиюе бар дип пошаманланды. Шул ук вакытта, кем икәнемне белгәч, бу эштән куулары ихтимал дигән коточкыч уй да аны борчый иде.

Аңа зур барактагы тулай торактан урын бирделәр. Алар бу бүлмәдә дүрт шофер бергә яшәсәләр дә, барысы берьюлы җыелганнары булмады диярлек, чөнки алар сменалы эштә иде.

Яббар үзенең кем икәнлеген, нинди хәсрәте барлыгын, нинди җан газабы белән яшәвен Захар Федоровичка үзе сөйләргә булды.

Куйбышевтагы киңәшмәдән кайтканда, начальнигенең кәефе күтәренкелектән файдаланып, нәкъ менә хәзер ачам серемне дип, Яббар машинаны юл читенә туктатты да үзе турында сөйләргә тотынды. Ләкин, ни гажәп: Яббарның начальниге инде барысын да белә икән.

—Нишлисең бит, тәкъдиреңә шулай язылгач,—диде Захар Федорович, Яббарның агарып каткан чыраена карамаска тырышып.

Шуннан соң ул , машинадан чыгып, багажниктагы сумкасыннан колбаса белән ипи алып килде.

—Әйдә капкалап алыйк,—диде ул, якты елмаеп.

—Мине эштә калдырасызмы?

—Син бу турыда бөтенләй кайгырма. Әйбәт кенә эшлисең бит, эшлә.—Беркавым тынып торганнан соң өстәп куйды.—Башка беркемгә дә сөйләмә. Кирәкми.

Тамак ялгап юлга кузгалгач, Захар Федорович хатынының бертуган абыйсы турында сөйләде. Ржев янындагы чолганыштан котылып чыккан булган ул. Аны дезертир дип хөкем иткәннәр. Шуннан аның турында бер хәбәр дә юк икән.

—Инде ничә ел узды, исән булса, кайтыр иде, исән түгелдер,—дип тәмамлады Захар Федорович сөйләвен.

Яббарның күзләреннән яшьләр тәгәрәде. Ул тагын машинаны юл читенә туктатты. Аның рульгә капланып туйганчы елаганын Захар Федорович бер сүз дәшми тыңлап утырды.

... Көн артыннан көн үтте. Төзелеш кайнады да кайнады. Әллә кайсы тарафлардан җыелган эшчеләр, белгечләр, инженерлар, галимнәр Идел елгасын буар өчен бөтен аңнарын, белемнәрен, көч-куәтләрен жиктеләр. Зур төзелешләргә хас күтәренкелек вә илһам күңелләрдә урын алды, жилкендерде, канатландырды. Күпме язмышлар үзара чуалышып, күпме гомерләр үз юнәлешен тапты. Күпме яшьләр шушында очрашып гашыйк булдылар, гаилә кордылар.

Комплектлау участогындагы Роза исемле татар кызы белән Яббар эшли башлаган атнада ук танышты. Инде утыздан узган ир-егет белән табельщица булып эшләүче егерме ике яшьлек кыз арасында шундук күңел аваздашлыгы сизелде. Розаны чибәр дип әйтерлек түгел, әмма чын хатын-кызларга хас нәзакәтлелек аның күз карашында, һәр хәрәкәтендә чагылып тора иде. Аз сүзле, тирән сагышка манылган чырайлы тыйнак егетне күргәч, Роза,

ниһаять, житди дус очрады, кияүгә чыгардай кешегә юлыктым дип уйлап карады.

Ул Куйбышевта эшчеләр гаиләсендә туып-үскән, туган телендә начар гына сөйләшүче татар кызы иде. Анын Куйбышевта ата-анасы, заводта эшләүче бер абыйсы, әле мәктәпне тәмамлап кына килүче сеңлесе, тагын төрле якын һәм ерак туган-тумачалары бар иде.

Яббар белән Роза эш ыгы-зыгысы арасында көн саен очрашу җаен эзләделәр. Мәхәббәт иде бу, чын мәхәббәт иде!

Өйләнешү турында сүз чыккач, Яббар бераз акча җыярга, торак мәсьәләсен хәл итәргә кирәклеген кузгатты һәм алар әле ашыкмаска булдылар.

Яббар башта үзе турында Розага барысын да сөйләүне бик мөһим булыр дип уйлады. Һәм озакка сузмыйча, беркөнне Роза белән поселок клубында кино караганнан соң, кызны тулай торагына озатканда ул үзенең сугыш вакытында легионда булганын, лагерьларда утырганын бәйнә-бәйнә сөйләп тә бирде.

Анын ачы бәяне, әлбәттә, Розага каты тәэсир итте, әмма кызның Яббарга мөнәсәбәте үзгәрмәде, ул аны барыбер яратты. Яббар исә мона куанса да, сөйгән яры анын фаҗигасен бигүк тирәнтен аңлап бетерми дигән уйдан арына алмады һәм Розадан ата-анасына, туганнарына бу хакта сөйләмәвен үтенде. Роза серне сакларга вәгъдә бирде.

Яббарда мәхәббәт белән беррәттән яңа өмет уянды. Әлегә бары тик анасы гына аны элеккечә ярата иде ләбаса. Атасы да, Сәет абыйсы да аны кичермиләр. Нәсимә хатын-кызларча кызганып караса да, Сәеттән куркып, ана якты йөз күрсәтмәскә тырыша. Нәсимәнең туганнары исә Яббарны белергә дә, танырга да теләмиләр. Фатыйманың туганнары аны кызгана һәм шул ук вакытта кызларының Әнсарга чыгуына шатланып туймыйлар. Авылда күршеләр йөз чөерәләр, авылдашлар исәнләшмиләр—нәфрәтләре бер чакрымнан бәреп тора. Хәзер анын Розасы бар, Розанын туганнары бар...

Әмма бер уй аны куырып-куырып ала—кайчан да булса Розанын туган-тумачасы анын тәрҗемәи хәлен белми калмас бит. Бу дөньяда нәрсәне яшерү мөмкин соң?!

Ярый, алга таба күз күрер. Иң мөһиме, булдыра алган адымны ясады ул—бергә тормыш юлыннан атлыйсы кешегә үзенең кайгылы серен ачты.

## 23

Тагын ике ел гомер узып китте. Шул ике ел гына да әллә нинди зур вакыйгалар алып килде. Иң әһәмиятлесе 1953 елны булды—«халыклар атасы», «бөек юлбашчы» Сталин үлде. Күпме кеше шатланды, күпмесе кайгыга батты—кем санаган, кем үлчәгән. Тик менә даһи юлбашчы бу дөньядан киткәнгә бер елдан артык вакыт узды, ә урман ягыннан кояш элеккечә көн саен чыга, кич белән тау артында гадәттәгечә бата. Шулай ук ел фасыллары берсен-берсе алмаштыра. Менә бит әле яздан соң тагын җәй килде.

Авыл халкының сәясәттән хәбәре юк. Кайдадыр ерак шәһәрләрдә кемнәрдер Сталин үлгәннән кайгыга батып, кайсылары, киресенчә, тиран бу дөньядан киткәнгә чиксез шатланып, киләчәккә зур өметләр баглап яшәсә, авылда исә авыр хезмәттән бөгелгән крестьян, ялсыз-бәйрәмсез, караңгыдан караңгыга кадәр эшләп, үзенең шәхси тормышында очны очка ялгап, дәүләт планын изге санап, гадәттәгечә көн күрде.

Тиздән печән чабар вакыт җитә.

Нәгыйм кече яктагы сәкедә инде яз башыннан бирле ята. Торып йөри алса да, хәле тиз бетә, сулышы каба, йөрәк үз турысында гына түгел, калак сөяге астында, инбашларында үзен сиздереп авырта.

Ул казан тирәсендә чуалган карчыгы белән килененә аһылдап эндәште:

—Быел печән дә чаба алмам микәнни?

—Нинди печән чабу инде сиңа,—дип җавап бирде Әминә.—Ят, берни турында уйлама.

Әминә казан астына утын алырга чыгып киткәч, Нәгыйм ишек катында иске ботинкасының куба башлаган төбен рәтләргә маташып утыручы Сәеткә шыңшып эндәште:

—Болай эшсез яту дөрес түгел. Эшкә яраксыз яту бик яман нәрсә икән.

—Бер сыерлык кына печән әзерләрмен әле,—диде Сәет.—Йөрәгеңне сакла.

Әминә кулына иске бүрек тотып килеп керде. Соңгы вакытта аның йөзендәге сагышта нindидер усаллык төсмере дә катнаша, ул күзгә күренеп кырысланды, хәтта күзләрендә көтмәгәндә нәфрәт очкыннары чагылып-чагылып ала. Авыл кешеләренең, хәтта туганнарының да Яббарга начар мөгамәләсе ананы нык үзгәртте.

Әминә ишек катында мыш-мыш килеп үз эше белән мәшгуль булган Сәеткә карап торды, аннары өй эченә узып сәкедә ятучы карты янына килеп басты.

Нәгыйм башын калкытты:

—Нишләп сөмсерең коелган? Нинди бүрек ул кулыңда?

—Лапас түбәсендә Яббарның бала чагында кигән бүреген таптым,—диде Әминә. Ул бүрекне әйләндергәләп карады, иснәп алды, шуннан соң мич башына илтеп куйды. Ул, аралыктан чыкмыйча, бик озак тып-тын гына елады.

Нәгыйм яткан җирендә боргаланып алды:

—Яббар, Яббар... Әйбәт кенә яшәп, ару гына эшләп ята микән?

—Арудыр, арудыр,—дип ата-анасын тынычландырырга ашыкты Сәет.—Ул эштән курка торган малай түгел.—Һич кенә дә төзекләнмәгән сыңар ботинкасын шапылдатып идәнгә ташлады, торып кулларын чалбарына ышкып сөртте.—Әле менә күрерсез, ул тернәкләнеп китәр, ә мин аска таба тәгәрәрмен.

Әминә күз яшьләрен сөртеп аралыктан чыкты, өстәл янындагы урындыкка барып утырды.

—Бәләкәй чакта Аулаш тавыннан чана шуа идегез,—диде ул хатирәләргә бирелеп.—Бер тапкыр Яббар бүреген шунда югалтып кайтты.

Нәгыймнең исә Сәет әйткән сүзләр колагында чыңлый иде. Әминәнең сүзләренә ул бөтенләй ригая бирмәде.

—Син, Сәет улым, аска тәгәри торган егет түгел,—диде Нәгыйм, улы белән ихластан горурланып.—Бирешмә.

Сәет аралыктагы юынгычның телен шылтыр-шылтыр китереп кулын юа-юа хатынына эндәште:

—Нәсимә, пешәме инде?

Өйдәгеләрнең әңгәмәсен бер сүз катмый тып-тын тыңлап маташкан Нәсимә:

—Хәзер токмачын салам,—дип кабалана башлады.

Әминә моңсу тавыш белән һаман үзенең сүзен дәвам итте:

—Шулкадәре ачуланган идем, балакаемны, бүреген югалтып кайтканы өчен. Яланбаш кайтканы өчен кызганасы урынга, бик каты тиргәп ташладым баланы. Җилтерәтә-җилтерәтә тауга җитәкләп алып киттем үзен. Эзли торгач, таптык. Тау итәгендә карга күмелгән булган. Кар эченнән колакчыны чак кына күренеп ята.

—Печәнне чүмәләләп урынында калдырсак та була,—диде Нәгыйм, Сәет килеп сәке кырына утыргач.

Улы башын чайкады:

—Юк, әти, алып кайтып куйсак яхшырак, ни дисәң дә, печән йортка

кайтса гына синеке санала ул.

Әминә һаман үзенекен сөйләде:

—И-и-и, белсәгез иде Яббарны, балакаемны ничекләр сагынганымны!

Өйдә тынлык урнашкач Нәгыйм сорап куйды:

—Киткәненә күпме булды?

—Дүртенче ел инде,—диде ана.

Нәгыйм аһ-ваһ килеп стенага борылып ятты:

—Илле дүртенче ел бара диген инде, ә! Сталин үлгәнгә дә бер елдан артып китте. Узган гомер—аккан су ди.

Капка тавышы ишетелгәч, барысы да сагаеп калдылар. Соңгы вакытта аларга керүче сирәк, үзләре дә йомылыбрак яши башлаганнар иде.

Өйалды ишеге шыгырдагач, Сәет, кем керә икән дип, каршы чыкмакчы иде, ләкин шул вакытны өй ишеге киерелеп ачылды да бусагада Яббар пәйда булды. Иңендәге капчыкны, кулындагы чемоданны идәнгә куеп, ул ишек катында шактый вакыт елмаеп басып торды. Яббар нык үзгәргән, кыяфәтенә бераз рәт кергән шикелле, ләкин чәче нык агарган, күзләрендә тирән моңсулык, елмаюында да әйтеп бетергесез сагыш. Өйдәгеләр тып-тын калдылар. Нәгыйм торып утырганда гына сәке такталары шыгырдап тынлыкны бозып куйды.

Мөгаен, Яббар шушылай бусагада гына басып торырга да әзер иде, ата-анасын, абыйсын күрү бәхетеннән артыгы кирәк түгел иде лә ана. Аның өстендә өр-яңа кәчтүм-чалбар, эчтә ап-ак күлмәк, аягында калын табанлы ботинка, чал чәчен матур итеп кырыйга тараган, гәүдәсе дә турайган, кайткандагы кебек бөкрәеп тормый—үзгәргән, нык үзгәргән Яббар, яхшы якка үзгәргән.

—Исәнмесез!—диде ул, күкрәк тутырып. Аның исәнләшүе үзенең ыспай киеменә бик тә туры, тәңгәл килеп яңгырады.

Әминә кулларын сузып улына таба атлады:

—Улым, әле генә сине искә алдым бит мин! Кайттыңмыни, балакаем!

Әнкәсенә аркасыннан сөяргә җайлырак булсын өчен, Яббар бераз иеленкерәде.

—Исәннәрмесез,—дип тагын бер кат исәнләште Яббар.—Абыйсы белән кул биреп күрешкәннән соң, атасы янына килде.—Чирлисеңме әллә, әти?

Нәгыйм салкынаеп киткән кулын улына сузып күреште:

—Йөрәк келтер-мелтер бит инде минем.

—Исәнме, Нәсимә.

—Исәнме,—диде Нәсимә, Яббарны җентекләп күзәтеп.

Әминә куанычтан тәмам югалып калды, улы урындык алып мич буена утыргач, аның тирәсендә нишләргә белми бөтерелеп йөрде:

—Бигрәк озак кайтмадың бит, улым.

—Эш бик каты,—диде Яббар.—Бөтенләй ялсыз эшләдек соңгы вакытта.

—Гис төзеләме?—дип сорап куйды Нәгыйм.

—Төзелә.

Сәет энесенең яхшы өс киемен гаҗәпсенебрәк күзәтеп утырганнан соң:

—Отпускы алып кайттыңмы?—дип кызыксынды.

—Әйе. Мин хәзер бер зур нәчәлникнең шоферы булып эшлим. Кырыс булса да, хәлгә керә торган, гадел, яхшы кеше.

Кече улының киләчәк язмышына бернинди өметләр багламый башлаган Нәгыймгә хәл кереп китте.

—Нинди машинада эшлисең?—дип сорады ул, Яббарның машина йөртүче булып киткәненә әле тәгаен ышанып җитмичә.

—«Москвич»та.

—О-о-о, хәтә-ә-ә-әр!—диде Нәгыйм, шаккатып.

Нәсимә ягымлы итеп Яббарга эндәште:

—Мактап кына йөрисең икән—әле генә аш пешеп җитте.

Яббар сикереп торды да кабаланып ишек катындагы чемоданны ачты, аннары капчыгында актарынырга тотынды:

—Туктагыз әле, ашарга утырганчы бүләкләремне өләшим. Күчтәнәчләрем дә бар. Әти, син тельняшка яратасың бит. Менә сиңа тельняшка.

Нәгыйм тәмам терелеп китте, Яббарның кулыннан бүләкне алганнан соң алдына куеп озак итеп сыпыра-сыпыра әйләндергәләде:

—Рәхмәт. Тәнгә иң рәхәт нәрсә шушы. Рәхмәт.

Яббар чемоданыннан ачык төстәге чуклы шәл алып әнкәсенә сузды:

—Әнкәй, сиңа шәл.

Яббар шәлне әнкәсенең иңенә үзе салды. Әминә исә оялып кына күзгә каршына килеп:

—И-и-и, улым, бик кыйбаттыр бу, бигрәк затлы шәл бит,—диде.

—Кыйбат түгел, кыйбат түгел, әнкәй. Аны табуы гына авыр—дефицит. Минем нәчәлнигемнең һәркайда танышлары, дуслары күп—шуның аша алдым мин аны.—Ул капчыгыннан фуражка алып Сәеткә елмайды:—Сиңа, абый, менә нинди фуражка. Размеры синеке. Киеп кара әле, таман микән.

Сәет фуражканы теләр-теләмәс кенә алды:

—Рәхмәт.

—Кая, киеп кара инде,—диде аңа Нәгыйм.

Сәет:

—Тамандыр, тамандыр,—дип фуражканы киде дә хатынына таба борылды.

—Шул хәтле килешә,—диде Нәсимә, сокланып.—Таманмы?

—Таман, таман,—диде Сәет, фуражканы салганнан соң әйләндергәләп карап.

Шуннан соң Яббар чемоданнан ал чәчәкле яулык алып Нәсимәгә сузды:

—Монсы сиңа, Нәсимә.

Нәсимәнең йөзе шатлык катыш каушаудан кып-кызыл булды.

—Рәхмәт!—диде ул читенсенеп һәм өйдәге ыгы-зыгыдан файдаланып яулыкны тиз генә каядыр яшереп тә куйды.

Яббарның капчыгыннан тәмле-тәмле күчтәнәчләр дә чыкты—кәгазьгә төрелгән хәлвә, шикәр, кәнфит, печенье, берничә банка куертылган сөт.

—И-и-и, улым, шушы хәтле күчтәнәчләр белән кайтмасаң!—диде Әминә, өйгә кергән бәйрәмнән тыны кабып.—Болай ук расход тотмаска иден.

—Һи, әнкәй, шундый зур ГЭС төзеп тә күчтәнәчләр белән кайтмагач!—диде Яббар, якын кешеләрен куандыра алганга үзен бәхетле тоеп.

Нәсимә табын әзерләде. Ашарга утырдылар. Әминә кече улыннан күзен алмады.

—Эшең бик авыр түгелме, улым?—дип кызыксынды ул.

Яббар җавап бирергә дә өлгермәде, Нәгыйм сүзгә тыгылды:

—Эш җиңел булмый инде ул, бигрәк тә андый стройкада!

—Түзәрлек, әнкәй,—диде Яббар, анасына ягымлы карап.—Инде мин күргәннәрдән соң теләсә нинди эш авыр тоелмас.

—Син анда кайда, ничек яшисең соң?—дип сорады Сәет, кайнар ашын агач кашык белән болгатып.

—Жигулевск дигән кечкенә шәһәрдә. Поселок сыман, җыйнак кына шәһәрчек. Ул күптән түгел Отважное белән Моркваши авыллары урынында төзелде. Анда ГЭС төзүчеләр генә түгел, нефть эзләүчеләр дә яши. Баракта урын бирделәр—тулай торак дип атала.

—Ул яңа шәһәрчек стройканың үзеннән еракмы соң?—дип кызыксынды атасы.

Бу әңгәмә Яббарның күңеленә хуш килде. Ул хәтта ашау турында да онытты, якын кешеләренең сорауларына рәхәтләнеп җавап биреп утырды.

—Ул шәһәрчек Самарская Луканың төньягында.

—Анысы нәрсә тагын?—дип сорады Сәет.

—Иделнең, Куйбышевтан сиксән километр югарырак, дугаланган урыны бар, анда Идел бик зур дуга булып ага.

Нәгыймгә кече улы сөйләгәннәр бик кызыклы булып тоелды.

—ГЭС үзе Куйбышевтан ерак булачакмы соң?—дип сорады ул.

—ГЭС әлеге дә баягы Самара Лукасының төньягында, Куйбышевтан сиксән километр өстәрәк урнаша. Безнең Жигулевск төзелеш белән янәшә генә диярлек. Ай-яй зур ГЭС, Иделдә иң зур гидростанция булачак. Ленин исемен йөртәчәк. Беренче агрегатны киләсе елның азагында җибәрәчәкләр.

—Ә җәмгысе ничә агрегат корылачак?—дип кызыксынды Сәет.

—Егерме. Мощность 2,3 миллион киловатт тәшкил итәчәк. Сусаклагычның мәйданы гаҗәп зур булачак. Иделнең киңлеге дә, тирәнлеге дә артачак.

Нәгыйм шаккатып баш чайкады. Әнкәсе исә кече улы өчен зур горурлык хисе тоеп соклануын белдерде:

—И-и-и, балакаем, боларны кайлардан белеп бетердең?

—Мин бит зур нәчәлникне йөртәм, әнкәй,—диде Яббар, илһамланып.

Сәетнең кәефе кинәт сүренкеләнде. Әчке киеренкелеге чыраена чыкты.

—Нәчәлнигең төрмәләрдә утырганыңны белмиме?—диде ул, бөтенләй көтмәгәндә.

—Белә,—диде Яббар, ашый башлаган җиреннән туктап.

Сәет:

—Ә легионер булганыңны?—дип сорагач, барысы да тып-тын калдылар.

—Анысын да белә,—диде Яббар, абыйсына карарга кыймыйча.

Табынның шундук яме китте.

—Каян белгән?—дип сорады Нәгыйм.—Кем хәбәр иткән икән?

—Үзем сөйләдем барысын да,—диде Яббар.

—Ничек кабул итте?—дип кызыксынды атасы.

—Төшенкелеккә бирелмә, диде. Гаепсезлегең күзеңнән күренеп тора, диде. Урнаш, эшлә, әмма боларны башкаларга сөйләмәскә тырыш, диде. Әле шундук ике банка тушенка, бер банка сгущенка да бирде.

Сәет кашыгын шакылдатып өстәлгә куйды:

—Нәчәлнигең үзе, яки берәр туганы легионер түгелдер бит?!

—Юк,—диде Яббар, абыйсына туры карап.

Сәетнең ачуы бәреп чыкты:

—ГЭС, агрегат, водохранилище, киловатт! Начальнигың миһербанлы кеше! Тушенка, сгущенка! Син балда-майда йөзәчәксең! Ә мина эшем буенча күтәрелергә районнан рөхсәт бирмиләр!

Әминә кырыенда утыручы олы улының иненә кулы белән кагылып ялварды:

—Сәет, улым, түз, сабыр ит.

Нәсимә кубарга торган давылдан куркып эндәште:

—Ашагыз әле, ашыгыз суына.

Әмма инде ашның тәме югалды. Шулай да Нәсимәнең тавышы табын янындагы ярсуны бераз таратыбрак җибәрде.

—Авылда нинди яңалыклар бар?—дип кызыксынды Яббар, өстәл башында теләр-теләмәс кенә ашап утыручы атасына карап.

Нәгыйм урындыгын шыгырдатып җайлабрак утырды:

—Иң зур яңалык шул—Әнсарны райкомга эшкә алдылар. Авыл җитәкчесе булып аз гына эшләде югыйсә. Ай-яй тиз күтәрделәр үзен.

Әминә күрше малаеның дәрәҗәсе күтәрелүгә ихластан куанды.

—Маладис,—диде ул.—Сүз дә юк, маладис, читтән торып укыды, кулыннан эш килә, акылы бар.

—Аның урынына силсәвиткә кемне куйдылар соң?—диде Яббар.

—Килгән кешене сайладылар,—диде Нәгыйм.—Харис исемле. Агроном иде ул, практикага монда җибәргәннәр дә, шушында төпләнеп калды. Күп

тә үтмәде, каяндыр бер керәшен кызын хатынлыкка алып кайтты. Сәер булса да, бик тырыш кеше, аны сайлап дөрес эшләгәннәрдер.

Сәет авыз кырыйларын алдындагы тастымал белән сөрткәч, Яббарга карап торды да кырыс тавыш белән әйтеп куйды:

—Синең аркада мине яхшы эшкә алмыйлар. Минем өчен иң зур яңалык шул.

Яббарның үзәге куырылып куйды:

—Нинди эшкә?

—МТСның баш механигы итеп тәкъдим итмәкчеләр иде, энесе сатлыкҗан дип кандидатурамны кире кактылар.

—Бәлки Әнсарга мөрәҗәгать итәргә кирәктер,—диде Нәгыйм, сызлый башлагын аягын бөгелеп кулы белән угалый-угалый.

—Күпме мескенләнергә, түбәсенергә була инде!—дип җикерде Сәет.—Шул Әнсар алдында гомер буе бил бөгәрмен микәнни?! Кемнендер сатлыкҗанлыгы аркасында мин гел кол сыман тезләнеп яшәрменме?!

Шунда Әминә көтелмәгән усаллык белән олы улына җикерде:

—Уңышсызлыкларыңны гел Яббарга гына сылтама!

Сәет «әкбәр» итеп тиз генә битен сыпырган булды да сикереп торды:

—Сылтамаскамы?! Мин уңышсызмы?! Миңа эшем буенча бер генә дә кыек-мыек сүз әйткәннәре юк, эшемдә мине бернәрсәдә беркем гаепли алмый! Ә Яббар аркасында әле монда, әле тегендә абынырга туры килә.

—Энем ялга кайтты дип куанып утырасы урынга тагын өйдә тузан тузгытырга торасыңмы?!—диде Әминә, ачуланып.

Көтмәгәндә Нәсимә ирен якларга керешге:

—Соң, әнкәй, миңа да мәктәптә еш кына төрттереп куялар—имеш, гаиләбездә изменник бар. Мин укытучы кеше, патриотизм турында сөйли башласам, телем әйләнми. Баштарак үтәр, яки күнегермен дигән идем...

—Түзәргә кирәк!—диде Әминә, тагы да кырысланыбрак. Соңгы вакытта ананың тавышында да элек ишетелмәгән катылык яңгырый башлады.—Син, Сәет, энең аркасында абынасың икән, егылсаң да, торып кит. Эшеңнән кусалар да, түз, гади эшче булып эшлә.—Аннары тавышын йомшартыбрак Нәсимәгә эндәште:—Ә син, килен, кияүгә чыкканда Яббарның фаҗигасен беләидең. Зинһар өчен, син дә түз!

Нәгыйм:

—Аллаһы әкбар,—дип табын янынннан китеп сәкегә барып ятты.—Түз... Синең гомергә шул бер сүз булды инде—түз, түз, түз.

—Әнкәй, китим мин,—диде Яббар тыныч кына.

—Юк, юк, улым, мунчалар кереп, ял итеп китәсең,—диде Әминә катгый итеп.—Аннары... берничәне кунмыйча китмисең, улым.

—Син теләсә кайчан китә аласың,—дип мыгырдады Сәет.—Ә без монда калабыз, синең яман атың белән!

Яббар битен сыпырып:

—Аллаһы әкбар, рәхмәт, тәмле булды,—диде. Шуннан торып:—Мин һава сулап керәм, әнкәй,—дип ишегалдына чыгып китте.

Әминә әле Сәеткә, әле Нәсимәгә ачулы караш ташлады.

—Мин шуны әйтмәкче булам...—диде ана янаулы тавыш белән.—Сез, балалар, тагын Яббарга тел-теш тигезсәгез, миннән якты чырай күрмәссез! Риза-бәхил түгел!

Нәсимә елый-елый олы якка кереп караватка ауды. Сәет хатынын юатырга дип аның артыннан кереп китте.

—Әнкәй күзгә күренеп үзгәрә, көнеле кырыслана,—диде Нәсимә, сулкылдап.

Сәет караватк кырына утырды:

—Әйе шул, сизәм.

—Мондый коры кеше түгел иде ул.

—Яббар аркасында күнеле катты анын,—диде Сәет.—Нык ярата ул кече малаен.

Нәсимә торып утырды, битен учлары белән сыпырды:

—Ничек инде баласын яратмасын.

—Мунча ягып җибәрәсе бар,—диде Сәет, хатынын елаудан туктатып игътибарын башка нәрсәгә юнәлтер өчен.

Алар мунчага су ташыйсы бар дигән сылтау белән өйдән чыгып киттеләр.

Нәгыйм кече якның сәкесендә түшәмгә карап яткан килеш тәрәзәдән олы улы белән киленнен урамдагы коедан мунчага су ташыганнарын күзәтеп торучы карчыгына эндәште:

—Синең дә холкын үзгәрде, карчык.

—Шулаймы...—диде Әминә битараф кына.

—Артык кискенләнмә әле син.

—Барыгыз да Яббарны кыерсытасыз,—диде Әминә, картына карамыйча гына.—Син, ата кеше, үз баланны әле бер тапкыр гына да якламадын.

—Дөньялыкта һәрбер кеше үзенә язганын алырга тиеш.

—И-и-и, нәрсә дип ята бит!—диде Әминә, нәфрәтләнеп.—Яббарнын күнеле тутырук ут икәнне күрмисеңмени?! Тагын нәрсә алырга тиеш ул бала?! Шундый җәбер-золымнар кичкәннән соң да бимазалана бит ул! Нишләп шушы кадәре каты бәгырьле сон син!

Нәгыйм яткан урынында боргаланып алды:

—Бала, бала... Син Сәет белән Нәсимәгә бик орынма. Яббар ул читтә яшисе кеше, ә болары белән гомер азагына кадәр бергә яшисебез бар.

—Нәсимәсе дә Яббарга тел-теш тигезә башлады бит,—диде Әминә.

Нәгыйм тавышын әкренәйтте:

—Соң, ансы да гасабиланып инде. Аларның соңгы вакытта кыбырсуларынын сәбәбе—балалары юклыктан. Күпме торып балалары юк бит.

—Булыр әле, Алла боерса,—диде Әминә, «бала» сүзеннән кинәт йомшарып.

Нәгыйм:

—Булса булыр иде инде,—дип тагын стенага борылып ятты.

—Тик кенә ят,—диде Әминә бернинди ачусыз.—Йөрәгенне тынычландыр да, тик кенә ят.

—Ятам бит инде,—дип җавап бирде Нәгыйм чак кына ишетелерлек итеп.

Нәгыйм шулай торымнан-торымга ыңгыраша-ыңгыраша сәкедә ятты, Әминә казан тирәсендәге вак-төяк эше белән мәшгуль булды.

Бераздан берни булмагандай кыяфәт белән Яббар килеп керде, беркавым әле атасына, әле анасына елмаеп карап торды.

—Әти! Әнкәй! Мунчалар кереп тормам инде,—диде ул.

—Ничек инде мунчалар кереп тормыйсын?—дип пошаманга калды Әминә.

—Мина кичекмәстән китәргә кирәк.

Әминә улына ялынырга тотынды:

—Юк, юк, улым, алай итмисен! Ничек инде мунчалар да кермичә, берничәне кунмыйча?!

—Тиздән иркенләп, озакка кайтырмын әле. Әти, сина бирәр төрле яна дарулар кирәкмиме?

Нәгыйм әкрен генә торып утырды:

—Дарулар бар минем, улым.

—Әле булганнарын да ялындырып кына эчә,—диде Әминә.

—Дарулар кирәк булса, хат языгыз—фәлән-фәлән дару кирәк дип. Алып кайтырмын.

—Нинди хат инде!—диде Әминә.—Тиздән кайтам дисең бит. Син кайт, улым, гел кайтып йөр. Минем янымa кайтасың бит син. Син башкаларга игътибар итмә. Мин сине бик сагынам бит, улым. Иң кадерле кешем син минем, балакаем! Шуны онытма. Гел кайтып йөр!

Әминәнең күңеле тулганны күреп Нәгыйм чыраен сытты:

—Елама инде. Улың шундый бөек төзелештә эшли. Горурланып, сөенеп, елмаеп кына утыр.

—Ул төзелүче ГЭС белән бигүк горурланырга иртәрәктер шул әле,—диде Яббар.—Нәчәлник әйтә: алты мең квадрат километрдан артык мәйданны су басачак, ди. Сер итеп әйтте. Бу тирәләрне дә отыры су басмагае дип куркам әле мин.

—Ул кинәт басмыйдыр бит,—диде Нәгыйм.—Баса башласа әйтми калмаслар. Аннары, Куйбышев моннан ерак бит ул. Нүҗәли суы монда хәтле менәр?!

—Менүе дә ихтимал. Егерме агрегат төзеләчәк бит. Хәер, әле алдан куркып утырырга кирәкмидер. Ләкин нәчәлник әйтүе буенча, су нык күтәреләчәк.

—Күрә торып, авылларга хәтле суны күтәртмәсләр әле,—диде Әминә әллә кайчан әллә кайдан су килеп басасын күз алдына да китерә алмыйча.

—Шулай, әнкәй, шулай. Анда бит бик зур инженерлар, белгечләр эшли, алар нишләгәннәрен аңлап эшлиләр.

—Улым, әллә берәрне генә булса да кунасыңмы?—дип тагын бер тапкыр үтенеп карады Әминә.

—Юк, әнкәй, китим инде мин.—Ул тагын әле атасына, әле анасына карап куйды.—Шуны әйтмәкче идем... Миңа инде утыз яшь... Мин тиздән өйләнермен, ахрысы.

—Йөргән кызың бармы соң, улым?—диде Әминә, йөрәгенең дерт итеп киткәнен тоеп.

—Бар.

—Татар кызымы?

—Татар. Куйбышев кызы. Татарча сөйләшүе чамалырак, әлбәттә.

Әминә бу хәбәргә бик сөенде.

—Булсын, булсын,—диде ул.—Татар кызы булгач шул җиткән. Үзебезнең кеше булгач бик әйбәт. Кайчан алып кайтасың соң инде аны монда?

—Мин аны монда алып кайтып тормас идем... Сез рөхсәт итсәгез... Никахны барыбер кыз ягында укыталар. Сезне шунда алып барып...

Әминә улының сүзен бүлде:

—Ник башта аны монда алып кайтып күрсәтмисең соң?

—Мин, гомумән, аны монда алып кайтмас идем.

—Ничек инде?!

—Аңламыйсыңмыни ник алып кайтырга теләмәгәнен!—дип кысылды Нәгыйм.

Әминәнең әле генә яктырган йөзе тагын караңгыланып китте:

—Ул белмимени?

—Белә. Мин яшермәдем, аңа барысын да сөйләдем. Тик аның болай белүе бер нәрсә, ә туганнарымның миңа карата мөгамәләсен сизүе, күрүе бөтенләй башка нәрсә!

*Дәвамы киләсе санда*



Рафаэль
Мостафин

# БЕРЕНЧЕ ИДАРӘ

1934 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕНДА СССР ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ УСТАВЫ «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛА

Шул ук елның июнь аенда Үзәк комиссия утырышында Язучылар союзына (берлегенә) әгъзалыкка кабул итү була. Ул вакыттагы комиссия бик таләпчән: әгъзаларны сайлыйлар. Иң житлеккәннәрне, язучы булып танылганнарны гына алалар. Әгъза булачак кеше берничә яхшы китап авторы да булсын, укучылар алдында дан да казанып өлгерсен, ә иң мөһиме—сәяси яктан революция яклы, чыгышы ягыннан да бәхәс тудырырлык булмасын. Ягъни мулла яки кулак малае була күрмәсен. Равил Фәйзуллин «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» китабында язганча, ул чорда Союзда әгъза булу югары гыйльми дәрәҗә алудан бер дә ким булмый.

Татарстан Язучылар союзына барлыгы 21 кеше кабул ителә. Болардан тыш 8 кеше әгъзалыкка кандидат итеп алына (ул чорда шундый статус та булган).

Татарстан язучыларының беренче съезды (хәзер без инде корылтай дип әйтер идек) Татар Дәүләт академия театры бинасында 1934 елның 25 июлендә ачылып, дүрт көн дәвам итә. 29 июль көнне оешмабызның иң беренче идарәсе сайлана. Анда тугыз кеше керә. Кемнәр алар?

**Кави Нәҗми**—идарә рәисе. Аның кандидатурасы бер дә очраклы түгел. Танылган язучы, талантлы шагыйрь һәм прозаик булудан тыш,1932 елдан бирле К. Нәҗми Татарстан совет язучылары союзын оештыру комитетында бик актив эшли. Шул ук вакытта ул башта «Атака», соңыннан «Совет әдәбияты» журналларының җаваплы мөхәррире вазифасын башкара.. Татарстанның ВКП(б) өлкә комитеты да аны бу җаваплы эш өчен иң лаеклы кеше дип саный.

**Кәрим Тинчурин.** Шул вакытта ук ул татар совет драматургиясенең классигы булып исәпләнә. 1910 елдан К. Тинчурин беренче татар профессиональ театр труппасында башта актер, соңыннан режиссер булып эшли башлый һәм бөтен гомерен татар театр сәнгатен һәм драматургиясен үстерүгә багышлый. Аның егерменче елларда ук язылган драмалары—«Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл» һ. б.—әлегәчә Академия театры сәхнәсеннән төшми.

**Гомәр Гали.** Танылган язучы-публицист, абруйлы тәнкыйтьче. 1925—1927 елларда «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы хезмәткәре. 1927 елдан 1937 елга чаклы Татарстан дәүләт китап нәшриятында матур әдәбият секторы мөдире булып эшли. 1932—1934 елларда исә ул да К. Нәҗми кебек Татарстан совет язучылары союзын оештыру комитеты җитәкчеләренең берсе була.

**Гомәр Толымбайский.** Шул чорның әдәбият мәйданында бик актив эшләп килгән язучы, прозаик һәм тәнкыйтьче. Казан вакытлы матбугатында, аеруча «Безнең юл» журналында, сугышчан рухлы тәнкыйть мәкаләләрен һәм агитацион рухтагы әдәби әсәрләрен бер-бер артлы бастырып тора. Ул шулай ук әдәби агымнар көрәшендә дә актив катнаша. Г. Толымбайский—«Сулф» («Сул Фронт») оешмасын төзүчеләрнең берсе. Кайвакыт, артык «кызылланып», «чыгышы ягыннан шикле» каләмдәшләрен фаш итә, кызып китеп, әдәби мирасны да инкарь итә.

**Хәсән Туфан.** 1924 елдан яза башлап, егерменче еллар ахырында үзенең әлегәчә әһәмиятен җуймаган «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады» һәм «Бибиевлар» исемле поэмаларын иҗат итә. Бу поэмалар татар поэзиясенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

**Ләбиб Гыйльми.** Яшь язучы-прозаик. Аңа 1934 елны нибары 28 яшь була. 1930 елдан яза башлап, ул берничә хикәя, повесть бастырырга өлгерә, «Чын мәхәббәт» исемле романын яза башлый. Идарәгә сайлануының бер сәбәбе: бу вакытта ул комсомолның Татарстан өлкә комитетында икенче секретарь булып эшли, идеология ягыннан бик ышанычлы кеше булып санала.

**Гаяз Ризванов.** Танылган журналист, «Кызыл Татарстан» газетасының баш мөхәррире. Ул Язучылар берлегенең эше белән турыдан-туры шөгыльләнә, үзе дә язучы булырга хыяллана. Союзны оештыру комиссиясенең рәисе буларак, зур эшләр башкара. Татарстан язучыларының Беренче съездында ул өч сәгатьлек доклад белән чыгыш ясый. Шул ук съездда аны язучыларның беренче Бөтенсоюз съездына делегат итеп тә сайлыйлар.

**Василий Красный** (Краснов-Асли). Танылган чуаш язучысы. 1900 елны хәзерге Буа районының Чураково авылында туган. 20нче еллардан башлап чуаш авылы турында матур-матур хикәя һәм повестьлар иҗат итә.

**Кәшшаф Төхфәтуллин,** секретарь. Аның турында бернинди мәгълүмат та таба алмадым. Күрәсең, ул язучы булмагандыр, техник эшләр генә башкаргандыр.

Беренче идарә нибары өч ел гына эшләп кала. 1937 елны барысын да диярлек кырып-себереп утыртып чыгалар. Бик сирәге генә исән кала.

Кави Нәҗми ике елдан артык утыра. Ул күргән газапларны дошманына да теләмәссең. Аны көне-төне эт итеп кыйныйлар, җенси әгъзаларын итек үкчәсе белән басып сыталар, атналар буе салкын карцерда билдән бозлы суда тоталар. Хатынын кулга алалар, бердәнбер улы Тансыкны утырту белән яныйлар. Тәмам кешелеген җуйгач, җәзаларга түзә алмыйча, «гаепләрен» танырга мәҗбүр була. Алай гына да түгел, башкаларны гаепли торган кәгазьләргә дә кул куя. Соңыннан, 1939 елны тулысынча акланып ирекккә чыккач, ул аның катнашлыгында утыртылган иптәшләрен төрмәдән чыгарырга булыша.

Кәрим Тинчурин 1938 елны атып үтерелә.

Гомәр Толымбайский, тоткыннар истәлеге буенча, җәзаларга түзә алмыйча, акылдан шаша. Шуңа да карамастан, аны шул ук 1938 елны атып үтерәләр.

Хәсән Туфанны 1937 елны Язучылар берлегеннән чыгаралар. Әмма нигәдер кулга алмыйлар. Ләкин өч ел үткәч, 1940 елның көзендә төрмәгә утырталар. Ун ел утырып чыкканнан соң, мәңгелек сөргенгә Себер якларына җибәрәләр. Ул 1956 елны гына, Сталин үлеп, «җепшеклек» чоры башлангач кына, туган якларына кайта.

Ләбиб Гыйльми 1937 елны үзен шактый ямьсез тота, башкалар өстеннән шикаятьләр яза. К. Нәҗмине кулга алгач, аны Татарстан Язучылар союзының рәисе итеп куялар. Әмма ничек кенә «кызыл» булырга тырышмасын, бу аңа ярдәм итми. Шул ук дәһшәтле 37 елның җәендә аны да кулга алалар һәм берничә айдан атып үтерәләр.

Гаяз Ризванов 1937 елда кулга алынып, 1939 елны лагерьда вафат була.

Шунысын да искәртеп китәргә кирәк: бу вакытта әлеге әдипләргә нибары кырык яшь чамасы.. Әгәр репрессияләр булмаса, күпме яна әсәрләр язылыр да, күпме әдәби ачышлар булыр иде!

Василий Красный да шул ук 37нче елны кулга алына. Әмма ниндидер могжиза белән исән кала. Ун ел утырып, исәнлеген тәмам югалтып, туган якларына кайтып егыла. Хәтта күпмедер вакыт иҗатын да дәвам итә, берничә китап язып, Чабаксарда бастырып чыгара.

Югарыда әйтеп үткәнемчә, бер Кәшшаф Төхфәтуллин язмышын гына ачыклый алмадым. Кайбер журналистларнын фаразлавынча, ул каядыр әллә Урта Азия, әллә Казакъстан якларына качып котыла. Алматыга баргач, мина атаклы нефтьче, Казакъстанда эшләп дан казанган Рид Кәшшаф улы Төхфәтуллин турында сөйләгәннәр иде. Имештер, ул әлеге Кәшшаф Төхфәтуллиннын улы икән. Дөресме, түгелме, тәгаен генә әйтә алмыйм.

Шул тугыз язучы Татарстан язучылары съездында Мәскәүгә, СССР язучылары съездына да сайлана. Аларга өстәп тагы өч әдипне сайлыйлар: Ибраһим Газины, Галимжан Нигъмәтине һәм Фатих Сәйфи-Казанлыны. Бу өчлектән бары Ибраһим Гази гына иректә кала. Калган икесе—репрессия корбаннары.

Шундый сорау туарга мөмкин: ни өчен әлеге беренче идарә әгъзаларын уптым-илаһи җыеп, юк итәләр? Әллә берәр гаепләре булганмы?

Сәбәбе бик гади. Бабам мәрхүмкәй әйтә торган иде: 1937 елны НКВД балыкчылары эре балыкны гына сөзеп ала иделәр. Вак балык ятьмәгә эләксә дә, очраклы рәвештә генә эләккән. Чыннан да, ул чорнын тәртибе шундый иде: өлкә, шәһәр комитетлары, райком кешеләрен бөтен бюросы белән җыеп алып атканнар. Завод-предприятие житәкчеләрен шулай ук өере белән кулга алганнар. Шул ук хәл Язучылар берлеге белән дә кабатланган.

Бер ел эчендә өч идарә составын кулга алалар. Башта К. Нәжми житәкчелегендәге идарәне. Аннан сон Л. Гыйльми рәислегендәгесен. Иң соңыннан, ел ахырында— Мирсәй Әмир житәкләгән идарәне.

Югарыда әйтелгәнчә, Татарстан язучылар берлегенә барлыгы 21 әгъза һәм 8 кандидат кабул ителә. Шулардан 13 әгъза һәм 2 кандидат репрессияләнә (югарыда санап үтелгәннәрдән тыш, Мансур Крыймов, Фатих Кәрим, Фәтхи Бурнаш, Мирсәй Әмир, Таһир Госман-Сулмаш (Хатип Госманнын абыйсы), кандидатлардан Шамил Усманов һәм Галимжан Мөхәммәтшин.)

Барлыгы исә иллеләп татар әдибе репрессия корбаны була. Әмма шуна да карамастан татар әдәбияты юкка чыкмый, репрессияләнгән язучыларга алмашка яшь әдипләр килә. Әдәбият яши, әдәбиятны үтереп булмый.



*Бауман урамындагы Матбугат йорты балконында бер төркем язучылар. Сулдан уңга: Н. Дәули, С. Әдһәмова, Б. Гыйззәт, Х. Хәйри, Х. Туфан, И. Гази (эшләпәдән), Г. Бәширов, Ә. Давыдов. 1966 ел.*



*Дус әдипләр очрашуы. Сулдан уңга: А. Гыйләҗев, Ш. Мәхмүдов, Х. Туфан, А. Айвазов, М. Кәрим, Г. Ахунов, Х. Госман, М. Гайнуллин. 1970 ел.*



*Төрле милләт вәкилләреннән бер төркем совет язучылары. Арада татар язучыларыннан Г. Бәширов, С. Хәким, Х. Туфан, М. Әмир, Л. Ихсанова, Х. Вахит һ. б. бар. СССР Язучыларының IV съезды көннәре. Мәскәү. Кремль. 1967 ел.*



*Данлыклы Матбугат йорты. 1933-35 елларда архитектор С. Пэн проекты белән конструктивизм стилендә салынган бина. XX гасырда чыккан татар китапларының, газета-журналларының күбесе шушы бинада әзерләнде һәм аның полиграфия комбинатында басылды.*



*Әлмәт төбәге язучылары. Сулдан уңга— Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



Гази Кашшаф

# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

Һәрбер редакциянең үзенең «ломовой аты», авыр йөк тартып баручы хезмәткәре була. «Казан утлары» журналы редакциясендә дә андый хезмәткәрләр булды. Редакциянең бүгенге көнен телгә алмаска да мөмкин, чөнки илнең гомуми икътисади куәте үсү белән бергә журналның аппараты да киңәйде. Бүген эш төрләре хезмәткәрләр арасында тигез бүленгән. Барыннан да бигрәк журналга материал эзләп төрле якка чабасы юк. Хәзер роман, повестьларны эзләмиләр, калын-калын кульъязмалар басылырга чират көтеп ята. Язучылар санының көннән-көн арта баруы калынайганнан-калыная барган шушы журналның мәйданын тарайтып җибәрде. Әле бит без күптән түгел генә тиешле югарылыктагы материалны каян алырга интегә идек. Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби хезмәткәр штаты кыскартылды. Ул чакта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Гомәр Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде. Бөтен эш Абдулла Гомәр җилкәсенә авып калды. 1942 елны Гомәр Бәшировны мин алыштырдым. Гомәр Бәширов Татарстан радиосының баш мөхәррире итеп билгеләнде. Журналда хәл авырлыгына котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле Матбугат йорты ягылмый иде. Менә без Абдулла Гомәр белән икәү «Совет әдәбияты» журналының нәүбәттәге санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын үзәккә үтә. Һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда урамда җылырак шикелле тоела безгә. Менә шундый авыр шартларда кемнең нәрсәгә сәләтле һәм ни дәрәҗәдә чыдам икәнен күрәсең. Абдулла Гомәр журналга барлык энергиясен салып эшләде. Сугыш сузылган саен кыенлыклар арта бара: кәгазь кытлыгы, типографиядәге авырлык, кульъязмалар җитмәү һәм башкалар. Өстәвенә баш мөхәррир айлар буе чәчү, урып-җыю кампанияләрендә йөри. 1943 елның җәендә типографиядә җыелмыйча хәрәкәтсез яткан журналларыбызның саны җидегә җитте. Димәк, җиде ай буе без укучыларыбызга журналны җибәрә алмыйча тордык. Бу өзеклекне бетерү өчен, билгеле, партия оешмалары күп тырыштылар. Ләкин типографиянең эшен, сугыш заказларын үтәүне тыярга кемнең кулы күтәрелсен. Ул чакта Абдулла Гомәр дә нәшриятка күчерелде. Без башта Әнәс Камал белән калдык. Бераздан Фатих Хөсни килеп кушылды. 1943 елның октябрендә мина тагын бер эш йөкләделәр. Мөхәррирлектән бушатмыйча гына Татарстан Язучылар оешмасының җитәкчесе итеп сайладылар. Бер көнне кич белән мине җитәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык. Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт һәм мин Мәскәүгә китәргә һәм СССР Язучылар союзының президиум утырышында Татарстан Язучылар союзының эше турында хисап бирергә тиеш идек. Язучылар союзы президиумында хисап докладын мин ясадым. Безнең эшебез мактанырлык түгел иде. Шуна күрә кимчелекләрне һәм аның сәбәпләрен төкми-чәчми сөйләп бирдем. Утырышны

Александр Фадеев алып барды. Мона кадәр ул Казанда ике тапкыр булып киткән һәм безнең хәлләр белән яхшы таныш иде. Бу безнең мәсьәләне президиум утырышына куеп, кулдан килгәнчә гамәли ярдәм күрсәтү, булышу теләге белән эшләнгән иде. Президиумда ачыктан-ачык житди сөйләшү булды. Әйбәт, эшлекле тәкъдимнәр әйтелде. Ләкин Александр Фадеевны мондый сөйләшүләр генә канәгатьләндермәде. Шушындагы сөйләшүләрнең гамәли нәтижәсе булсын өчен ул безне Партиянең Үзәк комитетына алып барырга теләген әйтте. Икенче көнне Тажи Гыйззәт, Кави Нәжми һәм мин Александр Фадеев белән Үзәк комитетка юнәлдек. Үзәк комитетның пропаганда бүлегендә мина шактый зур хисап докладды сөйләргә туры килде: Татарстандагы әдәби хәрәкәтнең торышы, нәшрият эшләре, язучы кадрларның барсы диярлек фронтның алгы ут сызыгында булуы, аларның солдат хезмәтен үтәү белән бергә язучылык эшен дә алып барулары, үзебезнең дә бик авыр шартларда яшәвебез хакында сөйләдем. «Унышлар турында сөйләмим, кимчелекләр турында әйтәсе килә», дип башлаган идем сүзне. Кызып китмәч, бердәнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәле турында да сөйләргә туры килде. Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр. «Ничек, сездә журнал чыгамени?» Фадеев мин утырган урындык артында басып тора иде. Сорауны аңа да бирделәр: «Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?» Мина Фадеевның йөзе күренми, ул һаман кулын минем жилкәмә куеп басып тора һәм бик гади нәрсәне раслаган төсле үзенең ягымлы тавышы белән: «А как же, без жите климбез»,—диде. Фадеев чыннан да бу хәлне белә иде. Шуна күрә аның сүзе «Бу шулай һәм шулай булырга тиеш» дигән мәгънәдә яңгырады. Казанда вакытлыча туктаган хәрби эшелоннардан бер генә данә булса да журнал бирегез дип килүче офицерлар турында, үзем командировкада йөргәндә күрше Башкортстан районнарыннан берәр журнал сорап кеше жибәргән колхоз рәисләре турында, редакциягә килгән хатлар турында сөйләдем. Үзәк комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар, авырлык белән булса да журналны туктатмыйча чыгарып килүебезне хупладылар. Бу сезнең «подвиг» диделәр. Бу мактауны без Татарстан өлкә комитетының һәм журналда актив катнашучы барлык язучыларның уртак казанышы дип кабул иттек.

***

*Мин рядовой солдат бу сугышта,*
*Тик бер нәрсә белән аерылам:*
*Рядовойлар төнен йоклаганда*
*Мин йокламыйм, шатлык-кайгыдан.*
*Бер минут та башка тынгы бирми*
*Окоп почмагында утырам.*
*Аламын да куен дәфтәремне*
*Янып жыр язарга тотынам.*

Фатих Кәримнең бу шигыре татар фронтовик язучыларының күмәк портретын дөрес сурәтли. Шәрәф Мөдәррис, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Әхмәт Ерикәй, Ибраһим Гази, Шәйхи Маннур, Гадел Кутуй, Мөхәммәт Садри, Хатыйп Госман, Гали Хужи, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Абдулла Әхмәт һәм башка фронтовик язучыларның эзлекле ярдәмнәре булмаса, журналны чыгару мөмкин булмас иде.

«Совет әдәбияты»ның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан-кулга күчә. Тылдан бик кадерле бүләк төсендә, фронтка юнәлә. Хәрби частьләрдән махсус соратып алалар, кичектерми фәлән-фәлән саннарын жибәрегез дип таләп итәләр. Әгәр дә алар сораган саннар барып житмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат жибәрәләр. Мондый хатларны без тылдан да ала идек, очрашу вакытларында да шушы мәсьәлә күтәрелә иде. Шул рәвешчә, «Совет әдәбияты» журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды.

*1972.*



Туфан
Миңнуллин

# МИНЕМ ЭШЕМ ТҮГЕЛ ИДЕ УЛ

Түрәләр рәтенә ничек килеп эләккәнемне үзем дә сизми калдым! Югыйсә беркайчан да нәчәлник булу турында уйламаган да, хыялланмаган да идем. Күрәсең, миндә үзем дә белмәгән лидерлык сыйфатлары булган. Малай чакта да, егет булырга җыенып йөргәндә дә иптәшләрем арасында авторитет бар иде бугай үзе. Физик көч белән мактана алмасам да, берәүнең дә миңа сукканы булмады. Үзем дә, Ходайның биргәненә шөкер, берәүгә дә кул күтәрмәдем. Ләкин әйткән сүземне тыңлыйлар иде. Чөнки нинди дә булса кызыклы, әкәмәт әйбер уйлап чыгарырга һәвәслек бар иде.

Язучы исемен йөртә башлагач та, рәислеккә омтылмадым, кызыкмадым. Президиум өстәле артында утыручылардан көлеп залдан репликалар кычкырып утыручы Батуллалар арасында булдым. Партиягә керүем дә карьера белән бәйләнмәгән иде. «Нигә әле миннән башка гына партҗыелышка җыелып, мине тикшерергә тиешләр» дип кердем партиягә. Һәм көтмәгәндә-уйламаганда мине Язучылар союзының партоешма секретаре итеп куйдылар. Эшемне җиренә җиткереп эшләргә өйрәтелгән идем, эшләдем. Өстәгеләр тарафыннан да, каләмдәшләремнән дә начар сүз ишетмәдем шикелле. Ә инде Язучылар союзы идарәсенең рәислегенә килгәндә, анысы бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Отчет-сайлау җыелышына атна-ун көн вакыт калгач, мине өлкә комитетының идеология буенча секретаре Мөҗәһит Фәтхиевич Вәлиев чакырып алды. Аның янында культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин утыра иде.

—Без сине (обкомда безнең ишеләр белән «сез» дип сөйләшмиләр иде) Язучылар союзы рәислегенә тәкъдим итәбез,—диделәр.

Ике дә уйламыйча баш тарттым.

—Минем эшем түгел ул,—дидем. Шактый озак тарткалаштым. Соңгы аргумент белән алар мине сындырдылар.

—Син нәрсә, обкомнан башка гына яшәмәкче буласыңмы?—дигәч, курыктым. Обком сүзен тыңламауның ни икәнен белә идем. Сөйләшә торгач, берничә шарт куйдым. Берсе Союзда рәис урынбасары булып эшләүче Фәрваз Миңнуллинны янадан үз урынында калдыру иде. Чөнки аны җибәрәчәкләрен әйткәннәр иде. Туры сүзле Фәрвазны Мусин яратмады.

Съезд җитмичә беркемгә берни әйтмәскә куштылар. Сайлаулар башланганчы минем рәис булачагымны беркем белмәде. Сайладылар. Каршылар күп булмады

бугай. 1984 ел иде бу. Рәис вазифасын ничек үтәвем турында язмыйм, үземәүзем бәя бирергә теләмим. Төрлесе булгандыр. Шунысын төгәл беләм, кем генә эшләсә дә, рәислек рәхмәт ишетә торган эш түгел. Чөнки язучы халкын идарә итеп булмый—һәрберсе даһи. Эшләгән елларымның бер күнелле истәлеге шул—Союзны биналы иттем дип мактана алам. Комлев урамындагы затлы бинаның бушаячагын ишеткәч, өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усмановка киттем. Ни сәбәпледер, Усмановның мина мөнәсәбәте бик яхшы иде.

—Әгәр дә йомышың төшсә, әгәр дә мин үз кабинетымда булсам, туп-туры ишекне ачып кер,—дигән иде ул мина. Һәм беркайчан да сүзеннән кире кайтмады. Мин кабул итү бүлмәсендә чират торуымны хәтерләмим.

Бу юлы да туп-туры кереп киттем.

—Нигә бик сирәк керәсең? Нәрсә, минем ярдәмнән башка гына эшләргә остардыңмы?—ди бу.

Мин, жил ягына салам кыстырып:

—Сезне мин үзем хәл итә алмаслык проблемалар чыкса гына борчыйм,—дидем.

—Нинди проблема чыкты?—ди.

—Комлев урамында бик матур бер бина бушый, Язучылар союзы өчен салынган диярсең. Бирегез шуны безгә,—дидем.

Минем әрсезлегемнән көлде Гомәр Исмәгыйлович.

—Беләсеңме ул бинага претендентларның күпме икәнен?—ди.

Белдем—унлап оешма дәгъва кыла икән. Сөйләшәбез—Усманов көлә генә:

—Фантазерлар сез,—ди.

Аптырагач, уенга мин «уен тузын» ыргыттым:

—Уфада Башкортстан Язучылар союзы бинасын күреп кайттым. Шакиров бүләк иткән искиткеч гүзәл бина. Без әллә алардан кимме?—дидем.

Чиртте.

— Шулай ук гүзәлмени?—ди.

—Гажәеп бина!—дим.

—Сез алырга теләгән бинадан да матурмы?—ди.

—Безнеке әйбәтрәк булачак,—дим.

—Алыгыз. Ремонтлап та бирәбез. Башкортларны кунакка чакырып күрсәт,—диде беренче секретарь.

Инде рәис булып эшләгәндә истә калган хатирәләргә килгәндә, күбесе онытылган. Хәтергә иң сеңеп калганы—шагыйрь Роберт Әхмәтжанов белән әңгәмә. Аны мин кайдадыр язып та чыктым шикелле. Тагын кабатлыйм.

Салгалап йөргәне өчен Робертны ЛТПга алып китәргә жыенганнар. Ягъни лечебно-трудовой профилакторийгә—милиция карамагындагы эшләтеп дәвалый торган жиргә инде. Әйе, искиткеч талантлы шагыйрьнең андый йомшак ягы бар иде. Ләкин бүтәннәрдән артык эчте дип әйтә алмыйм, беркайчан да «исерек»шигырьләр язмады, эчсә, холкы бозыла иде. Күрәсең, бу гадәте бернича тапкыр участок милиционерының ачуын китергәндер инде. Роберт ЛТПның ни икәнен белә, шуңа күрә минем янга килгән. Бераз гына салмыш.

— Абдулыч, жибәрттермә мине ЛТПга,—ди. Мин моңа эчкечелеккә каршы вәгазь укырга керештем (начальник бит). Шуннан бу минем каршыма килеп тезләнде:

—Жибәрттермә,—ди.

Шунда мин шартладым. Ниләр әйткәнемне төгәл хәтерләмим дә инде, әмма кычкырдым, сүгендем:

—Син бөек шагыйрь башыңнан кем алдында тезләнгәнеңне аңлыйсыңмы?! Мин бит талантыңа баш иеп, үзем синең алдыңда тезләнергә тиеш. Нинди хәлгә төштең, шуны беләсеңме?!—дигән сүзләр дә әйтелде. Шуннан Роберт жылый башлады. Мин дә аның каршына тезләндем. Күзләремнән яшь атылып чыкты. Ике яшьтәш бүлмә уртасында тезләнеп жылаштык.

Милиция белән сөйләшеп, Робертны жибәрми калуыма бүген дә куанам.

Күңелдә төер булып калган истәлекләр дә бар. Язучы Атилла Расихның 70 яшьлек юбилее иде. Аны зурлап үткәрергә дип идарә утырышында карар кабул

иттек. Юбилей уңаеннан язучыга орден юллап кайларга, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем. Ниһаять, «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены юлладык. Юбилей кичәсендә орденны түшенә кададылар. Юбиляр рәхмәт әйтте.

Берничә ай узгач, язучыларның җыелышында Атилла абый:


—Язучылар союзы идарәсе берни дә эшләми, юбилейлар үткәрү белән генә шөгыльләнә,—дип чыгыш ясады.

Рәнжедем.

Рәхмәтләр дә ишеткәнмендер, ләкин күңелгә тия торган сүзләр мине рәислектән тәмам биздерделәр. Эшлисе килми башлады. Соңгы елда бөтенесенә кул селтәп, иҗат белән генә шөгыльләндем. СССР халык депутатлыгына кандидатлар тәкъдим итү башлангач кайбер язучыларның ямьсезләнүен искә төшерәсем дә килми. Ә отчет-сайлау вакыты җиткәч, рәислеккә омтылучыларның мәш килүен күрү оят иде. Ана тиклем рәисләрне өлкә комитеты мәҗбүр итебрәк куя иде, мин киткәндә рәислек постын эләктерү өчен кайберәүләр нишләп кенә бетмәде. Исемнәрен дә атыйсым килми хәтта.

Рәислектән котылуыма сөенеп туймадым. Хәтта идарә составына керүдән дә баш тарттым. Соңгы сайлауда гына идарә әгъзасы булырга ризалык бирдем.

Җыеп әйткәндә, рәис булган елларымны сагынмыйм. Минем эшем булмаган ул.



*Т. Миңнуллин М. Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан үткәрелгән тантаналы җыелышта чыгыш ясый. Мәскәү, Союзлар йортының Колонналы залы, 1986 ел.*



Ринат
Мөхәммәдиев

# ИҢ БӘХЕТЛЕ ЕЛЛАРЫМ

Казанны, анда узган яшьлек елларымны, гомеремнең кадерле һәм онытылмас мизгелләрен сагынган чакларымда мин еш кына шәхси архивымда хисапсыз күп булып тупланган фоторәсемнәрне барлап утырырга яратам. Әле менә шуларның берсенә күзем төшкәч байтак кына телсез-өнсез калып утырдым. 1985 елның 8 май көнендә Арча кырындагы Үзәк ял паркы каршында, мәңгелек ут янында төшерелгән фоторәсемдә—кырыкка якын татар язучысы, һәммәсе фронтовиклар. Шулар арасында—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов һәм иждади оешманың ул еллардагы партия оешмасы секретаре мин фәкыйрегез... Сискәнеп куйдым кинәт, күз алларым караңгыланып киткәндәй булды... Шул рәсемдәге асыл затларның бүген ник берсе исән булсын икән! Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Риза Ишморат, Салих Баттал, Зәки Нури, Нәби Дәүли, Нури Арсланов, Сибгат Хәким, Әбрар Кәримуллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих... Саный китсәң—исән-акылыңны жуярлык. Әйе, вакыт аяусыз, ул үзенекен итә. Әле кичә генә булган кебек иде ул көн: «Мәңгелек ут» янындагы һәйкәлгә чәчәкләр куйгачтын, барыбыз бергә бәйрәм унаена оештырылган мул табында утырып нинди матур теләкләр теләгән идек бер-беребезгә! Гомер мәңге шулай дәвам итәр кебек иде. Баксаң, ул көннәрдән соң тулы бер дәвер кичкәнбез. Әдәбиятыбызның гына түгел, халкыбызның да горурлыгы булган шул асыл затлар арасыннан ник берсен, ичмасам бер мизгелгә генә булса да кире кайтарып булсын икән... Ә бүген исә көндез чыра яндырып эзләсәң дә китап кибетләреннән күпләренең әсәрләрен табу мөмкин түгел хәтта.

Әнә шундый Татарстан язучылары мине ике мәртәбә үзләренең рәисе итеп сайлап куйды—моннан да олырак нинди дәрәҗә булырга мөмкин язучы өчен! Шуңа да 1989-1999 елларны мин үземнең иң бәхетле елларым дип саныйм. Болгавыр еллар иде. «Үзгәртеп кору» дип башланган шаукым бөек бер империя булган СССРның таркалуы белән тәмамланды. «Бәйсезлек» дигән өмет һәм хыяллар, ташкынны хәтерләтеп, мәйданнарга чыкты. Язучыларның гына түгел, барлык татар зыялыларының иңнәренә ике канат үсеп чыккан иде кебек ул елларда...

Язучылар берлеге рәисе булып тулы бер ел тынычлап эшләргә өлгермәдем, Россиянең Халык депутаты итеп сайладылар. Сигез кандидат арасында барган бәйгедә җиңеп чыгу шулай ук зур казаныш иде ул еллар өчен. Укучы хәтерли булса кирәк, демократиягә безнең ихлас ышанган, халыкның үз ихтыярын ачыктан-ачык белгерткән еллар иде. Менә шуннан башланды да инде. Мин, бер генә түгел, ә ике утлы таба өстендә сикергәләргә мәҗбүр булдым. Мәскәүдә зур дәрәҗәле урыннарга тәкъдим ителү, сайлану һәм сайланмау, Горбачев һәм Ельцин, Усманов һәм Шәймиевлар белән күзгә-күз очрашып әңгәмә кылу һәм киңәш-табыш итүләр... Кремльнең зур сарае трибунасыннан ясалган чыгышлар, КПСС Үзәк

Комитеты секретарьлары һәм демократик хәрәкәт лидерлары белән даими әңгәмә һәм бәхәсләрне искә алсан—бүген дә чәчләрең үрә торырлык! Ул гынамы соң: мин бит әле депутат кына түгел, барыннан да элек Татарстан Язучылар берлеге рәисе. Шуңа күрә атна уртасында Мәскәүдәге ыгы-зыгыларда катнашканнан соң даими рәвештә Казанга очып кайта һәм һава аланыннан туп-туры Язучылар берлегенә юнәлә торган идем. Җомга һәм дүшәмбе көннәрендә берлектә язучыларны кабул итәм, аларның очсыз-кырыйсыз борчуларын уртаклашам, хәл кадәри ярдәм итәргә омтылам. Ә инде шимбә һәм якшәмбе көннәрендә юбилей кичәләре, тантаналы вакыйгалар яисә республиканың кайсыдыр бер районында алдан планлаштырылган очрашулар уздырыла торган иде. Бу көннәрдә мин каләмдәшләрем һәм укучылар белән очрашып яңа туасы атнага җитәрлек җегәр дә туплаганмын булса кирәк.

Шулар өстенә әле иҗат итәргә дә атлыгып торган чак, Мәскәү һәм Казан архивларында казынып Мирсәет Солтангалиев язмышына багышланган «Сират күпере» романын язган елларым. Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк: Мәскәү—Казан маршрутында очкан самолет салонында язарга керешкән чакларым да була торган иде.

Әлбәттә, даими рәвештә Казанда яшәмәвемнең Язучылар берлегендәге эшемә зыяны булмый калмагандыр. Бу уңайдан даими рәвештә канга тоз салып торучылар да табылмады түгел. Әмма язучыларыбызның күпчелеге, аеруча өлкән яшьтәге әдип һәм шагыйрьләр, ихлас күңелдән хәлемә кереп ярдәм кулларын сузарга һәрчак әзер иде. Шул елларда Берлек рәисе урынбасары булып эшләгән Мансур Шиһапов, Мәдинә Маликова һәм Зиннур Мансуровларның да фидакарьлекләрен билгеләп узмау мөмкин түгел. Ә инде өлкән остазларымнан Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники, Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин белән Ренат Харис иң авыр минутларда һәрчак ышанычлы киңәшче булып килделәр. Олы җанлы, кеше хәленә керә белгән әлеге талант ияләре каршында мин үземне бүген дә бурычлы саныйм һәм алар каршында баш иям.

Ә Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиевлар хакында оныттмадыңмы, дип сораучы булуы бик ихтимал шушы урында. Җавап бирәм: әдәбиятыбызның бу өч пәһлеваны белән аралашмый калган көнем дә булмагандыр. Татарстанның кайсы гына районында, кайсы гына авылларында булырга туры килмәде безгә бергә-бергә. Юлга дисәң, халык арасына дисәң, елның кайсы фасылы булуга карамастан, алар шундук портфельләрен күтәреп Язучылар берлегенә килеп җитә торганнар иде. Шартлар нинди, барасы юл еракмы дип сорау кая, тәүлегенә җиде-сигез җирдә очрашырга туры килсә дә офтануны, зарлануның ни икәнлеген белмәделәр.

Туксанынчы еллар башында, җәйге ямьле көннәрнең берсендә, безне Әтнә районында колхоз рәисе булып эшләгән Фәйзи абый Галиев авыл халкы белән очрашуга чакырды.

—Шоферыңны алып торма, үзең генә бар рульдә,—дигән тәкъдим кертте Мөхәммәт абый Мәһдиев.

Мин шундук килештем. Беләм ич, Мөхәммәт абый алда, шофер янәшәсендә утырып, ачык тәрәзәдән терсәген чыгарып, җилләнеп барырга ярата.

—Аңлашылды, Мөхәммәт балачактан хыялланган үз урынына утыра болай булгач,—дип, дусларча шаяртып алды Аяз Гыйләҗев.

—Казан артына, туган як тарафына юл тотабыз ич. Туган якның кыска җилен тоеп барасы, безнең якларның матурлыгын күбрәк күреп каласы килүдән генә...

—Казан арты—минем дә туган як. Аның каравы, Аяз дус, мин сиңа юл буе очраган авылларның тарихын сөйләп барырмын,—дип сүзгә кушылды Гариф абый.

—Аяз, әзер булып тор, Гарифҗан сиңа юл буена тынгылык бирмәячәк. Аз гына күзеңне читкә бордыңмы, терсәге белән касыгыңа төртеп барачак,—дип көткелдәп куйды Мәһдиев. Бу өч талант иясе үзара гел шулай уенын-чынын бергә кушып, үткен, әмма йомшак киная белән сөйләшә торганнар иде. Ләкин бу аларның чын дуслыкларына һичбервакыт күләгә-фәлән төшермәде.

Фәйзи абый Галиев безне иң олы кунакларыннан да болайрак каршы алды. Мәктәптә һәм авыл клубында очрашулар уздырганнан соң, үз өенә алып кайтты һәм без кайнар бәлеш бизәп торган мул өстәл янына утырып, төне буе диярлек кунак

булдык. Фәйзи абый үзе дә гаять зыялы кеше, болар нәрсә әйтер икән диеп дәшми генә язучыларның авызына карап утыра торганнардан түгел. Сүз ни хакында гына булмасын, аның очы, телисеңме-юкмы, ил язмышы, халык язмышы, әдәбият һәм мәдәниятебез язмышына барып тоташа иде.

Иртәгәсен, бергәләшеп авылның инеш буйларын урап кергәннән соң, без кайтыр юлга чыктык. Мин руль артында, татар прозасының өч классигы—пассажирларым, Фәйзи абый күчтәнәчләреннән багажник та шактый авырайган күренә. Ә көн... Андый матур җәйге көн елга, юк-юк, гомергә бер генә була торгандыр ул! Кайтасы юл әллә ни ерак та түгел иде югыйсә, «Волга»быз да өр-яңа, юлы да зарланырлык түгел. Алтмыш-җитмеш чакрымлык кайтыр юлга иртән тугызларда чыккан булсак, Казанга кичке уннарда, энгер-менгер төшеп килгәндә генә кайтып җиттек. —Син безне бер-бер җирдә туктатып сугарып алырга да онытмассың инде, Ринат,—дигән тәкъдим Аяз абый авызыннан чыкты иң элек.

—Көн безнеке, кайда кушсагыз—шунда туктыйм,—дидем.

Авылны чыгып ерак та китмәдек, Мөхәммәт абый бүлде тынлыкны.

—Безнең Казан артында гына ул мондый матур табигать. Күрегез әле әнә теге үр итәгендәге буа читен...

—Аңлашылды,—диеп күтәреп алды Аяз абый.—Беренче тукталыш шунда була, димәк.

—Фәйзи булган кеше, ул кайгырткан булса кирәк, анда—багажникта—ниләрдер челтер-челтер килә кебек,—дип кеткелдәп алды Гариф абый да.

Юлдан читкә төшеп, машинаны яшел чирәм өстеннән шул тарафка бормый чарам калмаган иде.

Су өсте тыныч, анда-монда эреле-ваклы балыклар сикергәләп уйный. Арырак кыр үрдәкләре балаларын йөзәргә өйрәтә. Безнең табын тагы да ямьлерәк булсын дигәндәй, янәшәбездән үк сузылып киткән борчак басуына бер төркем торналар очып төште шунда.

—Менә Аяз, хозурланып утыр, безнең Казан арты шундый инде ул,—дип, чираттагы мәртәбә мактану катыш горурланып куйды Мөхәммәт Мәһдиев.

Безне һичкем борчымады, куаламады, бүлдермәде, эчне пошырып урынлы-урынсыз чылтырый торган кесә телефоннары да юк иде әле ул чакларда...

Бер ниятенә кереп киткәчтен, тукталышлар ешаеп ук китте безнең! Чөнки җиләкле урман читләре, чәчәккә күмелгән тау битләре, куе яшел чирәм белән түшәлгән инеш буйлары, бөтнек исләре белән җанны иркәләгән салкын сулы чишмәләр берөзлексез очрап кына торды. Бүген исә, кайчандыр, бала чакларда колагыма кереп калган бер тылсымлы әкият кебек кенә күз алдына китерәм мин ул көнне...

Икенче бер чакны без—төркем язучылар—Балтач районына сәфәр кылдык. Чепья авылы музеена кергәч тә язучыларыбыз игътибарын фойедагы «Өч баһадир» картинасы җәлеп итте. Яшьрәк язучылардан берәү тәкъдим кертте шунда: «Безнең әдәбиятта да бар ич ул өч пәһлеван. Әйдәгез әле, Аяз абый, Гариф абый, Мөхәммәт абый, басыгыз шул рәсем астына. Фотога төшерәм...» Әдипләр, шаяруны дөрес аңлап, тегеләрчә килештереп, позага бастылар... Дөньяның матурлыгыннан, көннәрнең яктылыгыннан тәм табып, юкка да куанып яши белә иде шул алар! Бу фоторәсем соңрак матбугатта да чыкты. Бүген дә истәлек булып саклана. Ул фоторәсем дөньяга чыккачтын үзен «дүртенче пәһлеван» дип хис иткән кемнәрнеңдер эче дә пошып йөргән кебек иде. Ә Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Аяз Гыйләҗевлар андый ваклык, тар җанлылыктан өстен, югарырак тора белә иделәр. Сагынып искә алырга гына калды...

Сәяхәтләр хакында сүз чыккан икән, укучы хәлемә кереп гафу итә алса, тагы бер кечкенә эпизодны искә төшереп узыйм инде. Чөнки татар әдәбиятының иң олы классиклары да тормышта гап-гади кеше, җорлар иде, шаяру һәм шаяртуның тәмен белеп яши белә торганнар иде. Ничектер шулай Мамадыш якларыннан Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники белән бер машинада кайтып киләбез. Көн кичкә авышкан. Кояш алсуланып офыкка якынлашып бара. Түбән Яке авылына таба сузылган чишмәле тау итәгенә төшә башладык. Каршы яктагы тау өсте яшел

хәтфә җәйгәндәй матурлыгы белән үзенә тартып тора. Гомәр абыйның да, Әмирхан абыйның да карашлары шул тарафта икәнлекне абайлагач, минем, үземә күрә, туып-үскән якларым белән мактанып аласым килгәндер инде: «Дөнья матур бит, ә...»—диеп әйтеп куйдым.

Туксаннар тирәсендә булган Гомәр абый Бәширов шундук күтәреп алды:

—Шул тау башына менеп бер аунасаң иде, шулаймы Әмирхан?..

—Аунасаң иде димә, аунатсаң иде диген,—дип, шундук төзәтмә кертеп куйды Әмирхан Еники. Ник бер мизгел уйлап торсын!

Татарстан Язучылар берлеген җитәкләгән ун ел гомеремнең һәр атнасы һәм һәр көне диярлек әнә шундый матур, онытылмас һәм ихлас очрашулар, әңгәмәләр белән, истәлекле һәм тарихи вакыйгалар белән хәтергә уелып калган. Ә вак ыгы-зыгы, тырнак астыннан кер эзләп, стакан эчендә давыл кузгатырга йөргән «дус-ишләр»нең кылган гамәлләре дә, үзләре дә тора-бара онытыла икән ул...

Татарстан Язучылар берлеге бинасына Россиянең булачак президенты Борис Ельцинның килүен дә мин үзем оештырдым дип әйтә алам. Бу тарихи шәхескә караш, әлбәттә, төрлечә, ләкин тарихта мондый вакыйга булмаган һәм булмас та дип уйлыйм. Россиянең бер патшасы, генераль секретаре яисә башка бер президентының да милли төбәктәге язучылар белән очрашканын ишеткән юк иде әлегәчә. Ельцинның Татарстанга сәяхәт маршрутын төзегәндә мин үзебезнең Мамадыш районындагы татар авылына керү һәм Язучылар берлегендә очрашу кирәклегенә Борис Николаевичны шәхсән ышандыра алдым. Татар зыялылары белән шыплап тулган Тукай клубының уч төбе кадәрле генә сәхнәсенә менгән чакта ул минем колагыма пышылдады:

—Минем белән янәшә утыр. Уң яктан,—диде.

—Ярар,—дидем.

—Әйт: язучыларга мин ни вәгъдә итим? Әсәрләрен укып әзерләнергә вакыт булмады,—дип, күзләрен текәде ул бераздан үзенә урын тәкъдим иткән чакта.

—Суверен Россия җитәкчесеннән татар язучысы бары бер нәрсә—суверенлык, бәйсезлек көтә,—дидем, шаярган атлы булып.

Иреннәрен турсайтып, күзләрен зур ачып, караш ташлап алды ул шунда. Әмма, ни кадәрле кырыс булса да, усал түгел иде аның карашы. Ә инде бераздан үзенә сорау арты сорау яудырыла башлагачтын, ул шул хактагы сорауга: «Берите столько, сколько можете проглотить...» дигән тарихи җавабын бирергә мәҗбүр булды. Халык каршында чыгыш ясаганда, мавыгып китеп, вакыт-вакыт тормышка ашмастай вәгъдәләр биреп ташлый торган гадәте бар иде шул аның...

Бүген ул бәйсезлектән нидер калдымы-юкмы, әйтүе кыен, ләкин Татарстанның һәр яктан алга китүен, үсешен, ил һәм дөньякүләм танылуын һич кенә дә инкарь итү мөмкин түгел.

Мин Татарстан Язучылар берлегендә рәис булып эшләгән елларымны заяга уздырганмын дип әйтә алмыйм. Житешсезлекләр дә, ялгышулар, мавыгулар да булгандыр, бик мөмкин. Гади бер татар авылында, күп балалы бер гаиләдә яланаяк йөгереп үскән бер малай ич мин дә! Шәхси гувернантлардан һәм махсус гимназияләрдә тәрбия алып үсмәдем. Әмма Татарстанның һәм илебезнең төрле төбәкләрендә, дөньяның кайсы гына континентында яисә илләрендә, кем белән генә очрашсам да мин татар әдәбиятын һәм татар язучысын лаеклы гәүдәләндерергә омтылдым. Бүген дә, Мәскәүдә яшәвемә карамастан, мин Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы саналам, Европа яисә Африка илләрендәме, Азиядә яисә башка бер континенттамы, яңа китабым чыгу уңаеннан оештырылган очрашуларда һәрдаим үземне татар әдәбияты вәкиле буларак лаеклы рәвештә күрсәтергә омтылам. Һәм мине Россиядән килгән татар язучысы дип укучыларыма тәкъдим итәләр. Булган уңышларымның һәммәсе дә туган җирем, туган якларым, әти-әнием һәм татар зыялылары, каләмдәш остазларымнан алынган бетмәс-төкәнмәс тәрбия нәтиҗәсе дип саныйм.



Фоат
Галимуллин

# ТЫНЫЧ ҺӘМ ЭШЛЕКЛЕ ЕЛЛАР

Мәкаләнең исемен шушы рәвештә язып куйдым да, уйга калдым. Нигә әле Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән елларымны (1999-2005) «тыныч» дип атадым. Болай диюнең үзенә күрә тарихы бар. Билгеле булганча, язучыларның унөченче корылтае бик шау-шулы узды. Беркайчан да күренмәгәнчә, ул ике айга сузылды, ягъни май ахырында башланган җыелышка, ниһаять, 23 июльдә генә нокта куелды. Туксанынчы еллар, гомумән, ил күләмендә гаять катлаулы бер чор булды. Иҗтимагый-сәяси һәм, әлбәттә, икътисади мәсьәләләрне халык мәнфәгатьләренә якынайту өчен көрәш гомуми төс алды. Бөтенесе асты-өскә килгән бер вакытта җәмгыятьнең акылы һәм әйдәп баручы көчләреннән берсе, хәрәкәтчәне булган каләм осталары мондый вакыйгалардан читтә кала ала идеме соң? Әлбәттә, юк. Бу хәл аларда үз иҗат оешмабыздагы хәл-әхвәлләрне дә күпмедер дәрәҗәдә үзгәртеп кору ниятен барлыкка китерде.

Хәтерлим әле, корылтай алдыннан Г. Тукай исемендәге клубта булган бер җыелышта Татарстан Язучылар берлеге үзен мөстәкыйль иҗат оешмасы дип игълан итсә, Мәскәү әдәби фондыннан матди ярдәм килүдән туктар дигән мәсьәлә күтәрелде. Бик күпләр очынып-очынып сөйләде. Ахырда берәү, кем икәнен хәтерләмим, алгы рәттә утырган өлкән шагыйрь Әхмәт Исхакка мөрәҗәгать итте:

—Әхмәт ага, Сез ни әйтерсез?

Ә. Исхак шунда бер генә сүз әйтте:

—Түзәрбез!

Зал бу сүзгә дәррәү кул чапты һәм гаять катлаулы булып тоелган мәсьәләне хәл итеп тә куйды.

Менә шушындый шартларда узган корылтайның «һавасы» шактый югары дәрәҗәдә кызу булуы беркемне дә гаҗәпләндермәде. Әдипләр, шагыйрьләр, драматурглар һәм тәнкыйтьчеләр иҗат оешмасын җәмгыятьтәге әлеге шартларга бәрабәр итеп үзгәртеп коруны күрергә телиләр иде. Мондый үзгәреш корылтайның үзендә үк башланды. Элек тәртип шулай иде: корылтай 25ләп кешене идарәгә сайлый. Болар исә үз араларыннан берәүне рәис итеп билгелиләр. Унөченче корылтай исә башта Язучылар берлеге рәисен аерым сайлап куйды (ул ук идарә рәисе дә). Аннан соң гына идарә составы тәгаенләнде. Рәис тә, идарә дә альтернатив рәвештә, ягъни көндәшләр арасыннан демократик тәртиптә сайланды. Халкыбызда «кинәшле эш таркалмас» дигән бик тә акыллы сүз бар. Әйтелгәннәргә өстәп, тагын бер бик әһәмиятле адым ясау мәгъкуль күрелде. Шул ук елның 1 октябрендә, ягъни өлкәннәр көнендә, Татарстан Язучылар берлегенең Аксакаллар шурасы оештырылды. Аның

рәисе итеп халык язучысы Әмирхан Еники сайланды. Бу институт без эшләгән барлык елларда да шактый актив эшчәнлек күрсәтте. Әмирхан аганын вафатыннан соң анын вазифаларын М. Хәбибуллин бик әйбәт башкарып килде.

Язучылар берлегенен жин сызганып эшкә керешүен халык та сизеп алды. Әйтик, без жәлилче-каһарманнарның җәзалап үтерелүенә 55 ел тулуга аерым игътибар итәргә булдык. 25 августта чал Казан Кремле каршындагы 1 нче Май мәйданында «Хәтер жыены»н зур һәм сәнгатьчә камил итеп эшләнгән программа белән уздырдык. Анда Татарстан Республикасы житәкчелеге: Президент М. Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин катнашты. Жыелган халык исән жәлилче-каһарман Фәрит Солтанбәков, шагыйрьләр һәм язучылар И. Юзеев, Р. Мостафин, Р. Харис чыгышларын, Г. Камал исемендәге театр артистларының унбер жәлилчене гәүдәләндергән тамашаларын һәм программаның башка сәхифәләрен зур игътибар һәм тетрәнү белән карады. Аннан соң хәтер чаралары Милли музейда һәм М. Жәлилнең музей-фатирында дәвам иттерелде. Без шуннан соң бер хакыйкатьне ачык анладык: Язучылар берлеге бик тә абруйлы оешма, ул уздырган чаралар халык күңеленә мөрәжәгать итә торган биек мөнбәр. Аларны бары тик тиешле әзерлек һәм житди мөнәсәбәт белән генә үткәрергә мөмкин. Г. Тукай туган көнгә һәм Татарстан Жөмһүрияте көненә багышлап уздырыла торган шигырь бәйрәмнәре дә һәр елны янадан-яна бизәкләр белән төрләндереп оештырылды. 26 апрель көненә туры китереп Туган тел бәйрәмен игълан итүдә дә безнең оешманың өлеше булды. Бөек шагыйребезнең туган көне бәйрәмен анын газиз әнкәсе Мәмдүдә абыстай жирләнгән Сасна Пучинкәсе авылыннан (Балтач районы) башлау традициясен кертеп жибәрүебез дә дөрес гамәл булды дип саныйм. Шигырь бәйрәме көнендә Г. Тукай, М. Жәлил, А. Пушкин һәйкәлләренә чәчәк бәйләмнәрен салу белән бергә h. Такташның Үзәк мәдәният һәм ял паркы янындагы каберен дә онытмау кирәклеген Аксакаллар шурасы искә төшереп бик дөрес итте. Сүз дә юк, санап кителгән бөек шагыйрьләр һәйкәлләре яныннан соң шундый ук бөек Такташның кабере янына гына килә алмау мөмкинлеге күнелдә канәгатьсезлек хисе тудыра иде.. Ихтимал, «Жир уллары трагедиясе» авторының һәйкәле дә көннән-көн матурлана барган шәһәребезнең бер матур мәйданында урын алыр әле дигән өмет тормышка ашар бервакыт.

Язучылар берлегенең Татарстан мөфтияте белән эшлекле элемтәләр урнаштыруы, аларның, бер-берләрендә булып, рухи өлкәләрдә үзара ярдәмләшеп эшләү турында мәслихәтләшүләре, ифтар мәжлесләрендә катнашулары,Казандагы Россия Ислам университеты, дини мәдрәсәләр белән әдәби-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек итүе халкыбыз тарафыннан хуплап бәяләнде. Барыннан да элек үзебезне рухи канәгатьләндерде. Каләм әһелләребезнең ислам динебезнең затлы әхлакый нигезләренә мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган әсәрләре һәм чыгышлары бу шартларда аеруча мөһим иде. Анлашылганча, төп игътибар югары һәм урта-махсус уку йортлары, гимназияләр, мәктәпләр белән элемтәләрне ныгытуга, аларда ижади мохит булдыруга бирелде. Язучыларны шушы максат белән уку йортларына беркетү,алардагы һәм район газеталары каршындагы ижат түгәрәкләренә, берләшмәләренә консультантлар итеп билгеләү республикабызда яшь каләм көчләренең ижади омтылышларын кузгатып жибәрде. «Идел» яшьләр оешмасы белән берлектә «Иделем акчарлагы» конкурсларын башлап жибәрү һәм анын елдан-ел эшчәнлеген колачлы итә баруы яшьләрнең каләм көчен сынау, аларга үзләрен ижади раслау өчен әйбәт мәктәп булды. Шуның өстенә ел саен яшь каләм көчләренең республика семинарларын үткәрүнең дә бу юнәлештә нәтижәсе яхшы күренде. Л. Шәех, Р. Сәлахов, Л. Гыйбадуллина, Л. Мөстәкыймова һәм башка талантлы яшьләр шушы мохиттә каләм чарладылар. Узган гасырның икенче яртысында университеттагы «Әллүки» ижат берләшмәсенең никадәр талантлы кешеләрне тәрбияләгәнен яхшы беләбез. Әмма, кызганыч ки, туксанынчы елларда ул сүнеп калды. Без бу хәл белән килешеп кала алмадык. Г. Гыйльманов шушы берләшмәне жанландырып жибәрү эшенә алынды һәм моңа ирешә дә. Бүгенге көндә КДУда «Әллүки», ТДГПУда «Илһам» ижат берләшмәләре эшли икән, аларга яшәү көче нәкъ менә шушы елларда бирелде. Яшьләрнең китапларын бастырып чыгарып,

аларны укучыларга таныту буенча да матур мисаллар булды. Н. Ахунова медицина институтында рус телендә язучы яшьләрдән төзелгән иҗат берләшмәсенә бик нәтиҗәле җитәкчелек итте. Бу елларда Язучылар берлегенең төп иҗат көчләренең күбесе яна әсәрләр тудыру буенча бик актив эшләделәр. 1999-2005 еллар арасында каләмдәшләребезнең дәүләти һәм хосуси нәшриятларда 744 китабы басылып чыкты. Бу—ел саен 124 китап дигән сүз. Әлеге елларда китап авторларына каләм хакы да бераз арта төште.

Тагын ике мөһим башлангыч турында искә алырга кирәк. Язучылар берлеге Халык язучысы һәм шагыйре исеменә лаек булган шәхесләребезнең бишәр томлык сайланма әсәрләрен бастырып чыгару мәсьәләсен җөмһүриятебез җитәкчелеге алдына куйды. Бу тәкъдим М. Ш. Шәймиев тарафыннан хупланды. Шунын нәтиҗәсендә Ә. Еники, И. Юзеев, Ә. Баянов, Ш. Галиев, Х. Камалов, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Г. Афзал, Н. Фәттахларнын күптомлы әсәрләре басылып чыкты.

Шуннан соңгы елларда Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миннуллиннарнын да күптомлыкларын кулга алдык. Бу эш хәзер дә дәвам итә.

Шул ук вакытта газета-журналларның гонорар түләү мөмкинлекләрен арттыру юнәлешендә чаралар күрүне дә үзебезнең вазифабыз санадык. Бу исә язучыларыбызга зур ярдәм булып чыкты.

Язучылар берлегенең язмышы кыл өстендә калган вакытлар булгалады. 2003 елның апрель аенда Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге утырышында, яшерен рәвештә, әлеге бүлекнең Татарстан Язучылар берлегеннән чыгуы турында карар кабул ителде. Бу хакта минуты-секунды белән хәбәр алгач, Г. Гыйльманов белән бергә Әлмәткә чыгып китәргә туры килде. Анда каләмдәшләрнең һәрберсе белән аерым-аерым сөйләшеп чыгарга, аларның бу хактагы карашларын белергә туры килде. Бу җимергеч эшнең башында буталчык фикерле бер-ике кеше торуы, аларның башкаларга басым ясавы мәгълүм булды. Аларның мондый да мөрәүвәтсез гамәленә бигрәк тә халык шагыйре Гамил Афзалнын исе китте. Ул үзе, авыруы сәбәпле, җыелышка килә алмады. Әмма, шуңа карамастан, чыгыш ясарга теләде. Ул, утырыш барган урынга телефоннан шалтыратып, кискен сүзен әйтте:

—Татарстан Язучылар берлеге безнең өчен изге оешма! Кемнәргәдер изге түгел икән, аннан чыксыннар, әмма Әлмәт бүлегенә—безгә тимәсеннәр. Шундый мәкерле карар кабул итәр алдыннан ник алар минем белән дә киңәшмәгәннәр?! Әллә мин инде хәзер исәпкә-санга кермимме?

Шулай итеп, бүлек утырышында катнашкан бер язучы да Татарстан Язучылар берлегеннән аерылып чыгуны хупламады. Анын каравы, бүлекнең җитәкчесен алыштырырга карар бирелде. Бу төбәктәге абруйлы язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Н. Әхмәдиев бүлекнең җаваплы сәркәтибе итеп сайланды.

Чаллы бүлеге, гәрчә Әлмәтнекеннән яшьрәк булса да, сафларын нык саклап, көндәлек нәтиҗәле эш белән мәшгуль иде, иҗат берлегенең бөтенлеген саклауда таяныч иде. Ф. Сафин, В. Имамов кебек унган егетләр бүлекнең дилбегәсен нык тоттылар, көймәне чайкалдыруларга юл куймадылар.

Шигърият өлкәсендәге казанышларыбызны билгеләп бару өчен махсус бүләк булдыру кирәк дип таптык. Идарә әгъзаларынын фикере бердәм булды, ул бүләк егерменче гасырның иң күренекле шагыйрьләреннән берсе, татар шигъриятенә зур үзгәрешләр алып килгән Һади Такташ исемендә булырга тиеш. 2005 елда бу премия беренче мәртәбә Р. Гаташка бирелде.

Күрәбез, әдәби премияләр барысы да татар телендә иҗат итүчеләр өчен. Әмма иҗат берлегендә кырыкка якын рус телендә язучылар да бар. Шул рәвешле, аларның иҗатын бәяләп бару өчен дә премия кирәклек ихтыяҗ булып әверелде. 2000 елда, ул вакыттагы Лаеш районы башлыгы А. И. Демидов белән мәслихәтләшеп, идарә Г. Р. Державин исемендәге премия булдырырга карар бирде. Чөнки бу зат—заманында рус шигъриятендә шулай ук борылыш ясаучыларның иң күренеклеләреннән. Бу очракта анын тумышы буенча якташыбыз булуы да, төбәгебезгә кагылышлы әсәрләр иҗат иткәнлегә дә искә алынды. Г. Р. Державин исемендәге беренче премия 2000 елда танылган рус язучысы В. В. Корчагинга бирелде. Әлеге башлангыч тора-бара киң янгыраш алды. Лаеш шәһәрендә шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесенә

багышланган музей ачылды. Аның туган көнендә биредә зур тантаналар уздырыла башлады. 2003 елның 14 июлендә Г. Р. Державинның тууына 260 ел тулу уңаеннан Лаешта шагыйрьгә бюст куелды. Тантанада М. Ш. Шәймиев, Мәскәүдән күренекле шагыйрә Римма Казакова җитәкчелегендә язучылар делегациясе катнашты. Казанда Г. Р. Державин һәйкәле яңадан торгызылу да Язучылар берлеге катнашыннан башка булмады.

Барыбызга да мәгълүм, узган гасырның соңгы чирегендә М. Җәлил исемендәге яшьләр бүләге бар иде. Әмма үзгәртеп кору елларында аны бирү тукталып торды. Язучылар берлеге тәкъдиме белән 2003 елда ул яңадан торгызылды, аның дәрәҗәсе республика хөкүмәте премиясе югарылыгына күтәрелде. Яңа гасырдагы беренче лауреатлар Мөдәррис Вәлиев белән Җәүдәт Сөләйманов булды.

Илһамлы мохит тудыру максатында 2004 елның 9 мартында Васильевода ачылган иҗат йорты каләмдәшләребездә зур өметләр уятты. Анда беренче ял итүчеләр Илдар һәм Тәфтилә Юзеевлар, Рәис һәм Диләрә Даутовлар, Фарсель һәм Фирая Зыятдиновлар булды.

Әлеге иҗат йортын каләмдәшләребез тиз арада үз иттеләр, анда дистәләрчә кеше булырга өлгерде.

Иҗат кешесе үз кабыгына бикләнеп яши алмый, бүтән кешеләр кебек үк, ана да аралашу, тәҗрибә алмашу, хезмәттәшлек кирәк. Шундый ихтыяҗны күздә тотып, башка төбәкләр һәм илләр белән элемтәләрне җайга салуга шулай ук беренчел дәрәҗәдәге эш итеп карадык. 2000 елның июнь аенда чорыбызның күренекле әдипләре Чыңгыз Айтматов белән Олжас Сөләймановның Казанга килүләре, татар язучылары белән очрашулары бу мәсьәләдә нык этәргеч булды. Гагауз иле язучылары белән ихлас мөнәсәбәтләр урнаштырылды. Ел саен Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә узган шагыйрьләр бәйрәмендә катнаштык. Уфада уздырылган яшь язучылар семинарына үзебезнең вәкилләребезне җибәрдек. Бер-беребездә уза торган тантаналарда катнаштык. Мәсәлән, М. Кәримгә 80 яшь тулуга багышланган тантаналарның колачлылыгына без хәйран калган идек. Башкорт дуслар Казанда уздырылган шигырь бәйрәмнәрендә, Татарстан Язучылар берлегенең 70 еллыгына багышланган тантананың түрендә булдылар. Чуаш язучылары белән аеруча җылы мөнәсәбәтләр урнашты, ике республикада бер-беребезнең әдәбият көннәрен уздыру бу дуслыкны тагын да ныгытты. Удмурт, Мордва республикалары, Мари-Эл язучылары белән аралашу да гадәти төс алды. Әлбәттә, безгә Россия язучылары белән дә мөнәсәбәтләрне ачыкларга кирәк иде. Кем дә булса беренче адымны ясарга тиеш иде. Бу мәсьәләдә беренче башлап сүз кушучы без булдык. Мәскәү коллегаларыбыз безгә ачык йөз күрсәттеләр. Орелда узган 12 нче съездда без Россия язучыларына үзебезнең ихлас дуслык кулыбызны суздык. Безнең чыгыш зур җанлылык, хуплау белән кабул ителде. Чөнки аның төп фикере шул иде: тулы бер татар әдәбиятын Россия сүз сәнгатеннән аерып кую үсешкә китерә торган юл түгел. Бары тик тигез хәлдәге аралашу гына гомуми үсешне тәэмин итә. Өлкә губернаторы Е. С. Строевның тәнәфестә үз инициативасы буенча безне кабул итүе Татарстан вәкилләренә булган аерым игътибарны күрсәтте.

Безнең бу еллардагы эшчәнлегебезнең төп нәтиҗәсе шул дип уйлыйм: иҗат берлегебез исән, бөтен булып калды, түгелмәде-чәчелмәде. Максатчан эшчәнлек, әдәбиятка изге эш итеп карау төп юнәлеш булды. Алга таба да иҗат берлегебез шушы юлдан барыр һәм ирешелгәннәрне тагын да ныгытыр, үсешне дәвам иттерер дигән өмет белән яшибез.

# НУРИ АРСЛАНОВ

*(1912–1991)*

## Атлантида

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң ишетелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтта,
Тау-дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә—илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан упкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир упкан:
Дәшти-Кыпчак, Болгар, Алтын урда
Бер-берсенең тамырын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дүндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без—менә, без—бар, булганбыз!
Фал ачабыз ләкин, баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам, кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без—
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан.
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без—менә, без—бар, эз бар җирдә,—
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның анык бабасы:
—Нәселең кем?—дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр:—Без—татар баласы!

Татарстан дигән ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

*1969*

## ГАМИЛ АФЗАЛ

*(1921–2005)*

### Дөнья матур, дөнья киң

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә ярым,
Сөйгән ярым гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дус янында кем ятим?!
Күктә нурлар, җирдә шатлык;
Җирдә бәхет гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Елгалардай еллар ага,
Елгалар елларга тиң.
Нинди чор бар, нинди ел бар
Без яшәгән елга тиң?!
Дөнья матур, дөнья киң!

Юллар үтәм, юллар үтәм,
Юллар чиге кайда, дим.
Нинди ил бар, нинди җир бар
Туган-үскән җиргә тиң?!
Дөнья матур, дөнья киң!

*1966*

## ИЛДАР ЮЗЕЕВ

*(1933–2004)*

### Шагыйрьләр нигә картаймый?

*Шагыйрьләр нигә картаймый?*
*Дөнья уе—башында.*
*Асыл кошлар затыннан ул,*
*Сандугачлар яшендә.*

Болай да кыска гомерне
Мәгънәле итәсе бар.
Юлчы булып, дөнья буйлап
Сәфәрләр китәсе бар.
Тормыш дигән әкиятнең
Йомгагын сүтәсе бар.
Фатир сорап күңелләргә
Тәрәзә чиртәсе бар.
Картаеп сүнгән йөрәкнең
Бозларын эртәсе бар.
Үксезләрнең күзләреннән
Яшьләрен сөртәсе бар.
Гашыйкларны кавыштырып,
Туенда биисе бар,
Сабыйларның бишекләрен
Тирбәтеп йөрисе бар.
Сандугач киткән күңелгә
Кунаклап сайрыйсы бар,
Дошман йөрәген тишәрлек
Хәнҗәр-сүз сайлыйсы бар.
Юлда адашып калганга
Маяклар тезәсе бар.
Үзеңне адаштырсалар,
Бирешми түзәсе бар.
Халык кайгырганда—елый,
Көлгәндә—көләсе бар.
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.
Байлыгы юк, мөлкәте юк,
Каләме, биштәре бар,
Бар дөньяны тетрәтерлек
Җырлары-хисләре бар!

*1970*

# САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА

*(1926–1980)*

## Ач, шигърият, серләреңне

Үз энҗемне эзлим һаман,
көн туса, йөрим йөдәп...
Ач, шигърият, серләреңне,
тылсымлы сүзләр өйрәт.

Гөл серләрен тыңлар идем,
чәчәк атса бер гөлем.
Таңда торып, сандугачтан
өйрәнимме җыр телен?

Боз пәрдәсен умырзая
ничек ача?—күрсәйдең.
Энҗе гөлдән мәңге шиңмәс
такыялар үрсәйдең.

Тау чишмәсе таш эретә,
әллә суы кайнармы,—
шуның серен сорыйм әле
сездән, Урал таулары.

Кем уйламый бер очарга,
йолдызларга юл төбәп.
Уйларымны җырга салам—
яшендәй сүзләр кирәк.

Ташка тисә, таш эресен,
һич сүрелмәсен йөрәк!
Ач, шигърият, серләренне.
тылсымлы сүзләр өйрәт.

*1960.*

# РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ

*(1935–2008)*

## Татар иртәсе

Әле татар чукындырылмаган,
Җимерелмәгән Казан диварлары,
Кол Шәрифне кылыч чапмаган.
Сөембикә әле үсмер бала...
Кара яла ягып ак дөньяга,
Шаһгали дә денен сатмаган.

Милләтемнең таза, үсмер чагы,
Итил-йортнын дөрли үз учагы,—
Иман бөтен әле безләрдә...
Үт агызып кяфер бушанмаган,
Әле беркем җирдә ышанмаган
«Татар—батар» дигән сүзләргә.


Офыкта юк хәвеф кулагәсе,—
Итил-суда очкан кош шәүләсе,
Атларыбыз утлый чабында...
Олы юлда кутәрелми тузан,
Корган талга кунган бала козгын
Өмет итә нидер табынга...

Әле татар чукындырылмаган,
Дию бәйдән ычкындырылмаган,
Хыял—дәрья, каерып иш кенә!..
Тарихыбыз өчен бу—бер мизгел,
Ыруларым өчен керсез, изге
Сабыйлыкта күргән төш кенә!

*1990*

# БЕРГӘ БУЛЫЙК, БЕРӘГӘЙЛЕ БУЛЫЙК!

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ РӘИСЕ
ИЛФАК ИБРАҺИМОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



**—Илфак әфәнде, син әдәбиятка соңрак килдең. Башка даирәдән килдең. Бу дөньяга кереп китүләре кыен булмадымы?**

—Безнең буын кешеләре өчен әдәбият хак тарихыбызның бердәнбер дөрес чыганагы буларак кабул ителгәндер. Халкыбыз гомер-гомергә китаплы булган. Тукай әйткәнчә, тарихында «Мескин булып торган өч йөз елда» да әдәби иҗат үзенең таза тамырында—халык авыз иҗатында яшәвен дәвам иткән һәм татар кешесендә китапка сусау, язучы-иҗатчыга, мөгаллим-мәгърифәтчегә изге затларга табынгандай ихтирамлы караш ана сөте белән тәрбияләнгән. Шуна күрә без барыбыз да әдәбиятка-китапка телебез ачылу белән «килгәнбездер». Әдәби иҗатка исә мин чыннан да ир уртасы хәлемдә, сиксәненче еллар азагында «килдем». Беренче китабымны да 1994 елда гына бастырып чыгардым. Ә аңарга кадәрге егерме еллык чорда үзем өчен, күнел өчен ике калын дәфтәр тутырып язылган шигырьләрем әдәбияткә «килү» булгандыр...

*Аерма татлы газабың,*
*Шигърият, колыңнан.*
*Сине эзләп килде җаным*
*Мең яктылык елыннан.*

Иҗат татлы газап булса, иҗатсыз тору тагы да газаплырак бит. Иҗаттан алган ләззәтне бернинди байлык, дан, дәрәҗә дә алыштыра алмый...

**—Үзеңнән алдагы рәисләрнең эшчәнлеге хакында мәгълүматың бармы?**

—Беренче рәисебез һәркайсыбызга яхшы мәгълүм Кави Нәҗми бит инде. 1937-45 елларда бу «җаваплы түрә» урынында күпләр утырып караган. Язучылар берлеге белән хәтта Имаметдинов кебек язучы булмаганнар да рәислек итеп алган. Әхмәт Ерикәй, Гариф Гобәй, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Зәки Нури, Гариф Ахунов,Туфан Миңнуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллиннарның һәркайсы, олуг каләм ияләре яки әдәбият галимнәре буларак та, җитәкче-оештыручы буларак та Язучылар берлеге тарихында үз эзләрен калдырган шәхесләр. Алар һәркайсы—үз дәвере-чорының балалары...

Шәхсән үзен күреп калырга өлгермәсәм дә, безнең гаиләдә Ибраһим Гази исеме еш телгә алына иде. Әткәм Мирза Ибраһимов 5нче армиядә сугышканда аның фронт газетасында чыккан язмаларын даими укып барган. Шуңа без аның барлык повестьларын укып үстек тә... Өлкән буын һәм урта буын язучылары Гариф абый Ахунов рәислек иткән чорны бик искә алалар. Ул түрә булган тотрыклы «торгынлык»

елларында Республика Язучылар берлеге чып-чынлап ныгып кала... Гариф абый олы язучы буларак та, җәмгыять тудырган бөтен өстенлекләргә ия булган һәм шуны җәмгыять файдасына кулланган талантлы житәкче буларак та үзе үк әдәби каһарман саналырга лаек дип беләм. Башка рәисләрнең исемнәрен дә фәкать ихтирам белән телгә алыр идем.

**—Бу 75 еллык тарихны икегә бүлеп сөйләшик без. Тоталитар чордагы Берлек әдәбиятыбызны үстерүгә түгел, киресенчә, үстермәүгә хезмәт итте түгелме? Аннан, Берлек ул репрессиянең тегермән ташына орлык, ягъни союз әгъзаларын коеп торучы улак кебек тә булган бит әле... Әйтик, Тукай 48 яшенә житеп, яңа оешкан Союзга керә калса, аның каләме һәм ул үзе нишләрләр иде икән?**

—Әйдәгез, уйлап карыйк, бу чорда оешма кемгә күбрәк хезмәт итте икән? Тоталитар режимгамы, әллә милли әдәбиятыбызгамы? Читләр арбасына утырып үз жырыңны жырлау мөмкин хәл түгел кебек. Әмма шундый шартларда да безнең өлкән буын әдипләребез үз жырларын жырладылар! Татар әдәбияты-сәнгатенең ренессансы 19 гасыр азагында башланды гына, ә булган кадәресе—шушы 75 ел эчендә...

Язучылар берлеге «тоталитар» хакимлек чорында да, күпмедер дәрәжәдә хәзерге вәзгыятьтә дә «язучы һәм җәмгыять» мөнәсәбәтләрен (мин «язучы һәм хакимият» дип әйтмәдем!) көйләүче бердәнбер оешма булмаган. Дәүләт үзенең гражданнарының һәммәсен житмеш жиде иләктән иләгән. Сабый чагыннан алып гүргә кергәнче кеше октябрятлар, пионерлар, комсомол оешмалары өстенә тагын ничәмә-ничә җәмәгатьчелек оешмасы күзәтүендә булган. Тоталитар хакимият чорында 50дән артык язучының төрле дәрәҗәдә репрессияләнүе ул чордагы Язучылар берлегенең «эшчәнлеге» дип бәяләнергә тиеш түгел. Шул үтә кыен шартларда да милли әдәбият барыбер үсте.

**—«Казан утлары»нда чыккан хатирәләрендә Марсель Әхмәтжанов Нәкый Исәнбәтнең шундый сүз әйтүен яза: «Исәпләүләрем буенча, 1913 елда гына да татар матбугатына языщкан 400 шагыйрь бар иде». Исхакый, Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев кебек бөекләребез Союз дигән нәрсәне белмичә дә шаһ әсәрләр иҗат иткәннәр. Ш. Камал, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Х. Туфан кебек бөекләребезгә Союз «кызыл тормоз» гына булган бугай. Иҗатлары тулысынча диярлек Берлек кочагында узган яшьрәк буын язучыларның шактый өлеше исә М. Садри кебек:**

***«Сандугачым сайрый чут-чут дип,***
***Безнең илдән матур ил юк, дип»***

**дип «сайрап» яшәү җайлырак икәнен тиз төшенеп алган. Син әйткәнчә «үз жырын» җырлаучылар бик-бик-бик аз булган бит алар, Илфак әфәнде.**

—Туган ил турында барыбызга да язарга кирәк ул. Сөенеп тә, көенеп тә, уйланып та... Мөхәммәт Садри гына түгел, Нәкый ага үзе дә «Безнең ил—сандугач сайрар жир» дип язды. Хәсән Туфанның да туган ил турында «матур» шигырьләре бар...

Һәм:

*Син сорама мине җәлләсәң,*
*Җәлладләрнең ниләр кылганын.*
*Мин җавапның әйтә алам бары*
*Трибуналга илтә торганын.*

—дигәне дә бар.

Һәр икесе безнең өчен мәгънәле, гыйбрәтле.

Татар язучысы, шагыйре иң беренче чиратта, Роберт Әхмәтжанов язганча, Тукай катламына күтәрелергә тиеш. Шунда гына ул чын милли язучы, шагыйрь була ала. Габдулла Тукай әнә Тукай катламына 20 яшендә күтәрелгән. Ана 48 яшькә «житүнең» «кызыгы» калмаган. (Болай әйтүем, әлбәттә, сүз уйнату.)

Тоталитар җәмгыятьтә Язучылар берлеге булса да, булмаса да мөстәкыйль фикер йөртүче барыбер кысрыкланыр иде. Тарихта моңа мисаллар бихисап...

**—70-80нче елларда, хәтерлим әле, идарә рәисенең түшендә СССР Югары Советы депутаты тамгасы булыр иде. Хакимият баскычының шактый югары өлешендә тора иде рәис иптәшләр. Алар ачык тавыш белән «сайланып» куела иде. XI съездан алып (1989 ел) яшерен тавыш белән альтернатив сайлау үткәрелә башлады. Кандидатлар күп була торган иде, шул җөмләдән, үз-үзләрен тәкъдим итүчеләр дә. Аннары кандидатлар саны кимегәннән-кими барып, соңгы съездда синең үзеңә альтернатива әллә бөтенләй булмады инде? Хикмәте ни икән моның?**

—Язучылар берлегенең соңгы дүрт съездында үзем дә катнаштым, андагы хәлләрдән хәбәрдармын. Язучыларның рәис сайлау тәртибен үзгәртергә омтылуы ул иң әүвәл җәмгыятьтәге тәртипләргә мөнәсәбәт белдерү дә. Бүгенге көндә дә Язучылар берлеге җитәкчесе хакимият ишекләрен тибеп кенә ачып керә дә, бөтен мәсьәләләрне хәл итә ала дип уйлаучылар юк түгел. Вәзгыять үзгәрде шул. Язучылар берлеге хәзер—мөстәкыйль иҗат оешмасы. Ул Рәсәйнең җәмәгать оешмалары турындагы кануны кысаларында оешырга һәм эшен алып барырга тиеш. Язучылар берлегенең абруе җитәкчесенең түшенә нинди «тамга» кадалуыннан гына тормый. Ул җәмгыятьнең рухи үсешенә ихтыяҗ ни дәрәҗәдә булуга бәйле. Бүген тулаем җәмгыятьтә рухи кыйммәтләргә «бәяләр» үзгәрде. Кемдер бүгенге әдәбиятны рухи гариплек-примитивлык дип бәяли, кемдер бүгенге әдәбият-сәнгатьне бәясен җуйган дип исәпли. Ә минемчә, төп критерий бүген иҗатчының хезмәте телебезне үстерүгә өлеш кертәме, юкмы, ул халкының йөрәк тибешен, кан басымын дөрес билгелиме-юкмы, халкын рухи мескенлеккәме, әллә өметле үсешкә әйдиме дигән сорауга унай җавап бирү-бирмәү, гомумән, кешелек тарафыннан кабул ителгән рухи кыйммәтләр таләбенә туры килү-килмәү белән бәяләнергә тиештер... Әлегә, чын демократия булмаган җәмгыятьтә, иҗатчының хезмәте кемгәдер, әйтик, түрәләргә «ошады», «ошамады» дип кенә бәяләнә дә. Бу хәл үзе гариплеккә китерә...

Инде рәислеккә дәгъвачыларның азаюына килсәк, бу, бәлкем, иҗат берлеге рәисенең түшендәге «тамга»ларына карап кына түгелдер. Язучылар берлеге рәисенең абруен фәкать аның оештыру осталыгы һәм иҗаты гына күтәрә ала.

**—Гафу ит, Илфак, шушы урында бүлдереп, сүз кыстырып калыйм әле. Синең (ягъни шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның) иҗатың мине башта бераз шикләндергән иде, ләкин каләмеңнең яхшук чарланганы, шәп кенә үсеп китүең аермачык күренеп тора. «Адәм баласы» дигән оригиналь формадагы бишьюллыкларың исә чын-чынлап сөендерде.**

—Рәхмәт. Белгәненчә, оешмабыз бик «өлкән яшьтә». Үлем-китемнәр дә, күзгә күренми торган башка мәшәкатьләр дә хәттин ашкан. Боларның барысының да артыннан йөрергә, хәл итәргә кирәк бит инде. Ә иҗат кешесе өчен бу бюрократик-демократик җәмгыятьтә (вәгъдәсезләр җәмгыятендә) ярашып-яраклашып яшәү бер дә җиңел түгел...

Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллин һәм мин рәислек иткән чор СССР дигән дәүләтнең таланып-таралып юкка чыккан дәверенә туры килде. «Бар хилафлыклардан азат булган» тиңдәшсез кодрәт иясе—коммунистлар партиясе дә идарә итүдән туктады. Дәүләт структурасына кергән, шактый гына байлыкка, чыганакларга ия СССР Язучылар берлеге һәм СССР Әдәби фонды да таланып-таралуга дучар булды. Бу талану-таралудан соң барлык иҗат берлекләре дә, аеруча милли республиканыкылар ярык тагарак алдында торып калдылар.

**—Шундый шартларданиләр майтарырмын дип, нинди уй-планнар белән килдең инде бу урынга?**

—Төгәл соравыңа төгәл итеп ничек кенә җавап бирим икән? Милли язучы—милләтнең рухи хәзинәсе ул. Милли горурлык хисләрен тәрбияләүдә милләтнең популяр спортчылары, артистлары, хәрбиләре, сәясәтчеләре һ. б. профессия кешеләре зур роль уйный. Ә милли үзаңны тәрбияләүдә хак динебез белән

бергә милли мәктәбебез һәм милли әдәбиятыбызга тин башка бернинди көч юк. Республикабыз җитәкчеләре шушы хакыйкатьне бөтен тирәнлеге белән аңлаган хәлдә республикабыздагы иҗат берлекләрен саклап калу, аның эшчәнлеген яңа чорда янача оештыру өчен иң кирәкле шартларны булдыруга алындылар. Мин аеруча 90нчы еллардагы кыенлыкларны күз алдында тотып әйтәм...

Бу җаваплы вазифага ризалыгымны биргәндә миңа хәзерге чорның иң төп бурычы иҗат берлеген саклап калу булуын ассызыклап төшендерделәр.

**—Кемнәр?**

—Сез каләмдәшләребез. Һәм, әлбәттә, республикабыз җитәкчелеге дә... Иҗат берлеген саклап калу дигәндә оешмада нинди дә үзара килешмәүчән төркемнәр яки Берлекне таркатырга йөрүчеләр булуы күздә тотылмый. Иң әүвәл язучылар оешмасының шактый картаюы, соңгы ун елда әдәбиятка талантлы яшьләрнең аз килүе борчый иде.

**—«Алмаш» килми димәс идем. Берлек чүпрә кебек кабара түгелме соң?**

—Киләләр. Әмма 90нчы елларда без барыбер дә әдәбиятка киләсе бер буынны югалткан булып чыктык. Өлкән әдипләребез бер-бер артлы бакый дөньяга күчкән бу чорда 1972-82 елларда туган татар егетләре-кызлары арасыннан 30-35 яшькә кадәрге берничәсенең генә язучы булып җитеште. Бу беренчедән. Икенчедән, СССР Язучылар берлеге таркалу белән әдәби тәрҗемә эше бөтенләй тукталып калды. Әдәби бәйләнешләрне тергезү—болар һәм башка мәсьәләләр—яшь рәиснең уй-планнары иде.

**—Инде тәгаенләп санап чыгыйк әле. Тулаем оешмага һәм аерым язучыларга сихәт бирерлек нинди-нинди эшләр башкарылды икән?**

—Үземнең рәислек чорында эшләгән бөек эшләр белән мактана алмыйм. Шулай да... Әйтик, язучыларның иҗат активлыгын стимуллаштыру максатында, Язучылар берлеге әдәби премияләренең статусын күтәрдек. Хәзер алар Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге премияләре дип атала, һәм аларның матди дәрәҗәсен 10-15 тапкыр арттыра алдык. «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә Сәҗидә Сөләйманова исемендәге 3 әдәби премия, 3 кызыксындыру премиясе, яшь язучылар өчен 10 стипендия гамәлгә куелды.

Язучылар берлегендә әдәби тәрҗемә буенча даими эшләүче остаханә оештырылды. 90 язучыбызның чәчмә һәм тезмә әсәрләре русчага тәрҗемә итеп бастырылды. Хәзер драма әсәрләренең русчага тәрҗемәсе әзерләнеп килә... Без инде аерым авторларның иҗат үрнәкләрен рус, төрек, инглиз теленә турыдан-туры тәрҗемә итүне дә максат итеп куябыз.

Язучылар берлеге үзенең бәйләнешләрен да киңәйтергә омтыла. Соңгы 4 елда гына да Россиянең 5 төбәгендә татар әдәбияты көннәре (Ульяновск, Пермь өлкәләрендә, Чуашстанда, Удмуртиядә һәм Мари-Эльдә) үткәрелде. Удмуртия Язучылар берлегендә татар язучылары секциясе оештырылды.

Язучылар берлеге каршында Яшь язучылар клубы (җитәкчесе—Л. Янсуар), яшь тәнкыйтьчеләр төркеме (җитәкчесе—Р. Рахман) төзелде.

Бүген Язучылар берлеге республикабызның төрле министрлыклары һәм оешмалары белән уртак проектлар төзеп эш алып бара:

Мәдәният министрлыгы белән: барлык әдәби-мәдәни чараларны бергәләп үткәрү, әдәби премияләр тапшыру;

Яшьләр һәм балалар белән эшләү, спорт һәм туризм министрлыгы белән: ел дәвамында «Иделем акчарлагы» иҗат фестивале үткәрелә;

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән: ел саен җәйге чорда районнарга, авылларга «Әдәби десант»лар оештырыла;

Республика Милли китапханәсе белән: ел китабы конкурсы үткәрелә;

Камал театры белән: «Яңа татар пьесасы» конкурсы үткәрелә;

Татар дәүләт гуманитар педагогика университеты белән: IX-XI сыйныф укучыларының Республика әдәби иҗат конкурсы үткәрелә;

«Татнефть» һәм «Рухият» фонды белән: нефть чыгару төбәге районнарында иҗат итүче укучы яшьләрнең әдәби иҗат фестивален үткәреп киләбез.

Башка төрле эш-гамәлләрне дә әйтеп узыйк. Язучылар берлегендә социаль-көнкүреш комиссиясе эшли. Авыручылар күп. Соңгы дүрт елда гына да без дистәгә якын язучыбызга төрле дәрәҗәдәге операция ясауга булышлык иттек. Язучыларны соңгы юлга озату, аларның каберләрен барлау, истәлек ташлары булдыруга да катнашабыз.

Болар барысы да Язучылар берлегенең яңа шартларда үз эшен алып барырга омтылуының ачык мисаллары. Әмма шушы көндәлек эшләрне башкаруга да күп энергия һәм вакыт сарыф ителә. Матди мохтаҗлык аркасында бик күп уйларыбыз, теләкләребез хыял гына булып кала.

Кайберәүләр бүген, Язучылар берлеге миңа берни бирмәде, фатирны да теге җитәкчедән, бу җитәкчедән үзем алдым, дип сөйләп йөри. Тик теге җитәкче дә, бу җитәкче дә аңа фатирны ул язучы булганы өчен биргән бит, Язучылар берлегендә булганы өчен һәм дә Язучылар берлегеннән алынган белешмәләргә нигезләп.

**—Идарә рәисе буларак сине ниләр сөендерә?**

—Милли әдәбиятыбызга өр-яңа буын килә. Үз йөзләре, үз сүзләре белән. Алар тирән белемле, энергияләре ташып тора. Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Лилия Гыйбадуллина, Гөлнара Җәлилова, Гөлнур Корбанова, Илгиз Зәйниев инде Язучылар берлеге әгъзалары. Иң якын арада Йолдыз Миңнуллина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Айдар Җамалиев, Рөстәм Галиуллин, Эльмира Һадиева, Ләйсән Фәтхетдиновалар да берлекнең тулы вәкаләтле әгъзалары булыр дип ышанабыз.

**—Көендергәне ни? Хәер, алдан үзем бер-ике сүз әйтеп калыйм әле. Язучы дигәнебез—язучы, әдәбият дигәнебез әдәбият булсын өчен ким дигәндә ике нәрсә кирәк: әсәрләрнең язылуы һәм укылуы. Язылсын өчен син хатының яки ирең: «Юкбар белән маташма. Эш эшлә!» дип колак итеңне ашамаслык каләм хакы алырга тиешсең. Укылсын өчен язганың басылырга һәм укучыларга барып җитәргә тиеш. Бер сорау кала: бу «тиеш»ләрне кем тәэмин итәргә тиеш?**

—Барыбыз да. Мин бәлки артык иске караштагы кешедер. Дәүләтнең өстенлекле юнәлешләр дигән сәясәте була. Андый өстенлекле юнәлешләр төбәкләрдә дә, республикаларда да бар. Милли әдәбияты, сәнгате тарихы дистә, йөз еллар белән генә исәпләнгән һәм үз ана телен, үз этник мәдәниятен саклау өстенлекле юнәлеш дип билгеләнгән төбәкләрдә иҗатчылар хезмәтенә чын мәгънәсендә дәүләти кайгыртучанлык урнашкан да. Шушы мәсьәләне даими күз уңында тоту—иҗат берлегенең төп эшедер. Без, кулыбыздан килгәнчә, шуны эшләргә тырышабыз. Кулдан килгәнчә...

Көендергәне нәрсә? Хәтта юк дәрәҗәсендәге гонорарлар да түгел, ә бәлки татар китабына гафу ителмәслек дәрәҗәдә битарафлык барлыкка килү. Моның бик күп сәбәпләре барын үзебез дә тоябыз. Ләкин битарафлыкның сәбәбе—битарафлык кына.

Татар китапларының «сатылмый» ятуында кемнәрнедер гаеплибез. Иң беренче чиратта китап авторын, гонорар сорамасын өчен, «үтмәс товар» язгансын дип түбәнсетәбез. Дәүләт акчасына нәшер ителгән китаплар дәүләт учреждениеләре булган китапханәләргә, мәктәпләргә басылган көнне үк бушка таратылырга тиеш. Калганын сатуга чыгарырлар. Язучы хезмәтенең хәләл хакы булган гонорарлар турында исә сүз куертасым да килми, бу хакта язучыларыбыз үзләре соңгы съездда һәркемгә ишетелерлек итеп, аңлаешлы итеп әйттеләр. Тик нәтиҗәсе генә әлегә күренми.

**—Шул уңайдан бер тәп-тәгаен сорау бирим әле үзеңә. Татарстан китап нәшрияты быел ничә язучының китабын чыгарды?**

—Без гәп корган вакытка, ягъни август уртасына, Мөхәммәт Мәһдиевнең биштомлыгы гына басылды. Бу хәл барыбызны да сискәндерде.

**—Татар әдәбиятына шулай кизәнү кемнең ихтыяры белән килеп чыкты ул? Кризис дигәч тә, ул хәтлек афәт килмәде лә дөньясына. Татар язучыларының китаплары басылу хәтта Бөек Ватан сугышы елларында да тукталмаган лабаса... Идарә нәрсә карый дигән сорау да туа бит әле монда!**

—Идарә нәкъ шул мәсьәләләрне карый. Нәшрият житәкчелеге белән көндәлек элемтәдә эшлибез. Ниһаять, август аеннан финанслар бүлеп бирелә башлады. Әмма язучыларның китапларын бастыру да, аларның хак-әжерен түләү дә, китап сәүдәсе дә—болар Язучылар берлегенә тапшырылган вәкаләтләр түгел. Ни кызганыч, безнең бу хакта Язучылар съездындагы тәкъдимнәребезгә дә, даими хат-мөрәҗәгатьләребезгә дә тиешенчә әһәмият бирелми әлегә...

Идарә бу очракта ни эшли дигән соравына кайтып, тагы шуны да әйтим: идарә ижатчыларны рухи һәм ижади төшенкелеккә бирелмәскә өнди. Бүген ижади процесс бара. Китаплар языла. Нәшриятларга, редакцияләргә жибәрелә. Ижат ул—ташкын кебек, аны кемнендер ихтыяры белән барыбер буып торып та, кирегә агызып та булмый. Табигатьнең һәм яшәешнең кануннарына нигезләнеп ул да эволюция юлы белән алга бара... Тыярга теләсәң, әле ничек кенә көчәячәк ул!

*...Ничек мин язмый торыйм ди*
*Кол Гали язган килеш?..*

—ди әнә шагыйребез.

**—Татарстан хөкүмәте бу эшне тәэмин итә алмагачтын, бәлкем, Кол Гали заманындагыча, күчереп язуны оештырырга кирәктер? Каләмнәр дә шәп хәзер, кауры гына түгел... Бусы—ачы бер шаярту гына инде. Нәрсәдер эшләргә кирәк бит. Кемнәрдер өметләнгәнчә, төп укучыларыбыз булган авыл апалары, абзыйлары, Европа һәм Америка халкын да узып, житмәсә әле сәламәтлекләренә дә зыян китерә-китерә, повесть-романнарны компьютердан укып утырмас бит инде?**

**Ә менә татар әдәбиятының хәзерге хәлен ничек дип бәялисең син, Илфак әфәнде?**

—Әдәбиятыбызның хәленә бәяне бүген төгәл генә беркем дә бирә алмас. Аның өчен вакыт үтүе, дөресрәге, бүгенге әдәбиятның вакыт сынавын үтүе кирәк. Заманында Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Тукай бер-берсенә капма-каршы бәяләр биргәннәр. Өч бөегебезгә хак бәяне исә Халык һәм Вакыт үзе бирде. Әмма бүген ни әйткәнеңне иртәгә ишеткәннәрен көтеп ятып булмый. Бүген әйткәнеңне бүген ишетсеннәр дә, иртәгә һәм беркайчан да онытмасыннар! Әдәби сүзнең бөтен мәгънәсе шулдыр дип беләм...

Бүгенге әдәбиятыбызның хәле турында «XXI гасыр татар әдәбияты. Милли әдәби телебезнең сакланышы һәм үсеше тенденцияләре» дигән темага багышлап конференция үткәрәчәкбез.

**—Соңгы 10-20 елда югалтулар да зур булды бит.**

—Әйе. Югалтулар зур, бик зур. Әмма ул әдипләребездән күпме әдәби мирас калды. Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләжев, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов, Рафаэль Сибат, Мәгъсүм Хужин прозасы, Сибгат Хәким, Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Харрас Әюпов, Наис Гамбәр, Нияз Акмал шигърияте—бүгенге көн әдәбияты түгелмени?!. Әдәбият һәм тел галимнәребез болар һәм исән-сау олы әдипләребез Ш. Галиев, Ә. Баян, Р. Фәйзуллин, Т. Миннуллин, Х. Камалов, Ф. Яруллин, Р. Харис, Р. Мингалимов, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Батулла, М. Маликова, М. Хәбибуллин, Ф. Бәйрәмова, Л. Шагыйрьҗан, А. Хәлим, Р. Миннуллин, М. Галиев, Разил Вәлиев, Ф. Садриев, А. Хәсәнов, З. Мансуров, Н. Әхмәдиев әсәрләренең әдәби-эстетик кыйммәтләрен тирәнтен анализлап, үзләренең төпле фикерләрен әйтергә бурычлы. Аларның андый фикере—үз гомерендә бер генә татар китабын да укып карамыйча бездә әдәби кризис, бездә тәнкыйть юк дип сүз куерткан кемсәләр өчен түгел, ә бәлки фән өчен,

язучы-иҗатчыларның үзләре өчен дә бик кирәк. Мин яшьләре өлкәнрәкләрнең исемнәрен генә атадым. Әдәбиятыбызның урта буын вәкилләре Р. Зәйдулла, Г. Морат, Л. Лерон, Р. Шәрипов, Н. Гыйматдинова, И. Иксанова һ. б. талант ияләренең иҗатын тирәнтен фәнни өйрәнү зарур дип уйлыйм. Әдәбиятыбыз казанышлары бар ул, булганын күрә белү дә кирәк.

**—Алайса, мин күренекле язучыбыз Миргазиян Юныстан да сорау бирдерим әле, рәис әфәнде. Бу фикерләр аның «Казан утлары»ның өр-яңа (8нче) санында чыккан мәкаләсеннән алынды.**

**«Рухият өлкәсенә багышланган мәкаләләрнең көн тәртибендәге иң мөһим, иң изге милли проблемаларны ерактан урап үтүенә без инде күнегеп беткәнбез». «Фикерсез, эчтәлексез мәкаләләр, чиле-пешле һәм чип-чи сүз камырыннан әмәлләнгән вакытлы матбугат ташкыны. Юкка чыккан тәнкыйть. Мөхәммәт Мәһдиевкә, Нурихан Фәттахка, Гамил Афзалга һәм Илдар Юзеевкә алмашка килгән күпчелекнең төссез, төче иҗатлары...» «Илһам белән җанланмаган, хисләр кайнарлыгы белән җылытылмаган графоманлык язмалары басып китте... Бүгенге көндә татар әдәбияты минем өчен—тоташтан торган йөрәк әрнүе». Сорау рәвешендә язылмаса да, үткеннән-үткен сорау бит инде бу. Җавап нинди булыр?**

—Миргазиян ага белән килешәм дә, килешмим дә. Килешәм, чыннан да татар халкының рухи үсеше манифесты булырдай, барыбызның да йокысын качырырдай бердәнбер мәкалә, әсәр иҗат ителмәгәндер. Әмма соңгы 5-6 елда гына да Миргазиян аганың үзенең, башка тере классикларыбызның чор, җәмгыять, әдәбият-сәнгать, әхлак темаларына багышланган саллы-саллы иҗат үрнәкләре барлыкка килүен инкарь итеп булмый. Бер генә мисал. Ркаил Зәйдулланың «Башны бәрдем ташка» җыентыгы, минемчә, вакыйга булырлык. Тагын да дистәләрчә мәкалә, очеркларны атап булыр иде... Вакытлы матбугат белән әдәби басмаларны бутамыйк. Миргазиян аганың борчылуы, әлбәттә, әдәби журналларыбызга карата. Ни әйтсән дә, әдәби процесс иң әүвәл әдәби басмаларда чагылыш таба. Җавапны без бергә эзләргә тиешбез. Миндә әзер рецепт юк. Шунысы бәхәссез, иң югары эстетик кыйммәтләр хакында сүз алып барганда да бүген безнең өчен иң мөһиме—җәмгыятьтә китапка булган ихтыяҗның тоныклана баруын, «язучы» сүзенең бер кушамат кебек кенә булып калу ихтималын истән чыгармау. Исхакый кисәткән инкыйраз шул бит инде ул. Адәм баласы үрчүдән туктамас. Ә менә рухи инкыйразга дучар булып, бердәнбер Җәгъфәр көненә калуың ерак йөрми... Һәр милләтнең үзенең рухи үсеш программасы булырга тиеш. Бәлки, ул ташка басылган программа да түгелдер. Әмма аның асылында әдәби сүз, китап, дин, әхлак ятуы һәркемгә ачык.

**—Прозаның хәле аеруча авыр кебек. «Казан утлары»на папка-папка китереп кенә торалар үзе. Ләкин Еникиләр, Мәһдиевләр, Хөсниләр, Фәттахлар чыннан да юк шул инде. Роман жанры да борчый. Элек татарда романнар бик аз иде. Сыңар роман чыгу да зур вакыйга була торган иде. 16 ел эчендә 4 роман язып ташлап, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Кәрим әйтмешли, «шаккатырды халыкны!» Хәзер исә романнарны коеп кына торалар. Ләкин шактый өлеше—«сусыл», ни теле, ни киеренкелеге, ни укылышлылыгы юк, журналда баскан хәлдә дә кысып-тыгызлап, «журнал варианты» дип бирәсе була.**

—Романнарга да кытлык юк бер карасаң. Хәтта шигъри романнар да иҗат ителә. Әмма роман кадәр роман язып нинди эпохаль мәсьәләләр күтәрелә соң, дигән сорау куярсыз. Рөстәм Мингалим әйтмешли:

*«Чыгышы бөркет икәннең*
*Очышы ничегрәк?»*

Шәп роман, үзең әйткәнчә, күтәп алына. М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Н. Фәттахның һәр романын ничек күтәп алдык әнә. В. Имамовның «Сәет батыры»н, Р. Батулланың «Сөенбикә»сен, Ф. Латыйфиның «Хыянәт»ен, Ф. Бәйрәмованың «Күчем хан»ын, Ф. Сафинның «Саташып аткан таң»ын, «Ф. Садриевның «Таң

жиле»н, К. Кәримовнын «Ком сәгате»н халкыбызнын гыйбрәтле үткәнен һәм бүгенгесен, милли каһарманнарынын фаҗигале язмышларын, тирән күнел кичерешләрен, ана телебезнең матур үрнәкләрен кулланып иҗат ителгән әсәрләр дип беләм... Мәдинә Маликованын «Тылсым»ын тәэсирләнеп укыдым. Мин үзем укыган романнар хакында гына әйттем. Әмма, үзең билгеләп үткәнчә, хәтта «Казан утлары»нда да күбесенчә журнал вариантындагы романнар басылды шул. Урысчадан тәрҗемә ителгәннәре арасында да укучынын ан-зиһенен уятырдай романнар юк диярлек. Конференциядә болар хакында да зурдан кубып сөйләшү булыр дип уйлыйк...

**—Шигърияттә хәлләр ничегрәк? Әдәбиятнын башка төрләрендә?**

—Рәфикъ абый, син миннән шагыйрьләребезгә бәя бирдереп дошманнарымны арттырма инде, зинһар. Безнең шагыйрьләребез барсы да бөекләр! Мин бары зур-зур бүләкләр һәм исемнәргә ия булган олуг шагыйрьләребез бүген дә Фәнис Яруллин кебек ал-ял белмичә иҗат итсеннәр иде дим... Ркаил Зәйдулла буынынын публицистика жанрында да ат уйнатуын хуплаган хәлдә, алар үзләренең кабатланмас шагыйрьләр булуын алдагы иҗатлары белән тагын бер исбатласыннар иде дигән теләгемне белдерәм. Лена Шагыйрьҗан, Рәсимә Гарифуллинанын, Рәниф Шәриповнын поэма жанрында матур табышлары булды дип исәплим. Фәнни-гамәли конференциядә барлык жанрлар турында да абруйлы белгечләребез үз сүзләрен әйтер дип уйлыйм... Әдәбиятыбызнын бүгенге хәле турында галимебез Адлер Тимергалиннын саллы-саллы язмаларын «Казан утлары» даими бастырып килә... Адлер ага кыю да, гадел дә, миһербанлы да белгеч. Яшь галимнәребезгә бар яктан өлге булырлык.

Күренекле урыс тәнкыйтьчесе Лев Аннинский мондыйрак сүз әйтте: Бүген әдәби әсәрләрне нинди дер кысалар, кагыйдәләр, таләпләр-критерийлар аша анализлау-тәнкыйтьләү кирәкме икән? Мин үзем һәрбер әсәрне укыганда бу әсәр, гомумән, кешене ни нәрсә хакында булса да уй-фикер йөртергә этәрәме, юкмы, ул әйтергә-сурәтләргә теләгәннәр яналыкмы, юкмы,—дигән сорау куям, ди. Адлер ага да ин әүвәл автор иҗатындагы яналык мөһим ди. Ул яналык авторнын үзе өчен генә түгел, ә гомумән әдәбиятыбыз өчен яналык булсын ди. Таләп гади һәм аңлаешлы бит!..

**—Эштә рәсмилек күп. Кәгазьгә теркәлә торган эшләр дә кирәктер, әйе. Ләкин язучылар иҗади халык бит. Аларның Берлек бинасына киләсе килеп торырлык нәрсәдер табып булмыймы соң? Әйтик, бер рухтагы кешеләр җыела алсын, гәпләшсен, бәхәсләр куертсын, язучылар белән сәнгать әһелләре, галимнәр, әдәбият укытучылары арасында диалоглар барсын. Бер дә юкта бильярд, теннис, шахмат уйнасыннар шунда. «Тынгысыз каләм» кебек стена газеты чыксын.**

—Рәсмилектә нинди мәгънә күрәсен бит? Айга бер тапкыр үткәрелеп киленгән иҗат секцияләре утырышлары рәсмилектән бигрәк —хезмәттәшләрнен аралашуы да бит. Ни кызганыч, бинабыз авария хәлендә. Тукай клубы бинасынын җимерелүе барлык мөмкинлекләребезне чикли... Сонгы вакытта китапханәбезне бераз җиһазлый алдык. Анда язучыларыбыз аралашу өчен шартлар бар дип беләм. Менә яшьләребез күбәя бит. Андый чараларны да үткәрә башларбыз.

**—Элекке җитәкчелекнең Халыкара ПЕН-клубның «Татар ПЕН-үзәге» дигән язучылар оешмасын өнәп җиткермәве сизелеп тора иде. Хәзер сезнең «халыкара мөнәсәбәтләр» ничегрәк сон?**

—Мин рәис булып торган дәвердә ПЕН-үзәк белән язучылар берлеге арасында нинди дә булса мәсьәләдә фикер каршылыгы чыкканын хәтерләмим. Алар да безнең кебек бит инде. Барысы да үзебезнең язучылар, зыялылар. Бөтенесендә дә булмаса да, ПЕН-үзәк үткәргән чараларда катнашырга тырышам.

**—Элеккеге идарәдә янә Россия язучылар оешмасына кушылыйк дип дәртләнеп йөрүчеләр дә булды.**

—Мин үзем дә шул кешеләрнен берсе булып барам бугай. Мин Россия

язучыларының бердәм оешмасы булырга тиеш дип исәплим. Бүгенге көндә Россия Язучылар берлеге берничә оешмага бүленгән. Әлбәттә ,без нindидер бер бүлемтекнең бер өлеше булуга риза түгел. Ә менә Россиянең бердәм оешмасы төзелгән хәлдә, аның белән кушылудан бернинди зыян да күрмим. Россия Язучылар берлегенең соңгы съездында без Туфан Миңнуллин белән нәкъ шул фикерне күтәреп чыгыш ясадык. Әгәр дә Россия Язучылар берлеге күпмилләтле әдәби хәрәкәтләрне оештыру үзәге булу вазифасын ала икән, милли әдәбиятларның төп билгесе булган милли телләрнең сакланышы өчен җаваплылык вазифасын да үзенә алырга тиешлеген әйттек. Бүгенге көндә Россия Язучылар берлегендә дә илдә иҗат кешеләренә карата гадел булмаган сәясәт белән разый түгелләр. Әмма шул шартларда мәсьәләне дәүләт җитәкчелегенә бөтен кискенлеге белән куя алмыйча, алар үзләренә сыену эзләп православие чиркәве даирәләре белән хезмәттәшлек итүне өстен күрәләр. Күп милләтле, күп конфессияле илдә бу бик үк кулай күренеш түгелдер.

Шулай итеп, Россия Язучылар берлегенең соңгы съездына да без вәкилләр булып түгел, күзәтүчеләр булып катнаштык. Алдарак Россия Язучылар берлегенә кушылу-кушылмау мәсьәләсе бер-бер артлы ике идарә утырышында зур бәхәсләр белән тикшерелде. Бу шактый каршылыклы мәсьәлә булып чыкты. Төп шарт булып, дөресрәге, төп сәбәп булып, инде әйткәнемчә, бүгенге көндә бердәм Россия язучылар оешмасы булмау тора. Иртәме, соңмы, андый бердәм оешма төзелер һәм без Россия Язучылар берлеге белән ин тыгыз элемтәләр урнаштырып, Россия һәм дөньякүләм әдәби мохиткә чыгу юлларын эзләрбез дип ышанам.

**—Россия язучылар оешмасына ул берләшкән, бербөтен Берлеккә әйләнгән хәлдә дә кермәскә кирәк. Берләшү түгел, «составка керү» була бу. Тигез килеш хезмәттәшлек итик. Мөстәкыйльлекне бирү президентлар, парламентлар кимәлендә генә түгел, аерым оешмалар һәм хәтта шәхесләр кимәлендә дә була.**

—Язучылар оешмасының әшен җәмгыятьтән аерырга тырышу, бер уйласаң, хакимияттән түгел, язучыларның үзләреннән дә ул.. Менә син үзең дә тулы азатлык ягында икән бит. Соң бөтен яшәешебез тулысы белән бер илдә урнашкан тәртипләргә яраштырылгач (тәңгәлләштерелгәч), аерым «азат» булуның нинди өстенлеге бар соң?

**—Бердән, мин «мөстәкыйльлек» дидем, «тулы азатлык» димәдем. Икенчедән, әгәр дә Мәскәү татарга Татарстанда һәм Рәсәйдә милләт булып яшәргә, телен, мәдәниятен, мәгарифен үстерергә шартлар тудыра икән, ким дигәндә, моңа комачауламый икән, аерымлануның һич хаҗәте юк. Ләкин Мәскәү, хакимияткә кемнәр генә килмәсен, коммунистлармы, демократлармы, безнең шушы табигый хокукларыбызга күнә алмый шул. Суверенитет тикмәгә генә игълан ителмәде бит инде ул. 1992 елны референдумда нәрсәне хуплап тавыш биргәнебезне искә төшерик: «Сез Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коруына ризамы?» Һәм бу референдум карарын икенче референдумыбыз гына юкка чыгара ала юкса. Ә без менә «тәңгәлләшергә» үзебез үк тәкатьсезләнеп торабыз шикелле. Законнарыбызны бердәйләштерү аша татарны әкренләп үтерү дә җитмәде әле Мәскәүгә, татарча укытуны бетерү бавы белән буып ук үтерү кирәк булды, ахры. Мөстәкыйльлек өчен көрәшнең иң алгы сафында барырга тиешле оешмабызны нәкъ шундый мәлдә Мәскәү авызына кертергә омтылу—һич аңлап була торган эш түгел. Үзең әйтмешли, «иң тыгыз элемтәләр» урнаштырылсын, кирәк икән, килешү-фәләннәре дә төзелсен, ләкин «составка керү» дигәне генә була күрмәсен.**

—Алай гадиләштереп карау дөрес микән? Монда берничә бик мөһим проблема бар. Беренчедән: хәзерге дәвердә Россия Федерациясе субъектларының иҗат бүлегендә әгъза булып тору иҗатчының эш стажына исәпләнми. Бу аларның булачак пенсияләренә турыдан-туры кагыла. Шулай ук, налог түләүче буларак, без Рәсәй казнасына күпмедер үз өлешебезне бирәбез, ә дәүләтнең иҗат кешеләренә дигән азмы-күпме өлешләреннән мәхрүм булабыз... Бу Рәсәй күләмендәге төрле премияләр, грантлар һ. б. дигән сүз... «Без Россия Язучылар оешмасына керергә тиеш түгел, без үзал яшик»,—дип күкрәк суккан язучылар да икенче көнне үк минем янга кереп: «Миңа Россиянең «атказанган

сәнгать эшлеклесе» дигән исемгә документлар әзерлик инде, минем повестьны русчага тәржемә итик инде»,—дип сорап йөриләр. Хәтта «Бердәм Россия» сәяси партиясендә иң актив әгъза булып торган язучы-депутатка да бүген Россия Язучылар берлеге кирәкми. «Ул безгә берни дә бирми»,—ди. Хикмәт кемнендер «составында булу-булмау»дан бигрәк, үзен әйткән «милли үзан» дәрәҗәсеннән тора бит. Шөкер, бүген әдәбиятыбыз-сәнгатебез илбашыбыз Минтимер Шәймиев яклавында. Ә бит милли әдәбиятыбыз-сәнгатебезне кимсетеп, авыл әдәбияты, авыл сәнгате дип бәяләүчеләр, милли иҗатчыга чирканып, җирәнеп караучылар да аз түгел. Алар иртәгә ни күрсәтер? Мина калса, иң әүвәл шулардан «азат» булырга кирәк. Шуларның чын йөзен Тукай әйткәнчә «Үз сурәтләрен көзгедән күрсәткәндәй үзләренә күрсәтергә» кирәк... Ни кызганыч, әлегәчә Россия күләмендә иҗатчының хезмәтенә хәер-хак булырлык мөнәсәбәт юк. Ул, бәлки, вакыт үтү белән, буыннар алмашы белән акрынлап формалашыр.

**—Татар халкының язмышы шулай кыл өстендә торганда оешмабыз һәм аерым язучылар ни эшләргә тиеш соң, Илфак әфәнде?**

—Республика иҗат оешмалары башка төбәкләрнең иҗат оешмаларыннан, хәтта Россиянекеләрдән дә үзенең милли оешма булуы белән аерылып тора. Безнең үз йөзебез, үз максатыбыз бар. Иң беренче чиратта бу—ана телебезне саклау. Әдәби оешма халыкка берөзлексез ана телебезнең иң матур үрнәкләрен күрсәтүче әдәби әсәрләр бирергә тиеш.

*Сәясәт һични түгел—мал булеш,*
*Алмасаң да, бирмәү хәстәрен белеш...—*

дип язган иде бер шагыйребез.

Милли язучы өчен сәяси алыш-бирешләрнең аерым үз мәгънәсе, үз фәлсәфәсе бар. Иң аяныччы биреш 1552 елда булган. Дәүләтчелегебезне, азатлыгыбызны биргәнбез. Кемнәрдер исә иманын сату бәрабәренә алган-тапканын саклап калган... XX гасыр «алыш-биреш»ендә безнең халкыбыз кемнәргә ни-нәрсәләр генә бирмәде икән? Берәүләргә алфавит, әлифба эшләп, мәктәпләр төзеп бирде. Дөньяның төрле кыйтгаларына галимнәрен, акыл ияләрен бирде. «Яуларда калкан булды»—Җәлилләрне, Алишларны, Кутуйларны, Кәримнәрне ..., Мөҗәйләрне—дисталәгән солдат язучыларыбызны бирде. «Тыныч тормышта аттан артык эшләп» — нефть чыгарып, ашлык үстереп бирде. Бөек дәүләт таралганда «чит-ятлар» ягында калдырып, аларга миллионлаган милләттәшебезне бирде. Үзе, ниһаять, нидер алырга ниятләгәндә генә канунңарны «тәңгалләштереп», тагын да күбрәк бирүчегә әверелде. Дәрдемәнд йөз ел элек үк инде:

*Кайсы җилләр, нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?—*

дип язган дәвер килеп басты... Бездән инде газиздән газиз, җаныбыз белән бергә яралган ана телебезне «сорыйлар». Ягъни мәктәпләрдә «милли компонент» дип йөртелә торган ана телдә укытуны бетерүгә юнәлтелгән канун кабул итәләр. «Алыш-биреш» базарында без һаман «бирүче» булырга дучармы?

Без язучылар турыдан-туры олы сәясәттә катнашмыйбыз да кебек. Чынында исә һәркайсыбыз үз иҗатында аерым мәсьәләләрдә үзенең җан авазын житкергән һәм хәзер дә житкереп килә:

*—Татарстан—төтенстан,*
*Дәүләт тимерчелеге...*

*—Көрәшчеләр кирәк,*
*Беләкләр җитә,*
*теләкләр кирәк,*

—диде шагыйрь.

*—И Алып, билең бирмә!*

—диде икенче бер шагыйребез.

Әлеге һәм дистәләрчә, йөзләрчә шигъри мөрәҗәгатьләр иң әүвәл халыкның үзенә юнәлтелгән. Әгәр халыкның милли үзаңы житәрлек дәрәҗәдә икән, «компонент» турында янадан ник шунда ун закон чыгармыйлар, халык үз телен, үз өнен саклый ала, яклый алачак. Һәр язучының бу мәсьәләдә, Туфан Миңнуллин әйткәнчә «төп мәсьәләдә», фикерләре уртак, теләкләре бер.

Бу шартларда татар язучысы ни эшләргә тиеш соң? Мин үземчә болай дип уйлыйм:

—Татар язучысы, зыялы, аек, үз халкының тарихын белгән һәм хөрмәт иткән шәхес буларак, иҗаты белән үзенә хас шул сыйфатларны бөтен халкында, бигрәк тә яшь буында тәрбияләүче булырга тиеш;

—татар язучысы бөтен Рәсәй һәм дөнья язучылары тормышы белән уртак информация кырында, уртак әдәби мохиттә булырга тиеш. Үз-үзенне «бикләп куюң» да, «бикләтеп кую»да алыш-биреш базарында «бирү» дип бәяләнә;

—татар язучысы, зыялы милләтче буларак, башка халыклар, милләтләргә дә хөрмәтле булырга, толерантлык, тотрыклылык, хезмәттәшлек, дуслыкны ныгыта торган һәр акциядә катнашырга тиеш;

—татар язучысы, кан коюга бәйле бер генә эш-гамәлне дә хупламыйча, кан коюга өндәүчеләргә, нинди милләттән булуларына карамастан, кискен рәвештә үз мөнәсәбәтен белдерергә тиеш.

Рәсәйнең мәгариф өлкәсендәге стандартлар милли әдәбиятларның үсешенә тимер киртә булып тора.

Россия Язучылар съездында Туфан абый белән минем чыгыштан соң Карачай-Чиркәс, Якут-Саха, Дагыстан вәкилләре дә бу мәсьләне ачынып күтәрделәр, хәтта рус язучылары үзләре дә Россия мәгариф министрын «антинародный министр» дип атадылар.

**—Тукай үзенең саф, коеп куйган шагыйрь генә түгел, дипломат та, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә булуын әйтә. Тукай юкса татар үргә менгән, чәчәк аткан чорда яшәгән икән әле ул. Хәзер, милләтебез бетеп, бетерелеп яткан үтә хәвефле бер мәлдә язучыларыбыз (чыгарма рәвешендә, бәлки, унлап бармакны бөгә алабыздыр), әдәбиятка гына бикләнеп, анда да ошбу фаҗиганең күләгәсе дә чагылмаган «стериль» әсәрләр генә иҗат итеп яталар түгелме? Тагын унбиш-егерме елдан кайсы халыкның шагыйре-әдибе булырга, нинди телдә язарга исәп тота икән алар?**

—Әлбәттә, 90нчы еллар инкыйлабын 60нчы елларның «җепшеклек» жилләре белән чагыштырып булмый. Ул жилләр шәхес культының котып бозларын актарып атты. Бу процесс әле дә дәвам итә. Хәзерге дәвер, моңарчы гасырлар буе урнашып, дәвам иткән сәясәтнең яңадан үзенә кайтуы гынадыр, күрәсең. Һәрхәлдә—безнең өчен, безгә булган мөнәсәбәттә... Мин сәясәтче түгел. Язучы буларак исә каләмдәшләребез 60нчы еллардагы «жылы жилләр»гә дә, 90нчы елларның «бюрократик-демократиясе»нә дә битараф калмады дим. Бигрәк тә татар шигърияте... Безнең язучыларыбыз мәйданнарда ачыкты, үз сүзләрен әйтте һәм әйтәләр. Кемдер моны күреп тә—«күрми», ишетеп тә «ишетми» икән, монда язучыларны сукырлыкта һәм чукраклыкта гаепләү бер дә гадел түгел...

Рәфикъ абый, үзең соңгы 15-20 елдагы вәзгыятьнең елъязмачысы була торып, шундый сорау бирәсең. Берүзең генә түгел лә син, дистәгә якын ялкынлы каләмдәшебезне, әйдә әле, үзең санап күрсәт!

**—Илфак әфәнде! Мин «ак» исемлектәгеләр санын ун кат арттырырга да, төгәл санамавым өчен биш кат гафу үтенергә дә, үземне ата ваемсызлар исемлегенә кертергә дә ризамын. Ләкин рәсем матурланганнан гына хәл үзгәрер микән соң?**

—Мин язучыларның җәмгыять белән бердәм атлавы, җәмгыять белән бер сулышта булуы яклы.

Менә әдәбиятка өр-яңа буын килә. Мин аларның иҗатлары да үзләре яшәгән җәмгыять белән көрәшүгә дучар булуын теләмәс идем. Рудаки ханнар хозурында булган, 200 меңнән артык шигырь юлы язган. «Шигърият атасы» дигән исемгә лаек булган. Соңгы чиктә ул да ярамаган, сарайдан куылган. Бу—бер чиктән икенче чиккә ыргытылу... Бәлкем, иҗат кешеләренең тәкъдире шундыйдыр инде?... Язучылар берлеге бу уңайдан караганда да әле кирәк дип фаразлана.

**—Ярар, килешмәсәм дә, бәхәс куертып тормыйк, ары китик.**

**Әгәр дә мәгәр татар халкын бетерү программасы эшләнә калса, анда, минемчә, һичшиксез, шундый бер пункт булыр иде: «Бөекләрен түбәнәйтергә'', дигән. Программа буенчамы, әллә очраклы рәвештә генәме, ләкин мондый эш эшләнеп ята түгелме, Илфак әфәнде? Берәүләрнең язуынча, Сөембикә-ханбикәбез урыслар белән килеп аларга Казанны алышкан, имеш, Җәлилебезне Гитлер мактап туялмаган, имеш.**

—Халкыбызның милли байрагы булырдай бөекләребезне читтән килеп түбәнәйтүчеләр, шөкер, әлегә бик юк. Үзебезнекеләр тырыша.

**—Тәгаенрәк сөйлик әле, рәис әфәнде.**

—Төгәлрәге шул. «Мирас» журналының баш мөхәррире Миңнәхмәт Сәхапов менә бер дистә елга якын үзе нәшер итә торган журналда татар халкының милли каһарманнарыннан «ак таплар» эзли. Бигрәк тә М. Җәлилнең бөеклеге аңа тынгы бирми, күрәсең. Бу елның 6-7нче саннарында М. Сәхапов һәм Э. Яһүдиннарның «Барбаросс» инкыйразы» исемле пьесасы басылып чыкты. Анда авторлар М. Җәлилнең исемен тагын да ныграк пычраталар. Язучыларыбыз аларны кискен гаепләде. Һәм бездән аларны Язучылар берлегеннән чыгаруны таләп итте. Август аенда үткән идарә утырышында Сәхапов бертавыштан Татарстан Язучылар берлегеннән чыгарылды.

**—Михнәтле тормыш, авыр хезмәттән гайре берни дә диярлек күрмичә япь-яшьли үлеп киткән Тукайны үз дәрәҗәбезгә төшереп «тормышчанландырырга» маташучылар да, халкына бик зур, һаман әле үзләштереп житкерелмәгән әдәби һәм рухи мирас калдырган Нәкый ага Исәнбәтнең гаеп чебененнән фил ясаулар да татарга зыян гына сала бит. Килешәсеңме?**

—Килешәм.

**—Язучылар берлеге бинасында узган ел ремонтны туктаттылар. Халыкта бу бинаны да, «Болгар номерлары» урынын да, Баумандагы Матбугат йортын да яңа байлар тартып алачак дигән сүз йөри.**

—«Болгар» номерларының җимерелүе дә, Тукай клубы урнашкан Язучылар йортында ремонтның туктатылуы да бөтенебезне дә борчый. Кызганычка каршы, барыбыз да яңгыннан соң каравыл кычкырабыз шул. «Болгар» номерлары җире «Татнефть»кә күчкән дип ишеттек. Минем бу оешмага ышанычым бар әле. Анда вөҗдансез җитәкчеләр эшләми. Соңгы биш елда алар белән ничәмә-ничә уртак проект булдырдык.

**—«Болгар»ны җимерүне Берлек җитәкчелеге уртак проектлар хакына аклый булып чыгамыни, димәк?**

—«Болгар» номерлары да, ул биләгән җир дә—дәүләт милке. Язучылар берлегенең матди милке юк. «Болгар» номерлары һәм башка мәдәният һәйкәлләренең җимертелүе турында иң әүвәл язучылар чаң сукты. Ә сез Берлек кая карый димәкче. Сез Берлек белән аерым язучы арасында нинди киртә күрәсез соң? Иң абруйлы ике аксакалыбыз—халык язучысы Туфан Миңнуллин белән халык шагыйре Равил Фәйзуллин әлеге факт буенча җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать иттеләр. Башка шундый мәсьәләләрдә дә йә аерым язучы, йә секция, йә идарә исеменнән Язучылар берлегенең җитәкчелеккә һәм җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итми калганы булмады... «Казан утлары»ның быелгы 1нче һәм үткән елгы 12нче санында Равил Фәйзуллинның һәм үзеннең мәкаләләрегез—болар язучыларның фикере түгелмени?

Язучылар берлеге ул ниндидер куркыту таягымыни? (Безнең авылда «куркыту пумаласы» диләр.) Тарихи һәйкәлләрне саклау буенча Мәдәният министрлыгы структурасында махсус идарә бар. Һәйкәлләр дип билгеләнгән һәр бинада аларның рөхсәтеннән башка бер генә кадак та суырып алынмый, бер генә кадак та кагылмый. Безнең Язучылар берлеге бинасында көн итүебез дә—алар белән төзелгән шартнамә буенча. Миңа калса, бездә дөньяга булган үпкә-ачуны үз туганыңнан алу гадәте бар. Бу очракта, Язучылар берлегеннән дип өзеп әйтмәсәм дә, шундый тенденцияне тоям мин. Ак эт бәласе кара эткә диләрме әле? «Уртак проект» мәсьәләсендәге каһкаһәләрәк соравына мин өстәп башка берни дә әйтә алмыйм...

**—Тукай исемендәге клуб та Язучылар берлеге бинасында бит. Язучылар берлеге оешканнан алып бөтен тарихи җыелышлар да Тукай клубында үткән. Баштагысы Матбугат йортында иде бит инде.**

—Безнең бинабыздагы клуб та җимерелеп төшкәнгә кадәр буш тормады. Тукайның тууына 125 ел тулуга әзерлек буенча хөкүмәтнең чаралар планына биналарыбызны төзекләндерү һәм Тукай клубын сафка бастыруны кертү буенча тәкъдимнәребез чыннан да әлегә яклау тапмады. Бу безнең бинабызны кемнәрдер алырга йөри дигән сүзгә бәйле түгелдер дип өметләнәм. Бина идарәнеке генә түгел, бөтен язучыларыбызныкы да бит ул!..

**—Гафур Коләхмәтов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Сәгыйть Рәмиев, Такташ, Кави Нәҗми, Җәлил, Кутуй, Фатих Кәрим, Шамил Усманов, Нәкый Исәнбәт, Кәрим Тинчурин, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах...—татарның иң җете әдәби талантларын саный бу дип уйлыйсыңдыр инде, Илфак әфәнде. Татарстаннан читтә туып-үскән язучыларыбыз бу. Аларны сызып ташласак, әдәбиятыбыздан ни генә калыр иде икән? Хәзер менә асылда шул сызып ташлау, әдәбиятыбызның болай да авыр киләчәген Татарстан белән чикләү бара түгелме?**

—Әйе, татар язучыларының географиясе хәзер кайчандагыга караганда да тарайды. Төп чыганак булып Татарстан һәм Башкортстан республикалары калды. Язучылар берлегенең илдәге яшь иҗатчыларны барларга, алар белән аерым шөгыльләнергә алынуы бик вакытлы гамәлдер.

Алда әйтелгәннәрдән чыгып та, күпчелек каләмдәшләребезнең фикерләрен белеп тә шуны раслый алам, моннан 75 ел элек төзелгән Язучылар берлеге әлегәчә әдәби иҗатчыларыбызның ышанычын аклаган, зур сынаулар аша үтеп үзенен яшәргә сәләтен җуймаган бердәнбер оешма булып кала бирә. Аның эшчәнлеге каләмдәшләребезнең бергә туплану теләгенә һәм сәләтенә бәйле. Аның киләчәге бүген үз сафларына кабул ителгән һәм ителәчәк дистәләрчә яшь язучыларыбыз, яшь шагыйрьләребез, яшь әдәбият галимнәребез һәм яңа буын җитәкчелегенен югарыда күтәрелгән һәм күтәрелмәгән мөһим мәсьәләләргә мөнәсәбәтеннән тора. Шушы изге юлда бергә булыйк, бергәйле булыйк!

*Әңгәмәдәш*—**Рәфикъ ЮНЫС.**

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘЛМӘТ ОЕШМАСЫ

1963 елда Татарстан Язучылар берлегенең филиалы рәвешендә Әлмәттә Язучылар бүлеге оештырыла. Ул вакыттагы әдәби үсеш өчен зур вакыйга була бу. Бүлек Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче шактый күпсанлы каләм ияләрен туплап, шул төбәкнең бер мәдәни-әдәби үзәгенә әйләнә. Ул вакытта Әлмәт нефтьчеләр башкаласы санала, анда илкүләм масштаблы төрле чаралар еш үткәрелә. Татарстанга килгән язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре Әлмәткә сугылмыйча калмый. Алар чыгышлар ясап, жирле язучылар белән аралашып, Әлмәт оешмасының ныгуына булышалар.

Үткән гасырның житмешенче елларында биредә СССР Язучылар берлеге әгъзасы булган иҗатчылар саны 30га житә, ул илнең кайбер өлкәләрендәге язучылар оешмаларына караганда көчлерәк санала. Бу төбәктә яшәүче язучылар тарафыннан укучылар яратып укыган байтак күренекле әсәрләр—романнар, повестьлар, поэмалар, сәхнә әсәрләре, жырлар языла. Ул әсәрләрне иҗат иткән берничә язучы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары, соңрак Татарстанның халык язучысы, халык шагыйре исемнәренә лаек була.

Бу оешма белән төрле елларда Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Ә. Маликов, Ә. Гаффар, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллин житәкчелек итте.

Әлмәт төбәгендә яшәгән язучыларның иң зур куанычларыннан берсе—«Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең «Рухият» фонды булу. Язучыларыбызның әсәрләрен китап итеп бастырып чыгаруда, Сажидә Сөләйманова исемендәге премияләр булдыруда, кичәләр оештыруда, бүлмәбезне заманча ремонтлап жиһазландырудагы ярдәмнәре өчен, «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шәфәгать Фахраз улы Тәхаутдиновка, аның урынбасары, «Рухият» фонды рәисе Рөстәм Нәбиулла улы Мөхәммәдиевка, шушы фонд директоры Флера Мәгъдан кызы Шәйхетдиновага без бик тә рәхмәтле.

Соңгы елларда Лениногорскида Альберт Хәсәновның, Рәшит Шиһаповның, Таһир Шәмсуаровларның иҗат кичәләре үткәрелде. Тагын—Азнакайда татар әдәбияты көннәре, Нур Әхмәдиев, Марсель Галиевларның 60 яшьлек юбилейлары, Сарманда, Җәлил эшчеләр поселогында, авыл мәктәпләрендә Дамир Гарифуллинның житмеш яшь тулу уңае белән юбилей кичәсе... Сарманга житмеш яшь тулган көннәрендә Хатыйп Миңнегуловның кунакка кайтып, Сарман, Иске Кәшер халкын куандырып китүе дә күңелләрдә жылы тойгы калдырды.

Үткән елның октябрь аенда Данил Салиховның илле яшьлегенә багышланган атналык булып, ул Әлмәт драма театрындагы иҗат кичәсе белән тәгәлләнде. Кичә Россиянең төрле төбәкләреннән килгән уникә театр, Казаннан килгән кунаклар белән берлектә үтте.

Соңгы елларда Әлмәт төбәгендә яшәп иҗат итүче язучыларыбыз Фоат Садриев, Дамир Гарифуллин, Клара Булатова, Альберт Хәсәновлар—Сажидә Сөләйманова исемендәге, Рәмзия Габделхакова, Фәйрүзә Исмәгыйлевалар—кызыксындыру премияләренә, Әхәт Хәбибуллин Рафаэль Төхфәтуллин премиясенә лаек булдылар.

Без арабыздан киткән бик күп талантларны гел сагынып, аларны искә алып яшибез. Исемнәрен мәңгеләштерү максатында кылган эшләребез дә шактый. Әлмәт урамнарының байтагына язучылар исеме бирелде. Соңгы елларда гына да Фатих Кәрим, Гамил Афзал, Ләбиб Гыйльми, Жәмит Рәхимов, Роберт Рәкыйпов, Гариф Ахунов урамнары пәйда булды. Гариф Ахунов, Гамил Афзал яшәгән йортка истәлек такталары эленде.

Киләчәктә нишләргә? Укучыны ничек китаптан аермаска? Эшчәнлекнең тагын нинди формалары бар? Без болар турында даими рәвештә уйланабыз.

**Данил САЛИХОВ,**
*Әлмәт оешмасы җитәкчесе.*

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ЧАЛЛЫ ОЕШМАСЫ

Мәскәү түрәләре белән шактый озакка сузылган тартыштан соң, ниһаять, 1979 елның көзендә, КамАЗ төзелеше белән шаулап торган Чаллы каласында язучылар оешмасы булдыру турында махсус карар чыга. Моның өчен иң беренче чиратта Татарстан Язучылар берлеге рәисе, СССРның халык депутаты Гариф Ахунов башлап йөри. Нәтиҗәдә, 1980 елның 8 гыйнварында Чаллы төбәге язучылары үзләренең беренче җыелышларын үткәрә. Язучылар берлеге әгъзалары Эдуард Касыймов, Нәҗип Мадъяров, Кадыйр Сибгатуллин, Тәлгат Галиуллин һәм Мәхмүт Газизовтан торган оешма үз эшчәнлеген әнә шулай башлап җибәрә. Эдуард Касыймов оешманың беренче җитәкчесе итеп сайлана.

Чаллыдагы әдәби хәрәкәтне шәһәрдә аерым оешма нигезләнү генә уятып җибәрмәде. Әле 1963 елда ук каладагы «Коммунизм байрагы» газетасы каршында «Ләйсән» әдәби берләшмәсе эшли башлаган иде. Аның утырышларына Түбән Кама, Зәй, Минзәлә районнарыннан ук килеп, Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев, Хәниф Хөснуллин, Фәннүр Сафин кебек яшь шагыйрьләр үзләренең каләмнәрен чарлый башлады. 1970 елда Чулман елгасы буенда мәшһүр КамАЗ төзелеше кузгалгач, Чаллыга Рәшит Бәшәр, Газиз Кашапов, Фаяз Дунай, Инна Лимонова, Данис Хәйруллин, Рафис Сәлимҗанов, Вахит Имамов, Альберт Сафин, Равил Вәлиев, Шәүкәт Сибгатуллин (Гаделша), Харрас Әюпов, Мансур Сафин кебек яшь талантлар күчеп килде. 1981 елда оешманы Чаллыда канат ярган шагыйрь Разил Вәлиев җитәкли башлады. Элек «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә кайнап йөргән дистәгә якын әдип Язучылар берлегенә кабул ителде. Түбән Кама һәм Алабуга шәһәрләрендә яшәүче Рахмай Хисмәтуллин, Рәшит Гәрәй, Фатыйх Урманче, Нәиб Ләисов, Фазыл Шәехләр дә Чаллы язучылар оешмасына тартылды.

Казан әдипләреннән аермалы буларак, Чаллыда яшәп иҗат итүче язучыларның һәммәсе диярлек әдәбиятка турыдан-туры төзелеш мәйданнарыннан һәм КамАЗ цехларыннан килде. Чаллы язучылары, көндез яки төнлә төзелештә һәм конвейерларда эшләп кайтканнан соң, кич белән тулай торакларга һәм предприятиеләргә, завод цехларына һәм төзелеш мәйданнарына әдәби очрашуларга йөрделәр. Шушы ук язучылар һәм шагыйрьләр якын-тирәдәге авылларда һәм күрше районнарда булырга да вакыт тапты.

Сиксәненче еллар ахырында республикабызда башланган милли азатлык хәрәкәте татар әдәбиятына Чаллы җирлегендә дә бик күп каләм ияләрен бирде. 1991 елның октябрендә шәһәрдә «Аргамак» журналы нигезләнү дә Кама буендагы һәм читтәш төбәкләрдәге әдәби хәрәкәтне канатландырып җибәрде. Без Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Факил Сафин, Шамил Шәйдуллин, Ирек Диндаров, Мирһади Разов, Әмирҗан Моталлапов, Фирүзә Җамалетдинова әсәрләрен укып сөенә башладык. Яңа гасыр Татарстан Язучылар берлегенә Рәзинә Мөхиярова, Әнвәр Шәрипов, Гөлзада Әхтәмова, Галиәхмәт Шаһи, Вәсимә Хәйруллина, Равил Сабыр, Зөләйха Минһаҗева кебек яңа талантларны бүләк итте. 2001 елның августында калабызда өр-яңа типтагы «Мәйдан» журналы нәшер ителә башлау Чаллы төбәге язучылары һәм читтәш республикалардагы талантлар өчен нәшрият нигезенә әверелде.

Без 1991 елда ук КамАЗ типографиясе нигезендә газета-китап нәшрияты булдыруга һәм унбиш еллар чамасы хезмәт дәверендә 800дән артык мөстәкыйль әдәби җыентык нәшер итүгә ирештек. Шәһәрнең иң зур мәдәният сарайларында һәр ай саен «Җомга кичләре» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәләр шаулап барды. Ни үкенеч, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең соңгы еллардагы икътисади авырлыкларны сылтау итүе генә әлеге гүзәл башлангычларыбызның сүнүенә яки сүлпәнәюенә китерде. Шулай да, бик озак елларга сузылган көрәш-тартыштан соң, без Чаллы каласында бүгенге көндә яшәп иҗат итүче язучыларның әдәби музеен булдыруга ирештек.

**Вахит ИМАМОВ,**
*Чаллы оешмасы җитәкчесе.*

## Татарстан Республикасының халык язучылары:

1. Бәширов Гомәр Бәшир улы **(1986)**
2. Закиров Нәкый Сиражетдин улы (Нәкый Исәнбәт) **(1986)**
3. Еникиев Әмирхан Нигъмәтжан улы (Әмирхан Еники) **(1989)**
4. Ахунов Гарифжан Ахунжан улы (Гариф Ахунов) **(1993)**
5. Гыйләжев Аяз Мирсәет улы **(1993)**
6. Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы **(1993)**
7. Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы **(1993)**
8. Фәттахов Нурихан Садрилмән улы (Нурихан Фәттах) **(1998)**
9. Камалов Хисам Нуретдин улы (Хисам Камал) **(2001)**
10. Миннуллин Туфан Габдулла улы **(2005)**
11. Батуллин Рабит Мөхлис улы **(2008)**
12. Хәбибуллин Мөсәгыйт Мөдәррис улы **(2008)**

## Татарстан Республикасының халык шагыйрьләре:

1. Хәкимов Сибгат Тажи улы (Сибгат Хәким) **(1986)**
2. Афзалов Гамил Гыймазетдин улы ( Гамил Афзал) **(1991)**
3. Юзеев Илдар Гафур улы **(1993)**
4. Һидиятуллин Шәүкәт Галиулла улы (Шәүкәт Галиев) **(1995)**
5. Фәйзуллин Равил Габдрахман улы **(1999)**
6. Яруллин Фәнис Гатаулла улы **(2001)**
7. Харисов Ренат Мәгъсүм улы (Ренат Харис) **(2004)**
8. Баянов Әхсән Фәтхелбаян улы (Әхсән Баян) **(2004)**
9. Миннуллин Роберт Мөгаллим улы **(2005)**
10. Әгъләмов Мөдәррис Зөфәр улы **(2006)**

## Әдәбият өлкәсендә Татарстан республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатлары:

**1958.** Фәйзуллин Әхмәт Сафа улы (Әхмәт Фәйзи)—язучы, «Тукай» романы өчен.

**1959.** Әпсәләмов Габдрахман Сафа улы—язучы, «Сүнмәс утлар» романы өчен.

**1960**. Хәкимов Сибгат Тажи улы (Сибгат Хәким)—шагыйрь, «По зову Ленина» (русча), «Жил исми, яфрак селкенми» исемле шигырь җыентыклары өчен.

Вахитов Габделхәй Каюм улы (Хәй Вахит) драматург, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Беренче мәхәббәт» драмасы өчен.

**1966.** Туфан Хәсән Фәхри улы (Хәсән Туфан)—шагыйрь, «Сайланма әсәрләр» китабы өчен.

**1968.** Исәнбәт Нәкый Сиражетдин улы (Нәкый Исәнбәт)—язучы, галим, фольклорчы, «Татар халык мәкальләре» дигән өч томлы хезмәте өчен.

**1969.** Мингазиев Ибраһим Зарифулла улы (Ибраһим Гази)—язучы, «Онытылмас еллар» трилогиясе өчен.

**1972.** Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы (Фатих Хөсни)—язучы, «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» дигән китабы өчен.

Һидиятуллин Шәүкәт Галиулла улы (Шәүкәт Галиев)—шагыйрь, «Гәҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле йорт», «Кызык» һ. б. китаплары өчен.

**1973.** Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы (Гариф Ахунов)—язучы, «Чикләвек төше» повесте, «Хәзинә» романы өчен.

**1974.** Әмиров Мирсәяф Мәсәлим улы (Мирсәй Әмир)—язучы, «Агыйдел» пьесасы өчен.

Юзиев Нил Гафур улы—әдәбият галиме, тәнкыйтьче, «Шигырь гармониясе», «Хәзерге татар поэтикасы» дигән китаплары өчен.

**1976.** Вәлиев Диас Назыйх улы—драматург, «Дарю тебе жизнь» пьесасы өчен.

Шабаев Марс Садри улы—шагыйрь, «Җикән камыш», «Онытма», «Сине эзлим» дигән китаплары өчен.

**1977.** Афзалов Гамил Гыймазетдин улы (Гамил Афзал)—шагыйрь, «Айлы кичләр» шигырьләр җыентыгы, «Борылам да карыйм» дигән шигырьләр циклы өчен.

**1978.** Фәйзуллин Равил Габдрахман улы—шагыйрь, «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен.

**1979.** Миңнуллин Туфан Габдулла улы—драматург, «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы өчен.

**1980.** Юзеев Илдар Гафур улы—шагыйрь, «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» поэмалары өчен.

**1981.** Рәсүлов Атилла Кадыйр улы (Атилла Расих)—язучы, «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» һәм «Ямашев» романнары өчен.

**1982.** Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы—язучы, «Тукай» («Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән) һәм «Габдулла Тукай» дигән китаплары өчен.

**1983.** Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы—язучы, «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән киртәгә» повестьлары өчен.

**1984**. Еникиев Әмирхан Нигъмәтҗан улы (Әмирхан Еники)—язучы, повестьлары һәм хикәяләре өчен.

Родионов Григорий Васильевич (Гәрәй Рәхим)—шагыйрь, «Кара йөзләр» операсы либреттосы өчен.

**1985.** Арсланов Нури Газиз улы—шагыйрь, «Иделем—илем» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен.

**1986.** Камалов Хисам Нуретдин улы (Хисам Камал)—язучы, «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» исемле китаплары өчен.

**1987.** Зарипов Марсель Харис улы—язучы, «Поступь моей республики» һәм «Выгодный оборот» дигән очерклары һәм публицистик китаплары өчен.

**1988.** Хәсәнов Мәхмүт Максуд улы—язучы, «Язгы аҗаган» романы өчен.

**1989.** Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шәһиәхмәт улы—язучы, фольклорчы галим, Ярмөхәммәтов Хәмит Хөснетдин улы—язучы, фольклорчы галим (Хәмит

Ярми) (үлгәннән соң)—һәр икесенә дә «Татар халык иҗаты» дип исемләнгән уникe томлык фәнни хезмәткә керткән зур өлешләре өчен.

**1990.** Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы—язучы, «Кеше китә—җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» повестьлары өчен.

Салахов Ибраһим Низами улы—язучы, «Колыма хикәяләре» романы өчен.

**1991.** Кәримуллин Әбрар Гыйбадулла улы—галим, «У истоков ттарской книги» («От начало возникновония до 60-х годов XIX века»), «Татарская книга пореформенной России», «Татарская книга XX века» дигән трилогиясе өчен.

Зәйнашева Гөлшат Хисам кызы—шагыйрә, «Илле җыр» китабы өчен.

**1992.** Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр улы (Мөдәррис Әгъләмов)—шагыйрь, «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» дигән китаплары өчен.

Липкин Семен Израилевич—шагыйрь, татар халык эпосы «Идегәй»нен һәм татар поэзиясе классиклары әсәрләренен тәрҗемәсе өчен.

**1993.** Мөхәммәдиев Ринат Сафа улы—язучы, «Сират күпере» романы өчен.

**1994.** Фәттахов Нурихан Садрилмән улы (Нурихан Фәттах)—язучы, «Сызгыра торган уклар» әсәре өчен.

**1995.** Яруллин Фәнис Гатаулла улы—язучы, «Җан авазы» китабы өчен.

**1996.** Бәширов Гомәр Бәшир улы—язучы, «И язмыш, язмыш...» китабы өчен.

**1997.** Харисов Ренат Мәгъсүм улы (Ренат Харис)—шагыйрь, «Хисемнен җисеме» дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен.

**1998.** Миннуллин Роберт Мөгаллим улы—шагыйрь, «Кучтәнәч» дигән балалар китабы өчен.

**1999.** Баянов Әхсән Фәтхелбаян улы (Әхсән Баян)—язучы, «Урланган ай» китабы өчен.

**2000.** Маликов Дөлфәт Госман улы (Зөлфәт)—шагыйрь, «Ике урман арасы» һәм «Йөрәгемне былбыл чакты» китаплары өчен.

**2001.** Әхмәтҗанов Роберт Вәли улы—шагыйрь, «Тургай тәрәзәсе», «Кичке кошлар» китаплары өчен.

**2002.** Зәнкиев Якуб Камали улы—язучы, «Иртеш таннары» китабы өчен.

**2003.** Хәбибуллин Мөсәгыйт Мөдәррис улы—язучы, «Кубрат хан» китабы өчен.

**2004.** Юнысов Миргазиян Закир улы (Миргазиян Юныс)—язучы, «Альбатрос язмышы» китабы өчен.

**2005.** Мингалимов Рөстәм Гали улы (Рөстәм Мингалим)—шагыйрь, «Дәрт күлмәге» китабы өчен.

**2006.** Гатауллин Роберт Мөхлис улына (Рабит Батуллага)—язучы, «Сөембикә» әсәре, «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Яралы бүре» китаплары өчен.

Бохараев Равил Рәис улына—язучы шагыйрь, «Очсыз-кырыйсыз поезд», «Казан карлары» китаплары өчен.

Галиев Марсель Баян улына—язучы, шагыйрь, «Гомер бизмәне», «Кайту», «Догалы еллар» китаплары өчен.

Мостафин Рафаэль Әхмәт улына—«Өзелгән җыр эзеннән» китабы өчен.

**2007.** Вәлиев Разил Исмәгыйль улы (Разил Вәлиев)—язучы, шагыйрь, «Иске сәгать дөрес йөри» һәм «Ядкарь» китаплары өчен.

**2008.** Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы (Рәдиф Гаташ)—шагыйрь, «Мәнгелек сусау» һәм «Газәлләр» китаплары өчен.

**2009.** Мансуров Зиннур Мөҗип улы—шагыйрь, «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» һәм «Күнелдә фидаи яшәсә» китаплары өчен.

Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улы (Зөлфәт Хәким)—драматург, язучы, «Телсез күке» спектакле өчен.

# Әдәбият өлкәсендә М. Җәлил исемендәге республика лауреатлары:

**1968.** Юзеев Илдар Гафур улы—шагыйрь, «Миләүшә» дигән шигырьләр һәм балладалар китабы өчен.

**1970.** Фәйзуллин Равил Габдрахман улы—шагыйрь, «Мәрмәр» исемле шигырьләр китабы өчен.

**1972.** Харисов Ренат Мәгъсүм улы (Ренат Харис)—шагыйрь, «Кеше» ораториясенең тексты өчен.

**1974.** Миннуллин Туфан Габдулла улы—драматург, «Нигез ташлары» һәм «Үзебез сайлаган язмыш» дигән пьесалары өчен.

**1976.** Кашшафетдинов Миргази Солтан улы (Гази Кашшаф)—язучы-галим (үлгәннән соң), каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең мирасын барлаулары, аның тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге зур хезмәтләре өчен.

**1976.** Мостафин Рафаэль Әхмәт улы—язучы-галим, каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге зур хезмәтләре өчен.

**1978.** Яруллин Фәнис Гатаулла улы —язучы, «Аерылмас дустым», «Сагыш» дигән җыентыклары өчен.

**1982.** Вәлиев Разил Исмәгыйль улы— әдип, шагыйрь, «Яшисе килә» дигән повесте һәм яшьләргә багышланган җырлар циклы өчен.

**1982.** Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы—шагыйрь, балалар өчен язылган «Акбай цирк карый», «Жиде абый тай җигә», «Айга очтык» дигән шигырь китаплары һәм телевидение аша әдәбиятны актив пропагандалаганы өчен.

**1984.** Хәмидуллин Ризван Мирхәбибулла улы (Ризван Хәмид)—драматург, «Китәм инде», «Синең урыныңа кайттым» дигән пьесалары өчен.

**1988.** Маликов Дөлфәт Госман улы (Зөлфәт)—шагыйрь, «Көзге учаклар» дигән китабы һәм соңгы елларда «Казан утлары», «Ялкын» журналларында басылып чыккан шигырь бәйләмнәре өчен.

**1989.** Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе (җитәкчесе—язучы Хисмәтуллин Рәхмәтулла Хисмәтулла улы —Рахмай Хисмәтуллин).

**1990.** Зәйдуллин Ркаил Рафаэль улы—шагыйрь, «Күрәзә» исемле шигырьләр китабы өчен.

**2003.** Вәлиев Мөдәррис Харис улы (Салих Маннапов)—Татарстан Республикасының «Мәгариф» нәшрияты директоры, шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, талантлы яшь авторларга эзлекле ярдәм күрсәткәне өчен.

**2003.** Республика яшьләренең «Сәләт» иҗтимагый фонды (җитәкчесе—шагыйрь, техник фәннәр докторы Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы).

**2007.** Леронов Лемон Лерон улы (Ләбиб Лерон)—«Кояшны кочкан малай» китабы өчен.

Моратов Газинур Васик улы—«Төнге әверелеш» китабы өчен.

**2009.** Бикчурова (Гыйматдинова) Нәбирә Миннәхмәт кызы—«Бер тамчы мәхәббәт» китабы өчен.

Зәйниев Илгиз Газинур улы—бүгенге татар драматургиясен үстерүгә зур өлеш керүе өчен.

Хөснетдинов Зиннур Зыятдин улы—«Салават күпере», «Сәхнә» журналын нәшер итүдәге, балалар өчен китаплар иҗат итүдәге күпьеллык эшчәнлеге өчен.

*Кеше китә, җыры кала*

## РӘШИТ ӘХМӘТҖАН
*(1941–1995)*

### Бәйрәм

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

Чаба атлар, томырылып чаба,
Кыңгыраулар чыңлый юлларда.
Ил шатлыгы тынмас булгангамы,
Ятлар чыга куллар болгарга.

Чәчте-урды халкым,
Горур булды,
Үз язмышын ятка бирмәде!
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре.

Алар күргән авыр кайгыларны
Онытырмын димә тиз генә.
...Дошман килгән халкым сөягеннән
Һәйкәл куяр өчен үзенә.

Мин туганмын җиргә шул елларда,
Озак яшәремне ил белгән.
Мин туганмын,
Илем дошманнары
Нәкъ мин туган җирдә күмелгән.

Рәхмәт, илем!
Гомер биргәнсең дә,
Йөрәк янган сүнми-югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.

Илен яклап утка кергәннәрне
Дошман яуда җиңаламыни?!
Шундый кешеләрнең нәфрәте
Аны ерак җибәрәмени!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары!..

*1966*

## МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМ
*(1946–2006)*

### Ышаныч

Безме соң ул? Үзгәрергә тиешме,
Колак салып һәр имансыз сүзенә?
Мин сүземә ышанган күк ышанам
Халкыма, туган җиремә, үземә...

Без бит сабый түгел инде, беләбез
Җир шарының әйләнмәсен кирегә...
Иделемә ышанган күк ышанам
Халкыма, үземә, туган җиремә.

Куркып түгел, күпме ара үткәнне
Белер өчен борылам мин артыма,
Икмәккә ышанган кебек ышанам
Үземә, туган җиремә, халкыма.

*1967.*

# ЗӨЛФӘТ

*(1947–2007)*

## Курку

Ничәнче төн бер үк төш күрәм мин,
Мин—исемсез нәни кош икән...
Кемдер мылтык төзи астан миңа—
Тын алганын хәтта ишетәм.
Йолдыз серен аңламакчы идем,
Серен төшенмәкче болытның,—
Кемдер мылтык төзи астан миңа!—
Сайравымны хәтта оныттым.

Кемдер мылтык төзи,
мылтык төзи!
Очам кечке нурда ялтырап.
Күтәр мине, канат, биеккәрәк!
Янчы, кичке кояш, яктырак!..
Күкнең кеме соң сез, сак йолдызлар?
Чиксез ерак ялтыр ташлармы?

Әллә инде,
афәтләрдән куркып,
Артык биек менгән кошлармы?
...Ничәнче төн күрәм бу төшне мин,
Шомландыра ул төш, тетрәтә.
Мин уянам. Шомлы курку белән
Кош сулкылдый эчтә—
күкрәктә.
Ничәнче төн шомлы төш күрәм
мин
Һәм куркудан каба сулуым:
Кош булуың хәтта шомлы чакта
Җинаятьтер—
кеше булуың...

*1976*

# ХАРРАС ӘЮПОВ

*(1946–2008)*

***

Төркем-төркем кошлар күтәрелде,
Очып узды гомер өсләреннән,—
Таралдылар...
Кайдан эзлим инде,
Бу дөньяның кайсы төшләреннән?

Төркем-төркем китеп югалдылар,
Бик аз гына миндә булып бар да.
Бала чакның моңсу торналары!
Тавышыгыз кайсы болытларда?

Безнең өйнең түбә кыегына
Оялаган җитез карлыгачлар!
Сезнең кебек без дә бишәү идек...
Ниләр күрде икән сезнең башлар?

Әллә кайда, ерак-еракларда
Ачыргаланалар акчарлаклар,—
Тик аларга мәгълүм иде безнең
Мәхәббәттән күккә ашар чаклар.

Тел китергән серле сыерчыклар,
Аккошларым, тургай-былбылларым!
Бармы тагын берәр белүчесе
Ниндилеген безнең бу юлларның?

Төркем-төркем:
Көннәр... айлар...еллар...
Җил дә давыл гомер өсләрендә,
Кошкайларым!
Без кайларда икән,
Шул давылның кайсы төшләрендә?!

*1988*



Гәрәй Рәхим

# КҮҢЕЛГӘ УЕЛГАН ХАТИРӘЛӘР[1]

*СССР, Россия Федерациясе һәм Татарстан Язучылар берлекләре тарихы күренекле җәмәгать эшлеклесе, легендар шәхес, нәни балалардан алып карт бабайларга кадәр булган әдәбият сөючеләрнең яраткан язучысы Сергей Михалковның тәрҗемәи хәле һәм әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән.*

1980-87 елларда мин Мәскәүдә Россия Язучылар берлеге идарәсендә турыдан-туры Сергей Михалков кулы астында эшләдем. СССР Язучылар берлегенен Әдәбият институты каршындагы икееллык Югары Әдәби курсларын бетерер-бетермәс мин Россия Язучылар берлеге идарәсендә Татарстан, Башкортстан һәм Чуашстан Язучылар берлекләре буенча куратор, ягъни әдәби консультант, соңрак исә Россия милли әдәбиятларын рус теленә тәрҗемә итү комиссиясе сәркәтибе булып та эшли башладым. Бу җиде ел татар әдәбияты, Татарстан Язучылар берлеге һәм татар язучылары тормышында шактый уңдырышлы еллар булды. Бүген, гаять кешелекле, милли әдәбиятларга олы хөрмәт күрсәткән, аларга һәрдаим ярдәм итәргә әзер торган, бу яктан рус әдипләренең соңгы могиканнарының иң күренеклесе булган Сергей Михалков вафаты көнендә һәм Татарстан Язучылар берлеге төзелүгә 75 ел тулуны билгеләп үтү тантаналары алдыннан кайбер истәлекләрем белән уртаклашып үтәсем килә.

Сергей Владимирович мине һәрвакыт «татарин» дип кенә йөртә иде. Балачактан сакау буларак, ул бервакытта да диярлек «татарин» дигән сүзне берьюлы гына әйтә алмады, беренче иҗектән үк теле көрмәкләнә һәм мина «та...та...та...тарин» дип дәшә иде.

Консультант буларак минем төп вазифаларым шактый киң иде: мин СССР һәм Россия Язучылар берлекләре җитәкчелегенә, КПСС Үзәк Комитетының, СССР һәм Россия хөкүмәтенең әдәбият белән җитәкчелек итүче бүлекләре һәм бүлекчәләренә алар сораган һәр мизгелдә Татарстан, Башкортстан һәм Чуашстан әдәби хәрәкәтләренең торышы, әдәби үсеше, алардагы иҗади мохит турында мәгълүмат бирергә әзер булырга, бу язучылар оешмаларының олы-олы чараларын (съезд, пленум, фәнни-әдәби конференцияләр, республикара әдәбият-сәнгать көннәре, декадалары үткәрү һ.б.) оештыруда ярдәм итәргә, аларның Мәскәүдә үткәреләчәк чараларын (Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия юбилейларын, милли республикаларыбызның Мәскәүдә үткәрелә торган әдәбият көннәрен һ. б.) оештырырга, үзем кураторлык иткән өч автономияле республика язучыларына фатир алуда, аларның русчага тәрҗемә ителгән китапларын Мәскәүдә бастырып чыгаруда, иҗатларын Мәскәүдә пропагандалауда, Иҗат йортларына юлламалар алуда булышырга, хәтта кирәк чакта аларга Мәскәү кунакханәләренә урын алышырга,

[1] Бу мәкалә күренекле рус язучысы, Татарстан Язучылар берлегенә күп ярдәм иткән Сергей Михалков вафат булган көнне, 2009 елның 27 августында язылды.

поездга һәм самолетка билетлар юллап бирергә тиеш идем. Кунакханә һәм билетлардан кала бу эшләрнең һәрберсе турында диярлек мин РСФСР Язучылар берлеге рәисе Сергей Михалковка мөрәҗәгать итәргә, бөтен олы чараларны оештыруда КПСС һәм төрле дәүләт оешмаларының хәерхаһлыгын һәм ярдәмен аның имзасы куелган хатлар белән генә хәл итәргә тиеш идем.

Жиде ел эшләвем дәверендә мин Сергей Михалковның милли әдәбиятларга, милли язучыларга ярдәм сорап язган хатларның берсенә генә дә кул куймыйча чыгарганын хәтерләмим. Ярдәм сораган хат күтәреп бүлмәсенә керсәм: «Давай та... та...та...тарин, подпишу, ты их больше меня знаешь»,—дип кенә шаярта иде.

Ул елларда Татарстанда чит илләр белән багланышлар буенча бер генә структура да юк иде. (Аллага шөкер, хәзер әнә Татарстан Президенты аппаратында тышкы элемтәләр буенча махсус департамент республикабызны дөньяда таныту буенча күпме игелекле эш эшләп килә, Бөтендөнья Татар конгрессы чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне рухи яктан Татарстанга һәм Казанга туплый, Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллегебез тулы бер илчелек вазифаларын башкара). Ә ул елларда Татар әдәбиятының чит илләрдә яңгыравы өчен берниндi шарт та юк иде. Ярый әле хөкүмәтебез, Язучылар берлеге, бигрәк тә күренекле әдәбият белгече Рафаэль Мостафин тырышлыгы белән Муса Җәлилнең тоткынлыктагы тормышын һәм иҗатын өйрәнү өчен ГДР белән әйбәт кенә элемтәләр булдырылды. Әмма ул чакта әле безнең башка әдипләрне, бигрәк тә борынгы язучыларны киң дөньяга чыгару турында сүз дә булуы мөмкин түгел иде.

1983 елны Татарстан Язучылар берлеге КПССның Татарстан өлкә комитетына һәм хөкүмәтебезгә борынгы классик шагыйребез Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы язылуга 750 ел тулу датасын Россия күләмендә киң итеп уздыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте. Бу тәкъдим республика түрәләрендә яклау тапкач, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов шатлыгыннан очына-очына Мәскәүгә килеп төште һәм Кол Гали әсәре юбилеен Мәскәүдә ничегрәк үткәрергә икәнлеген киңәшләшү өчен минем кабинетка керде. Гариф абыйга мәсьәләнең бик җитди һәм гаять кызыклы икәнен, әмма моны Сергей Михалковның шәхси катнашыннан башка оештырып булмаячагын әйттем. Гариф абый «Кыйссаи Йосыф» поэмасы турында Татарстан галимнәре туплаган бай фәнни һәм тарихи мәгълүмат алып килгән иде. Мин Ахуновка хәзер үк бөтен материалны тотып Сергей Владимировичка керергә кирәклеген әйттем. Эчке телефон буенча Михалковка шалтыраттык, безне кабул итүен сорадык. Ул хәзер үк кабинетына керергә кушты.

Ахунов алып килгән язмалар белән танышып чыкканнан соң, Сергей Владимирович гадәттәге шаянлыгы белән: «Ну, и та...та...татары даю-ю-т, 750 летняя литературная история!»—дип куйды. Аннары ул бу юбилейны Россия һәм СССР күләмендә зурлап үткәрергә кирәклеген, юбилей тантанасының Союзлар йортының Колонналы залыннан да ким булмаган залда үткәрелергә тиешлеген әйтте. Залны алырга үзем булышырмын, диде. Әмма ул оештыру мәсьәләләре белән хәзер үк Россия Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе Анатолий Волковка мөрәҗәгать итәргә кушты. Без, рәискә рәхмәтләр әйтеп, Анатолий Иванович бүлмәсенә чаптык.

Волков Парижда эшләп кайткан дипломат кеше иде. РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә эшли башлаган беренче көннән үк ул мине ошатты, эшләү рәвешемнән, үз-үземне тотышымнан канәгать иде. Ул миңа һәм татар язучыларына һәрвакыт хөрмәт белән карады, ярдәм итте. Җае чыкканда без Гариф абый белән Анатолий Иванович бүлмәсендә бик шәп итеп «пирәшләп» тә утыра торган идек.

«Кыйссаи Йосыф» турындагы язмаларны карагач, гаҗәпләнүдән Анатолий Ивановичның күзләре яна башлады. «Татар язма әдәбиятына 750 ел! Гаҗәп бит бу, халыкара дәрәҗәдә гаҗәп!»—диде ул.

Шуннан ул үзенең күп еллар Берләшкән Милләтләр Оешмасының (БМО) Париждагы ЮНЕСКО бүлегендә эшләвен, анда әле хәзер дә бергә эшләгән дуслары һәм хезмәттәшләре барлыгын, дөньядагы бөек тарихи шәхесләр һәм вакыйгаларының юбилейларын ЮНЕСКО календарена кертеп халыкара күләмдә үткәрү мөмкинлеге бар икәнен әйтте. Татар әдәбиятының бу юбилее ЮНЕСКО күләмендә үткәрүгә тулысынча лаек икәненә ышаныч белдерде. Без Гариф абый белән бу шатлыклы

хәбәрдән сүзсез калдык.

Шуннан Анатолий Иванович Парижга шалтыратып, ЮНЕСКО хезмәткәрләре белән киңәшләшәчәген һәм нәтиҗәләрне безгә белдерәчәген әйтте.

Гариф абый Казанга кайтып китте, мин исә хәбәр көтә-көтә үз эшемне эшләдем. Көннәрдән бер көнне Анатолий Иванович мине үз бүлмәсенә дәште. Килеп керсәм, йөзе чытык, кәефе юк.

—«Кыйссаи Йосыф» әсәре юбилеен СССР һәм Россия күләмендә әйбәтләп үткәрербез, әмма халыкара кинлеккә чыгып булмый,—диде ул,—ЮНЕСКО календарена азагы ике яки өч нольгә беткән түгәрәк даталарны гына кертеп була икән, тәртибе шундый. Ә «Кыйссаи Йосыф» поэмасы язылуга 750 ел. Әлеге 50 саны бу датаны календарьга кертүгә комачаулый.

Волков миңа бөтен язмаларны кире биреп чыгарды. Минем, әлбәттә, бу юбилейны БМО күләмендә үк үткәрүгә артык өметем юк иде. СССР һәм Россия күләмендә үткәрү дә әйбәт бит.

Бүлмәгә чыктым да, бөтен язмаларны, фәнни-тарихи мәгълүматларны янадан карый башладым. Шөгер районы буенча минем якташ, күренекле галим Фазыл Фәсиев тикшеренүләре буенча, Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрен 50 яшьләрендә тәмамлаган. Галим фаразы буенча, шагыйрь 1183 еллар тирәсендә Идел буе төбәкләренең берсендә туган.

Тукта... тукта... Быел 1983 ел, әгәр Кол Гали 1183 елда туса, быел аның тууына нәкъ 800 ел була бит! Ике нольле дата! Ә нигә юбилейны шагыйрь Кол Галинең тууына 800 ел дип атамаска ди?!. Кол Галинең 800 еллыгы бит ике ноле белән ЮНЕСКО календарена керергә хаклы! Ә юбилей «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән башка була алмаячак. Мин бөек бер фәнни ачыш ясаган кебек канатланып Анатолий Иванович бүлмәсенә очтым.

—Анатолий Иванович! Безгә юбилейны «Кыйссаи Йосыф» язылуга 750 ел дип түгел, ә Кол Галинең тууына 800 ел дип атарга мөмкинлек бар!—дип документларны сәркәтип өстәленә салдым.

Волков документларны минем тәкъдим күзлегеннән карап чыкты да:

—Бу инде икенче мәсьәлә, шалтырат тиз генә Ахуновка, шагыйрьнең тууына 800 ел дип документлар әзерләп җибәрсеннәр, мин аларны тиз генә Парижга җибәрермен,—дип әмер бирде.

Мин шул көнне үк Ахуновка шалтыратып, үземнең «аферам»ны аңлаттым.

Бер атна да үтмәде, әр-яна документлар төяп, Татарстан Язучылар берлегенең оештыру эшләре буенча рәис урынбасары Мөсәгыйт Хәбибуллин Мәскәүгә килеп төште. Ә документлар бик кәттә иде. Анда Кол Гали һәм «Кыйссаи Йосыф» поэмасы турында галимнәр Миркасыйм Госманов һәм Нурмөхәммәт Хисамовның иң югары халыкара даирәләргә күрсәтергә дә лаек булган мәкаләләре, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтовның Кол Галине олы сакаллы, мөлаем акыл иясе итеп сурәтләгән портреты (аны хәзер һәркайсыбыз белә) һәм «Кыйссаи Йосыф» әсәрен көйләп башкарылган музыкаль тасма бар иде.

Без Мөсәгыйт Хәбибуллин белән бу материалларны Анатолий Ивановичка алып кергәч, аның йөзе яктырып китте һәм ул миңа ЮНЕСКО оешмасына Кол Галинең тууына 800 ел тулу юбилее датасын календарьга кертүне сорап язылган хатның проектын әзерләргә кушты. Шул көнне үк мин хатны язып, бланкка бастырып Анатолий Ивановичка керттем, ул, кул куеп, бөтен материалны Парижга юллады.

Безгә озак көтәргә туры килмәде, Париждан ЮНЕСКО календаренең кабул ителгән нөсхәсе килеп төште. Ул калын бер китап зурлыгында иде. Анда бөтен дөнья тарихында зур эз калдырган шәхесләрнең һәм вакыйгаларның 1983 елда ике яки өч нольле саннарга беткән даталары теркәлгән иде. Мин алфавит тәртибендәге исемнәр арасыннан тиз генә Кол Гали исемен табып алдым. Шушы калын календарьда нибары бер юл күләмендә теркәлгән бу исем минем өчен иксез-чиксез шатлык иде. Календарьның бу битен берничә дистә күбәйтеп мин тиз генә КПССның Татарстан өлкә комитетына, хөкүмәткә, ИЯЛИгә[2], Ахуновка, Сибгат ага Хәкимгә җибәрдем.

Әлбәттә, календарьны күтәреп мин Сергей Михалков бүлмәсенә дә кердем.

[2] Г. Ибраһимов исемендәге тел,әдәбият һәм тарих институты.

Сергей Владимирович календарьны карады да: «Молодец, та...та...та...тарин!»—дип мине мактап куйды һәм миңа тиз генә Кол Гали юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз юбилей комиссиясе составы проектын төзергә кушты. «Мин комиссиянең рәисе булуны үз өстемә алам, ә син аның сәркәтибе булырсың»,—диде.

Бу арада инде СССР Язучылар берлегенә Казакъстаннан да, Башкортстаннан да безнең борынгы шагыйребез Кол Гали юбилеен Мәскәүдә үткәрергә кирәк дигән тәкъдимле хатлар килеп житкән. Кол Галинең Бөтенсоюз юбилей комиссиясе составына КПСС Үзәк Комитеты, РСФСР хөкүмәте, СССР, Россия, Татарстан, шулай ук Казакъстан, Башкортстан вәкилләре, атаклы рус, татар, казакъ, башкорт язучылары, галимнәр кертелде.

ЮНЕСКО календаре нигезендә Кол Гали юбилее дөньяның күп кенә төрки, мөселман, яһүд илләрендә теге яки бу күләмдә билгеләп үтелде, ә СССРның барлык төбәкләрендә диярлек әдәби кичәләр үткәрелде, ана радио-телевидение тапшырулары, газета-журнал материаллары багышланды.

Мәскәү шәһәрендә исә юбилей Сергей Михалков теләгән атаклы Колонналы залда үтте. Афиша, чакыру билетлары бастыру, кунаклар исемлеген төзеп, аларга чакырулар жибәрү, кичәнең сценариен төзү, чыгыш ясаучыларга кинәшләр белән ярдәм итү, тамашачылар туплау, радио-телевидение, газета-журнал вәкилләренә ярдәм итү, кунакларга кунакханәләрдә урын булдыру, аларга Мәскәүдән китү өчен тимер юл һәм самолет билетлары алып бирү (Казаннан гына да 120дән артык кунак килде!)—барысы да минем өстә иде. Көне-төне аяк өсте чабып эшләсәм дә, ару-талуны белмәдем мин.

Кол Гали юбилее татар халкының мәдәни тарихында беренче буларак әнә шулай халыкара тантана итеп үткәрелде.

Габдулла Тукайның 100 еллык юбилеен инде ЮНЕСКО календарена кертеп эшләү жинелрәк булды кебек. Ул да безнең Татарстан Язучылар берлеге, татар әдәбияты өчен гаять зур вакыйга, горурлык иде. Тукай бәйрәмен дөньяның 14 илендә билгеләп үттеләр. Мәскәүдә ул шулай ук Колонналы зал сәхнәсендә узды.

Шунысын да әйтим әле: мин тамашачы чакыру эшендә бераз арттырып ташлаганмын, билетлы тамашачыларның бер өлеше кичәгә килмәс дип уйлап, түрәләргә әйтми-нитми генә берничә йөз билетны залдагы урыннардан күбрәк бастырдым. Әмма тамашачы шулкадәр дә актив килде ки, залдагы урыннарга сыймый башлады һәм Союзлар йорты бинасы урнашкан тар урамга берничә йөз кеше жыелды. Урамдагы транспорт тукталды, атлы милиция төркеме чакырылды. Колонналы зал хезмәткәрләре мине битәрли башладылар. Шуннан мин аларга урамга тавыш көчәйткечләр куеп, кичәне урамга трансляцияләргә тәкъдим иттем. Шулай итеп, Тукай юбилее кичәсе урамда да яңгырап торды, концерт барышында урамдагылар безнең артистларга кушылып жырлап та жибәргәләделәр әле.

Икенче көнне Михалков мине бүлмәсенә чакырып алды. «Ты что, та...та...та...тарин, натворил там вчера?!»—диде ул, кырыс булырга тырышып. Әмма соңыннан жилкәмә кулын куеп, ачуланмавын, әдәбиятны шулай олылап күрсәтүгә канәгать булуын әйтте.

Татарстан Язучылар берлегенең тырышлыгы һәм Сергей Михалковның турыдан-туры ярдәме белән бу елларда Мәскәүдә татар әдәбиятына багышланган күп кенә чаралар үткәрелде. Мәскәүнең атаклы Лужники Үзәк стадионының Зур залында татар поэзиясе кичәсе үткәрелү үзе генә дә ни тора! Халык белән шыгрым тулган биниһая зур залда Сибгат ага Хәким, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин һәм башка татар шагыйрьләре татар телендә шигырьләрен укыдылар. Бөтен зал дулап кул чабудан Лужники стадионы гөрләп торды.

Безнең язучыларыбызның юбилейлары СССР Язучылары йортының Зур залында да, Некрасов исемендәге китапханәдә дә, метро төзүчеләрнең Мәдәният сараенда да уздырылды.

Бу чараларның барысы да татар язучыларын бик якын иткән Сергей Михалковның турыдан-туры күрсәтмәләре белән үткәрелде. Татарстан Язучылар берлегенә Сергей Владимирович Россиядәге иң зур, тарихи яктан иң олы, талантлы оешма итеп карый иде. Бүген, оешмабыз төзелүгә 75 ел тулу тантаналары алдыннан һәм якын дустыбыз, бөек рус язучысы Сергей Михалковны югалткан көндә, без моны аеруча нык тоябыз.




*«Казан утлары» журналының 80 еллык юбилее уңаеннан төшерелгән рәсем. Сәхнәдә— журнал коллективы. Казан милли мәдәният үзәге. 2002 ел.*



*Татарстан Язучылар берлегенең Кабул иту коллегиясе әгъзалары. Сулдан уңга: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рөстәм Кутуй, Шаһинур Мостафин, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин (рәис), Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Марсель Галиев. 2000 ел. Казан.*



*ПЕН-Үзәгенең чираттагы утырышыннан соң. 1994 ел.*



*Бөек максат безнең—Азатлык! Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов. 1989 ел.*



*Татарстанның халык язучысы Хисам Камалов.*



*Дөньякүләм атаклы язучылар—Чыңгыз Айтматов (уңнан беренче) һәм Олжас Сөләйманов Татарстан Язучылар берлегендә очрашу вакытында. Казан. 2000 ел.*



Лирон
Хәмидуллин

# БЕРЛӘШЕП, АРАЛАШЫП ЯШӘҮ ЕЛЛАРЫ

## 1

Революциягә кадәр татар язучылары арасында иҗади берләмлекләр, аерым сәяси-иҗтимагый төркемнәр булмаган диярлек. Дөрес, 1907-1908 елларда берара «Әлислах» белән «Таң йолдызы» газеталары тирәсенә тартым яшь иҗатчылар үз төркемнәренә «елышырга» тырышып караганнар. Ләкин тиздән «таңчылар»ның җитәкчелеге кулга алынуы, газеталарның ябылуы сәбәпле, үз йөзе булырдай бер төркемгә оешып бетә алмаганнар. Ә менә егерменче елларда инде бер-берсеннән беркадәр аерылып торган, үзара «көрәш дулкыннары» уйнаткалап алган берләмлекләр хасил була. Үзләрен сәяси яктан «уң карашлы» яки «сул карашлы» дип танучы ике зур төркем күпчелек язучыларны берләштерә.

1924 елда Фәтхи Бурнаш, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Гадел Кутуй һ.б. яшьләр «Октябрь күмәге» төркемен оештыралар. Ә башкалада яшәп иҗат итүче яшьләр Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясендә (МААП) үз секцияләрен булдыралар (Мансур Крыймов, Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов һ.б.). 1928 елның май аенда Мәскәүдә эшче-пролетар язучыларның 1нче Бөтенсоюз съезды уздырыла. Гомәр Гали җитәкчелегендә анда берничә татар язучысы да катнаша. Съездан соң Казанда татар пролетар язучылар оешмасы—ТААП төзелә. Аның идарәсенә Гомәр Гали (рәис), Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Демьян Фәтхи, Габдрахман Минский керә. Ә берникадр вакыт элегрәк «пролетар булмаган» өлкәнрәк буын каләм әһелләре «Татар язучылары җәмгыяте»нә берләшә башлаган була. Аның идарәсенә Галимҗан Нигъмәти (рәис, Татар дәүләт нәшриятының баш мөхәррире), Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбайский, Гадел Кутуй сайлана. Вакытлы матбугат битләрендә бу төркемнәр арасында җитди генә бәрелешләр, кемнең «дөрес юлдан барганын» ачыклау бәхәсләре булгалап тора.

Әлбәттә, төрле сәяси юнәлешле мондый төркемнәр, алар арасындагы низаглар СССР рәвешендә оешып килүче мәмләкәтнең башка төбәкләрендә дә һәрдаим булгалап тора. Мондый хәлләр Мәскәү, Петербург кебек сәяси башкалаларда аеруча күзгә ташлана. Шундый хәлләргә чик кую, сәяси агым-юнәлешләрне бер җайга салу максатыннан чыгып, ВКП(б) Үзәк комитеты 1932 елның апрелендә язучыларның һәм башка иҗат әһелләренең бердәм оешмасын—союз-берлекләрен оештыру турында карар кабул итә. СССР Язучылар берлеген оештыру комиссиясе төзелә. Аның идарәсенә Максим Горький да керә. Казанда да шундый комиссия төрле әдәби төркем вәкилләреннән сайлана. Рәис итеп партияле Г. Нигъмәти билгеләнә. Татарстан Язучыларының 1нче оештыру съезды 1934 елның 25 июлендә ачыла. Ана Мәскәүдән һәм кайбер күрше республикалардан кунаклар чакырыла. Съездда 9 кешедән торган идарә сайлана. Идарә утырышында рәислек вазифасы Кави Нәҗмигә тапшырыла.

Шул ук елның август аенда язучыларның СССР күләмендәге 1нче съезды Мәскәүдә ике атна чамасы эшли. Анда катнашкан биш йөзгә якын язучы арасында Татарстаннан килгән 12 делегат һәм берничә кунак та була. Кави Нәҗми белән Кәрим Тинчурин съездда татар әдәбияты һәм сәнгатенен торышы турында доклад һәм чыгыш ясыйлар. Бу беренче съездларга кагылышлы вакыйгаларны берничә ел элек Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин «Казан утлары» журналында һәм «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» (2004) китабында тәфсилләп язып чыкты. Язучыларның Мәскәүдә узган зур съездында төрле төбәкләрдән килгән 19 татар каләм әһеленең катнашуын да шуннан укып белә алабыз.

Мәскәүдә узган съездның төп әһәмияте язучыларны бер оешмага беркетү, сәяси-иҗтимагый бердәмлек булдыруда гына түгел, билгеле. Дөньясын онытып, иҗат мавыгуына бирелеп үз кетәгендә баш күтәрми эшләп утырган язучының тормыш-көнкүрешенә бәйле бик җитди мәсьәлә дә хәл ителә бу җыен барышында. Күпләрне борчыган, матбугат битләрендә байтактан бирле күтәрелә килгән мәсьәлә. 1928 елда «Кызыл Татарстан» газетасында да шул хакта язучы Сафа Борһанның күләмле генә мәкаләсе басыла. Язучы нәтиҗәле эшләсен өчен аның тормыш-көнкүрешен җайга салу, матди хәлен кайгырту, иҗади очрашу сәфәрләрен оештыру зарур, дип яза ул.

Беренче оештыру съездына әзерлек барышында алда телгә алынган комиссия бу мәсьәләне хәл итүгә дә җитди килгән—каләм әһелләренең тормыш-көнкүрешен кайгыртырга тиешле фонд булдыру турында хөкүмәт карарын чыгарткан икән. Шул рәвешле СССР Әдәби фонды—Литфонд оешмасы барлыкка килә. Аның хөкүмәт тарафыннан хупланган уставы шул съездда ук раслана. Литфонд оешмасының төп максаты—язучыларга уңайлы иҗат итү шартларын тудырудан гыйбарәт иде. Ягъни язучы гаиләсен торак белән тәэмин итү, сәламәтлеген сихәтләндереп тору өчен хастаханәләргә, курорт-санаторийларга юлламалар юнәтү, иркенләп, дөнья мәшәкатьләреннән котылып иҗади мохиттә яшәп алырдай Иҗат йортлары булдыру, махсус китапханәләр, клублар тоту... Язучының дөньяви һәм иҗтимагый-сәяси белемен үстерүгә булышлык итәрдәй төрле семинарлар, курслар да, махсус ачылган Әдәбият институты да шушы Литфонд акчасына яшәп килделәр. Ил буйлап һәм ара-тирә чит илләргә барып кайту өчен командировка чыгымнары да, язучының сырхаулап торган көннәре өчен «больничный» түләүләре дә шул фонд хисабыннан булды. Хәзер иҗат кешесе өчен боларның берсе дә юк инде. Литфонд, Музфонд, Худфонд кебек оешмалар таркалу хәлендә. Иҗат әһелләренең тормыш-көнкүреш мәсьәләсе янадан патша Россиясе чорындагы торышына әйләнеп кайтты. Бай-буржуйларга яраша белгәне—яши, калганнары очын-очка ялгар-ялгамас килеш «көн күрә»...

Элек ул Литфонд, Музфонд, Худфондлар ни-нәрсә исәбенә яшәгән соң? Аларны яшәтү өчен кем акча биреп торган, дигән сорау туа. Хөкүмәт биргән. Дөрес, хөкүмәт тә акчаны турыдан-туры үзе өләшеп ятмаган. Аны иҗат әһелләре тудырган әсәрләрне «товар»га әйләндерүче газета-журнал һәм китап нәшриятлары, театрлар һ.б. шундый оешмалар хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән керемнән бер күләмдә чигереп, авторларның хокукларын барлаучы агентлыкка күчерә килде. Классик әдип, рәссам, композиторларның мирасын куллanудан килгән бәрәкәтле керем дә шул кассага күчә барды. Ул агентлык исә кайсы фонд исәбенә күпме акча кергән—шуны бүлеп бирә иде.

Литфондның Татарстан бүлеге 1934 елдан үз бурычын үтәүгә керешә. 1934—1992 еллар аралыгында Язучылар берлегенә кабул ителгән иҗат ияләренең күпчелеге шул фонд исәбенә фатирлы булдылар, курорт-санаторийларда дәваландылар, Иҗат йортларына барып ял итеп һәм иҗат итеп кайттылар. СССРның төрле тарафларына иҗатташлары яки булачак әсәр геройлары белән очрашуларга баргалап йөрделәр. Оешмаларда эшләмәүчеләре авырган көннәре өчен акчалата уртача хезмәт хаклары алдылар. Чит илләргә иҗади командировкаларга баручылар да булды. Мәсәлән, мин Литфондта эшләгән елларда Зәки Нури, Габдрахман Минский, Рөстәм Кутуй Польшада, Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин Германиядә булып, Бөек Ватан сугышына бәйле әсәрләренә материал туплап кайттылар. Шәйхи Маннур да,

«Муса» романын язган вакытта, әдәби фонд исәбенә Берлинда йөреп кайткан иде. «Сызгыра торган уклар» романын язарга керешкәндә Нурихан Фәттах, Монголия жирләрен аркылыга-буйга инләп, бер ай чамасы йөрде. Яртылаш диярлек әдәби фонд исәбенә түләнгән туристлык юлламалары белән чит илләргә чыгып йөрүчеләр исә санап бетергесездер. Алар төркем-төркем булып гарәп илләрендә дә, Төркия, Көнчыгыш Германия, Испания, Италия, Польша, Франция, Финляндия, Чехословакия, Япониядәрдә дә сәяхәт кылып кайттылар. Кайберләре, мәсәлән, Р. Фәйзуллин, М. Галиев, М. Мәһдиев, М. Маликова, Ә. Рәшит сәяхәтнамәләр язды, күргән-белгәннәрен әдәбият сөючеләргә житкерде. Ә инде жәйләрен көньякның диңгез буйларында, кыш айларында Мәскәүгә һәм андагы нәшриятларга якын Ижат йортларында бер мәртәбә булса да ижат итеп ятмаган язучы бик сирәктер. Иң актив ижат итүче язучылардан Г.Бәширов, Ш.Маннур, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Гыйлажев, М. Мәһдиев кебекләр андый мөмкинлекне дә бик актив кулланалар—жәен дә, кышын да берәр-икешәр айлык юлламалар алырга тырышалар иде. Шуңа күрәдер, аларның ижат жимешләре дә мул булды.





*«Әдәби фонд»ның әгъзалык билеты.*

Әдәби фонд исәбенә тотылган Әдәбият институтында яки аның карамагында эшләүче ике еллык Әдәби курсларда белем алучыларыбыз саны да ишле генә. (Татарстан Литфонды эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат минем 2004 елда «Казан утлары» журналының 10нчы санында басылган «Әдәби фонд сәхифәләре»ндә китерелә.) Шуны да искәртеп үтик, алтмышынчы-житмешенче елларда ул әдәби курсларда укучы сакаллы шәкертләребезгә әдәби фонд тарафыннан түләнгән стипендия милли газета-журнал редакцияләрендә, нәшриятларда эшләүче гади редакторлар хезмәт хакыннан (110—130 сум) әллә ни аерылмый иде диярлек.

Сугыштан соңгы дәвердә ел саен оештырыла килгән әдәбият атналыклары, конференцияләр, әдәби-мәдәни арадашлык бәйрәмнәре дә шул чараларда катнашкан Литфонд оешмалары катнашыннан башка узмас иде.

## 2

Ижат кешеләре борын-борын заманнардан бирле үзара аралашып, киңәшләшеп, фикер алышып яшәргә күнеккән. Бер-беренә теләктәш тә, таяныч та булу—тормыш таләбе ул. Ижат кешеләре өчен исә үзара аралашып, фикер алышып, бер-береннең уңышы белән танышып, бер-береннән үрнәк алып яшәү—киләчәк уңышның нигезе саналырлык нәрсә. Мондый аралашулар аеруча каләм әһелләре өчен бик тә кирәк. Үз казанында гына кайнап зур уңышка ирешә алмыйсың ул.



*М. Горький К. Кәҗминең «Шобага» хикәясенә үз кулы белән язган бәяләмә. 1928 ел.*

20нче еллар ахырына табарак ук ижат кешеләре өчен бик файдалы булган шундый аралашулар оештырыла башлый. Иң әүвәл башкала язучылары, төркемнәргә берләшеп, әле Алтай тарафында төзелә башлаган Новокузнецк шәһәренә, әле Урта Азия белән Себерне тоташтыручы Турксиб тимер юлы төзелешенә сәяхәт кылалар. Яна төзелешләр, яңа тормыш турында ни-нәрсәләр һәм ничегрәк язасы турында фикер алыша, бәхәсләшәләр. Яңа оешкан милли республикалар тормыш-көнкүреше һәм халкы белән танышуга да зур әһәмият бирелә. Казанга да язучылар һәм журналистлар әледән-әле килеп торалар. Шулардан иң күренеклеләре, әлбәттә, шагыйрьләр Демьян Бедный, Владимир Маяковский (Казанда ике мәртәбә була), дөнья

күләмендә танылган сүз остасы Максим Горький. 1928 елда Казанга килгәндә Горький татар әдәбияты тагын да югарырак иҗади унышка ирешсен, үссен өчен башка милли әдәбиятлар вәкилләре белән ешрак аралашырга кирәклеген дә искәртә. Олы трибунадан әйтелгән бу киңәшне Татарстан хөкүмәте җитәкчеләре дә ишетә, әлбәттә. Һәм киләсе елда ук шундый бер зур чара уздыруны максат итеп куялар.

1929 елның август ае башы. Татар язучыларыннан ишле генә төркем Кавказ төбәге республикаларында, Кырымда һәм Украина Совет Республикасында яшәп иҗат итүче каләмдәшләре белән очрашу, фикер алышулар өчен юлга җыена. Төркемдә композитор Салих Сәйдәшев, артист һәм режиссер Шакир Шамильский, «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарыннан берәр вәкил дә бар. Делегация башлыгы Галимҗан Нигъмәти, юл чыгымнарына дип хөкүмәт тарафыннан бирелгән бик зур сумманы үз чемоданына салып куйган казначы Кәрим Тинчурин, язучылар Шәриф Камал, Гомәр Гали, Һади Такташ, Зариф Бәшири, Кави Нәҗми, Мөхәммәт Гали, Гадел Кутуй һ.б. 10 августта Идел буйлап Әстерхан тарафына төшеп китәләр. Кырык көн дәвамында аларны Махачкала, Баку, Тифлис, Батумида, Ялта, Симферополь һәм ул чорда Украина башкаласы булган Харьковта һәм Мәскәүдә күп санлы шау-шулы очрашулар, дустанә мәҗлесләр көтә.

Дагыстан Автономияле Республикасы башкаласы Махачкалада кунакларны хөкүмәт җитәкчеләре, лезгин халкының олуг шагыйре Сөләйман Стальский, авар шагыйре Гамзат Цадаса (булачак шагыйрь Рәсүл Гамзатовның атасы) һәм бу республикада яшәүче башка халыкларның мәгълүм язучылары каршы ала. Монда татар язучыларын иң гаҗәпләндергәне нәшрият эшчәнлегенә бәйле була. Һәр әсәр диярлек биредә берьюлы биш-алты телдә нәшер ителә икән. Кайвакыт шул җирлектә бәхәсләр дә тугалап ала икән. Мәсәлән, нишләп кумык язучысы Абдулла Мөхәммәдев әсәре биш кенә телгә тәрҗемә ителгән дә, лак милләте вәкиле Корбан Алиевнеке алты телдә чыккан дип... Ул чорда бу республикада балаларны алты милли телдә укытканнар.

Көн исәбе һәм очрашу-аралашулар саны буенча иң дәвамлы кунакчыллык Әзәрбайҗан Республикасы башкаласы Бакуга туры килә, билгеле. Россия патшалыгына буйсындырылган дәвердән бирле әзәриләрне (аларның күпчелеге үзләрен шулай дип таныта һәм кайберләре: «Без борынгы Хәзәр каһанлыгының төп халкы булганбыз», дип сөйли) «Кавказ татарлары» дип йөрттеләр. Димәк, Идел буе татарлары белән бу республика халкы үзен йөз ел чамалы бер дәвердә иң якын кардәшлек хисе белән танып яшәгән. Әдәбиятларыбызның борынгылыгы, Идел буе татарларының әзәрбайҗанлы Низами Гәнҗәви, Мирза Фатали Ахундов, Тукаебызның чордашы Сабир әсәрләре белән электән таныш булулары да бу якынлыкны арттыра төшкәндер, мөгаен. Россиягә сонрак кушылган бер өлкә буларак, аларны кулдан ычкындырмаска тырышу максатыннан, патша хөкүмәте XIX йөздә үк әзәрбайҗан телендә газета чыгаруга һәм театр уеннарын оештырырга рөхсәт биргән. Россия биләмәсендәге төрки телдәге икенче газета булган «Игенче» Бакуда 1875 елда борын төртә. Ә беренче андый газета 1870 елның апреленнән Ташкент каласында «Төркестан вилаяте гәҗите» исемендә ике атнага бер мәртәбә казакъ һәм шул ук тәртиптә үзбәк телендә басылган. Әзәри Фатали Ахундов—Россиядә төрки телдә иҗат итүче беренче драматург. Әзәрбайҗан телендә беренче театр уены тамашачыга 1873 елда күрсәтелә. XX гасыр башыннан әзәрбайҗан һәм татар халкы театр әһелләре һәм драматурглары бер-берсе белән аралашып, бер-берсенә ярдәмләшеп яшиләр. Язучылар сәфәренә бер ел алданрак кына, 1928 елда Галиәсгар Камал «Кызыл Татарстан» газетасында «Әзәрбайҗан драматургы Мирза Ф. Ахундов» мәкаләсен бастырган була. Бу хәбәр дә хуҗалар күңеленә бик хуш килә. Хәер, алар да кунакларны буш кул белән каршыламый. Шул ук 1928 елда Бакуда Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте аерым китап рәвешендә басылып чыга.

Шушы җирлектә Бакудагы очрашулар бик күңелле үтә. Шагыйрьләрдән Такташ, Кутуй, Кави Нәҗми, Демьян Фәтхи чыгышларын тамашачы аеруча үз күрә. Республика җитәкчелеге С. Сәйдәш карамагына бер оркестр билгели. Берничә көн дәвамында ул оркестр композиторның үзе иҗат иткән көйләрне вә халык көйләрен өйрәнә. Һәм ике мең тамашачы җыелган хушлашу кичәсендә сәхнәдән татар моңнары әсәрләндереп яңгырап тора.

Бу ике Каспий буе республикасы хуҗалары өчен ин олы кунак, әлбәттә инде, Шәриф Камал була. Яшьлегендә бит ул Баку тирәсендәге нефть чыгаручы промыселларда эшләүчеләр белән танышып йөргән, борынгы Дәрбәнт каласы белән Порт Петровский (хәзерге Махачкала) арасындагы бер бистәдә балыкчылар артелендә үз бәхетен эзләп караган. Шул җирлектә соңрак аның «Бәхет эзләгәндә» җыентыгына кергән хикәяләре, «Акчарлаклар» повесте языла.

Грузия башкаласы Тифлистә әдәбият сөючеләргә аеруча Такташ һәм шигырьләрен рус телендә дә мәгънәле итеп сөйләүче Кутуй ошыйлар. «Кунакларны каршы алып һәм озатып йөрүче язучылар төркеменнән Бесо Жгенти белән Такташ бик дуслашып киттеләр. Батумида без пароходка кереп киткәнче култыклашып йөрделәр», дип искә ала шул сәяхәттә катнашучы әдип Газиз Иделле...

Гадәттә андый аралашулардан соң, уртак хезмәт җимеше буларак, истәлек язмалары, тәрҗемә әсәрләр барлыкка килүчән. Татар язучыларының беренче зур сәяхәтеннән соң тормышка ашырылмый калган килешү-сөйләшүләр байтак була. Мәсәлән, драматурглар, театр җитәкчеләре белән очрашу барышында шул елларда сәхнәдән төшми уйналган «Сәвил» пьесасын (драматург Җәгъфәр Җаббарлы әсәре) Казанда, ә Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен Баку сәхнәсендә кую планлаштырыла. Ләкин ни сәбәптәндер бу хыял тормышка ашмый кала. Фәкать 40 елдан соң, 1969 елның май аенда Татарстанда «Әзәрбайҗан әдәбияты һәм сәнгате атналыгы» үткәрелүенә бәйле рәвештә, шул ук авторның «Айдын» пьесасы Казан сәхнәсенә күтәрелә алды. Ә Баку театрында Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» пьесасы һәм чак кына соңрак Шәриф Хөсәеневнең «Әни килде» әсәре сәхнәләштерелде. Соңрак елларда әзәрбайҗан теленнән тәрҗемә ителгән унлап китап та дөнья күрде. Шул җөмләдән, берничә шигырь тупламасы, «Әзәрбайҗан хикәяләре» җыентыгы, Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» романы. Татар халкының «өч көлтәгә бер көлтә» дигән әйтеменә туры килгәндәй, Совет хакимияте дәверендә Әзәрбайҗанда чыккан китапларыбыз өчләтә-дүртләтә артыграк булса кирәк. Алар арасында Г. Тукай белән М. Җәлилнең шигырь җыентыклары, Г. Бәшировның «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, берничә күмәк проза һәм шигырь җыентыклары бар. Грузин әдәбиятыннан татарчага беренче тәрҗемә китап 1931 елда чыга. Ул Д. Чонкадзенең «Сурам крепосте» повесте. 1936да бездә «Таулар бөркете Камо» әсәре, ә 1939да Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресен ябынган батыр» дастаны тәрҗемә ителә.

Совет хакимияте чорында украин теленнән тәрҗемә ителгән китаплар саны кырыктан ашкан. 1929 елда Харьковта Татарстан кунакларын ике Иван—Кулик белән Микитенко озатып йөриләр. Безнең язучылар Украина җиреннән күтәрелеп чыккан Н.В.Гогольның байтак әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителүен, пьесаларының кат-кат сәхнәләштерелгән булуын сөйлиләр. Т. Шевченконың да кайбер әсәрләренең татарча чыгуын, Г. Ибраһимовның 1914 елда ук аның турында «Каһарман шагыйрь» мәкаләсен язып бастыруын әйтәләр. Һәм шул чакта: «Украиннардан кем татар турында язды яки нәрсә дә булса тәрҗемә итте икән?», дигән сорау да бирелә. Бу сорау әле дә сорау булып кала шикелле. Бу очракта «өч көлтәгә бер көлтә» әйтеме безнең файдага булса кирәк. Дөрес, Украинаның бөек тарихчысы Михайло Грушевский үзенең унөч томлык хезмәтендә байтак урында татарларга карата унай фикерен белдергән, украин халкының бер өлешенең саф кыпчак кавеменнән булуын раслап язган диләр. Совет хакимияте дәверендә, бигрәк тә утызынчы еллардан соң аның хезмәтләренә әһәмият бирелмәде, аны тарих фәнендә телгә алу тыелган иде диярлек. Ә 1926 елгы халык санын алу документларында шул чордагы республика чикләренә кергән халкының дүрттән бер өлеше чамасының үзен «по национальности половец, по языку украинец» дип язганлыгын искә алучылар бар. 1966 елда Киев янәшәсендәге Иҗат йортында ял иткәндә Мәхмүт Хөсәен белән мина шул хакта тарихи эчтәлекле әдәби әсәрләр авторы Василь Земляк белән кинорежиссер Владимир Денисенко да сөйләгәннәр иде. Ул вакытта алар Киевнең борынгы тарихына багышланган кино әзерлиләр, язма хәбәрләргә нигезләнеп, Батый ханның бер-ике кыш шул шәһәрдә яшәү мизгелләрен дә чагылдырырга ниятлиләр иде.

1929 елгы сәяхәттән соң украинчадан тәрҗемә ителгән беренче китаплар:

И.Микитенконың «Намус эше» пьесасы (1932), И.Куликның «Ундуртенче трубка»сы һәм А.Корнейчукның «Эскадра һәлакәте» (икесе дә 1935 елда чыга), Т. Шевченконың шигырь һәм «Кобзарь» дигән поэма җыентыклары (1939,1953). Сугыштан соңгы күләмле тәрҗемәләр арасында О. Гончарның «Байрак йөртүчеләр» романы (1951, Ә. Еники тәрҗ.), С. Ковпакның «Путивльдән Карпатка кадәр» дигән документаль әсәре (1948), И. Франконың хикәяләре һәм пьесасы (өч китап, 1951, 1955, 1958), сугыш елларында Татарстанда эвакуациядә яшәгән Л. Коваленконың «Кәләш» повесте (1985) бар.



*Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына китәр алдыннан. Сулдан уңга: Г. Әпсәләмов, А. Шамов, Г. Халит, Н. Гыйззәтуллин.*

Мәскәүдә дә Татарстан кунакларын бик җылы каршы алалар. Андагы очрашуларга шул елларда башкалада яшәүче Шамил Усманов, Афзал Шамов, Фатих Кәрими, Мәхмүд Максуд, Мәхмүд Галәү һ. б. кушыла. “Правда”, «Известия», «Литературная газета»ларда очрашу-аралашу вакыйгаларын чагылдырган мәкаләләр басыла. Гадел Кутуй белән «Кызыл Татарстан» журналисты Закир Гали дә башкала газеталарында шушы зур сәяхәткә бәйле хәбәрләр урнаштыралар. Язучылар йортында А. Фадеев, Ф. Гладков, И. Сельвинский кебек шул елларның күренекле язучылары белән һәм Галимнәр йортында Максим Горький белән очрашулар уздырыла. Шул елларның күренекле дәүләт һәм нәшрият эшлеклесе, М. Горькийның якын фикердәше Артемий Халатов кунакларны үзе җитәкләгән «Госиздат» нәшриятына да чакырып китерә. Шушы очрашуларның барысында да диярлек тәрҗемә мәсьәләләре зурдан күтәрелә. М. Горький, А. Фадеев, А. Халатов һ. б. үз чыгышларында татар әдәбиятын кичекмәстән рус теленә тәрҗемә итә башларга кирәклеге турында сөйлиләр. Тәрҗемә эшләрен оештырып җибәрүче комиссия төзү кирәклеге әйтелә. Дәүләт нәшриятында беренче чиратта Г. Ибраһимов әсәрләрен тәрҗемә итеп чыгара башларга тиешлеге турында җитди сүз була. Һәм озакламый ул сөйләшүләрнең нәтиҗәсе дә күренә. Классик әдибебезнең «Казакъ кызы» романы 1934 елда (тәрҗемәнең беренче вариантын автор кире какканнан соң ел-ел ярымнарга сонлап) дөнья күрә. Шушы очрашулар нәтиҗәсендә «Гослитиздат»та татарча берничә китап нәшер итә. Мәсәлән, Ә. Ерикәйнең «Шигырьләр» җыентыгын.

Мәскәүдә милли әдәбиятлар үрнәкләрен нәшер итү өчен оештырылган Үзәк нәшрият (Центриздат) бу елларда бик актив эшли. 1924-1933 елларда биредә алтмыш-җитмешләп татар китабы, шул исәптән Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (1924), Ш. Усмановның «Памирдан радио» әсәре һәм хикәяләр җыентыгы, К. Нәҗминең «Яр буенда учаклар»ы һ. б. әсәрләре, Һ. Такташның бер поэмасы, Ф. Бурнашның дүрт пьесасы аерым-аерым рәвештә, А. Шамовның «Рәүфә»се, Ш. Маннурның өч, М. Җәлил, Ә. Ерикәйләрнең берәр шигырь җыентыклары, Г. Нигъмәтинең 5-6 китабы һ.б. нәшер ителә. Шушы ук нәшриятта русчадан һ. б. телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар да дөнья күргән. Мәсәлән, Федор Гладковның ул елларда бик популяр булган «Цемент» (1928), «Энергия»(1933) романнары Афзал Шамов тәрҗемәсендә чыкканнар.

## 3

Татар язучыларының күмәкләп беренче тапкыр ил буйлап сәяхәт кылуына, шул очрашу-күрешүләрдән соң нindирәк нәтиҗәле эшләр башкарылуына озаграк тукталдык. Чөнки шуннан соң андый аралашу мөмкинлекләре утыз елга

кичектерелеп торачак. Әүвәл милли әдәбият вә сәнгать вәкилләрен эзәрлекләү, иң алдынгы сафта атлаучыларын күпләп юк итү чоры һәм шуннан соң ук Бөек Ватан сугышы фаҗигаләре башланып китә. Репрессияләр чорында юк ителгән иң күренекле берничә әдипнең исемен дә атап үтик: Г.Ибраһимов, Ф.Кәрими, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, Г.Гали һәм тагын бик күпләр. Сугыш башлангач яу кырына киткән һәм иленә кире әйләнеп кайтмаган язучыларыбыз исемлегендә дә утызлап фамилия теркәлгән. Шул исәптән М.Җәлил, Г.Кутуй, А.Алиш, Ф.Кәрим, Н.Баян, М.Крыймов...

Кабат җанлана башлаган аралашу чараларның иң зурысы, әлбәттә, 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате ункөнлеге (декадасы) булды. Бу иҗат бәйрәмендә бик күп артистлар, музыкантлар, рәссамнар катнаша. Язучылар төркеме дә бик ишле була. Янарак кына сөргеннән кайткан шагыйрь Хәсән Туфан да башкаладагы бәйрәмгә барырга лаеклы дип табыла. Артист, музыкантларның күпчелеге, шундагы зур-зур залларда үз осталыкларын күрсәтеп, дан-шөһрәт казаналар, шанлы исемнәр, бүләкләр алалар. Хәлил Әбҗәлиловка исә СССРның халык артисты исеме бирелә. Татарстанда эшләүче татар артистларыннан берәүнең дә мондый олы исемне алганы булмый әле. Язучылар өчен төп бүләк—Декадага әзерлек алдыннан нәшер ителгән яңа китаплар, бәйрәм көннәрендә күрсәтелергә дип сайланган сәхнә әсәрләре булгандыр, мөгаен. Беренче мәртәбә татар һәм рус телләрендә басылып чыккан зур күләмле «Татар поэзиясе антологиясе» һәм татар язучыларының биографиясен һәм әсәрләре исемлеген теркәгән китаплар да ямь өстенә ямь була.

Шушы зур вакыйгадан соң Татарстан язучылары Идел—Урал буе республикаларында яшәүче каләмдәшләре һәм әдәбият сөючеләре белән дә берничә Атналык оештыралар. Башкортстан, Чуашстан һәм Мари-Эль автономияле республикалары вәкилләре дә Казанда, Әлмәттә һәм кайбер районнарда булып китәләр. Күмәк әдәби җыентыклар, аерым авторларның тәрҗемә ителгән әсәрләре бер-бер артлы шушы автономияләр нәшриятларында дөнья күрә. Күрше республикаларда яшәгән классик әдипләрнең иҗатларын алмашып тәрҗемә итеп бастыру эше дә җанланып китә. Шул рәвешле чуаш К. Ивановның күләмле «Нарспи» поэмасы—Казанда, Г. Тукай әсәрләренең шагыйрь Я. Ухсай тарафыннан тәрҗемә ителгән китабы Чабаксарда нәшер ителә. Татар-башкорт әдәбиятлары вәкилләре арадашлыгының иң югары баскычка күтәрелгән чоры, мөгаен, нәкъ шушы илленче еллар ахыры белән алтмышынчы елларга туры киләдер. Бу дәвердә үзара тәрҗемә итешеп чыгарылган китаплар исемлеге дә шактый зур. Шулардан фәкать бер китапны—элеккеге «халык дошманы» Х. Туфанның сөргеннән соң башка телдә тәүге тапкыр басылган «Йөрәк дәфтәрдәреннән» дип исемләнгән шигырь җыентыгын (Уфа, 1960) атыйм. Башкорт кардәшләребезнең бу мактаулы хезмәте әлегә бездә беркайда да теркәлмәгән, 1986 елда чыккан кирпеч калынлыгы «Совет Татарстаны язучылары» белешмәлегенә дә кермәгән.

Башкортлардан кала иң җылы кардәшлек мөнәсәбәтләре, минемчә, татар-казакъ әдәби бәйләнешләре җирлегендәдер. Безнең ата-бабалар элек-электән казакъ халкы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Ике халыкка да хезмәт иткән әдәбият-сәнгать әһелләребез дә ишле: журналистлар, җырчылар, акын-шагыйрьләребез... Төркестан генерал-губернаторының җирле милләт вәкилләре белән эш итүче ярдәмчесе Шаһимәрдән Ибраһимов, мәсәлән, 1870 елда казакъ һәм үзбәк телләрендә беренче газета чыгаруны оештыра, шунда кардәш «нугай» ("татар" дип укы), казакъ һ.б. халыкларга багышлы хезмәтләрен бастыра. 1881 елдан аның эшен «нугай морза» Хөсәен Чанышев дәвам иттерә. Шагыйрь Акмулла иҗаты да кардәш халыкларны берләштерүгә юнәлтелгән. Укымышлы яшьләребез дә казакъ илен үз иткән. Аның шулай икәнлеген без классик әдипләребезнең—Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Сәйфи Кудаш һ.б.ларның биографиясен укып та беләбез.

1960 еллар башында Урта Азия республикаларында Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре оештырыла. Иң башлап зур бер делегация Казакъстан Союздаш Республикасы башкаласы Алма-Атага юнәлә. Казакъ илендә туып-үскән күренекле шагыйрь Нури Арсланов хәтерләвенчә, Свердловскидан Алма-Атага баручы поезд

«тулаем безнекеләрне генә төяп бара». Казакъ иленә килеп кергәч тә һәр зур станциядә кунакларны бәйрәмчә киенгән-жыенган халык каршы ала. Очрашу митинглары оештырыла. «Хуш килденез, бавырлар-карындашлар!»—дигән сүзләр янгырап тора. Татарлардан ул очрашуларның иң түрендә аксакал язучылар һәм Мәхмүт Хөсәен булганлыгы күпләрнең хәтерендә калган. Трибунадан татарчага казакъ сүзләрен мул кушып ялкынлы нотыклар һәм шигырьләр сөйләүче «якташ шагыйрь»не җирле халык та үз итеп, алкышлап кабул итә торган була.

Казакъстанда язучылар күпсанлы очрашу, сөйләшүләрдә катнаша, зур-зур мәҗлес-банкетларда да була. Аерым затлар иш-дус тарафыннан чакырылып, кунак-кунак уйнап та алгалыйлар. Шунда булган кешеләр тагын бер вакыйганы еш искә төшерәләр иде. Ул вакытта Казакъстан Язучылар берлегенең җитәкчесе, бәге Сабит Моканов була. Тумышы белән казакъ иленең төньягындагы Петропавел төбәгеннән. Татар шагыйрьләре Н.Арслан белән М.Хөсәеннәрнең якташы. Хатыны Мәрьям дә шул төбәк кызы, яшьли татарлар белән аралашып үскән. С.Моканов берара Оренбургта, «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә барлыкка килгән рабфакта белем алган. Ягьни икесе дә татар мохитен яхшы белә. Әдипнең вафатыннан соң зур фатирында оештырылган музеенда булганым бар. Китап киштәсендә татар китаплары да байтак иде. Карандаш белән билгеләр куеп, сүз-җөмләләр теркәп укылган шундый берничә китапны актарып та карадым. Мохтар Әуэзов музей-йортында да шундый ук хәл: эш бүлмәсендәге китап киштәсендә татар китаплары күп, диварларга эленгән фотолардан таныш йөзләр дә карап тора.

Инде әлеге вакыйгага кайтык. Зур мәҗлес-банкетларда түр өстәлнең уртасында ирле-хатынлы Мокановлар, алар тирәсендә ике республика җитәкчеләре һәм төрле дәрәҗәдәге түрәләр. Бу мәҗлесләрне искә алучылар хәтерләвенчә, шундый утырышларның берсе тәмамланырга якынлашып килгәндә юкарак гәүдәле, кечерәк буйлы Сәрвәр Әдһәмова, кемнән дә булса рөхсәт-фәлән сорамыйча торып баса да, бар куәтенә казакъның бер моңлы көен җырлап җибәрә. Халык тын калып тынлый, аннары бик озаклап кул чабалар. Һәм, кул чабулар тынып өлгермәстән, түр өстәл тарафыннан татар җыры яңгырый—Мәрьям бикә җырлый. Әлбәттә, янә озаклап кул чабалар. Һәм бу хәл ул кичтә дә, шуннан соңгы кичәләрдә дә кабатлана әле. Ике кардәш халыкның элекке вакытларда никадәр якын булганлыгына тагын бер дәлил ич бу!


Татар әдәбиятын рус әдәбиятыннан кала мул итеп тәрҗемә кылучылар да казакъ кардәшләребез була. Сугыштан соңгы чорда ул республика нәшриятлары ел саен кимендә ике-өч татар китабын бастырып чыгарды. Театрларында да безнең авторларның пьесалары еш сәхнәләштерелде. Бездә исә шул дәвердә егерме бишләп күләмле әсәр тәрҗемә итеп бастырылды. Революциягә кадәр бу өлкәдә өстенлек безнең якта була. XIX гасыр урталарыннан иҗат итә башлаган казакъ әдәбияты классигы Абай Конанбаевның икенче шигырь җыентыгы 1916 елда Оренбургта Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә, 1922 елда Казанда басылган. Шигырь-поэмаларының тулырак татарча җыентыклары 1947 елда М.Максуд тәрҗемәсендә һәм 1981 елда күмәк тәрҗемәдә басылып чыктылар. Казакъның беренче романы «Бәхетсез Җамал» (авторы М.Дулатов) 1910 елда Казанда, беренче повесте «Күргенде (тәрбияле) бала» (авторы М.Нурбаев) Оренбургта «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргән. «Вакыт» басмаханәсе ул елларда казакъча 8 китап бастыра, дип хәбәр итә академик Ә.Кәримуллин. М.Дулатовның Казакъ илендә зур абруй казанган, дөресрәге, ул илне дер селкеткән «Уян, казакъ» дип исемләнгән шигырь җыентыгы да 1909 елда Казанда басылган. Узган гасыр башында «Яшь казакъ» хәрәкәтен оештырган, түнтәрешләрдән соң беренче Казакъ Совет автономиясенең җитәкчеләреннән берсе булган Сакен Сәйфуллинның тәүге шигырь җыентыгы да 1914 елда Казанда дөнья күрә.

Бер елдан соң Казакъ әдәбияты һәм сәнгате көннәре Татарстанда уздырылды. Шул вакыйгага багышлап Казанда «Дала җыры» исемендә күмәк җыентык нәшер ителде (1964). Казакъ язучылары белән очрашулар республиканың төрле районнарында да үткәрелде. Соңыннан, татар әдипләре белән бер очрашу вакытында Олжас Сөләйманов Шәле авылының җәйләвендә булуларын искә алып сөйләгән иде. Җәйге матур төннең бер өлешен алар шунда Хәсән Туфан белән гәпләшеп

уздырганнар икән.

60нчы еллар белән 80нче еллар арасында Татарстанда бик тантаналы рәвештә Әзәрбайжан республикасы(1969), Кыргызстан(1972), Украина республикасының Донецк өлкәсе (1972), Каракалпакстан автономиясе (1981) әдәбияты һәм сәнгате көннәре, Совет әдәбияты атналыгы (1979), Идел буе өлкә һәм республикаларында Максим Горький иҗатына багышланган очрашулар (1978) уздырылды. Шул ук елларда безнең язучылар һәм сәнгать әһелләре Кыргызстанда, Донбасс шәһәрләрендә (1972), Каракалпакстанда (1979) булып кайттылар. Каракалпакстан язучылары белән арадашлык вакыйгаларына багышлап Ташкентта һәм Нөкистә татар хикәяләре тупламалары (1979), Казанда исә күләмле «Арал дулкыннары» әдәбият антологиясе (1981) нәшер ителде.

1976 елның декабрендә бер атна дәвамында Казанда бер төркем чит ил язучылары булып китте. Венгрия, Көнчыгыш Германия, Монголия, Норвегия, Төркия, Финляндия, Чехословакия, Швеция вәкилләре. Килүчеләрнең төп максаты—татар әдәбияты үрнәкләрен чит илләрдә бастырып чыгару һәм пропагандалау хакында фикер алышу иде. Бу очрашуны СССР Язучылар берлегендә тәрҗемә әдәбият мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бюро оештырды. Чит ил язучылары белән бергә Казанга шул бюроның җитәкчесе шагыйрь Вил Ганиев, СССР һәм РСФСР Язучылар берлегендә төрле республикалардагы әдәби оешмалар белән элемтә тотучы вәкилләр дә килде. Кунакларның тулы исемлеге һәм эш тәртибе язмалары миндә сакланган. Венгрия, Норвегия, Финляндия һәм Төркиядән килүче язучыларның нияте зурдан булуы, татар әдәбиятын үз илләрендә пропагандалауга чынлап керешәчәкләре аларның бәйләм-бәйләм татар китапларын, татар җырмоннары язылган пластинкаларны сорап һәм сатып алуларыннан билгеле иде. Чынлап та, тиздән Венгриядә татар әдәбияты белән кызыксынуның нәтиҗәләре күренә башлады. Язучылар берлегенә татар повестьларыннан һәм хикәяләреннән торган җыентык туплап җибәрүне үтенгән хат та килде. Венгр телен өйрәнеп, венгр һәм татар әдәбиятын тәрҗемә итәргә сәләтле булган берәүне укырга җибәрү мәсьәләсе дә хәл ителде. Бу җитди вазифа Равил Бохараевка йөкләнде.




*Тәрҗемә мәсьәләләре буенча Казанда үткән киңәшмәгә кагылышлы документның фрагменты.*

1980 елларның икенче яртысыннан башлап СССРда әдәбият вәкилләренең арадашлык хезмәтчәнлегә сүлпәнәя төште һәм озакламыйча ул эшчәнлек бөтенләй туктатылды.

Әдәбиятлар дуслыгы бәйрәмнәре, үзара аралашу, фикер алышу чаралары зурлап уздырылган елларда татар язучыларыннан Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Туфан Миннуллин, Рафаэль Мостафин кебек шәхесләребез ул чараларда бик актив катнаштылар. Көн баешындагы Киев, Минск, Калининградлардан башлап, Ерак Көнчыгыштагы Камчатка, Сахалиннарда яшәүче күпсанлы милләттәшләребезне урыннарда күреп, алар белән аралашкан, Татарстан хәбәрен ирештергән шәхесләр дә шулар булды. Шул хакта аларның байтак кына истәлек язмалары соңрак үзебезнең матбугат битләрендә дөнья күрде.

Якын киләчәктә дә бер-беребез белән шулай күрешеп, уртак уңышлар өчен бергәләп сөенешеп яшәргә насыйп булсын иде.

## Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия лауреатлары:

Батуллин Рабит Мөхлис улы **(1991)**
Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы **(1992)**
Әхмәтжанов Рәшит Хәниф улы **(1993)**
Бәширов Гомәр Бәшир улы **(1993)**
Еникиев Әмирхан Нигъмәтҗан улы **(1993)**
Рәшитов Әхмәт Әхәт улы **(1993)**
Даутов Рәис Нәүширван улы **(1993)**
Нәҗметдинов Нажар Нәҗметдин улы **(1994)**
Хисмәтуллин Рәхмәтулла Хисмәтулла улы **(1994)**
Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы **(1995)**
Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы **(1995)**
Имамов Вахит Шәех улы **(1995)**
Галиуллин Тәлгат Нәбиулла улы **(1997)**
Кәрамиев Рәфкать Кәраметдин улы **(1998)**
Сафин Факил Миннемөхәммәт улы **(1998)**
Моратов Газинур Васик улы **(2000)**
Бәйрәмова Фәүзия Әүхәди кызы **(2001)**
Сәгыйров Гакыйль Шәрифулла улы **(2001)**
Хуҗин Рафаэль Шәйхуҗа улы **(2002)**
Хәлимов Борис Нәҗметдин улы **(2003)**
Юнысов Рәфикъ Юныс улы **(2004)**
Миннегулов Хатыйп Йосыф улы **(2005)**
Салихов Данил Хәбибрахман улы **(2005)**
Зәйнуллин Зәки Лотфулла улы **(2006)**
Тимергалин Адлер Камил улы **(2006)**
Фәйзуллин Рөстәм Габдрахман улы **(2007)**
Хөснетдинов Зиннур Зыятдин улы **(2008)**
Гайнанова Лена Рәшит кызы **(2008)**
Закиров Шамил Зиннур улы **(2008)**
Әюпов Харрас Гыйльмегали улы **(2008)**
Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы **(2009)**

## Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреатлары:

Галиев Шәукәт Гали улы **(1996)**
Ихсанова Ләбибә Фәиз кызы **(1996)**
Миннуллин Роберт Мөгаллим улы **(1997)**
Мингалимов Рөстәм Гали улы **(1997)**
Халиков Хәкимҗан Шәяхмәт улы **(1998)**

Балалар һәм үсмерләр өчен чыгучы «Сабантуй» газетасы **(1999)**
Бәшәров Рәшит Гафар улы (Рәшит Бәшәр) **(2000)**
Леронов Лемон Лерон улы (Ләбиб Лерон) **(2000)**
Дәрзаманов Җәүдәт Харис улы (Җәүдәт Дәрзаман) **(2001)**
Хафизова Роза Сәет кызы **(2002)**
Гыйльманов Галимҗан Хәмитьян улы **(2002 )**
Сөнкишева Илсөяр Гали кызы **(2003)**
Корбанов Рафис Харис улы **(2003)**
Фәйзуллина (Тәржеманова) Мәрзия Низам кызы **(2004)**
Шәрәпова (Җамалетдинова) Йолдыз Әдип кызы **(2004)**
Татарстан Республикасының «Мәгариф» милли нәшрияты (директоры Мөдәррис Вәлиев) **(2004)**
Хәсәнов Әнәс Хәсән улы **(2003)**
Мөэминова Энже Илалетдин кызы **(2005)**
«Салават күпере» журналы **(2005)**
Рахмани Равил Фәйзрахман улы (Равил Рахмани) **(2006)**
«Ялкын» журналы **(2006)**
Татарстан китап нәшрияты **(2006)**
Гыймадиев Алмаз Марс улы **(2007)**
Нуриев Вакыйф Вәкил улы **(2008)**
«Әкият» татар дәүләт курчак театры **(2008)**

## Фатих Хөсни исемендәге әдәби премия лауреатлары:

Хуҗин Мәгъсүм Хәмит улы **(1997)**
Шәмсетдинов Солтан Сәләх улы **(2000)**
Гыйматдинова Нәбирә Миннәхмәт кызы **(2001)**
Фәизов Радик Хәбибрахман улы **(2001)**
Хөснетдинов Зиннур Зыятдин улы **(2002)**
Газизов Рафаил Шәкүр улы **(2003)**
Кәримов Камил Әдһәм улы **(2004)**
Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы **(2005)**
Леронов Лемон Лерон улы **(2006)**
Әмирханов Марат Әмирхан улы **(2007)**
Гаффаров Габделәхәт Габдрахман улы **(2008)**
Сәетбатталов Фәнзаман Сәетбаттал улы **(2009)**

## Һади Такташ исемендәге әдәби премия лауреатлары:

Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы **(2005)**
Гыйләҗев Илдус Сабир улы **(2007)**
Шакирҗанова Лена Галимҗан кызы **(2007)**
Маннапов Шамил Мәгыйз улы **(2008)**
Низамиев Рашат Мияссар улы **(2009)**

## Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреатлары:

Вәлиев Мансур Хажи улы **(2001)**
Сверигин Рифат Хәсән улы **(2002)**
Хафизов Сәгыйть Хәбибулла улы **(2003)**
Шәрәфиев Рәфыйк Кәләметдин улы **(2004)**
Галимуллин Фоат Галимулла улы **(2005)**
Заһидуллина Дания Фатыйх кызы **(2006)**
Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы **(2007)**
Хатыйпов Фәрит Миргалим улы **(2007)**
Хәйруллин Әнвәр Нәҗип улы **(2008)**
Гыймранова Дания Әхәт кызы **(2009)**

## Лауреаты литературной премии им. Г. Державина:

Владимир Владимирович Корчагин **(2000)**
Сергей Владимирович Малышев **(2001)**
Ахат Хаевич Мушинский **(2002)**
Лилия Ривкатовна Газизова **(2003)**
Лев Афанасьевич Кожевников **(2004)**
Николай Петрович Алешков **(2005)**
Салават Ильдарович Юзеев **(2006)**
Владимир Николаевич Лавришко **(2006)**
Николай Николаевич Беляев **(2007)**
Ольга Георгиевна Левадная **(2007)**
Рустем Раисович Сабиров **(2008)**
Геннадий Николаевич Капранов **(2008)**
Рустем Адельшевич Кутуев **(2009)**



Фәридә
Хәсәнова

# ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ:
# ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

XXI гасыр әле тугызынчы елын гына түгәрәкләп килсә дә, тарихыбызда зурдан алып әйтерлек олы вакыйгалар күзәтелде. Әйтик, 2004 елда Казан дәүләт университетының 200 еллыгы, 2005 елда башкалабыз Казанның 1000 еллыгы, 2006 елны Президент М.Шәймиевнең «Әдәбият һәм сәнгать елы» дип игълан итүе, шул ук елда татар әдәбиятының көзгесе булган «Казан утлары» журналының 1000 нче саны чыгу, халык шагыйре Р. Харисның Россия Дәүләт премиясенә лаек булуы, Тукай һәм Җәлилләрнең түгәрәк даталары һ. б. лар. Яңа гасыр башы шулай ук исән классикларыбызның күптомлыклары чыгу белән дә хәтергә уелып калыр. Шулай ук татар шагыйрьләрен рус, инглиз, төрек телләренә тәрҗемә итүнең активлашуын да хупларга кирәк.

XX гасыр ахырында илдә барган зур үзгәрешләр әдәбият дөньясын да битараф калдырмады. Тарихтан билгеле, илкүләм реформалардан соң татар иҗтимагый фикере һәм әдәбияты дөньясында янару билгеләре барлыкка килә торган булган. Нәкъ менә шундый чорда әдәби телне халыкка якынайту, поэтикада яңа формалар эзли башлау сизелгән. Ә инде XIX гасырда Россиядә барган икътисади һәм сәяси сәбәпләр матур әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре китереп чыгарган, татар әдәбиятының янарыш әдәбияты буларак формалашуына сәбәпче булган. Татар халкының, милләт буларак формалашу чорын кичереп, сәяси хокуклар өчен көрәше алгы планга чыккан чор бу. Халык тормышына, аның проблемаларына якынаю XX йөз башы реалистик татар әдәбиятының да зур казанышы санала.

Ә менә XXI гасыр башындагы татар шигыре күптән узган чорлардагыдан аерыламы? Анда яңа сыйфат үзгәрешләре күзәтеләме? 1934 елда оешкан Язучылар берлеге белән шагыйрьләрнең поэтик осталыгы арасында бәйләнеш бармы?

Совет язучыларының Беренче бөтентатарстан съездын 1934 елның 25 июлендә кереш сүз белән К. Нәҗми ача. «Бу съездда кабул ителгән Устав ким дигәндә ярты гасыр кагылгысыз булды»,—дип яза халык шагыйре Р. Фәйзуллин «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» исемле китабында (Идел-Пресс, 2004). Бу тарихи вакыйгадан соң татар язучылары җиң сызганып эшкә тотына. Әмма өч-дүрт елдан Зур съездда мактап телгә алынган язучыларның яртысыннан күбрәге репрессия корбаннарына әверелә. Бу чор шагыйрьләре, актив рәвештә иҗат итү белән бергә, әдәбият белеме, тәнкыйть өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли. Һ. Такташ, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Бурнаш, Ш. Маннур, Ф. Кәримнәрнең шул чор әдәбиятын өйрәнү һәм үстерүдә әһәмиятле роль уйнавы билгеле. 30нчы елларда тормышта үзе күргәнне, үзе кичергәнне иҗат иткән М. Гафури хезмәт кешесен, идеалга омтылган көрәшче образын сурәтләве белән аерылып тора. 20-30нчы елларда күп кенә яшь шагыйрьләр, классик стильне искергәнгә санап, яңа шигырь тудыруны максат итеп куялар һәм төрле юнәлештә тәҗрибәләр ясарга керешәләр. Шул рәвешле, имажинизм,

футуризм, символизм, конструктивизм һ.б.ш. исемле «тәҗрибәләр» классик стильне кире кагуга юнәлтелә. М. Гафури ачык һәм гади язуын дәвам итсә, К. Нәҗми, Х. Туфан, Д. Фәтхиләр катлауландыру принцибын алга сөрәләр. Утызынчы еллар шигърияте көндәлек тормыш күренешләрен, социалистик төзелешне сурәтли башлый. Бу елларда шагыйрьнең тормыштагы урыны мәсьәләсе яңача куела, шагыйрь төзелешләрдә, колхоз кырларында булырга тиеш дигән фикер урнаша. Ф. Кәрим, Бондюг химия заводында командировкада булып, «Жиденче мич» поэмасын яза. Ш. Маннур да, хезмәт батырлыгын мактап, «Бетончылар җыры» кебек әсәрләр иҗат итә башлый. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Баттал, Г. Кутуй, Ә. Исхак кебек шагыйрьләр авыл тормышы, эшчеләр язмышы, интернациональ дуслык турында әсәрләр иҗат итәләр. Бу чорда, «көн кадагына суга торгач», кайбер шигъри әсәрләр чын публицистикага да охшап кала. Бер төркем шагыйрьләр—аерым алганда, Г. Кутуй, С. Урайский—табигатьне җиңгән кешеләр турында, фәнни күзәтүләр тулы шигырьләр иҗат итә. Икенче бер төркем шагыйрьләр, аерым алганда Х. Туфан, халык тормышына якыная барып, шәхеснең рухи дөньясына тирәнрәк үтеп керә һәм шигырьдә җитди адымнарын ясый. Утызынчы елларда Ә. Фәйзи татар поэзиясен сәнгатьчә камил поэма һәм балладалары, нәфис парчалары, җырлары белән баета, «Флейталар» поэмасы белән иҗат казанышы ясый. Ә. Ерикәйнең кеше хисләрен бөтен тулылыгы белән сурәтли торган яшьлек, мәхәббәт, тормыш-көнкүреш турындагы шигырьләре языла. Ш. Маннурның кеше характерын психологик тирәнлектә ачып биргән «Гайҗан бабай» кебек поэмалары иҗат ителә.

Сугыш еллары татар әдәбиятына зур югалтулар алып килә. Репрессия елларыннан соңгы югалтуларга яңалары өстәлә. Язучы Ш. Мостафинның эзләнү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, 104 татар язучысының 31е корбан була. Исән кайтканнарының да шактые сугышта алган яраларыннан иртә дөнья куя. Сугыш чорында поэзиянең сурәтләү объекты үзгәрә. Үзәккә тормышчан һәм гаять кискен конфликт куела. Ф. Кәрим әйткәнчә, «үзең турында уйлама, илең турында уйла» дип фикер йөрткән каһарманның патриотик хисләре әсәрләрдә еш гәүдәләндерелә. Бу еллар шигъриятендә ант темасы, көрәшче-җыр, дошманга каршы көрәшкә күтәрелгән шагыйрь образлары өстенлек ала. Мәскәү, Ленин образлары да тәэсирле сурәтләнә. Солдат образын күпьяклы һәм җанлы итеп гәүдәләндерү тенденциясе көчәя. Ш. Мөдәррис, С. Хәким, Ә. Ерикәй, Б. Рәхмәт, Ш. Маннур, Ә. Исхак шигырьләрендә лирик герой, аның кешегә, батыр сугышчыга соклануы үзәккә куела. Җиңү көннәре якынлашканда, яз, кояш, азатлык образлары активлашып, шигырьләрнең публицистик пафосы көчәя, шатлык тойгысын гәүдәләндерүгә якынлашкан үзенчәлекле стиль барлыкка килә. Ә. Исхак, Н. Арсланов, З. Мансур, Ш. Маннур, Н. Баян кебек шагыйрьләр сугыш фаҗигасе белән бергә тирән хисле, моңлы лирик әсәрләр дә язалар. Баллада, шигъри очерк һәм поэма кебек жанрлар җанлана.

Сугыш елларында язылган поэмаларны этаплап тикшерсән, сугышның беренче көннәрендә язылган поэмалар белән сугыш ахырында язылганнары арасында аерма күренә. Ш. Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап» поэмасы сугыш чоры поэмаларының уңышлы үрнәге санала. Билгеле, бу жанрда, солдат батырлыгын сурәтләгән эпизодлар белән бергә, сугышчының психологиясен ачып биргән Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун», С. Батталның «Тын диңгез ярларында» кебек поэмалары да иҗат ителә. М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклы соңрак сугыш китереп чыгарган фаҗигале язмышларны документаль чыганакларга караганда да төгәлрәк һәм тулырак сөйләп биргән әсәрләр дип таныла, дөньякүләм югары бәя ала.

Ә Бөек Ватан сугышыннан соң шагыйрьләргә яңа бурычлар йөкләнә. Сугыш вакыйгаларына икенчерәк биеклектән карау, батырлыкны әдәби яктан күркәмрәк, сәнгатьчә нәфисрәк, тәэсирлерәк җанландыру сорала башлый. Поэзиядә бөек төзелешләр, «кара алтын» чыгаручылар, колхозда югары уңыш җыючылар турында күп кенә шигырьләр языла. Бу елларда поэзиядә тантаналы рух, оптимизм өстенлек итә башлый. Әдәбиятка нефтькә багышланган яңа тематика килеп керә. Бу яңалыкка С. Хәким, Н. Арсланов, Ш. Маннур һ. б.лар зур әһәмият бирә.

Ә. Фәйзинең әнә шундый мохиттә туган «Тышта яз» исемле лирик шигырьләре әдәби

җәмәгатьчелектә бәхәс кабынып китүгә сәбәп була. Аның шигыре Х. Хәйри тарафыннан «пассивлык үрнәге» буларак бәяләнә. Ләкин шулай да кешенең йөрәк кичерешләрен сурәтләү көчәя бара. Х. Туфан, Ш. Маннур, С. Хәким, Ш. Мөдәррис, М. Ногман, З. Нури, З. Мансур шигырьләрендә катлаулы язмыш сызланулары урын ала.

Илленче еллар урталары лириканы сафландырып җибәрә. Шигърияткә Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камал, И. Юзеев, Р. Гәрәй кебек шагыйрьләр килеп керә. Алар сафын Роб. Әхмәтҗанов, Ә. Баян, Н. Мальяров, М. Шабаев, Э. Мөэминовалар тулыландыра. Поэзиядә кеше күңеленә игътибар арта бара. Әхлак мәсьәләләре, гаилә ныклыгына игътибар көчәя. Шулай да «интим» темаларны яктырту каршылыкка очрый, хисләрне сурәтләүдә табигыйлек житенкерәми. Бу чор шигырьләрендә Җир шары, дөнья мәшәкатьләре дә киң урын ала. Ә. Давыдов, Н. Дәүли шигырьләре бәхәс, сөйләшү рәвешен хәтерләтә. Бу чорда «конфликтсызлык теориясе», догматик карашлар поэзиягә кире йогынты ясый. Кайбер шагыйрьләр тормыш каршылыгын җиңелләштереп бирү юлына басалар, психологик каршылыкларны бизәп бирү дә еш очрый. Нәкъ шул вакытта С. Батталның «Олы юл буйлап» шигъри повесте языла. Бу шагыйрь әсәрен туктаусыз камилләштерә, нәтиҗәдә ул тормышчан конфликтлар гәүдәләндерүгә ирешә. Тәнкыйть тә бу әсәрне уңышлы дип билгели. Шигъри повесть әдәбият тарихына сугыштан соңгы елларның бер казанышы булып кереп кала.

Эпик поэзиядә шулай ук сугыш темасын яктыртуга урын бирелә. Беренче чиратта бу эшкә үзләре сугышта булган шагыйрьләр алына. Беришә шагыйрьләр турыдан-туры сугыш шартларын сурәтләсә, икенчеләре тыл батырлыгына игътибар итә, өченчеләре Ленин турында яза. С. Хәкимнең «Курск дугасы», Н. Дәүлинең «Яр буенда шаулый нарат» поэмалары языла. Күренекле шәхесләрне гәүдәләндерү буенча эш башлана. Гали Хуҗинең Ф. Кәримгә багышланган «Гражданин, солдат, шагыйрь» поэмасы языла. 1952 елда «Чаян» журналының яңадан чыга башлавы сатираның көчәюенә китерә. Ә. Исхак, С. Баттал, З. Нури, Ш. Галиев, Г. Афзал сатирик шигырьләр иҗат итә. Монда, нигездә империализмны фаш итү, халыкара хәл белән мавыгулар күзәтелә. Бериш шигырьләрдә исә декларатив сөйләү, турыдан-туры тәнкыйть урын ала башлый.

Әлеге уңайдан Ә. Исхак шигырьләре аерым игътибарга лаек. Ул мәсәлләр иҗат итә. «Ялагай белән бюрократ», «Йөк һәм дөя» кебек тәэсирле әсәрләр яза. З. Нури, Г. Афзал, Ш. Галиевләр сатира-юмор өлкәсен яңа тема, образлар белән баетып җибәрәләр. Алар көлүнең социальлеген өскәрәк күтәреп, күренебрәк торуына ирешәләр. Г. Афзал көлүе аерылып тора. Ул укучының игътибарын вакыйгага түгел, бәлки анда катнашучыга, аның да психологиясенә юнәлтә белә, геройларны үзенчә сөйләтә, җанландыра.

Илленче еллар уртасында Х. Туфан иҗаты югары ноктага җитә. Бу турыда Т. Галиуллин «Бөтен татар шигърияте фонында Такташ белән Туфан поэзиясе отышлы булып аерылып тора»,—дип билгеләп үтте.

Алтмышынчы еллар иҗтимагый тормышта «Хрущев җепшеклеге» дип йөртелә. Бу еллардагы чагыштырмача демократия әдәбият-сәнгатькә уңай йогынты ясый. С. Хәким, Х. Туфан, С. Баттал, Ә. Давыдов, Н. Арсланов, Ш. Манур, Ә. Ерикәй иҗатларында заман, кеше һәм дөнья язмышы, сугыш һәм тынычлык турында фәлсәфи уйланулар киң урын ала. 60нчы елларда шигърияткә шаулап-гөрләп талантлы яшь шагыйрьләр килә. Болар: Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Мингалим, соңрак Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, Зөлфәт, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин.

1956-70 еллардагы шигъриятне Т. Галиуллин үз сыйфат югарылыгында калган дәвер дип билгеләгән иде. Бу чорда монарчы югалып, тыелып торган шагыйрьләрнең исемнәре әйләнеп кайта. Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич, С. Сүнчәләй, Н. Думавилар һәм Сталин режимы корбаннары Х. Туфан, Ф. Бурнаш, Г. Мөхәммәтшиннар иҗаты алга чыга. М. Җәлил әсәрләре киң яңгыраш ала. Г. Афзал, Ш. Галиев, Х. Камалов, Ә. Баянов, И. Юзеев, С. Сөләйманова иҗаты көчәя. Алтмышынчы елларда поэзиядә, Такташ һәм Туфаннардан соң, М. Кәрим сүзләре белән әйткәнчә, «икенче шартлау» барлыкка килә. Дөрес, Н. Юзиев үз вакытында «шартлау» феноменны белән килешмәвен дә белдергән иде. Ул «Шартлау төшенчәсе беренче чиратта җимерү дигәнне аңлата»,—дип белдерде. Ә 60нчы еллар буыны татарның традицион шигыренә үзгәреш кертергә теләп, каршылыкларга очраса да, үз юлыннан

тайпылмый. Алар ирекле шигырь, ак шигырь, кыска шигырьләр белән тәҗрибәләр ясый башлый. Әлеге буын шигырь төзелешен, строфа формаларын гына үзгәртеп калмый, Европа шигъриятенә йөз тотып, эчтәлек һәм форма өлкәсендә кыю тәҗрибәләр ясый. Әлбәттә, бүген бу шигырьләр гадәти шигырь буларак кабул ителә. «Аңлашылмый» торган шигырьләр язган шагыйрьләрнең бүген һәрберсе—мәртәбәле Тукай бүләге лауреаты, халык шагыйре исеменә лаек булучылар да бар. «Р. Фәйзуллиннар буыны» дип йөртелгән бер төркем шагыйрьләр егерме беренче гасырда да каләмен ташламады, алар бүген дә әйдәп баручылар сафында кала бирә.

Н. Гамбәр шагыйрьләрне шартлы рәвештә ике төркемгә—шигъри дөньясын тудыра алганнарга һәм, киресенчә, тудыра алмаганнарга бүлеп карый иде. Шигъри дөньясын тудыра алганнар төркеменә, әлбәттә, беренче чиратта «үз иҗат омтылышларының дөреслегенә фанатикларча ышанып» яшәгән Р. Фәйзуллин керә. Ул татар шигъриятендә беркемнекенә дә охшамаган ныклы, тотрыклы үз шигырь мәктәбен булдырган шагыйрь. Дөрестән дә, ул әдәбиятка җиңүче булып килеп керде, һәм хәзер дә «вакыт эчендәге вакыт»ны табып иҗат итә бирә: ул шагыйрь дә, тәнкыйтьче дә, галим дә, публицист та. Шагыйрь үзе һәм иптәшләре иҗатына гына түгел, бәлки гомумтатар шигъриятенә дә күзәтү ясап, Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дип исемләнгән фәнни-публицистик хезмәтен язды.

Сәяси, иҗтимагый һәм мәдәни шартлар әдәби хәрәкәткә тәэсир итми калмый. Шул рәвешле, 1917-1940 еллар әдәбиятында күзәтелгән сыйфатлар: әдәбиятка яшь авторлар килү, үткәндә калган әдәби мираска каршылыклы мөнәсәбәт булдырып, аны кире кагу, хакимияткә тәнкыйть, үткәндәге тарих, заманга хас яңа герой эзләү, жанр, форма-алымнар төрлелеге, яңа сурәтләү чараларын табарга омтылыш, тематик төрлелек, яңа эчтәлек, форма эзләүгә кайтып калган үзенчәлекләр хәзерге әдәбиятка да хас. Шулай да, Язучылар берлеге оешкан еллардан аермалы буларак, XX гасырның 80 нче еллары уртасында илдә башланып киткән демократик үзгәрешләр, 90 еллар иҗтимагый фикерендәге кискен борылышлар татарның милли үзаң үсешенә китерде. Бу елларда татар теленең гамәли кулланышын үстерү өчен актив эшчәнлек алып барылды. Милли идеяне эстетик идеал дәрәҗәсенә күтәрә алган шигъри әсәрләр барлыкка килде. М. Әгъләм аны, «иман тәрәз шакый» дип, шигъри калыпка да кертеп калдырды.

Милли теманы калкытып сурәтләү, XX гасыр ахырында киң җәелеп китеп, бүген дә дәвам итә. Дөрес, бүгенге шигырь ул—тынычрак, уйчанрак, фикерлерәк, әмма туган телне югалту куркынычы яный башласа, И. Гыйләҗев әйткәнчә: *«Минем ике Ватаным юк!»* дип аяусыз да булырга сәләтле ул. Тормышның тотрыксызлыгы шагыйрьләрнең Идеал эзләвен көчәйтә булса кирәк. Өлкәнрәк буын шагыйрьләр, аерым алганда Ә. Баян, «экологик, алкоголик хәл»дән теңкәсе коргач, *«Дөнья минем теләк белән Бармаганга үртәлеп: Шөкер, димен, уйлый алам, Елый алам бит әле»*,—дип белдерсә дә, эзләнүдән туктамады. Татар шагыйре Идеалны үз халкының күренекле, әмма күптән инде теге дөньяга күчкән шәхесләреннән, бигрәк тә йә язмыш, йә сәясәт тарафыннан рәнҗетелгән затлардан эзли башлады.

Ә менә соңгы елларда сонет жанры активлашуны шагыйрьләрнең Европага омтылуы дип карарга кирәктер. Ш. Мөдәррис, М. Хөсәен сонетларыннан соң Р. Харис бу жанр үсешенә үз өлешен кертте. Билгеле, классик таләпләрне үзгәртеп, Р. Зәйдулланың да сонет жанры буенча тәҗрибәләре бар.

Татар шигъриятендә Көнчыгыш поэзиясенә мөрәҗәгать итү шулай ук үзенчәлек буларак каралырга мөмкин. Бу өлкәдә иң нәтиҗәле эшләгән авторларның берсе—Р. Гаташ. Татар шагыйрьләре нигездә Көнчыгыш әдәбияты үрнәкләреннән газәл, робагый, касыйдә, кыйтга жанрларына мөрәҗәгать итәләр. Шулардан дүртьюллык тәмамланган робагый формалы шигырь соңгы елларда нык активлашты. Татарның «үз Гомәр Хәйямнәре» бар хәзер. Юкка гына Р. Фәйзуллин әле 1977 елда ук «Мәгънә—робагыйларда!..» дип язмагандыр. Шагыйрьләр дүртьюллыклар язуда тәмам остарып җиттеләр, хәтта исемләп яза башладылар! Әмма һәр дүртьюллык робагый түгел икәнлеген истән чыгармыйк, язылганнарның һәрберсе робагый жанрына куелган классик таләпләргә җавап бирми, бигрәк тә алар робагый интонациясен биреп бетерә алмый, фәлсәфәсе дә еш кына фәкыйрьрәк килеп чыга. Бүгенге татар робагыйларына еш кына «артыгы белән» иҗтимагый яңгыраш килеп керә. Бары

тик Р. Гаташ кына фәлсәфи һәм гыйшкый янгырашны тәгәл саклап яза. Анын робагыйларда фәнни һәм фәлсәфи эчтәлекне югары дәрәҗәдә саклавы турында галимә Р. Ганиева бик тәфсилләп язып чыкты. Көнчыгыш шигъриятенен камил үрнәкләрен саклап яза торган шагыйрь Р. Гаташ иҗатына галим Х. Миннегулов та «Газәл жанры һәм Гаташ иҗаты», «Робагый жанры һәм Гаташ» исемле хезмәтләрен багышлады. Башка күренекле шагыйрьләребез дә робагый жанрына еш мөрәҗәгать итә. Р. Харис, үзенен робагыйларын туплап, «Шигырь язган каләм белән» җыентыгын өч телдә бастырып чыгарды. Көнчыгыш әдәбияты нигезендә язу формасы шагыйрь М. Мирзанын да төп язу стиленә әверелеп бара, шулай ук Ф. Тарханова Шәрыкнын матур үрнәкләрен бирә.

Образлылык ягына да тел-теш тидермәслек, үзе кыска, үзе тыгыз фикерле шигырьне З. Мансуров иҗатында очратырга була. Анын шигырьләре композицион яктан да төзек, ритмика саклана, укучы бер үк вакытта акыл эшчәнлегенә этәрә торган информация дә ала. Аларда сәясәт тә бар, киная дә. Лирик субъект бер караганда күптән таныш халык акылын гына җиткергән кебек тоела, әмма шигырь уйланырга мәҗбүр итә, шагыйрь кулланган сүзләр яна мәгънәләре белән ачылып китә.

Мондый язу стиле Р. Фәйзуллиннын кайбер шигырьләрендә, Р. Харис, М. Мирза, Г. Морат, Р. Зәйдулла иҗатларында да ачык сизелә. Аларнын язу стилен сатирик юнәлештәге ирония дип атау дөрес булыр кебек. Мондый төр шигырьләрне һәркем кабул итә алмый, алар үз укучысын табарга тиеш. Бу—аналитик шигърият. Ирония шулай ук Р. Миннуллинда күп. Әмма анда сатирик юнәлеш зур үсеш алмаган, бәлки чиста юмор белән бергә ирония катыш юмор өстенлек итә. Шуна Р. Миннуллин шигырьләрен укыганнан сон күнелдә җиненлек хисе кала. Татар халкынын җорлык традицияләрен шулай ук Ш. Галиев, И. Юзеев иҗатларында табарга була иде. Р. Хариснын «Чехов базары» поэмасы да юмор алымына корылган. Шулай да, тулаем алганда, татар шигъриятенә юмор хисе җитенкерәми дигән фикер кала.

Татар шигъриятендә бүген тагын бер яна форма барлыкка килде. Ул да булса М. Мирзанын «Адәм баласы» исемле бишьюллык миниатюралары. Миниатюра формасы татар шигърияте өчен яналык түгел, Шамил Анак миниатюралары билгеле. Мирза миниатюралары аз сүзлелек, фикер тыгызлыгы, ачыклык, афористик янгыраш ягыннан Шәрык поэзиясенен кыска лирик шигыре булган кыйтганы хәтерләтсә дә, формасы белән ана туры килми. «Адәм баласы»нда тупланган шигырьләр, фикер поэзиясенен үзгә яшәү рәвеше булып, «яна татар танкасы» дип исемләнергә дәгъва итә. Афористик фикернен чарланган формасы булган япон танкаларын татар теленә Л. Шагыйрьҗан тәрҗемә иткән иде. М. Мирзанын яналыгы шуннан гыйбарәт: ул япон танкасына иярми, үзгә ритмик формалы бишьюллык шигырь яза. Хәзер бу яна форма күренешенә исем уйлап табасы гына калды. Берьюллык шигырьләр Г. Морат, М. Галиев иҗатларына да чит түгел. Әдәбият тарихында «һәрбер сүзнен үз тәхетен таба алган» М. Галиевнен эсселары һәм шигырьләре ныклы урын алды.

Хәзерге шигъриятгә тәнкыйди-сатирик әдәбиятка карый торган пародия-эпиграммалар язучы Л. Лерон татарнын җор теллелеге традицияләрен дәвам итә. Шагыйрьнен лирик шигъриятнен башка жанрларына карый торган шигырьләре дә нечкә зәвык белән аерылып тора. Бу жанрда Л. Лерон үзе генә түгел, Р. Миннуллин шигырьләре дә хөсетсез көлүе белән укучынын игътибар үзәгендә кала бирә.

Мәҗүсиләргә хас тасвирлау алымнары булган Себер ханнары нәселе вәкиле Ш. Гаделша иҗаты табигать турында мул мәгълүмат бирүе белән кадерле. Укучы илаһилаштырылган табигатькә сусаса, анын шигырьләренә мөрәҗәгать итә ала.

Лирик геройнын үз тормышындагы мизгелләре, хыяллары хакында сөйләвенә нигезләнеп, шәхси башлангычка өстенлек биргән, хисләрнен үсеп-үзгәреп торуына корыла торган, ин эмоциональ жанрлардан саналган күнел лирикасы шигырьләрен нигездә яшьләр һәм хатын-кыз шагыйрәләр иҗатында күрергә була. Менә Ф. Мөслимовадан бер мисал: *«... Алмагачта яфрак та юк—көзләр үткән, Кышкы җилләр кар себереп йөри күптән. Алмага да тия икән явыз язмыш: Ялгыз алма карда өшеп калган ялгыш». «Янар өчен дөрләп ялкынында мин күкләрдән ингән фәрештәмен»*,—дип белдергән Л. Янсуарнын мәхәббәт лирикасы да игътибарны җәлеп итә. Л. Гыйбадуллина сүздән үзенә генә хас матур сурәтләр ясый: *«Төннән*

*качып, йолдызлар да җиргә төште, Юлларында яктылыктан үргән келәм...»*

Поэма жанры шулай ук игътибар сорый торган өлкә. Лирик яки эпик башлангычның роленә карап, поэмалар ике төргә бүленә. Беренчесендә хис-кичереш, мөнәсәбәтнең алга чыгуы, төп геройның лирик герой булуы өстенлек итә. Бу очракта классик мисал булып, Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ы тора. Кызганыч, нәкъ менә лирик башлангычлы поэмалар бүгенге көндә язылмый, аларның урынын эпик башлангычлы поэма ала бара. Кайбер очракларда, шагыйрь жанрын поэма дип билгеләсә дә, әсәр жанрга куела торган классик таләпләргә җавап биреп бетерми. Соңгы елларда аерым кеше язмышыннан башлап, ил, халык тормышындагы вакыйгаларны яктырту, иҗтимагый-сәяси, шәхес, милли проблемаларны күтәреп чыккан тарихи поэмалар саны арта бара. Бу очракта Ә. Рәшитнең «Сөембикә», «Колшәриф», Р. Низаминың «Ике мөһаҗир», Р. Шәриповның аерым әсәрләре, Р. Харисның күпсанлы поэмаларын искә алып була. Бүген инде героик характердагы поэмалар арткы планга күчеп бара, фантастик эчтәлекле поэмалар да күренми. Укучы И. Юзеев поэмаларын сагына башлады. Аның драматик поэмаларын алыштырырлык әсәрләр язылмый. Соңгы елларда иҗат ителгән поэмалар илнең үткәндәге сәясәтенә, рәнҗетелгән аерым шәхесләргә бәйләп языла. Ф. Яруллин шулай халык тормышыннан берничә поэма язды.

Поэма жанры турында сөйләшкәндә Тукай темасын аерып чыгару дөрес булыр. Шигърияттә Тукай образын тудыру буенча зур эшләр эшләнә. И. Юзеевнең «Очты дөнья читлегеннән», Ә. Баянның «Каракош» шигъри трагедияләре, Р. Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре», М. Әгъләмнең «Тукайдан хатлар», Э. Шәрифуллинаның «Без—Тукайлы» поэмалары, башка шагыйрьләрнең күпсанлы шигырьләре бу мираска өстәлеп кенә тора. Бу темага галим Т. Галиуллин җентекләп язып та чыкты.

Соңгы елларда әдәби җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итәрлек тагын бер поэма язылды. Ул—Л. Шагыйрьҗанның «Дөнья базары, яхуд яңа Америка фаҗигасе». Әсәр нигезенә Нью-Йорктагы Сәүдә үзәген шартлату вакыйгасы салынган. Поэмада безне мөһим бер сорау «озатып бара». Ул да булса: «Нәрсәдән ул, диеп, террор чыга?». Поэманы язганда шагыйрь бик нечкә, деликат формадагы сәяси теманы күтәрә. Бу тема аерым сәясәтчеләр тарафыннан «ислам экстремизмы» дип аталган уйдырмага нигезләнә. Шагыйрә үзе үк поэманың нигезенә ялган сюжет һәм чын «уйдырма» салынуын билгеләп үтә. Халыкларны тетрәндергән 2001 елның 11 сентябре вакыйгасының зур күләмле эпик әсәр жанры өчен «азык» булып та, поэма жанры кысаларында гына калуы сәбәпләрен хәзер халыкның зур күләмле әсәрләрне укырга вакыты юклыгы белән бәйли ул.

Әсәрнең үзендә, чәчмә әсәр белән шигъри сөйләм мөмкинлекләрен берләштереп, яшәешнең дәвамлы хәрәкәтен чагыштырмача таррак планда күрсәтү аша, сурәтләү объекты итеп, дулкынландыргыч, киеренке вакыйгаларны, гыйбрәтле язмышлар бәйләнешен алу ягыннан кызыклы Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш», Ә. Рәшитнең «Мөхәммәдьяр» поэмалары язылды.

XXI йөз башы татар әдәбиятында Р. Харисның «Исемсезләр» шигъри романы да тарихка кереп калыр. Бер әдәбият та шигъри романнар күплеге белән мактана алмый. Әлеге жанр—әдәбиятның житлеккәнлеген күрсәтә торган билгеләрнең берсе. С. Батталның «Чирмешән ярларында» романыннан соң бездә «Исемсезләр» туды. Роман күпкырлы. Россия империясенең таркалуы, сәясәтнең милләтләр тормышында китереп чыгарган үзгәрешләре, совет системасында формалашкан кешенең яңа тормышка яраклашуы, һәм, ниһаять, яңа буынның яңа тормышта үз урынын булдырырга тырышуы турында бу роман. Илкүләм вакыйгалар фонында татар милләте, аның да иң авырткан җире—чит җирләрдә аерылып калган бер вәкиле фаҗигасе турында бу роман. Дөрес, романда сурәтләнгән унлап исемсез геройның барысы да—милли элита вәкилләре. Ләкин «байлар да елаган кебек» аларның да авырткан җирләре бар. Әмма шагыйрь образы—чын татарныкы, үзебезнеке. Әдәбияты да «Тукайның мәхәббәт төшләре»ндәгечә: *«Төп» эштән бушагач кына иҗат итү безгә язган»*,—булып чыга.

Соңгы егерме елда әдәбиятка дини мотивларның күпләп үтеп керүе күзәтелә башлады. Шулай булмый да хәл юк, чөнки дин һәрвакыт әхлак, тәрбия коралы булып

килгән. Бер караганда бу яналык түгел. Әдәбиятка дини тематиканы кайтаруны асылыбызга кайту дип карау дөрес. Әйтергә кирәк, язучылар әлеге максатны бик теләп тормышка ашыралар. Бүген инде дин, ден, иман турында язмаган автор чын миллилектән ерак торган кебек тоела. Шагыйрьләр бу турыда әйтеп кенә калмый, дөньяны шаулатырлык, мәйданнарда сөйләнерлек, ә кайчак киләсе буын алдында гафу үтенеп акланырлык көчле шигырьләр тудыра башлады. Шул рәвешле, заманча шигырьләрдә, тәнре, тәкъдир, Коръән, пәйгамбәр, ходай, фәрештә, дога, бисмилла, кыйбла, иблис, шайтан сүзләренен активлашуы күзәтелә. Хәтта әлеге сүзләрнен ижтимагый-сәяси лирикада урын алуы да гайре табигый күренеш түгел. Күрәсен, *«Ничә гасыр елый Йакуб халыкнын йөрәгендә»* дип әйтүе белән Х. Әюп хаклы булгандыр. Анын ижаты башка татар шагыйрьләренекенә караганда да дини төшенчәләргә ифрат бай иде. Вакыт-вакыт әлеге алым кирәгеннән артык та булып китә. Шагыйрьләрнен көнкүрештәге һәр гадәти күренешне сурәтләүдә дини тематикага мөрәҗәгать итүе кайчак сәеррәк тә тоела башлый. Күнелгә, «бәлки әлеге күренеш каләм ияләренен халыкка рухи байлыкларны кире кайтарырга тырышуыдыр», дигән уй килә башлый.

Бүгенге көндә һәр өч шагыйрьнен берсе шигырен Коръән сүрәләреннән эпиграф куеп яза, рухи кыйммәтләр турында Коръән юлларыннан чыгып фикер әйтә. Кешегә әхлакый ориентир рәвешендә шәригать кануннарын тәкъдим итү күзәтелә. Шигырьдә Коръән аятьләрен актив куллану алымы Равил Рахмани ижатында аеруча еш очрый. Х. Әюп өчен дә шигырь язу, хисен рифмага салып, образ тудырып шигырь ижат итү чын гыйбадәт иде, чөнки анын күнеле, йөрәге, пәйгамбәр күнеле сыман «күкләр белән тоташкан» булды. Биш кисәкле шигъри бәйләменен «Биш вакыт намаз» исеме белән аталуы монын ачык дәлиле иде.

Дини тема янәшәсендә мифологиягә мөрәҗәгать итү дә ешая бара. Мифологик образларны хәзерге дөнья жирлегенә күчереп утырту, аларга яна дөньяви сыйфатлар өстәп, постмодернистик дип аталган әсәрләр тудыру күзәтелә. Бу өлкәдә бигрәк тә Р. Харис (анын «Һарут белән Марут» сәяси поэмасы), З. Мансуров («Хозыр галәй-һиссәламне эзләү» сәяси поэмасы) аерылып тора. Шигъриятттә пәйгамбәр, фәрештә образлары артык еш очрый, шайтанга да кытлык юк. Әмир Мәхмүдов хәтта «Пәйгамбәр» поэмасы янәшәсендә «Иблис» дип исемләнгәнен дә язды.

Татар шигъриятендә баллада жанрына караган әсәрләр сирәк күренеш түгел. Әгәр шагыйрьләрнен, үзләре үк «баллада» дип, әсәрнен жанрын алдан билгеләп куюын да исәпкә алсак, күп тә булып китә. Бу жанрда «беренчелекне» А. Хәлим үз кулында тота. Анын хәтта «Катык турында баллада»сына кадәр бар. Әмма шагыйрьләр кайчак балладада башка лиро-эпик төр әсәрләренә караганда каршылыкнын үткенрәк булуы, һәм балладанын сюжетка корылуын һәрвакытта да исәпкә алмыйлар. Романтик, символик-аллегорик яссылыктагы балладалар язылмый, язылганнарынын да үзегенә драматик, фантастик хәлләр, гадәттән тыш вакыйгалар салынмый. Бу жанр турында фикер йөрткәндә, Зөлфәт, И. Юзеев балладалары югарылыгындагы әсәрләр күрәсе килә.

Укучы, вакыт-вакыт ижтимагый лирикадан туеп, Г. Афзал әйткәнчә, *«Базар сәясәтен эт ашасын, Бу йөрәккә нәфис мон кирәк. Табигатьне күреп мон табасын, Сәясәтсез үсә тал-тирәк»*,—дип, пейзаж яки күнел лирикасы шигырьләрен укуга күчә. Сонгы елларда лирик шигырьләрнен матур үрнәкләрен хатын-кызлар ижатыннан табарга була. Дөрес, *«Ач, шигърият серләренне, Тылсымлы сүзләр өйрәт. ...Уйларымны жырга салам, Яшенләй сүзләр кирәк»*,—дип язган, С. Сөләйманова, *«Мин тормышка гашыйк»*,—дип беллергән Г. Зәйнашевалар юк инде. Әмма шигърият үсүдән туктамый, ян-якка карамый, алга баруын дәвам итә. *«Ә шулай да—безнен бәхет,—Бар бит әле шагыйрәләр: Шагыйрьләр акыл өйрәтә, Шагыйрәләр—жан эрәләр»*,—дип язган Р. Жамал белән килешми булмый. Татар шигъриятендә шагыйрәләр аерым бер урын алып тора. Алар, үзләрен сонгы елларда Тукай премияләре читләтеп үтсә дә, армыйталмый ижат итәләр. Ә «халык шагыйрәсе» дигән исем шигърият лексиконында бөтенләй юк әлегә. Ә бит шагыйрәләребез сүзгә таләпчән карап, шигъриятне образлы гыйбарәләр белән баетуда үз өлешләрен кертәләр, тәрбия, әхлак, милләт, яшь буын язмышы өчен борчылып язалар. «Ел китабы» конкурсларында, бигрәк

тә балалар әдәбияты өлкәсендә, алар нәтиҗәлерәк эшлиләр, милли тәрбия бирүдә көчләрен кызганмыйлар. Шулардан Б. Рәхимова үз халкына «ятка бишмәт сырма» дип мөрәҗәгать итсә, *«Тормышы проза булса да, үзе шигырьдән генә торган»* Н. Сафина: *«Без әлегә хыялларны кочып, Канап торган җиргә инәбез...»*—дип яза. Ф. Тарханова өчен гомумән керә алмаган өлкә юк. Публицист та, галим дә, тарихчы да, сәяхәтнамә язучы да ул. *«Гел башкача һәрбер ярату!»* дип раслаган лирик шагыйрә Рифә Рахман «Истанбул мотивлары» һәм Төркиягә мәдхия укыган шигырьләреннән сон хикәя һәм публицистикага «күчеп бетте». Ә *«Болытның да үз холкы бар»* дип яза торган Э. Шәрифуллина ел да иң күп укыла торган китаплар авторы булып кала. Б. Рәхимова бик актив иҗат итә. Татар вакытлы матбугатында аның йә шигырьләр бәйләмен, йә үзе белән әңгәмә, йә теге яки бу китабына бәяләмә басылып кына тора. Үзе дә: *«Әйдәп барам, шигырь сөй дип һәр адәмне, Шигыремнең башкодасы, мин яучысы. Үзем эзлим, үзем табам—сүз аучысы, Күңел төбен актаручы—сунарчысы»*,—дип, авырлыкларны заманага сылтамый гына максатына ирешеп бара. Р. Вәлиева башка шагыйрьләрнең дә шигырьләрен укый ала торган яшь буын тәрбияләүдә көчен җәлләми, күпләр «ташлап качкан» патриотик лирикадан ваз кичми иҗат итә. *«Кыйбла якнын җиленә йөзен куйган»* Г. Бәйрәмова, *«Мин—шагыйрә. Мин шигырьләр язам. Минем бакчам—шигъри туталләр. Мин орлыклар гына чәчә алам, Җыючылар булыр бүтәннәр»*,—дигән К. Булатова, *«Бабичларны бирдек тыныч кына, житмәгәе чират Еникигә»* дип хафаланган А. Юнысова, *«Шигърияттә мин утырган каз шикелле»* дип белдергән Ф. Гыйззәтуллиналар каләмен ташламый. *«Бер кешегә юк эчемдә каралык, Яхшылыктан китә җаным таралып»* дип, Ш. Җиһангирова шагыйрәләрнең уртак фикерен житкерә.

Гасырлар чигендә татар шигъриятенә бер төркем яшь авторлар килеп керде. Бу буын үзенең көченә, белеменә, талантына ышанып иҗат итә. Соңгы елларда Язучылар союзында оештырылган төрле секцияләргә йөреп, югары уку йортларындагы әдәби берләшмәләрдә чарланып, «Казан утлары»нда Р. Гаташ ышыгында җылынып, «Сәләт» яшьләр лагеренда чыныккан әлеге яшьләр шигъриятькә яңа сулыш өрә башладылар, бер-бер артлы китаплары да чыгып килә. Иҗатларының башлангыч чорында әле алар нигездә мәхәббәт лирикасына карый торган шигырьләр иҗат итәләр. Алар сафында *«Татарлыгым—минем тарлыгыммы? Мамай ханнан калган ярлыгыммы? Татарлыгым—минем барлыгым»* дип белдергән Г. Вәлиева, шигырьләрендә ачык гражданлык лирикасы бәреп торган *«Ахыргы каһарман кем иде?»* сораулы Р. Мөхәммәтшин, *«Малевич квадратлы тәрәзәләре белән»* Й. Миннуллина, *«Милләтебез ихласмы?»* соравына җавап эзләгән Л. Шәех, *«Алмалардай янып алсуланып, хөрмәләрдәй тулган күңелле»* Л. Янсуар, *«Салкын кышта өшеп, Әгъләм булып караган»* Р. Сәлах, *«Вакытсыз юлчыга кизәнеп, көрсенеп сукмакка үрелгән каеннары»* белән Э. Һадиева һ.б. лар бара.

Соңгы елларда татар шигъриятендә фикер поэзиясе өстенлек итә кебек. Дөрес, шигырь фикерсез була алмый. Бу очракта без интеллектуаль шигъриятне әйтәбез. Акыллы шигырь язу күбәя. Мондый шигырьне кабул итү өчен укучының тирән белемле булуы, эрудициясе кирәк. Вакыт-вакыт хәзерге шигырьне аңлау өчен алдан кемнендер шәрехләп бирүе дә сорала кебек. Интертекст, шигырьгә заманчалык төсмерен биреп, укучының акыл горизонтын киңәйтә. Ә менә андый әсәрләрнең хис дөньясына тәэсир итүе икеле. Чөнки шигырь укучыларның барысы да югары филологик белемгә ия булмаска мөмкин бит.

Форсаттан файдаланып, «шигырь—шагыйрь—укучы» бәйләнешен тәэмин итәргә алынган тәнкыйтьчеләргә дә игътибар кирәклеге сорала. Бу очракта без галим-язучы-тәнкыйтьче Т. Галиуллин иҗатын күздә тотабыз. XX гасыр шигъриятен пропагандалау өлкәсендә аның хезмәтләрен тану һәм бәяләү кирәк.

Йомгаклап әйткәндә, хәзерге татар шигърияте, Р. Вәлиев сүзләре белән әйткәндә, «Ил алдында олы бурычымны Түләрмен мин шигырь, җыр белән...» дигән максат куеп, заман укучысына заманча сурәт тудыра торган әсәрләр язып, Р. Низами кебек «Мин елмаеп кына дөнья үзгәрерме?» ише сораулар куя-куя, хакыйкать эзләвен дәвам итә...



Халисә
Ширмән

# ТАТАР ПРОЗАСЫ: ЮГАЛТУЛАР ҺӘМ ТАБЫШЛАР

XX гасыр тарихка иҗтимагый һәм икътисади тетрәнүләр чоры булып кереп калды. Инде XXI гасырның да беренче унъеллыгы чигенә килеп життек, артка борылып, эшләнгән эшләрне—уңышларны һәм ялгышларны, туры юлны һәм читкә тайпылышларны билгеләргә, аларга тарихи яссылыкта бәя бирергә вакыт житте булса кирәк. Татар халкының рухи байлыгын үзендә туплаган, иҗтимагый вакыйгалар барышында ныклы калкан булып торган Татарстан Язучылар берлеге оешуга да житмеш биш ел узган инде... «Жаны-тәне, рухы белән ИРЕКЛЕ булган язучыны ниндидер оешмага беркетеп куеп буламыни?»—дип гаҗәпләнә кайберәүләр. Юк, беркетеп тә, бәйләп куеп та булмый. Язучылар берлегендә әгъза булып тору партиягә керү кебек мәҗбүри түгел, әмма бик дәрәҗәле. Киресенчә, беркайчан да таркалмас кебек тоелган дәһшәтле партияләр тузандай уалып, юкка чыккан заманда Татарстан Язучылар берлеге үзенең бердәмлеген, оешканлыгын саклап кала алды. Бу бердәмлекне совет чоры белән генә дә анлатып бетереп булмый, чөнки ана кадәр дә шагыйрь-әдипләрне, сәнгать әһелләрен туплаган Шәрык клубы булган. Гаҗәп түгелмени? Язучылар берлегендә власть-погоннар да, сәяси кәнәфиләр дә өләшмиләр. Димәк, әдип-шагыйрьләрне монда башка жепләр—күңел жепләре, мәсләктәшлек, фикердәшлек тартып китерә булса кирәк. Сәясәт тозагына эләгү дә куркытмый аларны. Слесарь-сантехниклар берлеге турында ишетелгәне юк бит әнә...

Язучылар берлеге тарихы—татар әдәбияты һәм әдәби теле тарихының бер өлеше дисәк, ялгышмабыз. 1934 елның шаулы җәй айларында «Без—берләштек!» дип аваз салган язучы-шагыйрьләрне гасыр дәвамында никадәр каршылык, авырлыклар, фаҗига-үлем сагалап торган. Сизгәндер язучы күңеле, тик артка юл юк икәнен дә аңлаганнардыр. Житмеш биш елда иҗат ителгән әсәрләрне кабат күз алдыннан үткәрсән, язучы күңеленең никадәр самими, ихлас булуына таң каласың. «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар» авторы Галимжан Ибраһимовка, революцион рухлы «Ил кызы», «Краском мәхәббәте», «Митинг» хикәяләрен язган Шамил Усмановка, «Кара такта янында» хикәясе авторы Гомәр Толымбайга һәм башка бик күпләргә «революция дошманы»дигән ярлык тагылыр дип кем уйлаган?

Житмеш биш ел дәвамында иҗат ителгән әсәрләр, әлбәттә, жанр буенча да, идея-тематика буенча да, сюжет-композиция буенча да аерылып тора. Әдәбият белгечләре бу вакыт аралыгында ике этапны аерып күрсәтәләр: 1) 1940-60 еллар әдәбияты; 2) 1960-90 еллар әдәбияты. Бүгенге көн әдәбияты (1990-2009) формалашты. Әлбәттә, мондый бүленешнең нигезендә иҗтимагый вакыйгалар ята, чөнки тел, тарих һәм әдәбият бер-берсеннән аерылгысыз. Шулай да XX гасырны, бигрәк тә шаукымлы революциядән соңгы елларны тулаем күз алдына китерү өчен аның башлангыч

чорын искә алмый мөмкин түгел.

XX гасырның беренче чирегендә иҗат итүче әдипләр сан ягыннан шактый булсалар да, нигездә күбрәк Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Кәрими, Фатих Әмирхан иҗатлары өйрәнелә. Бу аңлашыла да, чөнки әлеге әдипләр—шушы чор татар әдәби телен формалаштырган, билгеле бер юнәлешкә салган язучыларыбыз. Революциядән соң проза мәйданына Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш килә, Галимҗан Ибраһимов иҗатын дәвам итә, соңрак Гадел Кутуй, Гомәр Толымбай, Афзал Шамовлар аякка баса. Бу—яңа чор, яңа әдәби телдә иҗат итүчеләр чоры була. 1917 елдан соң татар әдәби теленең үсешенә йогынты ясаган шартлар: а) иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның күп булуы, аларның телдә сизелерлек үзгәрешләр китереп чыгарулары; б) бай әдәби традицияләрнең өзелүе, Шәрык йогынтысы кимү; в) рус теле һәм аның аша Европа телләренең татар теленә тәэсире көчәю; г) берничә тапкыр алфавит алыштырылу; д) дингә каршы көрәш башлану—боларның күбесе Татарстан Язучылар берлеге оешканчы яки ул оешкан елларда булган күренешләр. Язучылар Гражданнар сугышыннан, ачлыктан соң тыныч тормышка ияләнергә дә өлгерми калалар—репрессия еллары, ә аннан соң тагы да дәһшәтлерәк вакыйга—Бөек Ватан сугышы башланып китә.

Боларны язуымның сәбәбе—бүгенге көн әдәбияты торышын аңларга теләү. 1985-92 елларда без дә революция шаукымын кичердек. «Тыныч» узса да, тарихчылар бу елларны «иҗтимагый формация алышыну» дип билгеләделәр. 1991-94 елларда тормыш шәһәр халкын ачлык-ялангачлык белән сынады. Тарих кабатлана диләр бит. Әдәбиятта охшаш мотивлар, әдәби телдә охшаш чалымнар күренмиме? 1921 елда Һади Такташның «Җир уллары трагедиясе»ндә гәүдәләнгән мифологик образлар Нәбирә Гыйматдинова, Галимҗан Гыйльманов әсәрләрендә кайтаваз булып яңгырамады микән? Ә узган шанлы тарихка мөрәҗәгать итү? Мәхмүд Галәүнең татарча оригиналлары югалган «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнарының, Фазыл Туйкинның 1812 елгы Ватан сугышына багышланган «Ватан каһарманнары», Болгар тарихын сурәтләгән «Сугышчы Сатыш әфәнде» пьесаларының 1917 елгы инкыйлабтан соң язылуы очраклы хәлдер, бәлки... Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Марат Әмирханов, Вахит Имамов, Флүс Латыйфи һ.б. язучыларның туксанынчы еллардан соң тарих төпкелләренә төшүләре ни белән аңлатыла? Рәсәйнең бүгенге сәясәтен күзәтеп, тоталитар режим башка кабатланмас дип әйтә алабызмы? Сораулар күп, җавап табу исә бик кыен...

Бөек Ватан сугышы еллары язучылар сафын юкка чыгара язды: утыз бер язучы, ягъни берлектә рәсми теркәлгән каләм ияләренең өчтән икесе яу кырында ятып калды. Мондый шартларда татар әдәбиятын тиз арада аякка бастыру мөмкин булмас эш кебек тоелса да, язучылар отряды сугыш елларында төрле фронтларда журналист булып эшләгән (1942 елдан башлап, фронтта уналты исемдә татарча газеталар чыга) һәм исән калган каләм тибрәтүчеләр хисабына тулылана. Шулай да, бу инде башка әдәбият, башка проза—башлыча үзешчән проза була. Галимҗан Ибраһимов, Фатих Кәрими прозасы дәрәҗәсенә житү өчен әле тагы дистәдән артык ел узуы кирәк. Сугыштан соңгы беренче еллар чәчмә әсәрләренә конфликтсызлык, чын тормышны арттырып, матур буяуларга манып сурәтләү, ясалмалылык хас, «милләтчелек»кә (1944 елның 9 август карары нигезендә асылда татар халкының тарихын яктыртуга киртә куела) каршы көрәш әсәрләрдә һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә ямьсез төс ала.

Шулай да, бүгенге көнгә кадәр укучыларны җәлеп иткән иң зур феномен—1960-85 еллар прозасы. Хрущев «җепшеклеге»ннән соң бик тиз арада янадан идеологик кысаларга, каты цензурага дучар ителгән татар прозасын ил күләмендә танытуга ирешкән татар язучылары пәйда була: Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Миргазиян Юныс, Ибраһим Гази, Гариф Гобәй, Мирсәй Әмир, Хисам Камал, Әхсән Баян, Атилла Расих, Рафаил Төхфәтуллин, Хәсән Сарьян, Мәхмүт Хәсәнов, Фәнис Яруллин, Сөббух Рафиков, Шәйхи Маннур, Газиз Мөхәммәтшин, Эдуард Касыймов, Ибраһим Салахов, Ибраһим Нуруллин, Шамил Рәкыйпов, Мәгъсум Насыйбуллин, Мәгъсум Хуҗин һ.б. Һәр язучының иҗатына

аерым тукталмыйча, алар мөрәҗәгать иткән темалар үсешенә игътибар итик. Әлбәттә, сугыштан соң беренче унъеллыкларда төп тема булып совет халкының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыгын сурәтләү тора. Әле бу афәт китергән яралар төзәлмәгән; һәр йортта, һәр гаиләдә сугыш кырларында ятып калган, тылдагы авыр хезмәттән, ачлык-ялангачлыктан вафат булган якыннары өчен күз яше түгелә; сугыш турында Сталин режимы алып килгән мәгълүмати бушлык яки сугышны берьяклы тасвирлау (совет солдатлары—батыр, акыллы, ә фашистлар—куркак, җүләр) хөкем сөрә; сугыштан исән-сау кайтканнарның тылдагы авыр хезмәтне тулы күзаллавы юк. Мондый шартларда язучылар, әлеге ак тапларны бетерү кирәклеген аңлап, әмма цензура кысаларыннан уза алмауларын чамалап эш итәләр. Гадәттә, бу темага язылган әсәрләрдә авторлар документальлеккә, вакыйгаларны тарихи нигезләүгә омтылганнар. Сугыш, тыл һәм сугыштан соңгы авыр еллар турында Габдрахман Әпсәләмовның, Нәби Дәүлинең, Рафаил Төхфәтуллинның, Шамил Рәкыйповның, Әхсән Баянның, Самат Шакирның, Хисам Камаловның, Гомәр Бәшировның, Аяз Гыйләҗевнең, Нурихан Фәттахның, Мөхәммәт Мәһдиевнең, Вакыйф Нуруллин һ.б. повесть һәм романнары, очерклары языллы. Шунысын әйтергә кирәк: әлеге тема 1975-80 елларда да актив эшләнә (Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар»ы, «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәя»се), хәтта бүгенге көн прозасында да күренгәләп ала (Зәки Зәйнуллинның «Үрләргә карап», Габдулла Галиевнең «Кырык дүртнең буранлы кышы» әсәрләре). Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршылап язучылар бу темага янә әйләнеп кайтырлар дигән өмет бар.

Сугыш һәм тыл темасы тыныч тормыш еллары башлангач акрынлап тоныклана төшә, шул ук вакытта язучылар мөрәҗәгать иткән башка темалар тармакланып, төрләнеп үсә башлый. 1960-85 еллар совет халкы өчен гигант автотөзелешләр, нефть чыгару, чирәм җирләрне эшкәртү, магистраль юллар салу һәм шулар нәтиҗәсендә шәһәрләшү, авылдан китү еллары буларак билгеле. Әлбәттә, шул чордагы идеология әлеге вакыйгаларны партиягә кулай рәвештә яктырту бурычын иң беренче чиратта язучыларга йөкли. «Тормыш материалы» җыю өчен махсус командировкалар, түләүле иҗат яллары бирелә. Бу күренешнең уңай ягын да онытмаска кирәк: язучы һөнәре илдәге иң абруйлы, иң дәрәҗәле һөнәрләрнең берсенә әйләнә, язучылар матди яктан да, социаль тәэмин ителеш ягыннан да дәүләт кайгыртучанлыгын тоеп яшиләр, язу эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнәләр.

Мондый «кайгыртучанлык»ның тискәре ягы да билгеле: дәүләт үзе тәэмин иткән язучылардан тормыш төгәлсезлекләренә күз йомуларын, көнкүрешне партия идеологиясенә туры китереп сурәтләүне таләп итә; әсәрләр партия органнары тарафыннан контрольгә (цензурага) алына һәм бары аның рөхсәте белән генә басыла... «Яңа кеше» (совет кешесе) образын ачу өчен язучылар тарихи үткәннән алып автобиографик материалга кадәр мөрәҗәгать итәләр. Сугыш темасыннан соң янә калкып чыккан Гражданнар сугышы, колхозлашу вакыйгаларын сурәтләү һәм шуның барышында «яңа кеше» барлыкка килү темасы. Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар»ы, Эдуард Касыймовның «Гомер ике килми» повесте, Гариф Ахуновның «Идел кызы» дилогиясе, Сөббух Рафиковның «Беренче яз» романы шушы чор кешеләрен сурәтли. Тарих төпкелләренә чумып, татар халкының узган данлы тарихын яктырткан бик «хәтәр» тема Нурихан Фәттахның «Этил суы ака турур» романында ачыла. Әдипнең бу әсәре халкыбызның милли аңын уятуда мөһим роль уйнады. Соңрак аның «Сызгыра торган уклар»ы, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы дөнья күрә. Бу романнарда «рөхсәт ителгән тарих», ягъни Алтын Урда чорына кадәр булган вакыйгалар гына сурәтләнә, ә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры әле һаман да партия тарафыннан «табу салынган» темалар булып кала бирә. Гомәр Бәшировның XX гасыр башы авыл тормышын тасвирлаган «Туган ягым—яшел бишек» романы бер үк вакытта 1960-80 елларда популярлашып киткән автобиографик жанрга караган әсәр дә булып тора. Автобиографик повесть-романнардан Мирсәй Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», «Үсә төшкәч», Фатих Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Әмирхан Еникинең «Соңгы китап» һ.б. әсәрләрне, биографик романнардан Шәйхи Маннурның «Муса» романын, Гази Кашшафның «Муса Җәлил», Рафаэль Мостафинның « Герой-шагыйрь эзләре

буйлап» дигән хезмәтен һ.б. күрсәтеп була. Авыл кешеләренең рухи тормышы, әхлакый сыйфатлары Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә», Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә», Әхсән Баянның «Аязучан болытлы һава», «Тау ягы повесте»нда, Мөхәммәт Мәһдиев повестьларында сурәтләнә.

Авыл темасы белән беррәттән, шәһәр интеллигенциясе тормышы да тулы яктыртыла. Инженерлар һәм табиплар, укытучылар һәм галимнәр, сәнгать кешеләре үзгәрүчән тормыш вәзгыятенә куелып, совет кешесенә хас әхлакый ныклыкка имтихан тоталар. Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», «Яшел яр» романнары, Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын», Мәдинә Маликованың «Шәфкать», Атилла Расихның «Сынау», «Ике буйдак» һ.б. әсәрләре әнә шундыйлардан.

Ниһаять, 1960-85 еллар прозасында төп темаларның берсе булып, нефть чыгару һәм шуңа бәйле эшчеләр тормышы темасы калкып чыга. Гариф Ахунов бу темага беренче булып мөрәҗәгать итә һәм «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарын яза. Шамил Бикчуринның «Каты токым», Эдуард Касыймовның «Томан аша», «Һаваларда тургай» һ.б. әсәрләре эшчеләр тормышын гына сурәтләп калмыйча, конфликт яссылыгында яңа буынның иске фикерләүгә каршы көрәшен дә чагылдыралар.

Бу чорда яшь буынны тәрбияләүгә, балаларга һәм яшүсмерләргә адресланган махсус әсәрләр язуга игътибар зур була. Шигърият белән чагыштырганда, бу уңайдан проза бераз калыша кебек, шулай да Абдулла Алиш традицияләрен дәвам иткән Кояш Тимбикова, Роза Мулланурова, Роза Хафизова, Рабит Батулла, Ләбибә Ихсанова, Әминә Бикчәнтәева, Адлер Тимергалинның мажаралы повестьларын яшь укучы яратып кабул итә.

1970-75 еллардан башлап татар әдәбиятына яңа, сугыштан соңгы тыныч тормышта туган яшь, талантлы язучылар килеп керә. Фаил Шәфигуллин, Нәбирә Гыйматдинова, Мәдинә Маликова, Әхәт Гаффар, Марсель Галиев, Фәрваз Миңнуллин, Рашат Низами, Мансур Вәлиев, Камил Кәримов, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй һ.б. классик әдипләр остазханәсендә каләм чарлаган язучылар буларак билгеле.

Шулай итеп, «үзгәртеп кору» чоры дип аталган вакытка килеп кергәндә, татар әдәбиятында тормышның бар даирәләре дә диярлек яктыртылып, укучы үзен кызыксындырган темага язылган әсәр уку мөмкинлегеннән файдалана ала иде.

1960-90 еллар прозасы турында сүз алып барганда, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев һәм Нурихан Фәттахны гомуми агымнан аерып күрсәтми мөмкин түгел. Әлеге әдипләр татар «бишлеге» («баш йолдызы») буларак билгеле. Әмирхан ага—татар халкы тормышы эчендә кайнап, аның сагыш-борчуларын йөрәге аша үткәреп тасвирлаган һәм үзе исән чагында ук классик дәрәҗәсенә лаек булган әдип. Язучы өчен соңгы нокта—аның соңгы сулышы...» дип язды Әмирхан Еники. Һәм шулай соңгы сулышкача иҗат итте дә.

«Фатих Хөсни феномены» турында сүз йөрткәндә, иҗатның үтә дә үзенчәлекле, билгеле бер романтик шартлылыкка нигезләнгән дөнья икәнлеген дә искә алырга кирәк була торгандыр. Күпме генә эзләнсәм дә, милли әдәбиятыбызда бу әдипкә якын торучы, дөньяга карашлары яисә иҗаты белән аны хәтерләткән бүтән иҗатчыны таба алмадым»,—Рифат Сверигинның әлеге сүзләре Фатих Хөсни прозасына тулы бәя бирә кебек. Чыннан да, язучының тормышка, киләчәккә күңел күтәренкелеге белән сугарылган, һәрберсенә тирән мәгънә салынган, алмаздай эшкәртелгән камил, җор телле, матур сурәтләргә бай хикәя һәм повестьлары татар прозасының үрнәгенә әйләнде. Шушы ук сүзләрне Мөхәммәт Мәһдиев һәм Нурихан Фәттах иҗаты турында да әйтергә булыр иде, әмма бу язучыларның әдәбиятта һәрберсенең үз юлы, үз биеклеге бар.

«Мин сугышны күрмәдем, шуңа күрә сугыш күренешләрен тасвирлау (бары ике тапкыр!) минем өчен җан газабы булды»,—дип әйтә торган иде Мөхәммәт абый. Аның персонажлары энәсеннән алып җебенә кадәр авыл җирлегендә яралган. Әсәрләрендә хәтта авыл үзе дә башка төрле, көлке-мәзәкле, моң-сагышлы, якты, нурлы... Мәһдиев авылы ул—ниндидер илаһи авыл, геройлары да илаһи гадиләр... Бүген без шул авылны сагынып яшибез. Мәһдиевне кабатлау түгел, хәтта аның язу

рәвешен аңлау да мөмкин булмаган эш кебек тоела. Язучының батырлыгы татар гомумхалык сөйләме байлыгын әдәби тел югарылыгына күтәрү, аны зәркәннәрчә эшкәртеп, гади сөйләм сүзләреннән бизәк ясау. Мондый кыю алымны татар әдәбиятында Мөхәммәт Мәһдиевтән башка беркем дә кабатлый алмады.

Нурихан Фәттах исә, киресенчә, үзе күрмәгән, катнашмаган, тарих төпкелләренә яшеренгән вакыйгаларны әдәби осталык белән дөньяга чыгаручы әдип. Албуга, Тотыш, Аппак, Күрекле бикә, Тунгак алып кебек геройлар язмышы язучы фантазиясе белән генә барлыкка килгән дип кем әйтә алыр?! Нурихан Фәттах безне аларның барлыгына, кайчандыр яратып-сөешкәннәренә, бөек эшләр кылганнарына ышандыра ич! Әйе, бу—Нурихан Фәттахның осталыгы, ышандыру көченә ия булган язучы гына укучыны үз артыннан ияртергә сәләтле. Ә моның өчен язучы гына түгел, Нурихан ага кебек, галим дә булырга кирәк.

 Япь-яшь килеш хаксызга төрмә-колония газапларын кичергән Аяз Гыйләжев прозасы тоталитар хакимлек белән аерым шәхеснең теләге-ихтыяры арасындагы каршылык тудырган драматик киеренкелек белән тулы. Бу әсәрләргә психологик чынлык һәм форма камиллеге хас.

Иҗатка шактый соңлап тотынган Миргазиян Юнысның әдәбияттагы урыны да шушы асыл бишлек янәшәсендә дип беләм. Миргазиян ага—беркадәр күләгәдәрәк калып, дан-шөһрәт артыннан кумаган, әмма татар халкын башка халыклар, башка мәдәниятлар янәшәсендә кадерләп-сөеп, татар рухын сагынып иҗат иткән, татар әдәбиятын яна сулыш, яңа төсләр белән баеткан искиткеч талантлы әдип. Аның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» исемле повесте турында Мөхәммәт Мәһдиев болай дип язды: «Минем соңгы егерме биш ел эчендә бер генә татар язучысының да әсәреннән болай тәэсирләнгәнем һәм эчтән елаганым юк иде. Бу әсәр—Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыят»еннән соң психологик прозаның яңа баскычка күтәрелеше».

Габдрахман ага Әпсәләмовны искә алмасак, язмабыз төгәл булмас иде. Иҗтимагый шартлар аның иҗатына кагылып үтсә дә, ул—татар прозасын СССР мәйданына чыгарган, «Роман-газета»да миллионлаган тираж белән рус телендә басылган язучыбыз. «Алтын йолдыз», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр» романнары сугыштан соңгы буын өчен көтеп алынган, бер тында укылган әсәрләр булды.

Инде әдәбият тарихына әйләнеп кайтыйк. «Үзгәртеп кору» чоры күпмедер дәрәҗәдә «Хрущев җепшеклеге»нә аваздаш һәм аның төп казанышларының берсе—сүз иреге булды. Революцияләрне, репрессия һәм сугыш юлларын узган язучылар үзләре күреп-белгән вакыйгаларны башкача—тәнкыйди позициядән торып, документальлеккә нигезләнеп тасвирладылар. Бу чор чын мәгънәсендә күтәрелеш чоры, татар интеллигенциясенең күңелендә узганга әрнү, киләчәккә өмет уянган, хыяллар чәчәк аткан, иҗат тантана иткән чор иде. Әлеге елларда иҗат ителгән документаль проза үрнәкләре булып Әмирхан Еникинең «Соңгы китап», «Кояш баер алдыннан», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә», Туфан Миңнуллинның «Утырып уйлар уйладым», Марсель Галиевнең «Догалы еллар», Ринат Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә», Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» һ.б. әсәрләрне күрсәтергә була. Шул ук вакытта социалистик тормыш чынбарлыгының караңгы, фаҗигале, җинаятьчел яклары яшермичә, аяусыз тасвирланган әсәрләр язылды һәм үз укучысын тапты. Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?», Ринат Мөхәммәдиевнең «Кенәри—читлек кошы», Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә» (соңрак—«Сәет Сакманов» трилогиясе) әсәрләрендә геройларның фаҗигале язмышы иҗтимагый тормыш яссылыгында, «ялган социализм» нәтиҗәсе буларак сурәтләнә. Кайбер галимнәр мондый төр прозаны «негатив проза» дип атый. Идея-проблематиканы дөрес билгеләгән очракта мондый төр әсәрләр укучы тарафыннан уңай кабул ителә, әмма тупаслык, рухи гариплек, түбәнлек күренешләрен тасвирлау авторлардан зур осталык сорый.

«Үзгәртеп кору» һәм аннан соңгы чорга күзәтү барышында әдәбиятта публицистик алымнарның активлашуын искә алмый мөмкин түгел. Бирелә вакытлы матбугат битләрендә Ельцин реформаларыннан беркадәр «баш әйләнеп», эйфориягә бирелеп язылган мәкаләләр турында сүз бармый. Бу чорда сәнгатьчәлек принципларына корылырга тиешле әдәби әсәрләргә дә публицистик алымнар (иҗтимагый

вакыйгаларны анализлау, аларга автор мөнәсәбәтен белдерү һәм үз позициясен дәлилләү; халыкка мөрәҗәгать итү; саннар, даталар һәм фамилияләрдән торган мәгълүмати материал урнаштыру; риторик сораулар, эндәшләр, тойгылы җөмләләрне күп куллану һ.б.) килеп керә һәм нәтиҗәдә сәнгати сурәтләү какшый. Һичшиксез, милли күтәрелеш уянган вакытта, халыкның милли үзаңын үстерү өчен мондый алымнарны куллану үзен аклый, ләкин хәзерге чорда, ягъни халык һәртөрле өндәү-чакыруларга, вәгъдәләргә ышанычын җуйган бер дәвердә публицистик алымнар белән әдәби әсәрдә сак эш итү сорала. Чын публицистика исә үз юлын табып, алга бара: аның чын үрнәкләре Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Равил Фәйзуллин, Зәки Зәйнуллин, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Рәфикъ Юныс, Шаһинур Мостафин, Рәшит Минһаҗ, Флера Низамова һ.б. мәкаләләрендә чагыла.

1990-2009 еллар прозасы әдәбият тарихында дулкынсыман сурәт барлыкка китерде. Аның үз тарихы бар һәм бу тарих әле дәвам итә. 1980-85 елларда беркадәр пассивлаша төшкән (бәлки, салмакланган, дип әйтергәдер) татар прозасы, милли күтәрелеш чорында җанланып, өскә омтылды, беркадәр вакыт шул халәтен саклап торгач, 2005 еллардан соң сүрелеп, кабат үз хәленә кайтып төште. Нигездә, әдәбият тарихы шундый дулкыннардан тора да инде: бу дулкыннарның озынлыгы-ешлыгы, тирбәлү амплитудасы иҗтимагый вакыйгаларга бәйле. Димәк, киләчәк татар прозасындагы җылы җилләр, яңа дулкыннарга өмет саклана, һичшиксез саклана әле!

Дулкын күтәрелү чорын мин Фәүзия Бәйрәмова (фәнни-публицистик мәкаләләре, соңрак язылган «Кырык сырт», «Караболак» әсәрләре), Рабит Батулла («Сөембикә», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Яралы бүре»), Мөсәгыйт Хәбибуллин («Шайтан каласы», «Хан оныгы Хансөяр»), Айдар Хәлим («Татар вакыты»), Марат Әмирханов («Тояк эзе»), Вахит Имамов («Сәет батыр»), Флүс Латыйфи («Хыянәт»), Гурий Тавлин («Афәт»), Җәмит Рәхимев («Батырша») һ.б. язучыларның татар халкы дучар булган язмышка ачынып, әрнеп язган тарихи әсәрләреннән башлар идем. «Татар тарихы» темасының бу елларда активлашып китүе рус хакимияте тарафыннан «рөхсәт ителгән» сүз ирегенә бәйле. Совет елларында цензура кире каккан, «милләтчелек»тә гаепләнгән язучыларның әсәрләре дөнья күрде, Гаяз Исхакый мирасы илгә кайтарылды, Шиһабетдин Мәрҗани, Һади Атласи, Риза Фәхреддинов әсәрләре басылды. Милли күтәрелеш иң беренче чиратта «Без кемнәр, урыныбыз кайда?» соравына җавап эзли. Татар тарихының татарча дәреслекләрдә янача бирелеше язучыларны да моңа кадәр сөйләргә ярамаган, яшерелгән тарихны сәнгати тасвирлауга этәрде. Әдипләр, нигездә, роман жанрында эшләделәр («Идел» журналында игълан ителгән «Тарихи хикәяләр конкурсы» тарихи хикәяләрнең дә матур үрнәкләрен бирде). Бүгенге көндә дә Марат ага Әмирханов укырга җиңел булган, кызыклы, сәнгати яктан матур эшләнгән романнары белән татар укучыларын сөендерә.

1990-2009 елларда татар әдәбиятында чынбарлыктан читләштерелгән, мифик, виртуаль дөнья барлыкка килде. Ярымхыялый дөнья татар язучыларын XX йөз башында ук үзенә җәлеп иткән иде инде (Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Мәҗит Гафури әсәрләре). Нәбирә Гыйматдинова («Сихерче»), Фәүзия Бәйрәмова («Алыплар илендә»), Галимҗан Гыйльманов («Албастылар», «Оча торган кешеләр»), Марат Кәбиров («Сагындым, кайт инде», «Чиксез табут», «Хөрмәтле Мәет әфәнде», «Убырлар уянган чакта», «Параллель дөнья») һ.б. язучыларның әсәрләрендә әлеге хыялый дөньяда яшәүчеләр еш кына фани дөнья кешеләренә караганда яхшырак, кешелеклерәк, рухи гүзәлрәк итеп тасвирлана (maratkabirov.comда элленгәннәрдән каладыр, мөгаен). Бу—чынбарлык кануннары һәм җәмгыятьтә барлыкка килгән ямьсез әхлакый сыйфатлар белән килешмәүнең бер төре. Әсәрләрнең күбесе повесть яки роман жанрында язылган. Ә традицион фантастика зур күләмле әсәрләр бирә алмый әле, бу төрдә иҗат иткән Адлер Тимергалин, Радик Фәизов, Заһид Мәһмүди хикәяләр белән чикләнәләр. Татар яшүсмерләрен әдәбиятка тарту өчен татар телендә шундый махсус җыентык булдыру мөһим бурыч булып тора.

Соңгы елларда җәмгыятьтә авыл фаҗигасе үзенең коточкыч тизлеге белән ачык билгеләнеп килә, ләкин дәүләт башлыклары бу мәсьәләгә күз йомуларын дәвам итәләр. Язучылар арасында авыл фаҗигасе темасына беренчеләрдән булып

чан сугучы Нәбирә Гыйматдинова булды. «Идел» журналында басылып чыккан бер цикл хикәяләрендә ул авылда тамыр җәйгән эчкечелекне, ялкаулыкны, зина кылуны, яшьләрнең өметсез киләчәген, чарасызлыгын күрсәтеп, игътибарны авыл мәсьәләләренә җәлеп итәргә тырышты. Алай гына да түгел, «Идел» журналы коллективы тулаем (Ркаил Зәйдулла, Хәбир Ибраһим, Искәндәр Сиражи, Нәгыйм Шаһи һ.б.) һәр санда диярлек авыл проблемасын күтәрә. Фоат Садриевнын «Ватаным Татарстан» газетасында ел башыннан даими басылып килгән «Авылдан хатлар» циклы да шул ук темага җан авазы булып тора. Тик идарәчеләрнең генә колаклары томаланган, күзләре йомык...

Кешеләрнең күңел дөньясы, эчке кичерешләре, әхлакый сыйфатлары язучыларны XXI гасырда да кызыксындыра. Бу темаларны гадәттә язучылар кечерәк күләмле хикәяләрдә ачарга омтылалар (Әхәт Гаффар, Фәнис Яруллин, Ркаил Зәйдулла, Рәмзия Габделхакова, Фәрит Яхин, Зөлфәт Хәким, Вакыйф Нуриев, Рашат Низамиев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, Мәдинә Маликова, Ренат Гаффар, Марат Закир, Заһид Фәйзи, Равил Сабыр, Заһид Мәхмүди, Рафис Гыйззәтуллин һ.б.), шулай да зур күләмле әсәрләрдә дә рухи дөнья үсеше уңышлы гына сурәтләнеп килде. Кеше күңеленең әйләнә-тирәлек, иҗтимагый тәртипләр белән конфликты Рафаэль Сибатның «Ялгызак», Зиннур Хөсниярның «Терсәк сугышы», «Эттән туган», Фоат Садриевнын «Бәхетсезләр бәхете», Камил Кәримовның «Сакау күке», Мансур Вәлиевнең «Идел яры», Фирүзә Җамалетдинованың «Догалы корт», Рәфкать Кәраминең «Олы юл да сикәлтәле» повесть һәм романнарында чагыла.

Татар детектив әсәрләренең дә үз тарихы бар. Соңгы чорда «детектив реализм» термины кулланышка керде һәм җәмгыятьтә булган җинаятьчелек күренешләрен тасвирлап язган әсәрләрне шушы жанр кысасында карыйлар. Әлбәттә, классик детектив күренешне тасвирлап кына калмый, җинаятьнең фаш ителүе белән бергә, эзәрлекләнеп, ана рәсми җәза бирелү процессын да ачарга тиеш. Мәгъсум Насыйбуллин, Мәгъсум Хуҗин, Равил Хаҗиев юлын дәвам итү—киләчәк эше. Әлегә татар детективы Мәдинә Маликова, Тәлгат Галиуллин әсәрләре белән тулыланып килә.

Эзотерика, фәлсәфи уйланулар әдипләрнең күбесендә күренеп китә, шулай да укучылар Солтан Шәмсине эзотерик, Рашат Низамины фәлсәфи юнәлештә язучы буларак истә калдырды. Туфан Миңнуллинның «Кызыл тышлы дәфтәр», «Утырып уйлар уйладым» җыентыкларында күтәрелгән мәсьәләләр дә укучыны битараф калдырмады. Яшүсмерләр, яшьләргә багышлап язылган әсәрләрнең матур үрнәкләре Камил Кәримов, Фәрит Яхин, Рашат Низами иҗатларында чагыла.

Бер үк вакытта поэзия һәм прозада иҗат иткән язучыларыбыз да шактый күп. Аларның күбесе югарыда телгә алынды инде. Бу—Фәнис Яруллин, Айдар Хәлим, Марсель Галиев, Нияз Акмал, Ркаил Зәйдулла, Наис Гамбәр, Зөлфәт Хәким, Эльмира Шәрифуллина, Әхсән Баян, Рашат Низами, Ләис Зөлкарнәй һ.б.

Татар тәрҗемәчеләренең актив эшләве аерым игътибар сорый. Тәрҗемә эше XX гасырда беркайчан да туктап тормаган, һәр чорның үзенең атаклы тәрҗемәчеләре бар (Кыям Миңлебаев, Яхъя Халитов, Рәис Даутов, Лирон Хәмидуллин, Мәҗит Рафиков, Роза Кожевникова, Солтан Шәмси һ.б.). 2007 елда татар проза осталарының Зөмәррә Халитова, Лилия Газизова, Гәүһәр Хәсәнова, Фәридә Ситдикова, Мансур Сафин, Наил Ишмөхәммәтов, Фаяз Фәизов, Булат Хәмидуллин һ.б. тарафыннан тәрҗемә ителгән әсәрләре «Современная татарская проза» җыентыгында дөнья күрде.

Юмор-сатира прозасы да терелеп килә. Ләбиб Лерон, Фәнзаман Баттал, Алмаз Хәмзин, Марсель Галиевларның соңгы елларда чыккан юмор китаплары шул хакта сөйли.

Ниһаять, проза тәнкыйтьчеләре, әдәбият галимнәре турында да аерып әйтергә кирәк. Рифат Сверигин, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Нурмөхәммәт Хисамов, Флүн Мусин, Фәрит Хатыйпов, Хатыйп Миңнегулов, Дания Заһидуллина, Фатих Урманчеев, Резеда Ганиева, Назыйм Ханзафаров, Әлфәт Закирҗанов, Таһир Гыйләҗев, Нурфия Юсупова һ.б. прозага җентекле анализ ясауга һәм аның теориясен үстерүгә керткән өлешләре шактый зур.

Бүгенге көн татар прозасының торышы әнә шундый. Күргәнебезчә, темалар ягыннан кытлык юк. Жанрлар буенча да артык зур проблемалар күренми, күп санлы роман-повестьлар языла тора, һәрберсе диярлек үз укучысын таба. Хикәя жанры исә чәчмә әсәрләр арасында иң тотрыклы, сыйфат ягыннан да алга киткән төрләрнең берсе булып кала. Шулай да татар прозасының бүгенге торышы укучыны канәгатьләндерми. «Проза сүлпәнләнде, ярлыланды» дигән фикер ишетергә туры килә. Шактый күп әсәрләргә анализ ясаганнан соң, соңгы елларда басылган проза әсәрләрен 1960-80 еллар прозасы белән чагыштыру нәтиҗәсендә хәзерге прозаның өч кимчелеген аерып чыгару мөмкин дип саныйбыз: 1. Әдәби эшләнеш кимчелеге: а) идеянең дөрес куелмавы; б) композицион яктан әсәр өлешләренең укучыга дөрес тәкъдим ителмәве. 2. Тел матурлыгы югалу: а) хәрәкәт өстенлек итү; б) сурәтләү җитешмәү; в) татар әдәби тел үзенчәлекләрен дөрес кулланмау; 3. Цензураны (яхшы мәгънәсендә!) алыштыра алырдай әдәби һәм әдәби тел тәнкыйте булмау. Нәрсәдә чагыла соң бу кимчелекләр?

Соңгы елларда татар язучыларының күбесе, реализм тарафдарлары буларак, чын тормыш дөреслеген чагылдырган әсәрләр язу белән мавыгып алдылар. Бу исә еш кына идеянең ачык билгеләнмәвенә, әсәрдә берьюлы берничә идея тәкъдим ителүгә яисә автор үзе әйтергә теләгән фикернең әсәрдә нәкъ киресе раслануга китерде.

Мәсәлән, искиткеч мавыктыргыч композицияле, сыгылма матур телле «Соңгы намаз» әсәренең идеясенә игътибар итик. Әсәр турында матбугатта да язмалар шактый күп булды, нигездә, уңай фикерләр яңгырады. Бу әсәрдә Мәрьямбану исемле дөньяви фәннәр укытучысының дингә килү юлы тасвирлана. Төп герой авырлыклар аша үтә, хыянәт газабын кичерә, тормышта үзенең урынын табу өчен көрәшә. Әйе, хәзерге заманда дин юлы бик четерекле, геройга төрле каршылыклар, якыннарының кабул итмәве, аңлашылмаучылык белән очрашырга туры килә. Укучы моны бик яхшы күреп тора. Димәк, әгәр кеше мондый кыенлыклар аша узарга үзендә теләк, көч һәм тәвәккәллек таба икән, аның киләчәге якты, матур, өметле булачак. Тик укучыны ни көтә соң? Дин юлыннан киткән Мәрьямбануны ире ташлап китә, алай гына да түгел, күрше фатирда яшәүче динсез хатын янына күчә; бердәнбер улы, дин юлыннан китеп, һәлак була; улының сөйгән кызы (яулык япкан, намазга баскан кыз) тиләләр хастаханәсендә интегә; соңыннан Мәрьямбану үзе дә чечен исламчыларының үч алу корбаны булып, шартлау вакытында үлә. «Дин котылгысыз рәвештә һәлакәткә илтә» дигән идея килеп чыга түгелме соң монда? Әллә автор берәр төрле эксперимент-фәлән үткәрәме? Әллә бу иҗат алымы реализм белән бәйлеме? Шулай да әсәр гыйбрәт мисалында тәрбия бирергә тиеш бит. Кайбер муллаларның илле сум сәдаканы азсынып, йөз чытуын күреп торган хәзерге заман укучысын геройга ак кием кидереп, йөзендә нур уйнатып кына дингә тарту, ай-һай, мөмкин микән... Җитмәсә, автор шулкадәр матур әдәби тел белән яза ки, Мәрьям ананың шәһит киткән улы өчен сызланулары йөрәкләрне шулкадәр тетрәтә, әсәр азагында «геройның бу авырлыкларны күрүе ни өчен кирәк булды соң?» дигән сорау тумый калмый...

Мондый әсәрләр татар прозасында берәү генә түгел. Тарихи романнарның күбесендә төп герой һәлак була, җиңелә. Тарихи әсәр нинди максат белән языла соң? Укучыга тарихтан мәгълүмат бирү өченме, әллә шул тарихка мөнәсәбәт формалаштыру өченме? Елганың ике яры, кылычның ике ягы булган кебек, монда да укучыда төрле фикер уяныргa мөмкин. «Никадәр генә көрәшсәң дә, барыбер җиңеләсең: шулай булган, шулай булачак»—бусы беренче һәм иң хәтәр ягы. «Татар халкы нинди авыр газапларга түзгән, алга таба үзебезне якларга кирәк»—бусы икенче, ләкин әсәрләрдә бик көчсез бирелгән ягы. Татар укучыларыннан кайсысының үзен мескен, җиңелгән хәлдә күрәсе килсен? Әлбәттә, тарихи дөреслек бар. Документальлеккә нигезләнгән очракта да, аерым герой язмышында киләчәккә өмет чагылмаса, укучы күңелендә бушлык барлыкка килә. «Әдәбият ул—корал» дип тикмәгә генә әйтмибез ич...

Татар әдәбиятында үзенчәлекле композициягә корылган әсәрләр шактый. Татар укучысы яратып укыган әсәрләрдә көтелмәгәнлек һәм фаҗигалелек принцибы

сюжет коруда төп көчләрнең берсенә әйләнде[1]. Сюжет ул—герой башлаган көрәш. Төп герой алдына куелган дилемма-каршылык кризис-конфликтка әйләнеп, ул хәл ителгәнчегә кадәр булган көрәш. Кайбер очракта авторлар (бигрәк тә шәхси тормыш материалларына нигезләнеп язучы яисә шәхси тормышларын тасвирлаучы авторлар) бу турыда онытып җибәрәләр һәм герой көрәшенә бернинди мөнәсәбәте булмаган вакыйгаларны сурәтлиләр[2]. Әлбәттә, алар автор йөрәгенә бик якын, бик кадерле, язучы бу күренешләрне шулкадәр яратып, матур тел белән тасвирлый тасвирлавын, тик... Укучы вакыйгаларның артык булуын сизеп ала.

Сюжет, композиция һәм тел. Вакыйгаларны тасвирлауда игътибар җитмәгән күренеш—ни гаҗәп!—фигыльләрнең кулланылышы. Әйтик, вакыйгалар бер-бер артлы бара, көтелмәгәнлек, кискенлек юк, язучылар—*ды* кушымчалы категорик үткән заман фигыль формасы кулланалар (торды, юынды, ашады, киенде, китте һ.б.). Фигыльнең бу шәкеле үткәндә һичшиксез булган эш-хәлләрне катгыйлык белән белдерә. Әгәр ярты бит дәвамында һәр җөмлә—*ды* фигыленә тәмамланса, эпиклыкка корылган тасвир югала, тел аһәңе дә бозыла. Ә конфликтны, кульминацияне яисә кискен вәзгыятьне тасвирлаганда, әлеге форманы еш куллану үзен аклый: кушымчада яшеренгән катгыйлык мәгънәсе калкып чыга. Кабатланып килгән кушымчаларның кирәкмәгән урында ритм барлыкка китерүеннән җөмләләрне озайту, киңәйтелгән иярчен кисәкләр, иярчен җөмләләр кушып җибәрү юлы белән котылып була. Татар телендә фигыльнең тугыз заман формасы һәм аларның тагы бик күп өстәмә мәгънәләре бар ич әле! Заман шәкелләрен аралаштырып куллану чәчмә әсәрләрнең төп сыйфатын—эпиклыкны тәэмин итә.

Диалогларның бирелеше дә кайбер очракларда канәгатьсезлек хисе уята. Һәр репликаны «диде, дип, дип әйтте, дип сорады» сүзләренә тәмамлау шулай ук текстның тел матурлыгын боза. Бу яктан чит ил язучысы Джоан К.Ролинг әсәрләре үрнәк булырлык: барлык репликалар да диярлек геройның хәрәкәтен тасвирлаган сүзләр белән бетә. Бу—табигый, чөнки кешенең сөйләме һәрвакыт кул, гәүдә хәрәкәтләре, мимика ярдәмендә тулыландыра һәм аларны күрсәтү геройның холык-фигылен, шәхси сыйфатларын ачарга да, интонациясен бирергә дә ярдәм итә.

Кызганычка каршы, бүгенге көн проза әсәрләрендә автор сөйләменнән башка оештырылган диалоглар күбәйде. Зур күләмдә (кайбер әсәрләрдә берәр бит тоташ репликалар бирелә) мондый төрдәге диалоглар үзен акламый, чөнки чәчмә әсәр эпиклыгын югалта һәм драматургия жанрына якыная. Хәтта әсәрләренә җанлылык, халыкчанлык өстәү өчен кара-каршы сөйләшүне бик яратып кулланган М. Мәһдиевтә дә андый диалоглар юк.

Персонаж һәм автор сөйләме турында сүз барганда, берничә үзенчәлеккә кыскача тукталасы килә: 1) персонаж сөйләмендә диалекталь сүзләр кулланылырга хаклы, чөнки алар образ турында мәгълүмат бирәләр. Автор сөйләмендә диалекталь сүзләр һәм бигрәк тә диалекталь морфологик формалар бик сирәк очракта—әдәби телдә аларга тәңгәл сүзләр (эквивалентлар) булмаган очракта гына кулланылырга мөмкин. Бүгенге көн татар прозасында исә әдәби телгә диалекталь һөҗүм бара; 2) автор сөйләмендә алынмалар әдәби телдә шул ук мәгънәдәге сүз булмаганда гына кулланыла алалар, әгәр телнең үз сүзе булса, алынманың кирәге юк. Бер тел алынмасын икенче тел алынмасы белән алыштыру телнең ясалмалыгына китерә; 3) әдәби тел тупас, фамильяр сүзләрдән, гади сөйләм, сүгенү элементларыннан азат булырга тиеш!; 4) җөмләдә сүзләрнең туры тәртибе лирик хикәяләүдә, тойгылы сөйләмдә һәм персонаж сөйләмендә генә үзгәрергә мөмкин. Калган очракта автор сөйләме сүзләрнең туры тәртибенә нигезләнә.

Татар прозасында сүз бизәкләре куллану алымы бөтенләй югалып бара. Югыйсә һәр язучы белеп тора: «Бүген көн матур» дип әйтүгә караганда, аны сурәтләп бирү укучыга ныграк тәэсир итә. Авторлар төсләрне күрә белми, әдәбияттан рәссамнар юкка чыкты. Кеше күңеле дөньяны хискә бәйле рәвештә кабул итә: әгәр аның күңеле сулкылдап әрни икән, ул яз матурлыгын күрә алмый; әгәр герой күңелендә

[1] Гөлчәчәк Галиева. Зифа Кадыйрованың повестьларында укучыны нәкъ менә көтелмәгәнлек принцибы җәлеп итә.

[2] Рәфкать Кәрами. Олы юл да сикәлтәле.

шатлык мәтәлчек атса, тоташ янгырлы көзнең соры көне дә анын өчен елнын иң матур вакытына әйләнә. Язучылар дөньяны кабул итү үзенчәлеген сурәтләүдән баш тарталар: алар өчен хәрәкәт мөһим. Ә бу, үз чиратында, сүз-сурәтнен ярлылануына китерә...

Әдәбияттагы уңай, алдынгы күренешләр турында да әйтәсе килә. Бүгенге көн прозасында яна алымнарнын берсе—«кадрлы сурәтләү». Икенче төрле аны «клип рәвешендә тасвирлау», «интермедиаль сыйфатлы сюжет» дип тә атыйлар. Әсәрдә вакыйгалар, клиптагы кебек, бер-берсен еш алыштырып бара һәм үзенчәлекле тасвир барлыкка килә. Асылда бу форма әдәбиятта күптән кулланыла инде («Мең дә бер кичә»не искә төшерү дә җитә), хәзерге чорда бары тик әлеге «кадр»ларны еш алыштыру гына күзәтелә. Мондый алым белән язылган әсәрләрдә гадәттә кискен конфликт күренми, үзара аз бәйләнгән, ләкин бер жеп-сюжетка тезелгән вакыйгалар персонажларнын холык-фигылен ачарга ярдәм итәләр. Мәсәлән, «Догалы корт» повестенда төп вакыйгалар Илгизә тирәсендә куера, алар кызнын, анын әбисенең үткәненнән картиналар белән киселәләр, еш кына башка язмышлар килеп керә. Автор картиналар белән оста эш итә: читтәге (перипетиядәге) вакыйгалар төп сюжет линиясенә табигый рәвештә ялганып, аны тулыландырырга ярдәм итәләр.

Композицион өлешләрне ялгауда авторның тәҗрибәсе, осталыгы зур роль уйный. Вакыйгалар тарихи вакыт буенча төрле сызыкка урнаштырылса да, бердән, логик эзлеклелек сакланырга тиеш; икенчедән, мондый бүленеш укучының кызыксынуын арттыру максатында кулланыла ала. Бу яктан «Соңгы намаз» әсәре бик уңышлы корылган: бүлек ахырында автор киләчәктә булачак вакыйгалар турында искәртү юлы белән игътибарны җәлеп итә: «Әмма бу көрәшнең инде ахыры якынлашып килүен, үзенең бик тиздән терелә́й утта янасын Фабарисов әле белми иде...»; «Әмма үзе өчен бу төннең соңгы төн икәнен ул әле белми иде...» һ.б.

«Сурәтләү ярлыланды» дип әйтсәк тә, матур, сыгылмалы тел белән иҗат иткән язучыларыбыз барлыгын да онытмаска кирәк. Аларның күбесе классик язучылар остазханәсендә тәрбияләнгәннәр, алар белән аралашып, әсәр язу сәнгатен үзләштергән осталар. Фәүзия Бәйрәмова, Марат Әмирханов, Ркаил Зәйдулла, Камил Кәримов, Мансур Вәлиев, Вакыйф Нуриев, Фирүзә Жамалетдинова, Рәмзия Габделхакова әсәрләрендә классик татар әдәби теле үз югарылыгын саклап килә.

«Әдәбиятның киләчәге—яшьләр кулында» дип кабатларга яратсак та, прозага киләчәк яшьләр әлегә Галиҗәнап Шигърият куенында иркәләнә. Күпмедер вакыттан соң шигырь галәмендә сүз-сурәт бизәкләрен отып алганнарның кайберләре хикәя яза башлар, беренче повестьлары дөнья күрер һәм... классик әдәби телебез балкып, янадан кабынып, очкыннарын йолдызларга үрләтер. Әлбәттә, киләчәк шигъриятен Ленар Шәехтән, Йолдыз Миннуллинадан, Лилия Гыйбадуллинадан башка күз алдына китерү мөмкин түгел, ә менә Гөлнара Сибгатова, Лилия Закири, Айдар Җамалиевларны мин нигәдер проза дөньясына юл алырлар дип өметләнәм. Рифат Салаховны булачак детектив остасы итеп күрәсе килә. Әлегә проза мәйданына курыкмыйча бил алышырга чыккан һәм берүзе күпләргә каршы торырлык Рөстәм Галиуллиныбыз бар, Айсылу Имамиева, Эльвира Кәлимуллина, Зөһрә Мостафина кебек кызлар-йолдызларыбыз баш калкыта...

Яшьләр килә, димәк—яна дулкын килә!



Афзал
Шамов

# ШУК ХАТИРӘЛӘР*

### Бик кыска доклад

Мөхәммәт Гали абый ачык чырайлы, сизгер күңелле, кеше хәленә керә белүче язучыларның берсе иде. Кайчак ул, унайсызрак хәлдә калган минутларда, нәрсә әйтергә белмичә, аптырый, басар урынын таба алмый, гадәтенчә, ике кулы белән чалбарын күтәргәләп куя, кызара, ояла иде. Замандашларымнан ояла, кызара белмәүче кайберәүләрне күз алдымда тотып, мин аның бу үзенчәлеген иң матур сыйфатларыннан берсе итеп санар идем.

Бөек Ватан сугышы елларында аны Татарстан Язучылары Союзы янындагы профсоюз месткомының рәисе итеп сайлаганнар. Тылда калган иптәшләрнең сөйләүләренә караганда, Мөхәммәт абый бу эшне яратып, бөтен көчен биреп эшләгән. Аңа шундый авыр, җаваплы елларда рәис булып эшләве ансат булмагандыр дип уйлыйм. Эш күп, ярдәмчеләр аз. Кулына корал тотарлык язучыларның барысы да диярлек фронтта, сугышта. Кайберләре инде каты сугышларда батырларча һәлак булган. Гаиләләренең, бала-чагаларының хәлләре авыр. Кыш кергән, ягарга утыннары юк. Кайберләренең пальтолары, аяк киемнәре булмаганлыктан, балалары мәктәпкә йөри алмый, һәм башка, һәм башка шунын кебек мохтаҗлыклар. Боларның барысы турында да местком кайгыртырга, ул ярдәм итәргә тиеш.

Шуның өстенә, сугышның беренче елында немец фашистлары тарафыннан оккупацияләнгән көнбатыш өлкәләрдән, Мәскәүдән эвакуацияләнгән язучылар һәм аларның гаиләләре Казанга өзлексез килә торалар. Татарстан Язучылар союзы бүлмәләре, Г. Тукай исемендәге клуб, Матбугат йортының коридорлары, баскычлары, кеше аягы басып торырлык бөтен урын язучылар, аларның гаиләләре, әйберләре, чемоданнары, алып килергә мөмкин булган урын-җирләре һәм башка шунын кебек нәрсәләр белән тулган. Бу язучыларны фатирларга урнаштырырга, алар турында кайгыртырга кирәк. Бу да Союз идарәсе белән берлектә местком өстендә. Мөхәммәт абый бу эш белән йөри, йөгерә...

1946 елны, көз айларының берсендә, исән калган язучыларыбыз Совет Армиясе сафыннан кайтып беткәннән соң, месткомның отчет һәм сайлау җыелышы булды. Җыелышта кеше күп иде. Армия сафыннан яңарак кайткан иптәшләрнең күбесе хәрби киемнән. Кайберләре орденнарын, медальләрен дә тагып килгәннәр.

Месткомның отчет докладын Мөхәммәт абый ясады. Доклад өчен регламент билгеләнгән идеме, юкмы—анысын хәтерләмим. Әмма шунысы бик ачык хәтердә: гомеремдә минем беркайчан да әле бу кадәр кыска, бу кадәр аз сүзле докладны тыңлаганым юк иде. Ул күпме дәвам иткәндер—өч минутмы, бишме, әллә алты-җиде минутмы? Белмим, ул кадәр үк булдымы икән? Булмагандыр. Һәрхәлдә, бик кыска

* Беренче тапкыр басыла.

булды. Хәрефкә-хәреф туры китереп булмаса да, кыскача, йомгак ясап әйткәндә, аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт иде.

—Безне 1941 елның фәлән аенда, фәлән көнендә сайладылар,—дип башлады ул докладын.— Без бөтен көчебезне биреп эшләдек. Көн димәдек, төн димәдек, йөгердек, хәтта кайчак өйгә кайтып кунарга да туры килми иде. Бигрәк тә эвакуация белән килүче язучыларны каршылаганда шулай булды... Кыскасы, Казанга килүче язучыларны каршыладык, фатирларга урнаштырдык, китүчеләрне озатып калдык, үлгәннәрен күмдек. Без узган биш ел эчендә көчебездән килгән кадәр солдаткаларның да күнелләрен табарга тырыштык. Җыйнаулашып бармасак та, һәрвакыт диярлек яннарына аерым-аерым барып, күңелләрен табып кайта идек. Бездән бик мәмнүн булып калалар иде. Шаять, алар безнең тырышлыгыбызны онытмаслар.

М. Галиненң сүзе шуның белән тәмамланды. Аннары фикер алышулар башланды. Беренче булып Абдулла Әхмәт сүз алды. Ул әле моннан бер атна элек кенә Армия сафыннан кайткан, погоннарын да салып өлгермәгән, ордены белән медальләре дә түшендә. Күңеле күтәренке. Хәер, болай да тиктормас җан иде ул. Теленә шайтан төкергән иде аның. Бер генә түгел, берничә шайтан төкергән булса кирәк, чөнки ул, берәр кызыграк фикерне яисә сүзне тотып алып, аны шундук шаяртуга бора, мәзәкли, нинди дә булса берәр кызык уйлап чыгарырга ярата иде. Ләкин бу юлы ул сүзне бик җитди төс белән башлады:

—Докладың бик ошады, Мөхәммәт абый,—диде,—бик эчтәлекле булды. Без фронтларда дошман белән сугышып йөргәндә күп эшләр башкаргансыз икән. Моның өчен сезгә бик зур рәхмәт! Тырышкансыз, көчегезне кызганмагансыз...

Мөхәммәт абый бу мактау сүзләреннән канәгать иде, күрәсең, әлеге иптәшнең сүзен ачык йөз белән җөпләштергәләп торды:

—Кулдан килгәнчә тырыштык инде, син...кем... Тырышмыйча... Еллары нинди иде бит аның...

—Хатыннарыбызның да күңелләрен тапкалап torгансыз икән.

—Тапмыйча бит. Без тапмагач, кем тапсын аны? Барыгыз да фронтта...—диде Мөхәммәт абый, юморист егетнең тел төбе кая барганын сизмичә.

—Бурычыгызны бик яхшы үтәгәнсез, ахры. Хатыннарыбыз бик риза булып калганнар булса кирәк. Армия сафыннан кайтуыма инде иртәгә менә бер атна була. Ә хатынымның әле урын җәеп янына яткырганы юк,—диде Абдулла Әхмәт, беркадәр тавышын күтәреп.—Сере нәрсәдә икән моның дип исем-акылым китеп йөри иде. Хәзер, Мөхәммәт абыйның докладын тыңлаганнан соң гына сәбәбен аңладым. Чыннан да, сәбәбе бар икән. Без сугышларда кан коеп йөргәндә, атакаларга барганда, илебез өчен җаныбызны аямаганда, Мөхәммәт абый безнең хатыннар янына барып, аларның күңелен тапкалап йөргән икән. Докладчы үзе әйтмешли, шуны онытмыйлар икән алар...

Бөтен җыелыш шаркылдап көлеп җибәрде, мескен Мөхәммәт абый исә катып калды, йөзе ап-ак булды, хәтта теле дә тотлыкты:

—Тукта әле, тукта әле, син... кем, кызма әле ул чаклы. Алай дигән сүз түгел бит ул,—диде.

—Ничек инде алай дигән сүз түгел?—диде юмористыбыз бик җитди төс белән. —Докладыңда үзен әйттең ич. Шулай дидең, солдаткалар янына барып, күңелләрен тапкалап кайта идек, дидең. Шаять, бездән зарланырлык урыннары юктыр, дидең. Йә, әйтмәдеңме?

Мөхәммәт абый, нәрсә әйтергә белмичә, һаман да әле, катып калып, аңа карап тора иде.

Абдулланың тоны бераз йомшара төште:

—Ярар инде, Мөхәммәт абый, ул чаклы калтырама. Гафу итәбез. Нишлисең бит, сугыш! Сугыш!

Ә Мөхәммәт абый нидер әйтергә тели, әйтә алмый иде.

Юмористыбыз, аның бу кадәр аптыравын күреп, түзмәде, шаркылдап көлеп җибәрде:

—Әй, Мөхәммәт абый, Мөхәммәт абый, бер дә мәзәкне аңламыйсың икән син!- диде. Мәзәкләп әйтүем бу минем.

Бу сүзләрне ишеткәч тә әле М. Гали, анын шаяртып сөйләгәнен аңлап бетермичә, кып-кызыл булып басып торуында дәвам итте.

Зал инде шаркылдавыннан туктый алмый иде. Жыелыш рәисе тәнәфес игълан итәргә мәжбүр булды.

## Кем белгән аны

Бер елны Хәсән Туфан Аккош күле буендагы дачада язучы Нәби Дәүли белән бер йортта торды. Н. Дәүли гел Казанга кайткалап йөри. Кайчак атналар буенча килми тора. Берзаман килсә, ни күрсен, кухня идәнен дә, коридор идәнен дә су баскан, атлап керерлек түгел.

Дәүли бик гажәпләнеп:

—Каян чыккан бу су?—дип сорый Хәсән Туфаннан.

—Белмим, каян чыккандыр. Үзем дә гажәпләнәм,—ди шагыйрь.—Әле ярый идәнгә жәяргә кирпечләр булды.

Кухняга керәләр. Керсәләр... умывальник астындагы чиләк ташыган икән. Дәүли, ачуланып:

—Юынтык суны түкмәгәнсең ич!—дип кычкырып жибәрә.—Шул ташыган! Түккәләп торырга кирәк иде.

—Ул кадәр чәпчемә әле син,—ди аңа каршы шагыйрь тыныч кына.—Аны түгәргә кирәк икәнен кем белгән.—Шул сүзләрне әйтә дә, идәнгә тезеп салган кирпечләргә баса-баса үз бүлмәсенә кереп китә.

## Савыт-саба үз урынында

Хәсән Туфан белән Абдулла Әхмәт бер-берләренә кода тиешле кешеләр иде. Жимеш бакчалары да бер үк жирдә. Күрше генә.

Абдулла Әхмәт аш-су пешерергә оста, Хәсән исә киресенчә. Ашаса—ашый, ашамаса—юк.

Бер көнне шулай А. Әхмәт иртә белән тәмле әйберләр пешерә дә Хәсәнне чәйгә чакырырга бара. Тәрәзәсеннән караса, шагыйрь башын күтәрмичә язып утыра. «Димәк, чәй эчкән икән»,—дип уйлый кодасы, эшеннән бүлдерергә теләми.

Көндез барса, көндез дә язып утыра Туфан. «Ах, бу юлы да чакырырга өлгермәдем бит»,—дип кайтып китә А. Әхмәт. Ахырда кич белән, караңгы төшкәч, түзми, кодасын чакырырга тагын бора. Ни күрсен, Туфан һаман язу өстендә. Шулай да тәрәзәсен шакып.

—Әй, Брамат[1], итле ботка пешергән идем, әйдә, бергәләп утырыйк әле,—ди.

Шагыйрь, каләмен куеп, бераз уйланып тора да әйтә:

— Әле генә ашадым мин, Абдулла,—ди.—Рәхмәт! Бар, үзең генә аша. Бетерәсе эшем бар.

А. Әхмәт тагын китеп бара.

Бераздан аның янына Хәсән Туфан үзе керә:

—Кара әле, Абдулла, ботканы бетмәгән булса, бераз бир әле,—ди.

—Ашадым дип әйткән идең ич.

—Ашамаганмын икән шул,—ди Хәсән.—Кухняга чыгып карасам, савыт-саба урыныннан кузгалмаган, кичә жыеп куйган хәлдә тора. Ашаган булсам, урыныннан кузгалган булыр иде.

[1] Брамат—Х. Туфан яшьлек елларында Брамат сүзен күп кулланганга,кайбер дуслар аңа «Брамат» дип дәшкәлиләр иде.



Фәнис Яруллин

# БЕРЛЕК БЕРДӘМ БУЛСА ГЫНА

Без, бер төркем әдипләр, шагыйрьләр 60нчы еллар башында яңа көчле агым булып әдәбиятка килдек. Р. Фәйзуллин—табышмакка, мәкальләргә тартым кыска шигырьләре, Р. Гаташ—лирикасы белән яшьләрне үзенә тартты. М. Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов һәм бу юлларның авторы татар әдәбиятына яңа сулыш өреп җибәрде. Ул елларда Татарстан Язучылар союзының дәрәҗәсе бик зур иде. Мин армиядән имгәнеп кайтып шигырьләр яза башлагач, яныма кемнәр генә килмәде: М. Шабаев, Г. Бәширов, Р. Гәрәй, А. Гумеров, М. Хөсәен, Г. Шамуков һәм башкалар. Шушы олы язучыларның Казаннан 400 чакрымдагы Кызылъярга килеп, минем дәфтәремнән шигырьләр сайлап газета-журналларга биреп бастырулары, беренчедән, өлкәннәрнең яшьләргә игътибарлы булуын, икенчедән, минем шигырьләрдә ниндидер яңа очкын күреп, шуны үстерү теләге көчле булуын күрсәтә иде. Әгәр Язучылар берлегенең дәрәҗәсе зур булмаса, бернинди документсыз, паспортсыз-нисез бер бүлмәле фатир алып Казанга күчә алыр идемме икән? Нинди генә талантлы булмасын, әгәр аны вакытында күреп, күтәреп алмасалар, талантның сүнүе мөмкин.

Язучылар союзының кирәклеген мин менә шунда аңладым.

Үткәннәргә бераз экскурс ясамыйча бүгенгегә килеп төшсәм, сүзләрем дәлилсез булып тоелыр иде. Хәзер әдипләр, шагыйрьләр арасында «Язучылар берлеге кирәкме, юкмы?» дигән сорау кузгалып куйгалый. Бер уйлаганда, кирәкми кебек. Чөнки һәр язучы үз өендә иҗат итә. Теләсә яза, теләмәсә язмый. Беркем дә: «Син нигә язмыйсың?»—дип сорамый. Әмма күңеленә иҗат очкыны салынган кеше ул очкыннан учак кабызырга һәм учагының ялкыны мөмкин кадәр югарырак күтәрелүен тели.

Хәзер 60нчы еллардагы Ренессанс чоры үтте. Элеккеге Язучылар союзы таркалды. Безнең милләтебез 90нчы елларда бер уянып алган иде. Ләкин туктаусыз башка сугулар халыкны бераз миңгерәүләтте. Милләтебез рухи деградация чорына килеп керде. Менә шушындый вакытта язучыларыбызның бердәм булып, заманның яхшы һәм яман якларын төрле яссылыктан, төрле позициядән торып сурәтләп күрсәтүләре мөһим. Сәясәтчеләр, без демократик ил төзибез, без ирекле гражданнар, диләр. Ләкин безнең ирек муенчакка бәйләп куелган бозау ирегә кадәр генә. Муенчакның бавы кайчак озынаеп ала. Шул чакта без биеккәрәк сикерә алуыбызны күрсәткәләп куябыз.

Җәмгыятьтә барган барлык күренешләрне әдәбиятка кертеп калдырмасак, хәзерге чорны киләчәк буыннар ялган тарихлардан гына укып беләчәк. Әдәби әсәрдә вакытның сулышы, фикер үсешенең бормалы да, упкынлы да юллар аша үтүе барлык нечкәлекләре белән сурәтләнеп күрсәтелә.

Үз-үземә сорау куям: дәүләтчелеге булмаган халыкка Язучылар берлеге кирәкме, юкмы? Әйе, кирәк. Язучылар халыкның рухы булырга тиеш. Борын-борыннан килгән әхлагыбыз, гореф-гадәтләребез, телебез, милли менталитетыбыз әдәбият һәм башка төр сәнгать әсәрләре аша халык күңеленә гел сендерелә барганда гына без үз йөзебезне саклап кала алабыз. Хәзер безнең Берлектә әгъза булып торучылар гына да 300дән артык. Ә әгъза булмаганнар... Әдәбият мәйданына килеп кердеңме, нинди генә стильдә язма, ничек кенә фикер йөртмә, син әдәбият кануннарына, элгәрләрнең тәҗрибәсенә таянырга тиешсең.

Әдәбиятның үз кануннары, үз проблемалары бар. Алга килеп баскан проблемаларның чишелешен эзләргә Язучылар берлеге кирәк. Зур язучыларның юбилейларын үткәрергә, тегe яки бу әдипне Дәүләт бүләкләренә тәкъдим итәргә, үлем-китем булган очракта мәрхүмне җирләргә дә Берлек кирәк. Әдәби ел йомгакларына җыелып уңышлар һәм кимчелекләр турында сөйләшү дә бик әһәмиятле эш. Башлап язучыларга әдәбият дәресе булса, тәҗрибә туплаган өлкән әдипләргә үз иҗатларын башкаларныкы белән чагыштыру өчен кирәк ул. Кемдер матди яктан авыр хәлдә кала. Мондый очракта каләм иясе ярдәм сорап кая барсын? Әлбәттә инде, үзе әгъза булып торган язучылар оешмасына.

Билгеле, СССР чорындагы мөмкинлекләр хәзер юк инде. Элек хастаханәгә керсәң, язучыга «больничный» түләнә иде. Язучылар карамагындагы Әдәби фондның мөмкинлекләре зур, СССРның барлык нәшриятларында чыккан һәр китапның күпмедер проценты шунда җибәрелә һәм шушы фонд язучыларга Иҗат йортларына юлламалар бирә; бу исә төрле республикадан килгән әдипләргә үзара аралашу юллары ача иде. Зур әсәр еллар буе языла. Ә әсәрен басылып чыкмыйча гонорар түләнми. Мондый очракта тагын Әдәби фонд ярдәмгә килә иде. Дөрес, мин үзем, билгеле сәбәпләр аркасында, Иҗат йортларына бармадым, төрле жанрларда эшләвем ярлылыктан коткара килде.

Хәзер без, аерым Берлек буларак, мондый мөмкинлекләрне югалттык. Мәскәүнең үзендә дә берничә Язучылар союзы барлыкка килде. Китапларның тиражлары нык кимеде. Хәтта элеккечә Россия Язучылар союзына кушылган очракта да без әлләни отмас идек.

Безгә хәзер шушы мөстәкыйль Берлегебезнең абруен күтәрү турында уйларга кирәк. Ничек итеп? Беренчедән, аралашу каналларын киңәйтү юлы белән. Икенчедән, үзебезнең әдәбиятыбызның зурлыгын күрсәтергә кирәк. Хәзер безнең турыдан-туры чит илләргә чыгу мөмкинлегебез бар. Кемнәрнеңдер китаплары Төркиядә, Кытайда яки башка илләрдә басыла. Ләкин бу эш аерым язучыларның шәхси тырышлыгы аркасында гына эшләнә. Башкортстанда безнең күп кенә шагыйрьләребезнең китаплары чыкты. Ләкин бу бәхет минем үземә әлегә тәтегәне юк. Юкса бездә ПЕН-үзәк тә бар. Аның аша да кемнәрнеңдер китаплары төрле телләрдә басылып торадыр. Дөреслек хакына әйтеп китим: ничәдер ел элек бер хикәямне инглиз телендә чыккан хикәяләр җыентыгына керткәннәр иде. Ә бит минем «Яралы язмышлар» повесте «Рухият» нәшрияты аша татар, рус һәм инглиз телләрендә бер китап булып басылып чыкты. Хәзер бөтен газета, журналлар һәм телевидение ятим балалар турында чаң кага. Ә минем повесть язылганда ул теманы матбугат органнары читләтеп уза иде. «Яралы язмышлар»ның йөзләгән данәсен Америкага һәм Кытайга җибәрдек. Алар аны мәктәпләрдә укыдылар. Ә бервакыт Казан университетында укучы 26 кытай студенты безнең өйгә килде. Алар мине шушы әсәр буенча беләләр икән.

Сүземне кыска гына тотмакчы идем. Ләкин күңелгә җыела килгән вакыйгалар шактый булып чыкты.

Йомгаклау рәвешендә бүгенге Язучылар берлеге турында берничә сүз әйтми ярамас. Миңа калса, Берлек җитәкчеләре ярыйсы гына эшли. Мин алар белән һәрвакыт элемтәдә торам. Мине онытып җибәрсәләр, үзем шалтыратып, Берлектә нинди эшләр эшләнүен сорашам. Кайбервакыт кискенрәк тә әйтеләдер, бәлки, ләкин фикер каршылыклары килеп чыкканы юк. Әлегә тәнкыйть сүзен кабул итәргә көчләре җитә. Киләчәктә дә шушы көчне җуймасыннар иде. Берлек бердәмлек белән көчле ул.

Безнең илдә йә дефолт, йә акча реформасы, йә кризис булып тора. Матди яктан ярлылана баруны рухи байлыгыбыз белән каплыйсы иде. Иң мөһиме шул: яшьләр пассив булмасын иде. Кыю сүзле өлкән язучыларыбыз кимеп бара. Ә менә 60нчы еллардагы кебек үз стиле, үз темасы, үз проблемалары белән ташкын булып әдәбиятка килүчеләр юк. Ә бит җәмгыятьнең иң тулышкан шешләрен яшьләр ярырга тиеш. Әгәр язган әсәрләрне чыгару кыен дип каләмеңне ташласаң, китап сатылмауны сылтау итеп чыгарудан туктасак, барыбер татарны беркем аңламый дип русча гына сөйләшә башласак, милләтебезнең тамыры бик тиз корыячак.

Милләтебез яшәсен өчен Язучылар берлеге белән дә, аерым-аерым да туктаусыз көрәшергә кирәк. Бергә-бергә көрәшкәндә генә рухыбыз ныгыр. Дөньяга самолетлар, машиналар белән чыга алмаячагыбызны күптән аңладык. Без бары тик көчле язылган әдәбиятыбыз белән генә үзебезнең татарлыгыбызны белдерә алабыз.

Татарстан Язучылар берлеге талантларга юл ачучы булсын.



Адлер
Тимергалин

# ТИКӘН-ТИГӘНӘКЛӘР АША—РУШАН ЙОЛДЫЗЛАРГА ТАБАН

(КҮҢЕЛДӘГЕ ТӨЕННӘР)

*Халкы нинди булса, хөкүмәте шундый диләр. Әдәбияты да халыкның үзенә лаек: олыныкы—олуг, кечененке—кечек.*

Юбилейлар үткәрүгә гадәтләнеп, хәтта моңа остарып, тәмам шомарып беткәнбез. Юбилей тантанасы безгә бүгенге кыенлыкларны онытып торырга да ярдәм итәдер сыман. Турысын әйткәндә, бу тантанада, бу ыгы-зыгыда үз-үзеңне ... алдау да бар. Һәркемнең үзен тарихта эзле итеп күрәсе һәм күрсәтәсе килә. Гәзит-журналлар да әнә үзләренә «картрак» элгәр эзләп табалар.

Татарстан язучылар берлеге исә табигый исемен үзгәртмәде дияргә мөмкин. Болгавыр туксанынчы елларда мәскәүнекеләр үзара талашып, бүленеп, аерылышып беткәндә безнең берлегебез бердәм гаиләсен саклап кала алды. Һәм менә ана бүген 75 яшь.

Әүвәлгеләр әйтмешли, аның «юбиләсе» гәзит-журнал, радио-телевидение, театр эшлекләләре, кинематографистлар яки рәссамнар берлеге юбилееннан үзгәрәк, колачлырак, шанлырак һәм әһәмиятлерәк булыр.

Язучылар берлегендә журналист та, диктор, артист, галим яки рәссам һ. б. да әгъза булып тора ала. Аларны монда фикер һәм идея уртаклыгы гына түгел, фикер һәм карашлар төрлелеге дә берләштерә кебек. Аннары, гомумән, дөньядагы бөтен нәрсә Сүздән башлана бит. Әдип кеше сүздән сурәт ясый. Аңәнле жыр һәм мәдхияләр тудыра, сәхнәләр һәм пирамидалар төзергә ярдәм итә. Әдиптән башка, кино да, телевидение дә юк. Театр да юк... Гүзәллекне аңлау да, аңлатып бирүче дә юк.

Әдипләр берлеге шакмакларга бүленгән ботаника бакчасыннан бигрәк, каенсар уртасындагы шау чәчәкле табигый (кыргый) аланга тартым. Казан ханлыгы егылган заманда Төркиядә солтан булып торган Сөләйман Канунинын: «Чәчәкләрнең төрлелеге аларга ямь генә өсти» дигән акыллы сүзләре искә төшә. Дөрес, ул бу фикерне Истанбулда яшәүче тигез хокуклы һәм төрле кавемнәргә карата әйткән. Анысы да теориядә дөрес сүз, практикада гына башка.

1934 елда, сталинчыл тоталитар режим ныгып урнашкан заманнарда, Татарстан Язучылар берлеге оешканнан соң, берсе-берсе ун зәмһәрир кышка торышлы озын-озак еллар кичелгән. Гомумән, СССР Язучылар союзын оештыру әдипләрне бәйдә, тезгендә тоту өчен эшләнде, без монысын да истән чыгармаска тиеш.

Кая алып барачагы билгесез сикәлтәле юллар үткәнбез... Юл буендагы хисапсыз түмгәкләр—барысы да исемсез каберләр икән... Шулар арасында Галимҗан

Ибраһимов, Бурнаш, Тинчурин гүрләре дә булырга тиеш. Бу түмгәкләр—кешелексез совет чоры маяклары. Гүрдәгеләр безгә алашмаска ярдәм итәләр.

Җәяүле татар язучысы, биштәрен асып, абына-сөртенә Себер барган сукмакларны һәм ташландык лагерь хәрабәсен бүген әрсез тикән баскан, ә кайсыдыр бер даһи уйлап тапкан чәнечкеле тимерчыбык череп беткән инде... Җәен барак җимерекләрендә божаннар кайнаша, кышын монда—елак җил оясы. Зоналарны каравыллаучы тана хәтле этләр, битараф хуҗалары ташлап киткәч, кыргыйлашып беткәннәр дә, алардан яралган кушылгаклар адәмне дошман күрә торган өерләр булып оешкан... Ут пошкыра торган калашниклы хуҗаларыннан кешелексез сыйфатларны отып калган бу азманнардан тайга бүресе генә түгел, селәүсен дә ерак булу ягын карый имеш.

Татар каләм әһелләре тормышында һәм язмышында очраган тикәннәрдән аеруча «мәшһүре»—ин зәһәре—ул да булса үлгәнче Такташлардан көнләшеп, шул ук вакытта үзенең исән калуына сөенеп яшәгән Мөсәгыйть дигән мәҗик. Совет чорында татар язучылары бакчасында куркынычлы карачкыга әйләнгән журналист Мөсәгыйть турындагы язмаларын әдип Батулла үзенең махсус томына кертеп. Аның мәкаләсе «Карчыга» дип атала, укучым. Табып укырга тырыш. «Яшь чак, кулда пычак, турадык та турадык»,—дигән имеш явыз Мөсәгыйть.

Тукайдан күчереп: «И пычагым кергере!» дими ни дисен инде бу адәм турында.

СССР Язучылар союзына һәм, димәк, Татарстан язучылары берлегенә дә Максим Горький фатиха биргән иде.

Бүген без бу даһи «давыл хәбәрчесе»н оныта төштек. Аның кайчандыр татар сәхнәсендә дә барган «Тормыш төбендә»сен бездә кем хәтерли? Ә бит ул бүген элеккедән дә актуальрәк янгырый торган драма, өстәвенә, Казан материалына нигезләнеп иҗат ителгән. Ярты миллион тәрбиячесез бала, аннары ярты миллион сукбай-бомжларыбыз бар безнен бүгенге Рәсәй дигән иксез-чиксез илебездә! Демагог түрәләр бөтен хәерчелекне кризиска япсарып калдырмакчылар. Юк, йортсыз-җирсез сукбайларыбыз океан артындагы Америкада тумаган, үзебезнең гумансыз шартларда, кризиска кадәр күп элек үрчегән ләбаса.

Түрәләр ни көтә? Бишбалта ятиме «Зәңгәр бүре» (Туфаннан), Мокамай (Такташтан) һәм Гаврош белән Козетталар (болары француз бөеге Виктор Гюго тасвир иткән үксезләр) санының «критик масса»га җитүенме? Күптән түгел генә Татарстан шәһәрләрендә махсус ятимханәләр ачылып, балаларын туйдыра алмаган дисләрчә ата-ананың аларны шунда китереп тапшыруы турында ишеттек. Шунысы көн кебек ачык: кимсетелгән һәм рәнҗетелгән бу сабыйлар, Гаврош кебек, баррикадалар өяргә әзер булып үсәчәк. Аларга мылтык төбәрлек һәм тәтегә басарлык кансыз һәм имансыз ОМОНчылар табылыр дисезме? Йөрәкләре житсә—дарылары житмәс...

Татар әдибе «үз кендеген үзе кисеп» үсә торган яна Зәңгәр бүре, Мокамай, Гаврош һәм Козетталарны яклап чыгарга, чаң сугарга тиеш, югыйсә безнен киләчәгебез булмаячак. Бүгенге тормышнын да төбенә төшеп, былтыргы «а»ларны кабатламыйча гына, йөрәккә үтәрлек итеп язу кирәк.

Кеше дигән Сүз һаман горур янгырасын! Совет чорында кирәксә-кирәкмәсә дә кабатлаудан таушалып беткән бу хакыйкатьтә «Кеше» сүзен «Адәм»гә алмаштырып карагыз, сизәсезме,—ул шундук Илаһка якынаер...

Без Сталин культы кабат баш калкыткан заманда яшибез. Көч һәм хакимият культына, бинигаә кыргый йодрык культына әйләнеп кайтканыбызны сизми дә калдык. Ничәмә еллар буена тешебезгә тигән «Яшәсен КПСС!» шигаренә алмашка «Яшәсен Мин!» идеологиясе һәм яна фирка, мең капшавычлы спрут-чиновниклар килде. Ачы хакыйкатьне ачып, һәр халыкнын тарихында үз «төрекмән башы» зарури булуын беллек... «Перестройка»ның башлангыч елларында Михаил Сергеевич Горбачев, горурланып: «Процесс пошел!»—дип, беркатлы безләрне куандырмак булган иде. «Шалишь, браток!»—диде ана аксакаллы тарих һәм ГКЧП ясап ташлады, ә Кремльгә «яна искеләр» килгәч, тәгәри китте «антипроцесс» йомгагы, тәгәри китте...

Кирегә китеш. Затсызлану.

Культурадагы артка китеш безне, каләм ияләрен, аеруча изә. Бер яктан караганда—сүз иреге дә бар сыман, икенче яктан исә каләм иясенә күнелендәге бөтен уй-фикерләрен ачарлык мәйдан кими-тарая бара, тиешле «каләм хакы»—гонорар

да түләнми диярлек. Кислород җитми. Каләм әһелләре рухи ачлыктан кырыла. Арабыздан чын шагыйрьләр торналар кебек тезелешеп китеп баралар. Алар урынына, Шәйхи Маннур әйтмешли, «лилипутлар килә шигырьгә». Хәер, «Ялкау әдәбиятны шигырь басар»,—дигән иде Марсель Галиев, прозасында да шагыйрь язучы. Резин кереш кебек сузылмалы сусыл романнар да тешкә тия башлады бит, Марсель, сизәмсең? Аларны укымыйлар диярлек, чөнки алар—эрзац әдәбият.

Шулай да, элгәрләр әйтмешли, хөррияте калямиянен (сүз ирегенен) вактөяк кагыйдәләрен үзләштердек шикелле, һич югында горурланырлык үткен каләмдәшләребез исән әле. Бәйрәмова бар, Айдарыбыз бар, тагын берәүме-икәүме... Изге Хозыр Ильяс төкергән телләренә бал да май аларның.

Артка каерылып карыйсың да, кичәге көннәр искә төшеп бимазалый.

Казандагы Бауман урамында советчыл 30нчы еллар уртасында нигезенә чиркәү җимерекләре дә салып һәм, ул «чукынмыш» кирпечләр генә җитмәү сәбәпле, сынар канаты төзелеп бетми калган бәхетсез һәм ятим Матбугат йорты сыек күләгә кебек караеп тора. Ятим дим, чөнки аны төзегән директор ахыр чиктә халык дошманы дип игълан ителгән... Әйләнеп кайтмады, әлбәттә. Ә бүген бу йортны менә-менә җимерелә дип көтәбез. Анда, имештер, күнел ачу үзәге салыначак диләр... Исегезгә төшерим, бу бинаны—«Дом печати»ны русча «Дом печали» дип йөртә идек. Чыннан да, «Сагыш йорты» яки «Хәсрәт йорты»... Аның нигезенә салыначак күнел ачу үзәгендә Александр Пушкин язган «Пир во время чумы» пьесасы уйналыр микәнни?

Шушы Матбугат йортында Язучылар союзы (берлеге) каршында бишенче катта Тукай клубы бар иде. Күпне хәтерли ул клуб. Дөрес, Тукайны да, Такташны да белми, ләкин Туфанны, Кутуйны, Гомәр Разинны (Бәшировны), Еникине яхшы белә... Ул үзенең трибунасыннан Шәриф Камалны җылатып куып төшергән мизгелне дә хәтерли торгандыр. Ватан сугышының беренче айларында анда Мәскәүдән эвакуацияләнгән рус язучылары да килеп сыенган. Алланың һәр бирмеш иртәсендә баш төзәтеп йөрүче денсез Демьян Бедныйны да хәтерли бу зал.

Әйе... Денсез дигәннән.

Туксанынчы еллар башында язучыларның чираттагы съездына Казан мулласы да кунак итеп чакырулы иде. Ана сүз биргән булдылар. Мондый тынлаусыз һәм җәя кереше кебек киеренке залны гомерендә дә күрмәгән хәзрәт каушап калды шикелле. Аның мөнбәрдән генә сөйләргә яраклы сабыйларча самими нәсихәт сүзләрен үзара дошманлашып беткән агрессив җыелыш колагына да элмәде. Ике-өч минуттан нотыкчы хәзрәтне сызгырынып, тибенә-тибенә идән дөмбердәтеп, алкышсыз кул чабып озаттылар... Менә шул гасабыйланып аяк биеткән каләм ияләренең күбесе бүген диндар һәм тәкъва булып кылана инде... КПССның балык башы шикелле череп таркалуын искәреп алгач, фирка билетларын тапшырганы тапшырды, тапшырмаганы тапшырмады дигәндәй, Ислам дәргаһына килеп егылды бу үтә сизгер борын ияләре. Ислам кешелекле, гуманлы һәм гафур булганга, сакаллы сабый һәм сабияләрне,—мөнафикъ булуларына да карамастан,—җылы кочагына янә кабул итте. Ә бит болар сафында, боларның психологиясендә берни дә үзгәрмәде. Ялагай каләм биетүчеләр яна хуҗаларын бик тиз таптылар. Иске советчыл халтураны яна милләтчел халтура алмаштырды.

Күнеленә гел кара карангыны гына төйнәп барган икән бу дип уйламагыз. Дөм карангыда ничек яшәмәк кирәк? Якты, шатлыклы, өмет уята торган көннәребез дә хәтердә.

Беренче татар операсы... Татар балеты... Бөтен Шәрык дөньясы өчен үрнәк булган татарча язу машинкасы... «Издательство» сүзе урынына «нәшрият» сүзенең әйләнеп кайтуы...

Мәскәүдә беренче Татар мәдәнияте декадасына ашкынып әзерләнү көннәре (монысын Ватан сугышы бүлде)...

Авыр сугыш елларында, СССРдагы әдәби журналлар барчасы тукталып торганда да Татарстан язучылары берлеге чыгарып килгән «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы белән ничек горурланмыйсың ди?

Аталарыбыз, абыйларыбыз сугыштан әйләнеп кайткан көннәр...

Ә аннары, еллар үтеп сугыш яралары төзәлгәч, инде гамәлгә ашкан декададан кайтып килүче якташларыбыз утырган Мәскәү поездын каршылау тантанасы...

Сөргеннән кайтучы Туфан поездын алкышлап каршы алу...

«Халык дошманы» Галимҗан Ибраһимовның һәм «гаепсездән гаепле» дисталәгән башка әдипләребезнең, хурлык мөһере сугылган Муса Җәлилнең беренче томнары якты дөньяга чыгу...

Шәһәрнең нәкъ үзәгендә, юл чатында Тукайга һәйкәл торгызу. Уйчан Тукай гарәбкә караган, аның артында кичәге көннең дегеткә буялган фәхешханә йортлары тора (иде)...

Кремль бусагасындагы мәһабәт Җәлил исә, җан көчләрен куеп, инде ничә тапкырлар безгә афәт алып килгән көнбатыш богавыннан котылырга тырыша... Аның артында татарга бик билгеле почык пирамида.

XX гасыр ахырында халкым иманлы Тукайны кабат ачты...

Боларны онытырлык түгел. Чын бәйрәм алар.

Өстәвенә яшь идек әле, яшь! Рушан йолдыз безне алга дәшә, авырлыкларны онытты ра иде. Болгар чагындагы күнитекләр чабатага калса да, татарның байтагы: «Кеше болай иркен сулый торган башка илләр әле җирдә юк» дип ышана иде.

Көрәшчеләр түгел, лилипутлар без бүген. «Ура!» кычкыра-кычкыра, пәһлеваннарсыз калып барабыз. Ура кычкыру олпат пәһлеванга хас сыйфат түгел. *«Дөнья буйлап сау кәрләләр йөри, /Җиргә алар, һай, күп калыккан./ Пәһлеваннар нигә иртә китә, /Нигә иртә китә алыплар?»*

Күнел күзе белән күрә һәм ихлас сызлана белүче Айдар Хәлим бу сүзләренә *«Чын алыплар бетеп бара бугай /Кәрләләрне алып бәрмәгә»* дип тә өсти.

Мәктәпләрдә татар теленә һәм әдәбиятына бирелгән сәгатьләрне кыскартканнар имеш. Ә без татар теле түгәрәкләре эшен җанландырыйк. Ә без, татар язучылары һәм галимнәре, Успенскийның «Слово о словах» китабы кебек талантлы каләм белән бу темага язылган татар китапларын булдырыйк! Пакь төркичә язылган ул китаплар ялыктыргыч һәм йоклаткыч мәктәп программасына гүзәл өстәмә булсын. Ә без буш авыл мәчетләрендә балаларга гарәп графикасы өйрәтик! Безне милләт иткән гарәп һәм фарсы телләренә кабат ишек ачыйк. Имамнарыбыз дин гыйлеме белән генә чикләнеп, никах уку, исем кушу һәм җеназа эше белән генә шөгыльләнмәсен, ахирәткә кадәр, бүгенге фәнни нигездә кеше булу гыйлеменә дә өйрәтсен һәм үзләре дә гавамгә һәм педагогларга үрнәк булсын.

Моның өчен президентның да, мөфтиятнең дә махсус күрсәтмәсе яки фәрманы кирәк түгел, фикерле зыялыларыбызның катнашлыгы да җитә.

Боларын тәмамысы олыгайган һәм төзәлмәс бер идеалистның хыялы дип кабул итсәгез дә рәнҗемим. Ләкин мин сезне барыбер уйланырга мәҗбүр итәчәкмен...

Тагын бер борчыган нәрсә—вакытлы матбугатыбызның хорафатлар белән чүпләнүе һәм кайбер әдипләребезнең мона иярүе.

Үзәк газит нәшергый нумерология һәм саннар магиясе турында дилбегә бүе мәкалә бастыра. Атна саен астрологик әкияти прогнозлар игълан итеп киләләр. Адәм көлкесе, хурлык. Биологиядән хәбәре булмаган ханымнар Дарвинны инкяр итеп маташа. Хет алар килеп кысылмаса иде дисең, әзрәк эмбриологияне аңларга тиешләрдер бит инде. Могтәбәр ханым-әфәнделәр! Ана карынындагы яралгы кеше кавеме үсешендәге төп баскычларны кабатлый. Маймун яралгысы да шулай үзенекен кабатлый, фил яралгысы да. Илаһыбыз безгә яратылыш процессын җанлы мисалларда махсус кат-кат кабатлап күрсәтә дип аңласак,—фән белән дин арасындагы капма-каршылыкның, упкынның эзе дә калмый!

Бөтен мәктәп дәреслекләрендә ничәмә еллар элек кабул ителгән һәм инде үзебезнеке булып беткән «Европа» атамасын «Аурупа» дип язып, Европага (ихтимал, Мәскәүгә дә) «кәҗә мөгезе» күрсәткән булып кылану сабыйлык авыруыннан башка нәрсә түгел. Хәтерлим, матбугатта чыккан бер мәкаләмдә «Европа» сүзен «Аурупа»га алыштырып бетергәннәр, ә менә «европеид» сүзенә кагылырга җөрьәт итмәгәннәр иде. Чыннан да, газитчеләр үз өйләренә һич тә «Ауроремонт» түгел, «евроремонт» ясаталар, баеракларын акчаларын «доллар»дан «евро»га күчереп бетерде бугай инде.

Тел мәсьәләсендә көлке һәм борчылырлык фактлар күп, һәр редакция, аерым ханлык яки кенәзлек шикелле, үз кануннарын чыгарып маташа. Орфографиябездәге һәм терминологиядәге ялгыш-йолгыш экспериментлар эзсез-зыянсыз гына

үтми. Башбаштаклык юлы белән барсак, без җанлы татар теленнән ераклашып, укучыбызны һәм әбүнәчеләребезне генә югалтабыз. Болай да инде бүген ике теллелек дигән нәрсә, кирегә борылып, берьярым теллелеккә әйләнеп бара. Ярым дигәне—газиз ана телебез. Чөнки бүгенге шартларда рус телендә аңлашу җайлырак.

«Ана телегез үлсә, хөрмәт йөзеннән, аны «мәрхүмә тел» дип атарга кинәш итәм»,—дип колагыма пышылдый усал Шүрәлем.

Телдә үсеш-үзгәреш тенденциясе белән тотрыклылык арасындагы балансны саклый белергә кирәк. Ашыгу—шайтан фигыле. Дөрес, пошмау да—шайтаннан.

Гадел Кутуебызның улы Рөстәм Кутуй рус теленде яза, шәп яза. Сибгат Хәкимнең өлкән улы мәрхүм Рөстәм Хәкимов рус телендәге китапларны редакцияли иде, Гарәфи Хәсәновның Себердә туган улы Хәсәнов Аяз да рус телендә иҗат итә, мәскәүле Мирхәйдәров Рауль Мирсәетовичның детективларын русчадан татарчага тәрҗемә итәргә туры килә. Зарипов Марсель Харис улы да, Сабиров Рөстәм дә шулай. Бу исемлекне шактый дәвам итәргә мөмкин. Әйтик, президентыбыздан кала, кайсы министр гына теттереп татарча сөйли белә?

Казан урамнарында татарча сөйләшкәнне елдан-ел сирәгрәк ишетәсен.

Зиратларда гына татарга хас тыйнак тынлык.

Без рус теленә күчеп барабызмы әллә?—дигән сорау куярга да соң бугай инде.

Шулай да...

Аяусыз ярминкә шартларында беркайчан да яфрак астына посып дәрәҗәбезне төшермик. Бәләкәй халык булмасак та, борынны бик чөймик, ләкин аны тиешле кимәлендә тотыйк. Татар язучысы бүген исән калу тактикасын тотарга, ләкин алгарышка әзерләнергә тиеш. Басылмаган әйберләребез өчен язу өстәлебездә әрҗә бар. «Киләчәк әрҗәсе». Ул буш тормасын. Янә китереп, Интернет бар. Тик анда «мин» дигән сүзне азрак кулланыйк, «без»ләр күбрәк булсын.

Тырышлыгыбыз җитсә, инкыйразны авызлыклап, киләсе түгәрәк датага тикле, шәт, җанлы ана телебезне дә саклый алырбыз. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, туган телебезне саклыйк һәм аны фән теле дәрәҗәсендә камилләштерик дисәк, безгә Европа телләренең үсеш тарихын өйрәнергә кирәк. Безгә Шәрык та, Европа да якын—без алар арасында урталыкта калганбыз.

Рушан йолдызыбыз әле сүнмәгән, без дә сүрелмик, суынмыйк.

Язучылар берлеге озын гомерле булсын дибез. Ләкин моның өчен ул үзгәрешләр дә кичерергә тиештер. Иң беренче принцип—берлекнең мөстәкыйльлеге, үзенә үзе хуҗа булуы. Гомер бакыйга язучылар оешмасы хакимиятләргә һәм бөтенесенә баш ВКП(б)—КПССка бәйле булып килде, җаваплы постларга партия күрсәткән «затлы» затлар гына «сайланды». Хәзер дә моннан әлләни ерак китмәдек.

Үзенә үзе хуҗа булсын өчен берлекнең мөстәкыйль финансы булырга тиеш. Гади генә итеп әйткәндә, аның янчыгында үз акчасы булырга тиеш. Ә аны каян алырга?

Язучылар берлегенең үз нәшрияты, идеалда—үз басмаханәсе булса иде. Календарьлар кебек файда китерә торган басмаларны, ниһаять, хосусый эшкуарлар тырнагыннан тартып алырга һәм профессионаллар кулына тапшырырга кирәк. (Профессионаллар эшләгән редакциянең штаты хәзерге резин штатлардан икеләтә кыска булачак.) Рәссамнар берлеге белән уртакка төсле репродукцияләр җитештерергә мөмкин. Балалар өчен рәсемле китаплар да акча китерә алыр иде. Башка төрле сәнгатькә тотыну да гөнаһ түгел хәзергесе «оңгайсыз» заманда. Мескен татар әдипләрен бәрәңге һәм сөт-катык белән тәэмин итәрлек агрофирма төзү дә саваплы эш булыр иде. Язучылар берлеге карамагында китап киоскылары оештырып буламы? Пенсиядәге әдип халкы, хезмәт хакы сорамыйча гына, чиратлашып шунда сату итәр иде. Китап сөючеләр тере автор белән очрашып, автографлы китап сатып ала алыр иде. Начармени?

Бу киоскыларны кайда урнаштыру турында да фикер йөртергә була. Минемчә, аларның мәчет-мәдрәсә тирәсендә булуы муафыйк. Мондый киоскылар, үзенә бер төрле «лакмус кәгазе» кебек, китапларга объектив бәя бирергә дә ярдәм итәр иде. Янә китереп, бүген бик шәп китапларга да дөрес бәя бирүче оста, талантлы, йогынтылы реклама кирәк. Телевизион реклама бигрәк тә. Югыйсә барлы-юклы китап кибетләребездә күпме арзанлы татарча басмалар тузан җыеп кына ята. Ә инде буш, эчтәлексез китапны рекламалау әдәбиятка зыян гына китерә.

Бәя бирү дигәннән. Кайсыдыр бер гәзиттә татарча китапларның китапханәләрдә ничә тапкыр укылуын күрсәткән таблица сыман нәрсә биргәннәр иде. Мондый күрсәткечләргә ышаныч чамалы. Алдак хөкем сөргән бүгенге шартларда алар принципта объектив була алмый.

«Роман арты роман әвәләп ятучы елгыр каләм осталарына каршы көрәш ысулы бер генә: аларга гонорарны акчалата түгел, «чалбарлата» түләргә кирәк,—ди диссидент Шүрәлем.—Язып утырганда туздырган ыштан төпләре санынча».

Анын фикере белән килешеп бетмим. Монда бит әдәби тәнкыйтьне дә бер гаепсез дип булмый. Әгәр язучыларыбызнын иҗатына үз вакытында объектив бәя бирелеп барса, Тукай бүләгенә дәгъва кылучылар чираты Божрадан Мөштәри урамына кадәр сузылып, ерып чыккысыз «бөке» хасил итмәс иде. Әйе, тәнкыйтьчене—үзенә күрә урам хәрәкәтен тәртипкә салучы ГИБДД хезмәткәренә тинләп була торгандыр. Кызганыч ки, ГИБДД әһелен сатып алып булган шикелле, тәнкыйтьче агайны да шалкан бәясенә кулга ияләштерергә мөмкин икәнлеген беләбез.

Тукай иҗаты турында меңләгән хезмәт язылган. Асылда берсен-берсе кабатлый торган мәкаләләр һәм мәкаләчекләр. Кайчагында боларны укыйсын да: «Тукай турындагы мәкаләдә шигърият булырга тиеш, ул җырлап торырга тиеш, ә сезнекендә фәкать арифметика гына, ибдәш автор!»—дисен... Моннан ярты гасырдан шактый элек, әле башлангыч мәктәп елларында Гази Кашшафнын «Каләм мастерлары» дигән китабын укыганымны хәтерлим. Яшермим, мин бу китапны «Каләмне ничек ясыйлар микән?» дибрәк укырга тотынган идем. Ихтимал, иртәрәк укылгандыр, ләкин каләм остасы язган бу китап мина Такташ поэзиясен малай чакта ук аңларга ярдәм итте кебек шикелле.

Язучылар арасында өлкәннәр элитасы элек тә бар иде, тик алар рәсми оешма булып теркәлмәгән иделәр. Аксакалларыбызны санап тормыйм.

Бүген бездә халыкара ПЕН-клубнын татар ПЕН-үзәге оешты. Анда житди, олпат, абруйлы затлар җыелган дип беләбез. Шулай да ПЕН әһелләре арасында бунтарь Такташ шикелле: «Кирәк булган минем тууым!» дип укучыны ышандыра торган итеп әйтә алырлык зат юк. Әллә сон ялгышаммы?

Рәсмиләштерелгән элитанын хасияте шул: анда миллият хакына шәһит китәргә әзер Шонкарлар калмый, чөнки алар бөтенесе житү тормышка бик тиз күнегеп, түрәләр белән дуслашып-туганлашып, тора-бара «контрреволюция» кичерәләр—тәвә кошлары яки тук пингвиннар кебек, очу сәләтен, очар канатларын җуялар. Очыштан курка башлыйлар, хакимият тирәсендә җылы урын эзлиләр һәм табалар да. Диссидент фикерләрен читлектә—күнел төрмәсендә аеручылары да булырга мөмкин, әлбәттә.

Борынгы бер шәрык хикмәтен үзгәртебрәк әйтсәк, «Әдипләрнен иң яманы—түрәләргә якын булганы, түрәләрнен иң яманы—әдипләрдән ерак тораны».

Менә элитабыз үз нәшриятын булдырып, үлемсез китапларын шунда гына бастырып, ул китаплар мәжбүриятсез генә сатып алучысын һәм укучысын тапса, без элитанын көченә һәм потенциалына тәмам ышаныр идек. Югыйсә язучыларнын төп массасы чытыр арбага төялгән, жәяүлеләре дә бар, ә элита—өч дагалап жиккән импорт тарантаста тирбәлә. Хыялый батман алтынга баруыбыз... Ә абруйлы байрак йөртүчебез юк, барабан дөмбердәтүчеләр һәм ярык быргы өрүчеләр—буа буарлык.

Әдәбиятны рус, инглиз, кытай, татар әдәбиятларына бүлеп карау бик формаль бүленеш кебек тоела. Бердәм киләчәк күзлегеннән караганда, бар нәфис әдәбият һәм бар түбән («пошлый») әдәбият, чәйнәлеп, таушалып беткән хакыйкатьләрне мененче кат кабатлаган әдәбият, «сабын» әдәбияты. Тегесе дә, бусы да теләсә кайсы телдә иҗат ителергә мөмкин.

Офыкта даһиларыбыз күренмәсә дә, үзләрен бөеккә санаучы ярык быргылар пәйда булып тора. «Лаек түгел ат казанса, түмгәк саен маяк куяр...»,—ди борынгы төрки мәкаль. Карьерист психологиясе мең ел эчендә аз гына да үзгәрмәгән икән, валлаһи. Шунысын өстәп әйтим, борынгы телдә маяк «тизәк» мәгънәсен дә белдергән... (Шүрәле «фәкере», мин аны монда «иплә6рәк» әйтергә тырыштым.)

Китаплар саны һәм күләме ягыннан күбәүләрне уздырсак та, сыйфат ягыбыз ташка үлчим.

Дөньякүләм танылган, ә татар әдәбиятына өлге булып хезмәт иткән (һәм итәчәк) рус әдәбиятына күз салам.

Менә Нобель премиясе лауреаты Михаил Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романы. Ул—тулысы белән ялгыш сәяси-икътисади хакыйкатькә корылган әдәбиятның классик үрнәге. Асылда ул тормышны астын-өскә әйләндереп күрсәтә торган тезислы әдәбият (соцреализм) җимеше. Шулаймы? Шулай, шулай... Ләкин ни өчен соң без Шолоховның бу романын ләззәтләнеп укыдык микән? Мин, мәсәлән, бу романдагы күпчелек каһарманнарны хәтерлим һәм хәзергесе минутта да яратам мин аларны! Асылда җимерүче, хәрабәче булган романтик Давыдовның фаҗигале үлеме мине тетрәндергән, күздән яшь чыгарган иде...

Әйе, бу романның да тышкы кабыгы эчендә, тирәндә, бик тирәндә башка хакыйкать, сәнгатьчә хакыйкать, чынлык ята шикелле. Хәтерлисезме, станицага яңа тәртип алып килгән эшче Давыдовтан соң, «бөтендөнья революциясе» турында хыялланган «башы-бозык» Нагульновтан соң станица, дөнья кем кулына кала? Пакизә, ләкин артык садә Варюха-горюха кулына. Кичәге тынгысыз Щукарь картның күләгәсе һаман арткы фон, күз яше катыш елмаюлы декорация булып хезмәт итә... Беләсезме, әлеге Варюха Вл. Ульянов (Ленин) әйткән кухарканың үзе бит инде. Кухаркалар идарә иткән станица, ил язмышы аянычлы булачак. Тарих безгә шуны раслады да. Мирсәй Әмирнең Ватан сугышы елларында колхозны җитәкләргә алынган «Миңлекамалы» да асылда вакытлы каһарман гына булды, аны шомарак затлар алмаштырды (Миңлекамал образының прототибын да, Мирсәй Әмирнең үзенә чиләк сатып җибәргән һәм соңыннан коточкыч авыр язмышка дучар булган Сарман малаен да азмы-күпме белә идем мин).

Какшау нигезгә корылганга, колхозлар да, СССР үзе дә таркалды, ә җинаятьчеләр атаманы Сталинның Мәскәү Кремле каршындагы кабере өстенә куелган таш сынның борынын халык йодрыгы җимергән иде (аны ремонтларга туры килде). Чәнечкеле тимерчыбык җитештерү буенча СССР дөнья күләмендә алдынгы урыннарны били иде, шөкер, ул чыбыклар череп, матдәсе кабат җир куенына кайтты...

Бу хакыйкатьләрне Михаил Шолохов аңлап җиткермәгәндер. Аңлап язган булса, без фальшны сизми калмас идек. Һәрхәлдә, романнарын иҗат иткәндә аның каләмен галәми-илаһи көч йөрткәндер, ахрысы...

Бүген нобелиат Шолоховның дәрәҗәсен астыртын гына төшерергә тырышалар. Әйткәнемчә, давыл хәбәрчесе Горькийның да. Галимлекләре хәдтин ашкан шул ук кемсәләр маташа...

Балачакта мин дә авыл күгендә төннәрен—мәңгелеккә кадаклап куелган җанлы йолдызларны, ә көндез—туктауны белмәстән агылып, өерелеп, алмашынып торган көтү-көтү өем болытларны күзәтергә ярата идем. Йолдызлар миңа атап күз кысалар, мине күзлиләр сыман тоела иде... Аларның сихри җемелдәвендә, җәйге актин-ак болытларның серле агылышында мин бер уртак сыйфатны—мәңгелек хәятне (әбәдиятне һәм әзәлиятне) күргәнмен, тойганмын бугай. Алар авыл малаен үзләре янына чакырдылар, тик миңа пилот яки астронавт булырга язмады... Йолдызларга сәяхәт турында хыялый хикәяләр иҗат итеп юанырга гына язган булып чыкты...

Мин әкияти пакь дөньялар турында хыялланган арада, ил чүплек башына әйләнеп бетә язган.

Китаби телебез дә чүпләнде. Әдәбиятта «майт» мәсьәләсе елмайтып кына калмый инде бүген, укшыта ук башлады. Нурихан Фәттах тормышта да, кәгазьдә дә юньләп сүгенә белми иде. Аяз Гыйлаҗев исә «майт» лексикасын Сталин бабай лагерьларында шактый тирән үзләштергән иде, ләкин ул да бу «белем»ен иҗатында эшкә җикмәде. Мөхәммәт Мәһдиев, гомумән, читләтеп әйтүгә маһир иде бугай.

Соңгы вакытларда «Чаян»ыбызда татар әдәбиятындагы «майт»ка кагылышлы бер реплика күзгә чалынган иде чалынуын. Ләкин файдасы күренми, «майт эчендә» йөзгән авторлар һәм сәхнә әһелләре ишәя генә бара. «Тиле, тиле» дигән саен, тигәнәк буе сикерәләр.

Кешенең дөм караңгы күңел төпкелләрендә актарынган Федор Достоевский: «Человек, мерзавец, ко всему привыкает»,—дигән. Менә без дә соңгы күлмәгебезне салдыра торган кризиска күнегеп барабыз. Хәер, һәр тарафта һәр милләт өчен аңлаешлы уфтану һәм ыңгырашу авазлары ишетелә... Менә монда инде русча «майт»ны да гафу итеп була шикелле?

Бүгенге татар прозасы хәшәү сүзләр белән тулы—ягъни паразит сүзләр, чүп сүзләр белән. Күп кабатлана торгач, инде эшләмәс булган буш фикерләр белән. Каләмен хәшәү сүз яза башласа, өстәлен янынннан кит тә урамда йөреп кер! Үл, ела!

Бүгенге татар язучылары киләчәк әдәбият белгечләрен эшсезлеккә дучар италәр; үзләренең бөтен байлыгын, чүп-чарын да калдырмыйча, кичәге бөекләрнең төшенә дә кермәгән күптомлыкларына дыңгычлап тутыралар... Чеховны, Чеховны карагыз! Ул үзенең күпме җәүһәрен әсәрләр мәҗмугасына кертмәгән! Тукайның да яшьлек шигырьләренә мөнәсәбәте нәкъ шундый булган бит.

Сизәсезме, бүгенге шагыйрьләр артык төзек һәм тәрҗемә итү өчен җайлы итеп язалар... Шигырьне башка телгә тәңгәл тәрҗемә итеп булса, ул чын шигырь түгел инде, чөнки ул тапталган сукмактан бара, ә андый сукмак яна илләргә—монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән Гүзәллеккә ничек илтсен?...

Рәсәйдә язучының базары төшү—реаль факт. Мондый деградация—гомуми инкыйраз галәмәте. Татар әдәбиятында «майт» куллану да шуның билгесе. Көнкүрештә аты-юлы белән сүгенгән кешеләргә административ штраф салырга тәкъдим итүчеләр булды. Андый сүзләрне кәгазьгә төшерүчеләр һәм сәхнәгә менгерүчеләр өчен нинди җәза уйлап табарга?

Ибраһимов һәм Еники теле белән Исхакыйча язарга кирәк. Әсәренне урам сүзләре белән тутырмаска (идеалист шүрәлем «фөкере» бусы да).

Каһарманнарга тормышта кытлык булгач, аларны әдәбиятта да сирәк очратасың. Шуна күрә әдипләр Газинур һәм Муса кебек шәхесләргә мөрәҗәгать итеп карадылар. Әлләни уңыш казана алмадылар. Аннары тарихи шәхесләрне эксплуатацияли һәм, йомшак кына итеп әйткәндә, ирексезли башладылар. Болар арасында беренче урында Сөембикә тора торгандыр. Тора-бара әдәбиятта Сөембикә фигурасы тоныкланып, таушалып бетте. Инде аның тарихи көндәше Гәүһәршад бикәгә тотындылар бугай... Ничектер, Сүзгебикәгә тикле барып житмәделәр әле. Житәрләр дип уйлыйм, чөнки соңгы Себер ханы Күчемнең хатыны Сүзге—аеруча героик шәхес. Себер ханлыгы җинелгәч, рус казакларына түшәк булмас өчен, ул үзен-үзе чәнчеп үтерә. «Канатлы ат» / «Койгырыш» («Конек-горбунок») әкиятенең авторы П.Ершов Сүзге ханымбикә турында шул исемдәге поэмасын иҗат итә, бу поэмага нигезләнеп язылган «Сүзге» пьесасы 1889 елда Ермак явының 300 еллыгына багышланган «Себер кичәләре»ндә уйналган. 1896 елда композитор И. Корнилов шушы ук поэма нигезендә опера яза. Сүзге ханымбикә М. Знаменскийның берничә картинасында сурәтләнгән. Кыскасы, Сүзге шәхесенә рус сәнгатькярләренең игътибары, ихтимал, Казан ханбикәсе Сөембикәгә карата булган игътибардан ким түгелдер. Янә шунысы игътибарны җәлеп итә: Сүзге дә, Сөембикә дә асылда бер үк дала кавеменнән чыкканнар. Александр Пушкинның үзе белән хат алышкан П. Ершовның керәшен татары булуы турындагы хәбәр дә күзгә чалынган иде (эзтабар Фәүзия Бәйрәмованың вакытлы матбугатта басылган мәкаләсендә шикелле).

Тарихта (гадәттә рус елъязмаларында) теркәлеп калган барлы-юклы мәгълүматларга гына таянып, роман хәтле роман әвәлиләр һәм реаль тарихтан коточкыч ерак булган мактанчык фэнтэзи килә дә чыга.

Мәржани, Ризаэддин Фәхреддин, сәяхәтче Гобәйдулла Әмиров, дөньяда беренче казыя Буби ханым, «оча торган татар Лилиентале Гали Вәлиев-Сарыбаев шәхесләре турында роман язарлар иде дә, теш үтми, үҗәтлек житми. Чөнки монда инде алдашып булмый, вакыйгаларны һәм характерларны бармактан суырып кына әмәлли алмыйсың—чын һәм ышанычлы материал сине контрольдә тотачак. Аны эшкәртү өчен генә дә бер-ике ел гыйльми эзләнү һәм,—ин мөһиме,—күпкырлы хәбәрдарлыкка ия булу зарур. Ә Гобәйдулла Әмиров турында тәпле әсәр язу өчен яшь Нурихан Фәттах каләме һәм төпченү сыйфаты аеруча кирәктер. Нурихан булса, халыкара буралгы Гобәйдулла күргән ерак Кандәһар һәм Хәйдәрабадларны әйләнеп кайтмыйча тынычланмас иде дип уйлыймын.

Мамай темасына да тотынучы юк. Ә бит ул тарихчы һәм эзтабар әдип өчен гадәттән тыш кызыклы фаҗигаи шәхес. Мәктәп дәреслекләрендә рус күзлегеннән карап кат-кат тасвирланган «Куликово кыры»ндагы сугышта Мамай ягыннан болгарлар да катнашкан дип беләм. Өстәвенә бу орышта кем җиңгәнлеге ике сарылы. Намуслы тарихчылар безгә Дмитрий Донскойның (Дунинын) куркак бер

алла колы булуын тасвирлыйлар. Орыш-суеш алдыннан ул өстендәге затлы киемен үзенең «сөекле» яраны белән алмашып һәм кенәз байрагын шуна тоттырып, атына атландырып, үзе бер кисеп аударылган каен ботаклары арасына кереп ята. «Яфрак астына кергән» диикме? Сугыш тынгач, кәч-хәл белән табып алганнар үзен... «Кенәз, без жиндек!»—дигәч кенә күзен ачкан ярасыз батыркай.

Исән булсак, мондый романнар киләчәк буын тарафыннан язылыр.

Әйе, әдәбият мәйданына бүгенге рәсми тарихны инкяр итәргә йөрәкләре, белемнәре һәм талантлары житкән яңа буын вәкилләре килер.

Алар ана телебезне саташтыра торган кириллицада түгел, бәлки татар хоруфатында язарлар.

Алар берәүне дә кабатламас, хәттатлыкны һәм компромиссны белмәс.

Араларында татар байрагын күтәреп йөртүче пәһлеван да булыр.

Алар язучылар берлегенең янә Тукай исеме биреләчәк яна клубында сәхнәдә Тукай бюсты белән янәшә утырырлар.

Шуңа өметләник.

Татарстан язучылары берлегенә 75 яшь.

Бармак белән санап карасаң, бүгенгесе көнне ул безгә эне тиешле микәнни? Ләкин тиздән ул барчабыздан да өлкән булып калыр. Чынлыкта без аның балалары гына.

Берлек яшәсә, татар күнелендә Тукай да, Такташ та, Туфан да яшәр.

Алар мәңге яшәсеннәр иде.

---

## БЕРЛЕК ҺӘМ БЕЗ...

*(Яшьләр фикере)*

**Ленар ШӘЕХ:**

—Мине Татарстан Язучылар берлегенә вакытында алдылар дип уйлыйм. Дөрес, иртәрәк тә кабул итә алалар иде. 2004 елда остазым, халык шагыйре Илдар абый Юзеев: «Ленар, Язучылар берлеге тарихында беренче китап чыкканчы ук союзга алу очраклары бар. Уйла да, документларынны жыя башла!»—дигән иде. Нигәдер мин ашыкмадым. Акылым әзер булса да, күнелем әзер түгел иде.

Шул ук елны Илдар абый гүр иясе булды... Шуннан соң да өч ел вакыт үтте. Мин ижади яктан камилләштем, өлгердем һәм Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителдем. Барысын да дөрес эшләдем дип уйлыйм. Илдар абыйның рухы да сөенгәндер.

**Рифат СӘЛАХ:**

—Язучылар берлеге безнең әдәбиятыбызны үстерүдә һәрчак әһәмиятле роль үтәде һәм үтәячәк. Ул иң әүвәл язучыларны яклаучы һәм яшьләрне язучы итеп танучы рәсми оешма, минемчә. Бердәм булганда без көчле. Оешмабыз озын гомерле булсын иде.

**Гөлнара МАНСУРОВА:**

—Мина калса, Язучылар берлеге булу бик яхшы нәрсә. Ул булырга тиеш. Һәм ул конкрет максатлар куеп эш алып барырга, куйган максатларына ирешергә дә тиеш. Тәкъдимем бар: яшь язучыларны Берлек КДУ, КДГТГУ кебек уку йортларыннан, филологик факультетлардан гына түгел, башка вузлардан да, химиклар, технологлар һ.б.лар арасыннан да эзләсен иде...

Ркаил
Зәйдулла

## Иңгә-иң

*Язучылар Союзының 75 еллыгына*

Бу бергәлек—татлы хыял сыман.
Язмыш карурманын кичкәндә,
Кол Гали дә соңгы сулышында
Аны саркыт итеп эчкәндер.

Бу бергәлек—соңгы өмет кебек.
Диварлардан дошман үткәндә,
Кол Шәрифнең бер ораны булып
Ул безгә дә килеп җиткәндер.

Күтәрелгән кылыч безнең өскә,
Көч алдында булдык кечкенә.
Иелсә дә башлар ул афәттә,
Иелгән ак кәгазь өстенә.

Язу карасыдай чәчрәгән төн.
Күздән җуеп татар галәмен,
Якты юллар сызган әһле каләм,
Шул төннәргә манып каләмен.

Упкын авызына якынлашкач
Таркаулыкка эзләгәнбез им.
Һәйкәл булып җәлилчеләр баскан!
Без бергә, дип. Бергә! Иңгә-иң!

Себер карларына сарылганда
Сыкрагандыр Туфан—карусыз:
«Әдәбият—анабыз ул газиз,
Поэзия—сөйгән ярыбыз».

Нәфес белән нәфис килешкәндә,
И син, Тәңрем, күзгә карап әйт:
Сөйгән яр да баш тартачак бездән,
Анабызга итсәк хыянәт.

Юллар уба. Без барабыз әле—
Өскә килә гүләп карурман.
Йөрәк ярылырлык якты хәбәр
Офыкларда әмма бар сыман.

Ызаннарны бозып золым иңә.
Соңгы сынау... соңгы... иң-иң-иң!
Тере ташкын була алырбызмы?—
Без бергә, дип. Бергә...
Иңгә-иң...

*Август, 2009 ел*

## Өмә

1986 ел. Көз ае. Затлы Комлев урамын бер көн эчендә аркылыга казып чыгарга кирәк. Шунсыз язучыларның яңа бинасына жылы кертмәячәкләр. Өмәгә кем генә килмәгән. Язучылар союзы рәисе Туфан Миңнуллинның көр тавышы әле анда, әле монда ишетелә. Ленинград фронтында танкка каршы кылыч тотып барган Ворошиловны хәтерләтә ул.

Гариф Ахуновның Әлмәт бүлегендә эшләгән чагында алган кара-зәңгәр плащы кызыл балчыкка буялып беткән.

—Зарар юк, Шаһидә апаң юа аны,—дип каккалады да,—карале, егетем, син бик һөнәрле икәнсең, черәшеп эшли беләсең, болай булгач, мин синең иҗат портретынны язам. Чиратта—унөченче син,—дип, Камил Кәримовның аркасыннан кагып алды.

Үзенә карата жылы сүзне сирәк ишеткән Камил Кәримов шикләнебрәк карап куйды да:

—Мине болай да беләләр, мәшәкатьләнмәгез, Гариф абый,—диде.—Хикәямне тыңламасалар, курайда уйныйм, алай да батмаса, җырлап җибәрәм. Җырымны яратмасалар, биеп күрсәтәм.

—Шулай дисеңме?..

—Сез, Гариф абый, Өчиле авылыннанмы әле?

—Өч түгел, бер өй дә калмады инде анда.

—То-то...

—Син Михалков сыман сөйли башладың әле.

—Татар укучысының өчтән ике өлеше Шәле авылында яши. Шәлем исән торсын!—дип, Камил Кәримов көрәп һава сулады да, күкрәген кабартып, сикергәк адымнар белән китеп барды.

Мөдәррис Әгъләмов, борынгы стена нигезен тишәргә дип, үзе кадәр отбойный чүкечкә тотынды. Чүкечнең кендеге, таш арасына кысылып, автомат кебек тырылдый башлагач, көчле һава агымы шагыйрьнең гөнаһсыз гәүдәсен унлы-суллы бәргәли, яфрак кебек җилфердәтә башлады. Җәһәт килеп җиткән Равил Фәйзуллин отбойный чүкечне Мөдәррисе-ние белән күтәреп алды да секунд эчендә стенаны умырып та төшерде.

Аяз Гыйләҗевнең япон курткасы пычранмады пычрануын, шулай да тере классикның арада булуы үзе бер куаныч иде. Ул, ярым канәгать елмаеп, мәгънәле күзлек пыяласы аша яшьләр ягына—Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Зиннур Хөснияр кебек киң күкрәкле, кызылсу-мул чырайлы яшьләргә карап торды да, тирән сулап:

—Болар иҗатта Фәйзуллинны бәрерләр, ахры,—дип, үзалдына сөйләнеп алды.

—Ни дисез, Аяз абый?—дип сорады Хәйдәр, аңа таба иелә төшеп.

—И-и, Хәйдәр булсаң иде ул хәзер, слушай, парень. Кара инде, ул кыяфәт! Ул буй! Ул чибәрлек! И-и-и-их!—дип, Аяз ага Хәйдәрнең ак плащтан, сыгылмалы, көрәк сабыдай нәзек гәүдәсенә астан өскә карап торды.

—Сиксән икенче елны чыккан брошюра белән ерак китеп булмый шул, Аяз абый,—диде Хәйдәр.

—Слушай, парень, бүген алыштырам яшьлегенә алтмыш ике пьесамны, кырык ике том прозамны, сандык төбендәге дүрт йөз илле мең юллык шигырьләрне дә өстәп... И-и-и-их, яшьлекнең кадерен белмисең әле син, слушай, парень...

Ул арада:

—Фәйзуллин алтын тапты!—дип кычкырдылар.

Борынгы стена тирәсендә юкка булашмаган икән. 1815 елгы янгында харап булган кытай чынаягына ябышкан авыр металл тоткан Фәйзуллинны чокыр төбеннән күтәреп алырга дип берьюлы унөч кул үрелде. Маңгаеннан шыбырдап тарихи тир аккан Фәйзуллинны уратып алдылар. Һәрберсе табылдыкны тотып карарга тели, әмма Фәйзуллин чынаяк китеген кулыннан ычкындырмый. Алтын дигәнең хикмәтле нәрсә, күз алдында гаип булырга кызыгучан.

Менә Фәйзуллин металл өстендәге куныкны теше белән чистартып алды һәм... бөтенесе тын калдылар. Әлеге металл, чынлап та, алтын төсендә балкып китте. Ләкин үзенеке булмагач, аның алтын булуын берәү дә теләми иде...

—Ташла, бакыр ич бу!—диде Эдуард Мостафин.

—Авыр күренә,—диде Зиннур Мансуров, төкереген йотып.

—Юарга кирәк моны,—диде Хәйдәр.

Юарга дигәнне ишетүгә, Фәннур Сафинны очкылык тота башлады. Икеләнү-шикләнүләргә Туфан Миңнуллин нокта куйды. Табылдыкны, акча мәсьәләсендә тәҗрибәле учына салып, сикертеп карады да, сулышсыз калган толпаның йөрәген бозып:

—Алтын...—диде.—Бәләкәйдән үк алтын арасында аунап үскән малай мин. Ялгышмыйм...

Бу рәсми сүздән соң Фәйзуллин табылдыгын Туфан учыннан тиз генә суырып алды да, кулъяулыкка төреп, эчке кесәсенә салды, чокырга төшеп, бишләтә көч белән ломга тотынды. Стенаның өске өлешен дә ишеп бетерә иде—көчкә туктаттылар.

Бер кырыйда Камил Кәримов офтанып алды: «Кирәк бит, әй! Атна буена борынгы нигез буйларын казыдым югыйсә. Эштән соң калып бит... Ату тирәмдә көндез гел Мөсәгыйт Хәбибуллин тулганып йөрде. Табылса... икегә бүләсе була иде. Эштән соң калып бит. Илленче елгы сургыч бөкедән гайре ник бер нәрсә чыксын! Бөтен нәрсә дә шул Фәйзуллинга гына дигән микәнни! И-и-их».

—Алтын гадәттә акчалы кешегә керә. «Керәсе мал тешеңне сындырып керер» дигәннәр безнең бабайлар,—диде Барлас Камалов.

Кара эшләпәдән, иске зәңгәр халаттан, элеккеге амбар мөдирләрен хәтерләткән Рөстәм Мингалим әче итеп тәмәке суырды да:

—Төкерәм алтыныгызга!—дип, көрәгенә ябышты.

—Алтынны гомергә өемә аяк бастырмадым,—диде Гөлшат Зәйнашева, авыр таш күтәргән жиреннән билен турайтып. Арада берләнбер хатын-кыз буларак, таш күтәрү эшендә ул иде.

Бервакыт Мөдәррис Әгъләмнең бәрхет жилән итәгеннән ак нәрсә сузылып төшә башлады. Аптырап, ни микән дип карасак, ак киндергә бизәкләр чигелгән чуклы сөлге төшеп килә.

—Хатыныңның сөлгесен иярттеп килгәнсең бит!—дип кычкырдылар ана.

Мөдәррис үзе дә күреп алды, әмма югалып калыр димә:

—Кулъяулык ич ул,—диде дә, чүпләм сөлгене итәк астыннан суырып алып, тирләгән битен сөртте, кушаяклап сикереп, чалбарын күтәрде дә сөлгене биленә урап куйды.

Мөдәррис белән бәхәсләшүнең өметсез икәнен белгән халык сөлгене кулъяулык дип килешергә мәҗбүр булды.

Өмә әнә шулай гөр килеп торды. Иртәдән карлы-яңгырлы башланган көн Туфан Миңнуллинның ике каш арасындагы шомлы җыерчыгы белән бергә аяза барды, аяза барды. Каләмнән көрәккә күчкән язучылар, шөкер, сынатмадылар.

## Күршеләр

Татар язучыларына да икешәр катлы коттеджлар төзелә икән, дигәч, күпләр ышанмаган иде. Менә бит! Күп вакыт үтмәде—төзеп тә куйдылар. Уникe җыелыш җыеп, үзара канга-кан килеп бәхәсләшкәннән соң бүлешеп тә алдылар.

Иң матурын, иң зурысын Туфан Миңнуллинга бирергә дигән карар чыгардылар. Арыды... Ничә ел буе Мәскәү парламентында эшләде... Бүтәннәр трибунага чыгып юри уйнаса, Туфан чынлап уйный торган иде. Һәр политик мөнә дигән артист булса да, һәр артист политик түгел икән шул. Шулай чынлап уйный торгач, Туфан Миңнуллин, унҗиде кило да дүрт йөз илле ике граммга ябыгып, Казанга кайтып төште.

Жирәбә салганда аның күршесенә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов чыкты. Кичтән Хуҗа Насретдин булып йокыга китә, иртән Тукай булып уяна торган Мөдәррис Әгъләм:

—Яшибез болай булгач!—дип сөенеп куйды.

Күченү башланды. Туфанның мәһабәт йорты каршына өч «КамАЗ», кранлы бер япон машинасы, ике «Волга» килеп туктады. Өлгергән Әстерхан карбызы сыман кызыл чырайлы шагыйрь егетләр унике суыткычны (эчендәге утыз алты казылык, җиде каклаган каз, Сергач мишәрләреннән алган ат ите белән бергә), тагын сервант һәм шуның ише бинһая авыр кирәк-яракларны мамык урынына очыртып кына керттеләр. Егетләрне сыйлап, җайлап, көч-хәл белән машиналарга төяп җибәргәннән соң, Туфан, самолет трабына чыккан президент кыяфәтендә, коттеджның икенче катына менде. Ике канатлы ишекләрне җырлатып кына ачып, балконга чыкты. Ерак түгел авыл өйләре күренә иде. Бакчаларда иелеп, арт белән күкне тераэп чүп утаган хатын-кызларга карап торды. Башы әйләнеп китте. Биеклекне өнәми иде Туфан, шуңа күрә самолетка да утырмый иде. Аскы катта гына яшәрмен, ахры, дип уйлап куйды.

Ул арада, тәрәзәләрне зыңгылдатып, дөбер-шатыр иткән тавыш ишетелде. Караса... Күрше капка төбенә сабын савыты чаклы гына «Запорожец» килеп туктады. Тәрәзәсендә Мөдәррис Әгъләмовның пеләш башы чагылып алды. «Запарай»ның тутыккан, калҗайган калаен корт ашаган ишеген ача алмыйча азаплангач, Мөдәррис Әгъләм җыйнак гәүдәсен, йомарлап, тәрәзәдән тышка ыргытты. Аксак шофер белән икәүләп, ике минут эчендә Мөдәрриснең байлыгын ташып та бетерделәр: тутыккан пружина эзе төшкән бер матрас та тарихка кирәсе өч капчык кульязма-китаплар.

Бераздан калтырча «Запорожец» төтен торбасын җирдән шалтыр-шолтыр өстерәтеп китеп барды. Мөдәррис өске катка менде, чишенеп ташлады да ялгызак матраска сузылып ятты:

—Шәп!

Бераздан ул, аскы катка төшеп, болдырга чыкты. Карга канаты сыман кара трусигының Брежнев чорында тегелгән мул балакларын җилфердәтеп, сажинлы адымнар белән җирне үлчәргә керешге. Ике арадагы ызанга Туфан тимер чөй кагып, чәнечкеле чыбык сузып өлгергән дә икән. Мөдәррис чөйләрне суыра башлауга, биек баскычтан Туфанның бөдрә, көр тавышы ишетелде:

—Нишлисең, даһи?!

—Мине шигырь яздырмаскамы исәбең?! Мин үлчәп карадым, нәкъ житмеш ике сантиметрга аерма чыга.

—Синең якка кергәнменме?

—Киресенчә, үзеңнең якка кергәнсең!

—Ничек үземнең якка?

—Шулай! Миңа житмеш ике сантиметр киңлектә җирне күбрәк калдыргансың, казып чиләнсен, шигырь язарга вакыты калмасын дип.

—Ә минем пьесалар язасы юкмыни?!

—Пьесаларның әдәбиятка ни катнашы бар! Драматургия бит ул Сбербанкның бер филиалы гына!—диде Мөдәррис.

Бу низаг атна буена барды. Мөдәррис, ике араны үлчәп, ызанны үз ягына күчереп куя, Туфан үз ягына. Аптырагач, ике арадагы ызанга Туфан Сафуан Муллагалиевтән житмеш ике сантиметр киңлектә тротуар җәйдерде. Шуннан соң тынычландылар.

Шундый борчулы көннәрнең берсендә Туфан «Волга» машинасының, капка баганасына бәрдереп, ике ишеген умыртып чыгарды. Ул арада, кувалда тотып, Мөдәррис килеп җитте:

—Хәзер төзәтәбез аны, Туфан әкә, кайгырмагыз...

— Кайгырмыйм да. Миңа нәрсә тора ул ике ишек!—диде Туфан.

Ул арада Мөдәррис капканың иңен үлчәп алды:

—Иңе алты метр капкаңның. Машинаңны аркылы чыгарсаң да бәрелми бит югыйсә...

—Тизлек зур иде. Арт белән чигендем мин, туксан белән,—диде Туфан.

Кол Галидән алып Эдита Пьехага кадәр укып барган Мөдәррис Әгъләмов техникадан хәбәрдар иде. Туксан чакрым тизлек белән чигенә алырдай машинаның

безнең илдә генә түгел, байлыгы череп ятучы капиталистларда да юклыгын уйлап, бик аптырап башын чайкады. «Арттыра бу... Кичә Аяз Гыйләжев белән утырганнар, ахрысы»,—дип уйлады. Сынган «Астра» сигаретын төкереклэп ябыштырды да фикерле иреннәре арасына кыстырып куйды.

Икенче көнне Туфан утыз ике бройлер чеби алып кайтты. «Волга»ны сарай кырыена этеп китерделәр.

—Чебиләргә менә диган кетәклек була бу,—диде Туфан.

—«Мерседес» булмаганда ярый инде,—диде Мөдәррис.

Туфанның уң як күршесе Гәрәй Рәхим иде. Йортны үз проекты белән төзетеп куйган шул чукынчык Григорий Рәхим—Гәрәй Радионов. Аның мөселман һәм христиан архитектурасының гүзәл үрнәгендә төзелгән йорты алгы ягыннан карасаң, арткы ягына чыккан кебек, арткы ягыннан карасаң, алгы ягы кебек тоелмый иде.

Гәрәй Рәхим туган авылы Федотовкадан керәшен сарыклары алып кайтты (Батулла-Турай энциклопедиясендә керәшен сарыгы дип дуңгыз атала). Тоз күзле чучка малайларының җыбылҗык исе әрсезләнеп тирә-юньгә таралды. Аларның үтенне сытарлык итеп чинауларын Туфан каш җыерып тыңлап торды да: «Мөдәррисътән күрәсе казалар пүчтәк кенә булыр, ахрысы»,—дип уйлап куйды.

Туфан магнитофонга кадак кагу, балта-пычкы тавышларын яздырган иде. Магнитофонын бар көченә борып, тахтага сузылып ятты. Берзаман торып караса, Мөдәррис тә, Гәрәй дә үз ихаталарында үкертеп эшләп яталар. Бер сәгатьтән соң Туфан арыган кыяфәт белән баскычка чыкты.

Шабыр тиргә баткан, еш-еш сулу алган Гәрәй Рәхим чиләгеннән генә күтәреп су эчте дә:

—Ну эшлисең дә икән, Туфан!—диде.

—Ә как же, мин бит крәстиян малае!

«Шигырь-мигырь маташтырганчы, балта тотып эшләсеннәр, файда булыр, ичмасам»,—дип, үзалдына сөйләнде.

Шулай итеп, бер атна буе магнитофоннан балта-пычкы тавышларын уйнатып, «Диләфрүзнең кияүдән аерылуы» дигән яңа пьеса язып бетергәннән соң, Туфан дөньяга чыкты. Караса... Гәрәй Рәхимне танырлык та түгел, Хиросима бомбасыннан исән калган кеше кебек. Яңагы суырылып калган, Югары Совет ашханәсендә тукланып, матур гына түгәрәкләнеп килгән корсагы калакка эләккән футбол тубы сыман шиңгән. Кулында балта. Сикәлтәле борынын биетеп, нәселле тешләрен күрсәтеп көлгән була тагын үзе.

Мөдәррис исә бер атна эчендә, шигырь сөйләр өчен сәхнәле итеп, иркен сарай корып куйган. Кыяфәт тә элеккечә. Кулы коралга ябышып тора каһәрнең. Ярлы язучыларга юкка гына ун ел буе дача төзешеп йөрмәгән икән...

—Синең, Туфан әкә, пычкың тешәлмәгән, балтаң да үтмәсләнгән. Китер, үткенләп бирим, аннары пленкаңа яңадан яздырырсың.

Туфан бер мәлгә өнсез калды. «Менә йөр син моны шагыйрь генә дип, бөтенесен белеп тора, шайтан алгыры...»

Шагыйрьнең ничек булса да җаена төшәргә дип, Туфан кесәсеннән затлы сигарет кабы чыгарды:

—Мә, җүнлене тарт!

—Үземдәге җүнсезеннән дә туйган.

«Тукай булса да булыр икән, киребеткән»,—дип уйлады Туфан.

—Миндә суыткычлар күбәйгән, берәрсен алып чык үзеңә.

—Мин телевизор карамыйм бит,—диде Мөдәррис.

Күршеләр әнә шулай чөкердәшеп яши башладылар.

**Марсель ГАЛИЕВ**

*1987*

# МИН ДӘ БУЛДЫМ...

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» СӘХИФӘЛӘРЕННӘН*

Язучы халкы һәр атнаның бишенче уку көнендә, җыелышка дигән булып, әдәби җомгаларга йөрергә күнегеп китте. Бүген тагын җомга. Иске Матбугат-йортының Г. Тукай кушаматындагы клубында аяк басар урын юк—шыгрым тулы шул ук тамашачылар, сәхнәдә шул ук язучылар...

Партия җыелышыннан калган президиумда Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Рафаэль Мостафин, Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшитов, Әхәт Гаффар һәм Марсель Галиевләр кысылышып утыра. Башларына кәләпүш кимәгәннәр, конспирацияне нык саклыйлар, чукынчыклар...

Ахшам вакыты җиткәнне белдереп, Ә. Гаффар теге мыегын сыпырып куйды. Шуны гына көткәндәй, Ә. Рәшитов сикереп торды, торды да ясин чыгарга гына яраклы тавышы белән башлап җибәрде:

—Татар халкы элек-электән йөремсәк, зимагур инде ул. Әле күптән түгел генә бер өер язучылар чит җирләрдә йөреп, андагы мөселман кардәшләребезнең хәлләрен белеп кайттылар. Иң әүвәл Мәдинә Маликованы сөйләтәсем килә. Юкса чит илдән кайтканнан бирле өйдә минем белән юньләп сөйләшкәне дә юк.

—Кая барасың килә?—дип сорадылар.—Әлбәттә, Парижга!—дидем.—Мәдинә ханым дулкынлануын тыеп торыр өчен пауза ясап алды. Бу кадәр озын тынлыктан соң залдагы һәрбер дәрвиш Парижны күз алдына китерергә тиеш иде инде.

—Килеп төштек, Франция чип-числа! Игеннәр бот буе! Анда барысы да мәгъшукалар гына димәгез, парижлылар эшчән халык. Татар йокысыннан уянганчы француз эшләп арыган була инде... Культура үзәкләренә килеп кердек—мин аны ремонтта дип торам, ул үзе шундый икән. Ә халык бик тәрбияле, кая карама—төрле позада гәҗит укыйлар. Безне Моника Буби озата йөрде. Ә гомумән алганда, мин Францияне үзгәртер идем... Чат саен кызлар басып тора, ә ирләр...

Нәкъ шушы урында сөйләүчене Ә. Рәшитов бүлдерде:

—Ярар, ярар, бу турыда башкалар сөйләсен.

Әхәт Гаффар үзенә сүз бирүләрен түземсезлек белән көтә иде инде.

—Язгы ташулар күперне агызгач, авыл икегә бүленә: син бу ярда, хатының теге якта дигәндәй, нәкъ менә шулай Португалия ягында бүленеп калдым. Андагы татарлар русча шәп беләләр. Урамда эзләнеп йөргәндә борын төбемнән генә Алвару Куньял үтеп китте. Танымады... Йөзендә татар чалымнары бар иде...

Үзенә сүз бирелгәч, Гариф Ахуновның куенына ук кереп утырган Марсель Галиев, взнос түләргә килгән Марсель Зарипов шикеллерәк ялындырып кына, күз алдына чыгып басты.

—Мин Испаниядән кайттым.—Һәм Марсель, колхоз базарыннан ары китә алмаган залдагы апаларга һәм абыйларга карап: «мескеннәр» дип пышылдап куйды.—Әхәт зрә генә әллә кем булып сөйләнде, аның Португалиясе минем Испаниянең буш кесәсе хәтлек кенә ул... Ник Испаниягә бардың дисәләр, әйтермен: җир читенә барып аяк салындырып утырасым килде. Нәкъ шушы вакытта Гариф абый Африкада, Мәдинә апа Франциядә, Сибгат абый Германиядә нәрсәдер эзләп чатыр чабып йөриләр. Чатыр дигәннән, Азнакайның Чатыр тавына менсәң бөтен Җир шары күренә! Һәм менә мин, ниһаять, Атлантик океанның тозлы суына аякларымны тыктым... Нинди шәп ванна!..

---

* «Тынгысыз каләм»—татар язучыларының 70-80нче елларда чыккан стена газетасы.

О, Мадрид!.. Өйләре шикәр кебек, янгыр юып тора. Юллары безнеке хәтлек кенә булса да, таулары биек. Испаниянен получка алган чагы иде, халкынын холкын күрдек. Бабайлары татарларга охшаган. Ә кем белә, бәлки?!. Дөресен генә әйткәндә, яраттылар алар мине, саубуллашканда «Кампанерра!» дип йодрык күрсәтеп калдылар.

Ниһаять, җәлилчеләргә дә чират житте.

—ГДРга мин китаплар алып кайтыр өчен барам,—дип башлады Рафаэль Мостафин,—юкса бездә матур тышлы китап табу проблема бит ул. Биш тапкыр бардым, инде өемдәге китапханәм шактый зурайды. ГДРда иң сокландырган нәрсә—немецларның төгәллеге. Жыелышка киләләр икән—нәкъ белдерүдә күрсәтелгән вакытка төгәл сыешалар. Ә безнең татар язучысын җыелышка сөйрәп тә алып килеп булмый. Килсәләр, төн уртасына хәтле таралышмыйча интектерәләр. Безне немец язучылары университетка алып керделәр. Анда чит ил әдәбияты кафедрасында Марсель Галиевнең «Кар абагалар» исемле повестен өйрәнеп яталар иде. Дустым Небенцаль башта ресторанга кертеп ашатты да, аннан соң өенә кунакка алып барды. Өстәлендә бер сухой гына иде.

Гариф Ахуновка сүз бирелгәч, залдагыларның берсе-бер калмыйча аягүрә басты (моны союзга керәсе яшь язучылар оештырган иде). Г. Ахунов үзе дә торып басты.

—Индия!..—дип, идарә рәисе, сүзен башламас килеш, туктап калды, гүя ул бүгенге хикәясен менә шушы бер сүзгә сыйдырырга тели иде.—Индия... Җәмәгать, андагы күк йөзен күрсәгез икән! Төсен ни дип тә әйтергә белмим: Шаһидәмнең кофтасы төсенә Маһирә, Сафия, Гөлсинә, Мәдинә, Нурия, Рәмзия, Наилә, Дания һәм Язучылар союзында эшләүче калган хатын-кызларның кофталары төсен бергә кушсаң гына шундый төс чыгарга мөмкин! Самолет гүя мунчага очып килеп керде. Безне кара тутлы йөзләр каршы алды, үзләренә шундый күнектем, өйгә кайткач ак тәнле ханымнар да куркыныч булып тоелды. И-е!—дип, тамак кырып алгач, Ахунов тагын дәвам итте.—Нәрсәдә туктап калган идем әле? Ә-ә-ә, Марсель Гали әйтмешли, кесәң исән булсын! Индиядә миллион кеше эш эзләп йөри. Бер турист укытучы ханым, кызганып, кайсынадыр рупия биргән икән, башка хәерчеләр килеп аны сырып алганнар һәм дә ки, күз ачып йомганчы, ханымны чишендереп тә ташлаганнар. Шуңа күрә рупиябезне кысып кына йөрдек... Йогышлы авырулары күп дигәч, Дәһли базарына кергән идек, очрамадылар. Марсель, теге авыруның исеме ничек иде әле?.. Әйе, әнә шул проказа дигәне генә калган иде. Милли ризыкларыннан иң яратып ашаганым бака ашы булды. Тәмен белер өчен генә яшел кузакларын да капкан идем—күзем маңгаема менде. Шул килеш кайтып киттем.

Докладымны кыскартып шуны гына әйтәсем килә: Африка! Кырык яшьлек кара хатын баш өстенә кырык килолы йөк күтәргән...

* * *

Ә Сибгат ага Хәкимгә, гадәттәгечә, вакыт калмады. Тамашачылар таралып беткәч, ул әкрен генә президиумнан төште.

- Мин дә булдым,—диде ул, жин очыннан яртылаш чыккан уч төбен буш залга селтәп...

Урамда аны, Ирек мәйданына чаклы тынлый-тынлый озата барырга дип, бер төркем «диссидент» язучы көтеп тора иде...

**К. ШӘЛЕ**

*1981 ел, 13 нче гыйнвар.*

## ИЛ-ЙОРТ ТАНТАНА ИТТЕ

Татарстан Республикасы һәм Шәһәр көнен бәйрәм итәргә казанлылар иртәдән үк кереште. Башкалабыз халкы традицион бәйрәм урыннарына, паркларга, мәйданнарга ашыкты. Һәр җирдә музыка уйнап торды, чал Казан тулаем концерт мәйданчыгына әйләнде. Тәүлек буе яуган яңгыр да кинәт туктап калды, күңелләрне күтәреп, бәйрәмгә ямь өстәп, кояш елмайды.

Г. Камал театры бинасы янына бик күп кеше килде. Халкыбыз моңына сусаган милләттәшләребез бирегә, гадәттә, гармун тавышын ишетергә, милли асылын сафландырырга, Тукай рухын яңартырга килә. 30 августта нәкъ менә биредә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге ияләрен тәбрикләү матур традициягә әйләнде. Быелгы яңа лауреатларны котларга Президент Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин килгән иде.

—Вакытында кояшы да чыгып тора,—дип башлады сүзен М. Шәймиев.—Менә Татарстан Дәүләт Советы суверентлык Декларациясен кабул итүгә дә 19 ел вакыт узып китте. Бөтен илгә, бөтен дөньяга үзебезнең хокукларыбыз турында игълан иттек, өстебезгә зур бурычлар йөкләдек. Без сезнең белән үз язмышыбызны, үзебезгә булган хөрмәтне яулап, бөтен халык арасында тиң халык икәнебезне расладык.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенең быелгы лауреатлары арасында Казакъстанда яшәп иҗат итүче рәссам Камил Муллашев, Камал һәм Качалов театрларының иҗат төркемнәре дә бар.

—Безгә, бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләренә насыйп булган әлеге мәртәбәле бүләк иң зур төшенчәләрне берләштерә: татар, Татарстан, Тукай, дәүләт,—диде шагыйрь Зиннур Мансуров, Илбаш кулыннан югары бүләкнең билгесен һәм дипломын алгач.—Газиз халкым, пәйгамбәрдәй шагыйребез Тукай, бинаһая сынаулар кичергән дәүләтчелек алдында имтихан тоту бу.

Башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәле алдында шигърият бәйрәме үткәрелде. Кунаклар күп иде. Төркиядән Г. Исхакый фонды җитәкчесе Түләй ханым Дуран килүе аеруча куанычлы булды. Ул иҗади дуслыгын бигрәк тә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән ныгытып җибәргән. «Татарстан—әдәбият әһелләренә иң бай төбәк, шуларның иң каһарманнары—Тукай белән Исхакый»,—диде Түләй ханым.

«Вамин» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Вәгыйз Минһаҗев тантанага бүләк белән килгән. Бөек Тукайның тормыш юлына, иҗатына багышланган видео җыентык чыгарган. Күптән түгел Татарстан мәдәни традицияләрен саклау һәм камилләштерү фонды оештырып җибәргән.

«Әдипләр борын-борыннан дәүләт күләмендәге вакыйгаларга карата үз сүзен җиткерде. Аларның шигъри сүзе хакыйкатьнең үзе булып торды»,—диде Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов.

Ирек, бәйсезлек хакындагы шигырьләр мәйданын халык уратып алды. Танылган шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Лена Шагыйрьҗан, Салисә Гәрәева, Әхмәт Рәшит, Нәҗибә Сафина, Флера Тарханова, Фәйрүзә Мөслимова, Хәнәфи Бәдигый һ. б.ларның шигъри аһәңе халыкны кузгатып җибәрде.

Г. Камал театры каршында үткәрелгән «Уйнагыз, гармуннар!» бәйрәмендә чыгыш ясап, мәдәният министры урынбасары Ирада Әюпова киләсе елга бу чараны оештыра башлауга 25 ел тулачагын искәртеп үтте. Мәдәният министрлыгы хезмәткәрләре гармунчылар белән берлектә тагын бер күркәм чара оештырган иде. Гармунчылар Качалов театрыннан башлап үзәк урамнар буенча гармун уйнап әйләнделәр. Халык Ф. Туишев исемендәге гармунчылар бәйгесе лауреатлары, керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле, вокал, хореография, фольклор ансамбльләре чыгышын карап кинәнде. Алар арасында «Арча егетләре», Әгерҗедән «Көмеш телле гармун», Питрәчтән «Пимәр тальянчылары», Казаннан «Салават күпере», Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык уен кораллары, Башкортстаннан «Мирас» ансамбльләре чыгышын сокланмыйча карап булмый иде. Чиләбедән килгән «Гөлләр»

вокаль ансамбле кызларына тамашачылар кат-кат рәхмәт әйттеләр.

Халыкара ат спорты комплексында Татарстан Президентын зурлап каршы алдылар. Ишек төбендә М. Шәймиевкә быелгы уңыштан пешерелгән көмәч тәкъдим ителде. Аннары республика башлыгын Татарстанга Көньяк Осетиядән ялга килгән балалар урап алды. М. Шәймиевне Көньяк Осетия балаларының «Ногз Дау» оешмасына шәрәфле әгъза итеп алдылар.

Ат чабышлары программасына кертелгән 13 чабышның игътибарны нык җәлеп иткәне Татарстан Президенты кубогына уздырылганы булды.

Бу көнне киеренке ярышлар «Биектау» автодромында да булды. Биредә 14 нче тапкыр Татарстан Президенты кубогы ярышлары үтте.

Казанда бәйрәм тантаналары Меңьеллык мәйданында кичке сәгать 10да аллы-гөлле 50 залп белән тәмамланды.

Республика көненә багышланган чаралар Татарстанның барлык шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә дә булды.

### «ЕФӘК ЮЛЫ»НДА—БЕРЕНЧЕ!

13 сентябрьдә Төркмәнстан башкаласы Ашхабадта «Ефәк юлы» дип аталган беренче ралли-рейд төгәлләнде. Казанда старт алган бу ярышта йөк машиналары арасында Фирдәвес Кәбиров экипажына тиңнәр табылмады. «КамАЗ-Мастер» командасы узышчысы үзеннән соң килгән Жерар де Ройны бер сәгатьтән артык вакытка артта калдырды. Шунысы да бар: Ф.Кәбиров трассаны җиңел машиналарның да күбесеннән тизрәк узган булып чыкты.

Төркмәнстан Президенты тәкъдиме буенча оештырылган «Ефәк юлы» ралли-рейды 4500 чакрымга сузылган иде. Ярышта катнашучыларга Россия, Казакъстан һәм Төркмәнстан аша узарга туры килде. Казанда 25 илдән җыелган 20 йөк машинасы, 51 җиңел автомобиль старт алган булса, Ашхабадта финиш сызыгына йөк машиналарының 17се, җиңел автомобильләрнең 34е генә килеп житә алды.

Татарстан Президенты М. Шәймиев «КамАЗ-Мастер»ны «Ефәк юлы» раллиенда җиңү белән тәбрикләде һәм «КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры С. Когогин белән «Ефәк юлы» проекты житәкчесе, «КамАЗ-Мастер» командасы башлыгы С. Якуповка котлау телеграммасы юллады. «Зур халыкара спорт чаралары стандартларына туры китереп, югары оешканлык белән үткән яна «Ефәк юлы» ралли-марафоны бөтен дөньяда иң дәрәҗәле ярышка әйләнә ала. Оештыру эшләрендә Татарстан турыдан-туры катнашкан әлеге проект—безнең республика спортчыларының чираттагы казанышы. Катлаулылыгы буенча «Дакар»га тиң шартларда җиңү яулавы Фирдәвес Кәбиров экипажының автомобиль-юл спортының югары осталыгын раслый»,—диде Президент. Ул илебезгә дан китергән төркемгә рәхмәт сүзләрен житкерде һәм узышчыларга алга таба да зур җиңүләр теләде.

### КАНН ДА БЕЗГӘ ЯТ ТҮГЕЛ

Франциянең Канн шәһәрендә 12нче тапкыр Россия сәнгате фестивале үткәрелде. Бу чара Россия белән Франция арасында мәдәният өлкәсендәге иң саллы уртак проект булып тора.

Быел Канн фестивалендә Татарстан әлеге чараның йөзен билгеләүче буларак катнашты. Аның эмблемасы итеп тә татар милли орнаменты сайланган иде. Фестиваль сәхнәсендә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Йолдызлык» республика эстрада сәнгате фестивале лауреатлары, «Каладан юл» бию театры, «Мирас» җыр ансамбле, «Яңа музыка» квартеты, Казан хореография училищесы шәкертләре һәм башка сәнгать осталары чыгыш ясады.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева житәкчелегендәге Татарстан делегациясе составында Тышкы багланышлар департаменты директоры, Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе Тимур Акулов һәм Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев бар иде. Россия тарафыннан фестивальне ачу тантанасында Россия Федерациясе хөкүмәтенең гаммәви коммуникацияләр, мәдәният һәм мәгариф департаменты директоры Денис Молчанов, Россия Президентының мәдәният мәсьәләләре буенча киңәшчесе Юрий Лаптев һ. б.лар катнашты.

XII Россия сәнгате фестивалендә катнашучыларга республикабыз Президенты Минтимер Шәймиев тә котлавын юллады. Анда әйтелгәнчә, Канн фестивалендә Россия Федерациясен тәкъдим итү—Татарстан өчен зур горурлык. «Җәмәгатьчелекне татар милли ашлары, гамәли-декоратив сәнгать әсәрләре белән таныштыру котә. Татарстанның иҗат төркемнәре чыгышы безнең җыр һәм биюләребезнең үзенчәлеген тоярга, алардагы борынгы чалымнарның вә заманча ритмнарның үзара ярашканлыгын күрергә мөмкинлек бирер. Канн фестивале Россия һәм Франциягә мөнәсәбәтле мәшһүрләребез—Казаннан үсеп чыккан Федор Шаляпин, Василий Аксенов һәм атаклы Рудольф Нуриевне искә алып, зурлау өчен дә бик яхшы форсат»,—дигән сүзләр бар иде Президент котлавында.

Чыннан да, Татарстан өметләрне аклады, бай мәдәни программа тәкъдим итте. «Татарстанның традицион сәнгате» күргәзмәсе беренче көненнән үк французларны үзенә җәлеп итте, милли чигү эшләре, кун

сәнгате әсәрләре аларны әсир итте.

Күргәзмәне ачуда Канн шәһәре мэры Бернар Брошан һәм БДБ эшләре буенча федераль агентлык житәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты. Татарстан күргәзмәсен беренчеләрдән булып атаклы француз җырчысы Мирей Матье тамаша кылды.

Каннда, Татарстан сәнгать әһелләреннән тыш, «Русские ночи» дигән концерт программасында, Татарстанны тәкъдим итеп, җырчы Алсу чыгыш ясады. Казан дизайнеры Катя Борисованың милли бизәкләр белән баетып эшләнгән хатын-кыз киемнәре күргәзмәсе дә зур уңыш белән узды.

## ЯҢА СОСТАВ РАСЛАНДЫ

Россия Хөкүмәте Рәисенең 2009 елның 28 августында имзаланган карары нигезендә, РФнең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясенең яңа составы расланды. Аңа, федераль министрлыклар һәм ведомстволар житәкчеләре, төбәк башлыклары, фән һәм мәдәният эшлеклеләре белән бергә, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тә кертелгән. Исегезгә төшерәбез, Татарстанда да ЮНЕСКО эшләре буенча комиссия эшли, ул республика министрлыклары, ведомстволары, предприятие һәм оешмаларының ЮНЕСКО компетенциясендә булган өлкәләрдә килешенгән эшләрен координацияләүче орган булып тора. Комиссияне ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева житәкли.

## ЯНАДАН ВИЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ

Казан шәһәре мэры Илсур Метшин Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасының вице-президенты вазифасына янадан сайланды. Шәһәр башлыгы сүзләренә караганда, әлеге пост һәм сигез мәрдан торган идарәдәге урын өчен танылган тарихи шәһәр башлыклары арасында житди көрәш булган.

Оешманың Эквадорның Кито шәһәрендә узган бөтендөнья конгрессына 70тән артык мэр килгән. Алар арасында Париж, Вена, Пекин һәм башка бөтен дөньяга тарихи мирасы белән мәгълүм булган шәһәр башлыклары да булган. Моннан тыш, Илсур Метшин сүзләренә караганда, форумда Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасының Евразия бүлегенең эшчәнлеге турында да исәп-хисап бирелгән. Әлеге бүлекнең штаб-фатиры Казанда урнашкан.

## ЖИТӘКЧЕ АЛЫШЫНДЫ

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры алышынды. Икенче эшкә күчү сәбәпле, Сергей Журавлевны Айдар Сәлимгәрәев алыштырды. 2008 елның гыйнвареннан ул «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятендә генераль директор урынбасары һәм 2009 елның 8 июненнән—«Татарстан» журналының баш мөхәррире вазифаларын башкарган иде. Сергей Журавлев исә «Татмедиа»ның генераль директоры булып 2007 елның октябреннән бирле эшләде.

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ИНТЕРНЕТТА МӘЙДАН ТОТА

Мәдәният министрлыгында «Татарстан Республикасы мәдәнияте» дип аталган интернет-порталны тәкъдим итү булды.

Әлеге проектның максаты—Татарстанның виртуаль мәдәният пространствосын дөньяви киңлеккә чыгару.

Бу порталда мәгълүматлар түбәндәге блокларга бүленгән: мирас, гореф-гадәтләр, иҗат, мәгариф, хезмәттәшлек, этика, химаячелек, ширкәтләр һәм мәдәният индустриясе.

—Әлеге порталны дөньяга чыгарырга 9 ай буе әзерләндек,—диде Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева порталны тәкъдим итү тантанасында.—Аның яшәп китә алуына өметебез зур. Бу безгә күптән кирәк иде инде. Икътисад өлкәсендә мәгълүматлаштыру буенча Татарстан Россиядә әйдәп баручы республика һәм моның уңай нәтиҗәләре күз алдыбызда. Ә мәдәният өлкәсенә килгәндә исә, Интернет пространствосын тулыландыру шактый озак вакыт таләп итә торган эш. Чөнки мәдәни мирас гасырлар дәвамында туплана. Бүген безнең интернет-порталда 300гә якын мәкалә, 20ләп видео, 70ләп аудиоязма, 300гә якын мәдәният мәркәзе турындагы мәгълүмат белән танышырга мөмкин.

Порталда мәгълүматлар нигездә ике дәүләт телендә—татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә. Алга таба алар инглиз теленә дә тәрҗемә ителәчәк.

## ТАТАРСТАНГА ТӘРӘЗ АЧЫЛА

Башкортстанның Татарстан белән чиктәш Октябрьский шәһәрендә яшәүчеләр, ниһаять, «Татарстан—Яңа Гасыр» телевидениесе тапшыруларын карау мөмкинлеген алды. Әлеге шәһәрдә яшәүчеләр дә, Туймазы халкы да, «Татарстан—Яңа гасыр» каналын карый алу өчен, Башкортстан хакимиятләренә дә, Россия житәкчеләренә дә еллар дәвамында бихисап хатлар, мөрәҗәгатьләр юллады. Әмма Башкортстан түрәләре республикада яшәүче татарларның гозерләрен ишетмәмешкә салыша килде. Хәтта «Татарстан—Яңа Гасыр» каналын үз челтәрләре аша күрсәтә башларга теләгән кабельле телевидение башлыклары төрлечә кисәтүләргә, лицензияләрен тартып алу белән куркытуларга дучар ителде.

Шулай да гаделлек өлешчә булса да

жинде. Мәскәү һәм Түбән Новгород тарафларыннан Башкортстан житәкчеләренә тиешле күрсәтмәләр бирелгәч, республиканың Октябрьский, Агыйдел, Сибай һәм Нефтекама шәһәрләрендә «Татарстан—Яңа Гасыр» телевидениесен күрсәтү өчен рөхсәт бирелде.

Киләчәктә Башкортстанның барлык районнарында да «ТЯГ» каналын карау мөмкинлеге бирелер, дигән өмет белән яши республика татарлары. Ни өчен дигәндә, Башкортстанның «Юлдаш» (БСТ) телевидениесен Татарстанда бернинди чикләүләрсез карарга мөмкин. Башкортстан татарлары, без кемнән ким, дигән урынлы сорау куя.

## МУЗЕЙ ЖИТӘКЧЕЛӘРЕ ТӘЖРИБӘ ТУПЛЫЙ

Бу атнада Татарстан Милли музеенда Россия Федерациясе музей белгечләре өчен «Музей белән идарә итү—XXI гасыр» дигән илкүләм укулар булып узды. Ул ЮНЕСКОның Мәскәүдәге бюросы һәм БДБ дәүләтләре гуманитар хезмәттәшлегенең Халыкара фонды химаясендә үткәрелде.

Укуларны Татарстан Милли музее, РФ һәм ТР Мәдәният министрлыклары, Россиядәге ИКОМ бүлеге белән берлектә әзерләгән иде. Тренингка Россиянең 30лап төбәгеннән музей житәкчеләре килде.

Мондый дәрәжәле жыенның ТР Милли музеенда үткәрелүе очраклы түгел. Ул Россиядәге төбәк музейлары арасында иң эреләрдән берсе һәм иң зур тарихи-мәдәни мирасны саклау урыны, РФ музейлары арасында дәрәжәле методик үзәк булып исәпләнә.

Укуларны ачып жибәрү тантанасында ТР мәдәният министры урынбасары А. Гайнетдинов, ЮНЕСКО Секретариатының музейлар һәм мәдәни объектлар секциясе житәкчесе К. Манхарт һ. б. рәсми затлар катнашты.

Тренингны ТР Милли музее генераль директоры Г. Нәжипова ачып жибәрде, А. Гайнетдинов үз чыгышында музейларның әһәмиятен күрсәтеп үтте. «Алар күптән инде экспонатлар тупланмасы булу белән бергә, буш вакытны файдалы үткәрү, анбелемне үстерү үзәгенә әверелде»,—диде ул.

Музей белгечләре 4 көн дәвам иткән укуларда экспонатлар сакланышы, иминлек, кадрлар белән тәэминителеш, күргәзмәләр, экспозицияләр эшләү осталыгы, экспонатларны күчерү мәсьәләләре буенча тәжрибә уртаклашты, гыйлем эстәде, һөнәрмәндлеген арттырды.

Моннан тыш, жыенга килүчеләр Идел кичлекләрендә сәяхәт кылды, Казан Кремле биләмәләрен карады, музейлар шәһәре—меньеллык Алабугада булды.

## «ГОМЕРЕМНЕ ХАЛКЫМА БАГЫШЛАДЫМ»

Кремльдә урнашкан Татар халкы һәм Татарстанның дәүләтчелек тарихы музее әле күптән түгел генә ачылган иде. Кайберәүләр аны белеп бетермәүләре дә мөмкин. Ул Сөембикә манарасы янәшәсендәге ике катлы таш бинаның беренче катында урнашкан. Сентябрь аенда анда бөек әдип Гаяз Исхакыйга багышланган экспозиция ачылды. «Гомеремне халкыма багышладым» дип исемләнгән бу күргәзмә язучының чит илгә китүенә 90 ел тулуга туры китереп оештырылган. Анда, нигездә, Г. Исхакыйның мөһажирлек чорындагы тормышына, ижатына, эшчәнлегенә бәйләнешле экспонатлар куелган.

Фотолар һәм документлар, китапларның күпчелеге Исхакый исемен һәм мирасын илгә кайтаруда күп көчен сарыф иткән галимә Лена ханым Гайнанова тупланмасыннан алынган. Экспозициядә уникаль документлар куелган: 1918 елда Милли Мәжлес тарафыннан Версаль Солых конференциясенә Г. Исхакыйның делегат булып сайлануы турындагы таныклык, Алманиядә Идел-Урал комитетының президенты, шулай ук 1934 елда Ерак Көнчыгышта төзелгән «Идел-Урал» милли-мәдәни жәмгыятенең гомерлек президенты итеп сайлануы турындагы таныклыклар, әдипнең төш кисәгендә генә йөрткән «Милли юл» мәжмугасының мөхәррире, Варшавада яшәгәндә Төркиядә чыккан «Жөмһүрият» газитенең хәбәрчесе булуын раслаган таныклыклар һ. б. бик күп документлар, шулай ук фоторәсемнәрнең төп нөсхәләре экспонатларның күпчелеген тәшкил итә.

Гаяз Исхакый—гомере буе татарны дәүләтле итәргә хыялланган, шул юлда ижтиһад иткән, көрәшкән фидакарь шәхес, милләт улы, һәм аңа багышланган күргәзмәнең нәкъ менә Дәүләтчелек тарихы музеенда ачылуы бик табигый.

«Гомеремне халкыма багышладым» дип аталган күргәзмә Дәүләтчелек тарихы музеенда ноябрь аена кадәр эшләячәк.

Музей, дүшәмбедән кала, атнаның һәр көнендә 9 сәгатьтән 18 сәгатькә кадәр эшли. Белешмәләр өчен телефоннар: 567-80-24, 567-80-85.

## «ӘХСӘН ЙОРТЫ» ЭКСПОЗИЦИЯСЕ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясендә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдиновның шәхси күргәзмәсе эшли башлады. Анда останың агачтан уеп ясалган иялар сыннары, шулай ук мифологик каһарманнар урын алган. Күргәзмәгә рәссамның табигатькә чиксез мәхәббәт белән сугарылган 60 ижат эше куелган.

«Әхсән йорты» экспозициясенең ачы-

лышында Премьер-министр урынбасары— мәдәният министры Зилә Вәлиева, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады. Зилә Вәлиева рәссамны 70 яшьлек юбилее белән котлап, Президентыбызның Рәхмәт хатын тапшырды. Мәдәният министры Түбән Кама шәһәрендә «Әхсән йорты» дип аталган музей-үзәк төзеләчәген хәбәр итте.

«Иҗат иткәндә җаным тибрәнә, әсәрләремдә шул тибрәнеш тоемлана»,—диде Әхсән ага үз чыгышында. Рәссамның җан тибрәнеше тәэсирендә туган әсәрләр күргәзмәдә серле, иманлы, моңлы бер мохит хасил итә.

Күргәзмәне ачу тантанасында шулай ук Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев, сәнгать белгече Розалина Шаһиева чыгыш ясап рәссам иҗатына югары бәя бирделәр.

### АМЕРИКАННАР ТАТАРЧА ӨЙРӘНӘ

ТДГПУ ректоры Рәдиф Җамалетдинов Американың Аризона дәүләт университеты студентлары белән очрашты. Бу яшьләр Казанда интенсив рәвештә өч атналык рус һәм татар телләре курслары үтә.

Курсләр инде икенче ел рәттән университетның татар теле һәм мәдәниятара коммуникацияләр кафедрасы ассистенты А.Фатыйхова инициативасы белән оештырыла. Ул 2006 елда Фулбрайт грантын отып, Америкада студентларга 1 ел татар теле укытты һәм шул арада интенсив укыту курсын әзерләде. Студентлар башта Аризона университетында ике ай курслар уза һәм арадан практика үтәргә теләүчеләр сайлап алына. Казанда укулар тәмамлануга, студентларга сертификат бирелә.

Быел программада беркадәр үзгәрешләр бар: укучы яшьләр татар гаиләләрендә яши. Берничә көн алар «Сәләт» лагеренда булды, Кремльне, Раифа монастырен карады, Тәтеш районының Келәш авылында милли бәйрәмдә катнашты.

### КҮРГӘЗМӘГӘ РӘХИМ ИТ

22 сентябрьдә Казанның «Эрмитаж» үзәгендә «Илаһи нәсел балалары. Борынгы һәм хәзерге чор сәнгатендә антик каһарманнар» исемле күргәзмә ачылды. Биредә антик сәнгатькә караган 200гә якын экспонат тәкъдим ителгән. Алар антик (безнең эрага кадәр VII гасыр) һәм соңгы чор (XVIII-XIX гасырларга кадәр) Көнбатыш Европа сәнгатендә борынгы Эллада каһарманнарын чагылдыру үзенчәлекләрен ача. Экспонатлар арасында борынгы Греция мифлары, эпос һәм табыну геройлары турында мәгълүмат бирә торган гүзәл сәнгать әсәрләре, мәдәният һәйкәлләре үзәк урынны алып тора.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча урынбасары, язучы һәм шагыйрь **Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов** Дуслык ордены белән бүләкләнде.

***

2009 елның 19 августында 84 яшендә күренекле фольклорчы-галим, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, журналыбызның даими авторы **Илбарис Нурислам улы Надиров** вафат булды.


***

2009 елның 15 сентябрендә 71нче яшендә күренекле язучы-тәрҗемәче, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Миргалим Харис улы Харисов** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Дүртенче биттә:* Татарстан Республикасының халык шагыйрьләре һәм халык язучылары. Сулдан уңга, беренче рәттә: **Шәүкәт Галиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян;** икенче рәттә: **Ренат Харис, Рабит Батулла, Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин.** *Сентябрь, 2009 ел.* Авыру сәбәпле **Хисам Камалов** күмәк фотога төшә алмады, аның рәсеме 136 биттә бирелде.

# Яңа китаплар




Англиянен «Bennett and Bloom» нәшрияты яңа татар сөйләүлеге чыгарган. Инглиз ягыннан—төрле сүзлекләр авторы Nicholas Awde (Ник Оуд), безнең яктан—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, чит телләр белгече Гөлназ Вәлиева язган. Китапны тәкъдим итү сүзендә (инглиз телендә) болай диелә: «Татар теле—Россия Федерациясенә караган Татарстан республикасындагы төрки тел. Аны Казан татарлары теле дип тә йөртәләр. Бу телдә Татарстанның күрше төбәкләрендә, Казакъстан, Үзбәкстан кебек төрки илләрдә миллионлаган кеше сөйләшә. Бүтән чит илләрдә дә (Кытай, Финляндия, Төркия, Австралия, АКШта һ.б.) шактый зур татар диаспоралары бар».

Бу китап татар телен өйрәнергә теләүчеләр куллану өчен унайлы латин имласында тәкъдим ителә. Гамәлдәге кирил имласында да үрнәкләр китерелә. Татарлар, Татарстан турында тарихи белешмә, грамматика һәм фонетика бүлекләре, 4000 сүздән торган икеяклы сүзлек бар.




**Татар календаре.**—2010.—Казан: «Мәгариф» нәшрияты.—365 бит. Тиражы—10 000 данә.

Халкыбыз яшәешендә календарьлар аерылгысыз юлдаш булды. Чөнки ул, татар дөньясының мәдәнияте, сәнгате, мәгарифе-мәгърифәте, зыялылар даирәсе, халык бәйрәмнәре, тарихи даталар, табигать фасылларының үзенчәлекләре турында төгәл эзлеклелеккә салынган энциклопедик характердагы белешмә чыганагы. «Мәгариф» нәшриятында басылган календарь, табигый, мәгърифәтчелек идеяләрен дәреслекләр дәрәҗәсендә яклау һәм үстерү максатын да күздә тотып эшләнгән.

Календарьны Казанның Татарстан урамының 13нче йортында урнашкан китап кибетеннән, Оренбург тракты, 20 а йортының 4 катындагы «Мәгариф» нәшриятыннан *(телефоннары: 277-52-88, 277-52-62)* алырга була.



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**